
ISSN 0206—418

# КАЗАН УТЛАРЫ

6.1995



## Татарстан Республикасының 1995 елгы Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләген бирү турында Указ



Г. Тукай исемендәге Татарстан Республикасы Дәүләт бүләкләре буенча Комитет тәкъдимнәрен караганнан соң:

1995 елның Г. Тукай исемендәге Татарстан Республикасы Дәүләт бүләген «Җан авазы» китабы өчен (Татарстан китап нәшрияты, 1994 ел) **ФӘНИС ГАТАУЛЛА** улы **ЯРУЛЛИН**га бирергә, дип карар бирәм.

Казан, Кремль
1995 ел, 25 апрель

Татарстан Республикасы Президенты
**М. Ш. ШӘЙМИЕВ.**

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИЖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**6**

**(872)**

**1995**

КАЗАН

## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

НИЗАМИ. Исәнме, Сабантуй! *Шигырь* . . . 3
Ш. ГАЛИЕВ. Минем беренче гомерем. *«Хисталек»ләр* . . . 4
Ф. ГАБДРӘХИМ. Бөек Иванга ачык хат. *Шигырь* . . . 74
А. ХӘЛИМ. Гомеремнең ун көне. *Сәяси ачлык көндәлеге* . . . 82
Л. ШАГЫЙРЬҖАН. Төрле еллардан. *Шигырьләр* . . . 124
Ш. МАННАП. Моңсу хатирәләр . . . 131
Д. ГАРИФУЛЛИН. Минем уйлар сездә, робагыйлар . . . 141

ПУБЛИЦИСТИКА

Р. НИЗАМИЕВ. Без кая барабыз? . . . 147

КАРДӘШЛӘРЕБЕЗ ИҖАТЫ

М. ЧАВУШ. Ялгыш аңламагыз безне. *Шигырьләр* . . . 154

ӘДӘБИ МИРАС

М. ӘХМӘТҖАНОВ. Шагыйрь Габдессәлам . . . 157
ГАБДЕССӘЛАМ. Илаһи бәетләр . . . 159

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

И. НИЗАМОВ. Татар рекламы: кичә һәм бүген . . . 170
Н. ТАИРОВ. Сембердә Акчуриннар мәчетләре . . . 176

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕНДӘ—ТАТАР ШӘХЕСЛӘРЕ

Х. ХӘСӘНОВ. «Хөсәен әфәнде Ямашев хатирәсе» . . . 180

КИТАП КҮЗӘТҮ

Х. БАДЫЙКОВ. Тау чишмәсе кебек . . . 183

Безнең календарь . . . 187
Укучы сүзе . . . 188
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан . . . 190

*Баш мөхәррир*

**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**
**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**
**Тәлгат Галиуллин**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Зиннур Мансуров**
**Рөстәм Мингалимов**
**Минтаһир Минһаҗев**
**Мөхәммәт Мәһдиев**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Индус Таһиров**
**Наис Гамбәров**
*(җаваплы сәркатип)*
**Тәүфикъ Әйди**
*(бүлек мөхәррире)*
**Марсель Әхмәтҗанов**

Безнен адрес: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
жаваплы сәркатип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: окончание повести-воспоминания Ш. ГАЛИЕВА «Моя первая жизнь»; дневник политической голодовки А. ХАЛИМА «10 дней моей жизни»; рассказы Ш. МАННАПОВА; стихи Ф. ГАБДРАХИМА, Л. ШАКИРЗЯНОВОЙ, Д. ГАРИФУЛЛИНА.
«Публицистика»: статья Р. НИЗАМИЕВА «Куда мы идем?»
«Творчество братских народов»: стихи М. ЧАВУША.
«Литературное наследие»: статья М. АХМЕТЗЯНОВА «Поэт Габдессалям», баиты ГАБДЕССАЛЯМА.
«Из страниц истории»: статьи И. НИЗАМОВА «Татарская реклама: вчера и сегодня»; Н. ТАИРОВА «Мечети построенные Акчуринами в Симбирске»; Х. ХАСАНОВА «Воспоминания о Хусаине Ямашеве».
«Книжное обозрение»: Х. БАДИКОВ рецензирует новую книгу Р. Низамиева.
Наш календарь.
Слово читателя.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Ранняя весна» — картина художника Р. Каримуллина; известная поэтесса Л. Шакирзянова.

## IN OUR ISSUE

«Prose and Poetry» the sequel of Sh. Galiev's narrative-recollection «My first life»; the diary of A. Khalim's political hunger-strike «10 days of my life»; Sh. Mannapov's stories; the verses of Ph. Gabdrahim, L. Shakirzyanova, D. Gariphullin.
«Publicism»: R. Nizamiev's article «Where are we going?»
«Creative work of fraternal people»: M. Chavush,s verses.
«Literary heritage»: M. Akhmetzyanov's article «The poet Gabdesalyam», Gabdesalyam's stories.
«From the history pages»: the articles of E. Nizamov «Tatar advertising today and tomorrow»; N. Tairov «The mosques built by Akchyrins in Simbirsk»; Kh. Khasanov «The recollection about Khusain Yamashev».
«Book review»: K. Badikov reviews R. Nizamiev's book.
«Our calendar».
«Reader's Word».
«The diary of social and cultural life».
In our corvers: R. Karimullin's picture «Early spring», the well-known poet L. Shakirzyanova.

● Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.

● Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

● Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

*Мөхәррирләр:* Мансур Вәли, Марсель Гали, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин.
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Гөлназ Хөснетдинова.

Производствога бирелде 25.04.95 ел. Басарга кул куелды 5.06.95 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учети.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 10 975. Заказ Д-232.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1995 ел.

# ШИГЪРИЯТ

## Низами

### Исәнме, Сабантуй!

Җырлары һәм гармуннары белән
Сабантуйлар килде әйләнеп.
Ап-ак һәйкәл гүя калкып чыккан:
Авыл саен — сөлге бәйләме.

Тамаша кыл, күңел ач син бүген,
Биеп җибәр, әйдә, булмаса!
Болынлыкны яшел постау итеп,
Табын кора туган-тумача.

Бабалары, моңы — Иделдәндер,
Сибелгән шул татар, сибелгән.
Туган җирен сагынып кайта алар
Донбасс якларыннан, Себердән...

Туган якның чишмәләре тәмле,
Җилләренә хәтле, һәй, тыгыз.
Кардәшләрем, кунак булып түгел,
Бөтенләйгә инде кайтыгыз!

Шәрран ачык күңел бакчалары,
Хөсетлек юк, юктыр яман уй.
Җанны, рухны, йөрәк тибешләрен
Бергә тоташтыра сабантуй.

«Бу бит безнең Ватан»,— дия-дия,
Шатланыйк без. Уйныйк, гөрләшик.
Татарларым! Сабантуйда сыман,
Яшәүдә дә мәңге берләшик!

*1995.*

# ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР



**Шәүкәт Галиев**

# МИНЕМ БЕРЕНЧЕ ГОМЕРЕМ

ХИСТӘЛЕКЛӘР[1]

## Еллар тыныч, чикләр тынычсыз

Хатип абыйның армия хезмәтенә китүен хәтерлим, 1915 елгылар шактый иде. Никрутның йоласы шул: берничә көн кала эштән бушап, саубуллашу мәҗлесләре була. Дуслар-яшьтиләр, каракаршы тезелешеп, кочаклашып алалар да, тальянга җырлый-җырлый урам әйләнәләр. Һай, матур иде җырлары, гайрәтле иде үзләре, көр иде тавышлары, горур иде! Малай-шалай күз дә алмый ияреп йөрибез, абыең белән мактансаң да ярый. Һәркем мактана да алмый... Эчкәнен буена сеңдерә алмаган берәрсе әтәчләнсә, хәбәр авылга тарала... Хатип абыйлар әйбәт йөрде, калай әтәчне тыңлатырлык абруе да бар иде.

Тыныч еллар, әмма Ерак Көнчыгыш тыныч түгел. Хатип абыйны шул якка җибәргәннәр. Бер хатында: «Без китәбез...»— дип тарафын язган иде: Халхин-Гол вакыйгалары аңа да кагылган. Кайткач та сөйләргә ярамаган. Алай да бер вакыйга колакка чалынган: радистның окопына кызылармеец киеменнән самурай төшә дә чәнчеп китә. Хәйләкәр, мәкерле, ди алар. Хатип абыйга охшатам дип, чик сакчысы рәсемен ясыйм: мылтык тоткан, бинокль таккан, янында «Юлбарыс»ы, теге, кинодагы ише... Буркасын җилфердәтеп җилгән Чапай сурәтен дә төшерәм. Танклар ашкынып алга бара — шундый ул безнекеләр! «Өч танкист»ы бигрәк тә.

Шәкерт абыйның армиядә төшкән төсле фотосы бар, бигрәк матур. (Ул чакта андыйлар юк, күрәсең, буяп эшләнгәндер). «Истәлек өчен начар гына төшкән карточкамны җибәрәм...»— дигән икән, чак кына мутланып алуыдыр, ул чакта шулай язалар иде. Петлицада ике өчпочмак — взвод командиры ярдәмчесе, күкрәгендә «Осовиахим», «Вороши-

[1] Ахыры. Башы 5 нче санда.

ловский стрелок» значоклары. Кайткач, бусына Мәсгут тә кызыкты, мин дә тагып карадым. Хатип абыйны тыңлаганнар авыр сулады:

— Сугыш ерак түгел... Хәтәр булачак... Өйрәнеп кайткан командирлар беренче чиратта китәр...

Күңелгә куркыныч иңә, җанга борчу төшә... Әле хәзер дә бик еракта ишетелер-ишетелмәс тальян моңлана сыман. 1940 ел. Тынмый тальян, югалмый-өзелми, тик гасабиланып өзгәләнми — бәхилләшер көннәр алдарак әле...

Хатип абыйның шул чакта — 23-25 яшьләрдә гаскәри киемнән төшкән рәсемнәрен алып карыйм. Беренчесе 1938 елның апреле, соңгысына: «1940 елның 28 сентябре» дип язылган. Татищево тимер юл станциясендә, бер төркем командир — булачак курсантларны алырга кайткан. Шәкерт абый моңсу күренә, хәсрәтле сыман, 1941 ел күләгәсе төшкән диярсең — киләсе сентябрь аныкы түгел бу дөньяда. Бәлкем, шуңа да караңгыдыр ул сурәтләр — кара дөньядан караган сыман...

## Кара тышлы җырлар дәфтәре

Ерак Көнчыгыштан кайтканда Шәкерт абыйның җырлар дәфтәре бүтән иде: йомшак кара тышлы, кесәдә йөртергә уңайны сайлагандыр. Ул чакта телдән төшмәгән русча күчерелгән җырлар: «Три танкиста», «Катюша», «Если завтра война», «Прощание». Бу соңгысы — «Саубуллашу» татарчага тәрҗемә ителгән, класста җырлый идек. Аерылганда кыз үзенең сөйгән егетенә:

> «Әгәр үлсәң, бик кинәт үл...
> Яралан җиңел генә...» —

ди. Әнә шул «кинәт үл» аңлашылмый. Шулай теләргә ярый мени? Теләк яхшыга гына була ич... Үлем газабы кичермәсен, дигән икән, соңлап белдем. Ә Хатип абый, язмышын сизенгәндәй, белеп җырлаган...

Сугышка киткәндә ике дәфтәрен дә калдырган иде. Кызыксам да, сорыйсы итмәдем: үзе кайтыр, төп йортта саклансын. Ни үкенеч — юкка чыктылар... Эвакуация белән кайткан яшь җилкенчәк, чормадагы төрле кәгазьләр белән бергә, учак тергезергә тоткан. Абый үзе сугыш утында янган көннәргә үк туры килмәде микән әле...

Элегрәк тә, аннан соң да безнең халыкта авыл тарихлары, шәҗәрә, борынгы китап, язмалар, нәсел-ыру хатирәләре төрле сәбәпләр белән бетә килгән. Саклау гадәте үзе дә юкка чыккан... Аның урынын гамьсезлек-хәтерсезлек дигән хәтәр чир яулап алган.

Кара портфель белән мин мәктәпкә йөрдем, Шәкерт абыйныкы — күрегез!

Кылыч төсле тимераякта шуарга өйрәндем, күрәмсез — Шәкерт абыйныкы!

Шәкерт абыйныкы ише җырлар дәфтәре ачтым. Ерак Көнчыгыштан кайткан кайберләрен искә төшереп, язып куйдым. Үзем җыйган халык җырлары да күп. Абыйга ияреп башлаган идем, соңрак үз шигырьләрем дә кушылып, ялганып китте...

## Көтелгән «көтелмәгәнлек»

Сакчыллык дигәндә, Бибигайшә апага бирәү дә җитмидер! Әле күптән түгел, сабан туе көнне, сандыгыннан оек алып сеңелем Нәҗиягә бүләк иткән:

— Хатип көчтәнәче... Ленинградтан алып кайткан иде.
— Соң, апагынам, кырык ел узган лабаса!
— Үзе кайтыр, хатынына булыр, дип тордым... Өр-яңа бит?
Өр-яңа итеп саклый белә апа әйберне. Өмет саклаткан, өмет. Сугыштан соң, кырык алтынчы елны, Ярхәм җизни кайтып төшкәч тә, идән асты базыннан бодай башаклары төшерелгән, сургычлы пичәте чайрап яткан чирекле аракы алып менә — туфракка күмеп биш ел саклаган!
Әле сүз кузгатасы листовка да апада иде. Хатип абый һәлак булгач, сорап алдым. Ерак Көнчыгыштан алып кайткан, район газетасы зурлыгында. «Күрсәтергә ярамый»! — диде абый, бер почмагында «Частьтан алып чыкмаска!» дигән кисәтү бар. Шушы сер, тыюлар ярты гасыр саклаткандыр. Үзе хезмәт иткән взвод исеменнән «Частьның барлык сугышчылары, командирлары, һәм политработникларына мөрәҗәгать» бу. РККАның XXI еллыгын каршылауга багышланган. Имзалар: «Взвод тапшыруы буенча, кече командирлар: Ильвич, Идиатуллин, курсантлар: Лещенко, Фролков, Марченко». Бу саргаеп беткән кәгазьне кулыма алам да, шул елларга кайткандай булам:
«...Күптән түгел бөтен дөнья Кызыл Армиянең көчен һәм кодрәтен күреп таныды. Корыч полкларыбызның дәһшәтле көчен иң беренче булып, җиңел уңышка исәп тоткан япон сугыш чукмарлары үз сыртында татыды. Кызыл Армия сугыш провокаторларына сабак бирде».
Бусы — Халхин-Гол вакыйгалары хакында. Кабынып килгән сугыш уты да биткә бәрелә сыман:
«Чикләребезнең теге ягында герман, итальян, япон фашистлары башлаган икенче империалистик сугыш ялкынлана. Теләсә кайсы мизгелдә ул канлы ялкын безнең чикләргә күчәргә мөмкин. Фашистлар социалистик илебезгә каршы сугыш әзерли».
(Без әзерләнәбез каршы торырга. Әзерләнә ил, әзерләнә полководецлар... Халхин-Голда 16 сентябрьдә сугыш хәрәкәтләре туктатыла — анда комкор Жуков. Солдат белән маршал очрашмас, әмма нәкъ ике елдан аларны немецлар һөҗүменә каршы Ленинград оборонасы көтә...) 1939 ел... Әнә шул шартларда армиядә хезмәт иткән Хатип абый.
Кан коюлы фин сугышы илне тетрәтеп алды. 1940 елның көзендә абый армиядән кайтты, тыныч түгел иде җаны...
— Армияне үттең, яшең дә бара... Өйлән, Хатип! — дип өндәде туганнар.
— Ятимнәр калдырасым килми... — диде, уйчанланып. Запастагы кадровый командир дөнья хәлләрен шәбрәк белгән, күрәсең.
Мин листовка укыйм:
«Безнең совет халкы һәм аның Кызыл Армиясе дөньяда иң кодрәтле һәм көчле армия, фашист агрессорларга каршы, кешелектә мәгълүм булган иң гаделдән гадел сугыш алып барачак. Безнең сугыш һөҗүмчән булыр. Кызыл Армия дошманның барлык чикләрен үтеп, үз җирендә кыйнаячак».
Бусы Хатип абый турында әйтелгән урын:
«Без, иптәш Мельников подразделениесенең кече лейтенанты Балабаев взводы курсантлары һәм командирлары, үткән уку елында сугышчан һәм политик әзерлектә уңышларга ирештек. Отделение командиры Идиатуллин, үзенең отделениесе белән 4 гомум баллга иреште һәм бердәшмәдә беренче урынны алды. Әмма бу уңышлар чик түгел, алар тагын да яхшырак булыр һәм булырга тиеш тә».
Листовкада шул чорның сурәтләре: сул читендә нарком Ворошилов, уңда — Сталин. Ярыш йөкләмәсенең берсе мондый: «Һәр сугышчыны Ленин-Сталин партиясе эшенә бирелгәнлек, революцион уяулык һәм социализмның барлык дошманнарына, партия һәм халык дошманнарына нәфрәт рухында тәрбияләргә».

Хәрби тактика буенча, билгеле инде, «һөҗүм һәм атака» темасын үзләштерәсе... Матур әдәбият китаплары «Икмәк», «Кочубей», «Мин — хезмәт халкы улы» буенча әңгәмәләр уздырырга. Бусы — рухи әзерлек. Без дә мавыгып укыдык ул әсәрләрне. В. Катаев повестеның соңгы җөмләсе истә: «Безнең байракта бер генә тап та булмаска тиеш!» Хәзер беләбез — Сталин таплаган җинаять эзләре аз булмаган. Күпме стратег полководецлар, хәрби белгечләр кырылган... Бусы да сугышка «әзерлек». Гитлер файдасына...

Листовка — шул дәвернең бер документы. «Көтмәгәндә» башланган сугышның нинди әзерлек белән көтелгәнен күрсәтә. Авылда кичен янгын сарае янында гәп корган ирләр сүзендә шул, халык дипломатиясе белеп-чамалап тора. Сугыш ялкыны су сибеп сүнми икән, яшен янгынындай «кара сыер сөте»нә дә бирешми, кеше каны кирәк, миллионнар каны...

Көтелгән көтелмәгәнлек... Армиядән кайткач, Хатип абыйны авыл яшьләрен өйрәтергә куштылар. Яшүсмергә иң кызыгы — кече калибрлы винтовкадан ату. Тик ул көнне мылтык шартлаудан таллардагы бихисап каргалар тузгып күтәрелә, яман чарылдашып чәүкәләр чайкала, бик озак тынычлана алмый.

...Элекке янгын сарае урынында сугышта һәлак булганнарга һәйкәл тора. Мин тыңлап, яратып карап торган абыйлар да шунда, исемлектәге 169 авылдаш арасында... Ул исемлек үзе сугышка каршы исемлектер, анда Хатип абый исеме дә бар...

## Трибунал

Листовкадагы «революцион уяулык» турындагы сүзләргә бәйләнешле шөбһәле бер хәл Хатип абыйны Ерак Көнчыгыштан хәрби трибуналга кайтарган... Без ул чакта, 1940 елның җәендә, әткәй эшләгән район үзәгендә идек. Уйламаган-көтмәгәндә Хатип абый кайтып төште! Мин сөенечтән урамга чабып малайларга мактанырга әзер, әмма, т-сс, шаулама, диделәр. Ай буе поездда кайткан, кием алыштырмаган, тыкрык буйлап шым гына Бәрле елгасы буендагы мунчага төштек. Керләнгән эчке киемен йомарлап мунча чормасына ташлады — күрсәтәсе, мәшәкать тудырасы килми. Соңыннан, әнкәй аларны юып, өтәләп биргәч, аптырап калды, рәхмәт, аптый, диде.

Кеше күзенә чалынырга теләмәүнең сәбәбе бар икән: военкоматта эшләүчеләргә юлыгудан саклана — монда тукталу каралмаган. Трибунал коточкыч сүз, абый бик борчулы. Шаһит итеп чакыралар. Бергә хезмәт иткән егетне, Киев хәрби округына күчерелгәч, кулга алганнар. Язмышы Хатип абыйның ни әйтеренә бәйле. Якласа — үзе эләгүе бар... Кыл өстендә, кыл өстендә... Иптәшне дә коткарырга кирәк. Шул уй-ният белән бара ул. Тагын бер шаһит бар, тик анысы — тиешле урынга җиткергән кеше — каршы шаһит... Гаепләү дигәне бигрәк юк нәрсә аркасында, минемчә — көндәлек язган өчен! Ни күргән, ни уйлаган — шуны гына язган ич! Шуның өчен ун ел төрмә, йә — атарга... «Илле сигезенче статья» дип куркып әйткәнне еш ишетәбез, олыларның телендә ул. (Ярты гасырдан соң А. Солженицынның «ГУЛАГ архипелагы» әсәрен укыганда юлыктым, көндәлек язмалары да гаепләүгә нигез булган: 58 нченең 10 нчы пункты.)

Гомеремдә көндәлек язарга ничә омтылып, ничә ташладым. Ак кәгазь сере тартты да, сагайтты да — мин аңа ышанып бетә алмадым. Шәкерт абый вакыйгасы кисәтеп-өркетеп калдырган. Бар язганым һава торышы иде. Күңел торышы ничек, аязмы-болытлымы, берсе дә юк. Болай да онытмам сыман иде. Күп еллардан соң, әдәби мохиттә өлкән әдипләр белән аулакта серләшкәнне дә язып куймадым. Кем кулына кермәс, кемнең күзе төшмәс — сүз иясе өчен җаваплы син. Ай-һай, үтә саклыктан котыла алырбыз микән — канга сеңгән, җанга сеңгән ул безнең...

Трибуналдан кайтканда Шәкерт абый Кайбыч урамыннан иркен атлап, шат елмаеп йөрде! Мин дә зур адымнарыннан калышмаска тырышып, янынннан терт-терт киләм — аның кебек буласы иде! Иптәше котылган, абый курыкса харап буласы икән. Четерекле эш, сират күпере кичкәннәр...

Суд хәлләренә халыкның мөнәсәбәте үзенчә: «төрмәне дошманыңа да теләмә, анда кеше саен бер кирпеч бар ди, көферлегенә төшмә»,— диләр. Тормыш-яшәешнең үз рәте-тәртибе бар. Бәхетсез Павлик Морозов үрнәк була алмады, күңел кабул итмәде — безнең әхлакка ят иде ул. Бусын да эчтән тына идек. Һәр очракта үзең хәл ит — чуалчык чорлардан узганда да буялма, иманыңны югалтма...

## Хәтердәге хәзинәләр

Төрле хәлләр, тәэсирләр күңелгә, хәтергә катлам-катлам төшәлә. Еллар юшкыны кумсә дә, хисләр ташыганда хәтер елгасы вактөякне юып ташлый, онытылган хәзинәләр яктырып-ялтырап ачыла! Уйлана торгач, ярты гасыр элек югалткан монгол акчаларын — тугрикларны шулай таптым: Шәкерт абый Халхин-Голдан алып кайткан иде. Көмеше-бакыры, эресе-вагы: баганалап төшкән язулар, сәер гербы күз алдымда яңарды. Монголия җирендә булуын раслаган дәлил алар. Кайда булуым ачылыр — кеше күзенә чагылмасын бу акчалар, дигән иде. Күпме гомер үткәч, гасыр азагында хатирәләрдә буласы икән кыйммәте... Хәстәрле Бибигайшә апа ерак җирнең тагын бер истәлеген саклаган: җиңел генә, йомшак кына колак мендәре ул, киек үрдәк мамыгыннан икән. Кулыма алып утырдым — әйтерсең лә ярты гасыр буе абыем җылысын саклаган...

Матди нәрсәләр көнкүреш юлдашы гына түгел, яшәвебез, рухыбыз шаһитлары да: кешенең төсе итеп карыйсың. Кеше китә, аны хәтерләткән ядкарьләр кала. Чорлардан сөзелеп музейларга күчкән әйберләр бар. Гаилә, нәсел-ыруның буыннан-буынга күчкән үз хатирәләрен дә саклыйсы иде. Бу гамәл ата-баба абруен онытмый яшәтү мәдәнияте бит: нәсел-ырулардан милләт җыела.

Үземдә ниләр калган соң? Әткәйнең фронттан язган хатлары, фоторәсемнәр, кара савыты, стена сәгате, шахтер лампасы, шахтер көрәге. Бабамнардан ни калды? Шәҗәрә... Төп йортта кыйбланамә бар иде, хәзер ул шигыремдә генә.

Менә шулай һәр буын үкенә — саклыйсы калган, ди. Син дә үкенерсең. Гамьсезләр өлешсез калмый — үзеңне дә онытырлар... Уйланыйк: гыйбрәтлегә гыйбрәт бар.

Җиде генә түгел, житмеш җиде бабадан килгән уртак хәзинә бар. Ханнар, падишаһлар казнасы түгел, халкыбызның мәңгелек мирасы, иманы — туган телебез ул! Берүк, риваятькә әверелеп, Кабан күле хәзинәседәй үткән заманга чумып эзләрлек хәлгә калмасын иде... Хәтер югалса — хәтәр! «Безнең нәсел!» — диген — һәр нәсел милләтнең тере тамыры ул! Хатип абый миңа шуны төшендергән, шуның белән күңелдә калды.

## Фин сугышы

Кышкы яшен. Киноларда гел күрәбез: Кызыл мәйдан өстеннән кукләрне тутырып самолетлар оча, җир тетрәтеп танклар ашкына, шат колонналарда бихисап байраклар талпына, дәртле җырлар агыла! Алга! Алга! — илебез алга бара, аңа каршы торырдай көч юк дөньяда!

Ә бер көнне шушы ташкын барды да терәлде — Маннергейм линиясенә абыңды... Ничек инде шул — картага печтик кенә кысылган Финляндия көчле армиягә каршы тора ала? Кышкы яшендәй булды, көтмәгәндә башка сугып миңгерәтте бу хәлләр... Ленинград тирәсендәге кызылармеецлар җиңеп чыгар кебек иде дә, сугыш корбан сорап ерак авылларга җитеште, куплэрне эченә суырып алды. Бик якында икән — әле генә озаткан кешеләрнең үле хәбәре килеп өлгерде... Кыска гына сугыш илне тетрәтте, безнең ипи телемебә дә үрелде: халык кара таңнан чиратка чыга, әткәй бер бөтен икмәк алуына шатланып кайтты...

Яралылар кайткач сөйли: финнар баш калкытырга бирми, ут яудыра — карга, бозга капланган армеецлар өши, туңып үлә. Кара тунлы командирларны снайперлар чүпләп тора: агач башына оялаган «күке»нең каян атканын белмисең, чаңгы эзе юк, ул сине күреп тора, ул анда алдан килеп кунаклаган. Бетон ныгытмаларын туп алмый — снарядларны сикертеп читкә очыра... Финнәр чая халык — тумыштан чаңгыда. «Финка» дигән хәтәр хәнҗәрне дә шул чакта белдек. Күз алдымда китеп харап булган кешеләрне беләм. Аеруча истә калганнары бар...

Елап калыр балалары... Яраткан укытучыбыз ул, кара тутлы, кара күзле, зифа егет. Читтән килгән, монда ялгызы, шуңа моңсу, уйчан микән? Чаңгыда оста йөри, кызыктырып безне дә ияртә. Мин аны армиядәге Хатип абыйга охшатам. Сугыш башлангач ук укытучы абыйга хәбәр килде. Чаңгыда чая йөри, дигәннәр. Андый чакта:

— Елап калыр балалары юк, — диләр, анысын да ишеттек.

Сугышның кан коюлы, каты икәнен белеп өлгергән идек. Абыйның күзләре мөлдерәмә — озатырга һәммәбез җыелып килгәч, чак тыелып торды. Ә без тыела алмадык... Кочагына җыеп, аркадан сөеп хушлашты, ул да безне ярата иде.

Китте абыебыз, иске мәчет янында бергәләп чаңгыда йөргән таллыкта озатып калдык. Кара күзләре керфек какмыйча әле дә текәлеп тора: бер караганда — Хатип абый, бер караганда... абый, абый... ничек әле исеме? Исемен, фамилиясен хәтерләмим... Олы Кайбычта ике ай гына укыган идем шул әле. Алексей түгел идеме? Оңытылмас исеме — «абый» булып калган. Киткәч, кырык көн узды микән, хәбәре килде — һәлак булган... Ул көнне малайлар, кызлар бергәләп еладык. Елап калыр балалары юк, дип ялгышкан военкомат — күбәү идек без...

## Язмыштан дезертир юк

Палкин. Китүче авылдашларны военкоматта күреп калабыз — безгә кереп бәхилләшеп тә чыгалар. Ярхәм җизни дә алынды. Курсант чакта басмачыларга каршы көрәшкән, командир булган. Таза гәүдәле, шофер ул. Көчле кешеләр сабыр була, борчылганын сиздерми, сәфәр чыккандай гына — Ленинград туганнарга баргалап йөри иде. Әле кеше өчен борчыла:

— Палкин югалган, ди... Аны эзлиләр, авылда да сораштылар. Ни булды микән?

Авыл советы председателен әйтә. Беләм мин аны: көяз кеше, пөхтә, ак якасы күренеп тора, френч кигән булыр, галифесе көн төпле, килешле, көн итеге ялтыр-йолтыр. Шаярткан булып, җитәкчегә хас өстенлек белән көлсә дә, тиз генә җитди кыяфәткә күчә. Кызыл борынлы, әзрәк тынкышлыгы да килешеп тора...

Әле дә күз алдымда, без уйнап йөргәндә яшел чирәмле урамнан кәс-кәс атлап бара иде. Авылның хуҗасы, совет власте — кешеләр язмышын хәл кылучы, идарә итүче. Күрше йортка карап:

— Карә, бу Сабирзянны, тагын юрт тыргизган? — дип гаҗәпләнде. «Сабирзян» — аерым хуҗалык, өсте-өстенә салым өеп, ызбасын сүттереп

саттырган иде Палкин. Дүрт балага куыш кирәк бит — калдык-постык такта-бүрәнәдән кораштырмый нишләсен...

Авылның командиры шыгырт-шыгырт басып уза, хәрби кием ятышып тора үзенә. Кая инде ул чабаталы Гайнетдиннәргә аңа тиңләшергә! Әллә шуңа көнләшеп:

— Хәрби киемне хезмәт итеп аласы бар әле аның!— диешәләр үзара. Палкинның тавышы кискен, боерулы — атакага барган сафлар алдында күрәсең. Менә, килде ул көн дә — «Если завтра война...» Җыенды да, биштәр читләренә бәрәңге төенләп җилкәсенә элде, китте чабаталы егетләр — ике уйлый торган эш түгел:

— Бездән генә калмаган, ил белән. Исән булсак — сау кайтырбыз! Аллага тапшырдык,— диделәр.

Фин сугышы бетте, кайгысы калды: хатыннар тол, балалар ятим. Әле генә тормыш бөтен иде... Ярхәм җизни исән-сау әйләнеп кайтты. Кемнәр бар — кемнәр юк, сораштыра:

— Палкин табылдымы?

— Табылды,— дип, әткәй сөйләп бирде. Армиягә алынып, хәрби киемнең үзгәсен кигәч, фронтка барган эшелоннан качкан. Зур урындагы абыйсына аркаланмак булган. Барыбер трибуналга эләккән. Расстрел... Язмышы гыйбрәт-кисәтү булып калды. Ә Сабирҗан абый Ватан сугышыннан соң кырык ел яшәп, авылның иң өлкәне булып дөнья куйды. Ипле нигезендә Вагыйзе көн күрә, колхозда эшли.

Ярхәм җизнинең солдат капчыгыннан мин белмәгән әйберләр чыкты. Кызыл йолдызлы бер бәләкәй тартмасын бүләк итте. Пластмасса дигәнен шунда белдем. Боз салып учактагы күмергә куйган идем, чаж-чож килде дә гөлт итеп кабынды... Яна икән ләбаса! Кызылармеец әйберсе шундый чырт була микәнни? Фин учагы сүнсә, немец пожары көйрәгән. Корыч танклар да гөртләп кабына икән... Җизни тагын бер пластмасса «патрон» күрсәтте, чәнти бармак хәтле генә. Исем-фамилияне, адресны язганнар: сугышчы һәлак булса, шуннан карап өенә хәбәр итәләр...

Л а т ы й п. Иртә-кичен күреп күнеккәнбез: яңа пешкән икмәк төялгән әрҗәле арба як-якка чайкалгалап, су буендагы пекарнядан кибеткә менеп бара. Юл һаман үргә, аты сузылып тарта. Урта буйлы базык олаучы дилбегәсен каккалап янәшә килә. Атка кычкырганын, сөйләшкәнен ишеткәнем юк. Зур битле, киң иякле — андыйлар зур ихтыяр көченә ия дигән бер китапта — елмаймый торган кеше. Бетмәс-төкәнмәс уена бирелгәндәй бер атка, бер тәгәрмәчләргә караштырып атлый да атлый...

Әрҗәле арба көтеп алынган чак: фин сугышы чыгып, ипи чиратында мәхшәр купкач, таныш олаучы күренми башлады — сугышка алынгандыр, яшь бит әле. Ул арада кем йөргәндер — әрҗә эргәсеннән күреп күнеккән Латыйп абый атлый сыман. Кан коюлы сугыш-бәрелеш тынды. Өшеткән кыш үтте. Җәй җитте. Чиллә көндә хәбәр таралды:

— Дезертир тотканнар!

— Урманнанмы?

— Мунча кергән җирдән эләктергәннәр!

Шул якка йөгердек. Бәрле буенда икән ул мунча, пекарня кырында.

— Трибунал инде аңа,— диеште ирләр.

— Атарлар...

— Сугыш бетте, кем белә...

Каршысына юлыктык: кулларын артка куеп, ике милиционер алдыннан... Латыйп абый атлый. Битендә бөрчек-бөрчек тамчылар, изүе ачык, юеш күлмәге аркасына ябышкан... Бүтән күрмәбез дип, үлемгә барган кеше итеп карыйсың. Йөзендә курку да, уңайсызлану да юк. Беркемгә дә карамый, беркемне күрми, җиргә текәлеп, кара коелып бара — монда түгел инде, киткән инде... Аның ни уйлаганын кем белгән: «Эләктем...» дигәндер. Ә бәлкем, качып йөрүдән котылдым, дип барадыр, бу көннең бер килерен көткәндер...

Кайнар икмәк исе аңкытып әрҗәле арба узды, олаучысы үзгә иде. Дезертирга ипи бирәләрме? Элекке олаучының күпме ризыгы калган икән? Тәрәзәсез фанер әрҗә төрмәне хәтерләтә...

Фин сугышының кышкы чилләсе үткән, җәйге рәхәт көн: сугышсыз, тыныч көн. Исәннәр әйләнеп кайткан, элекке эшенә керешкән. Беткән сугышның атыласы патроны калганмы — кыеласы бер җан ак кәфенкүлмәк киеп киттеме? Кем белсен... Аңа кызганып түгел, ятсынып карыйлар, тормыштан китеп баручы итеп... Язмышың — кара сакалың кая барсаң да артыңнан калмый, аңардан кача алмыйсың. Язмыштан дезертир юк...

## Сагынам...

Авыл урамыннан ялтырап-кызыктырып үткән беренче лисапид безнең хыял иде... Кечкенә арбаларны кара-каршы куеп, алмаштилмәш этешеп йөрү түгел инде: җинеллер, җитезлер — оча гына! Кайбычта мин дә йөрергә өйрәндем. Иярдән аяк җитмәгәч, рам арасыннан әйләндердем. Беренче кузгалгач та чак тыкрыкка борып өлгердем... Элдертә генә, илтеп баганага сылыймы, Бәрлегә чумдырамы дип торам, дулаган ат сыман котны алды... Каушавымнан тормозны онытканмын. Аннары кибеттән ипигә дә лисапидта йөри башладым: авылдашлар килсә, аларга, күршеләргә дә ташыйм. Иярсез йөргәнне күреп исләре китә. Бу мине үсендереп җибәрә: Бакырчыда күрсәләр иде! Кыңгырау челтерәтеп олы урамнан үтсәң, мәктәп яныннан! Колагымда җиз кыңгырауның көмеш тавышы, күз алдымда шул җиз-алтынның кояшта чагылышы... Әле җәйге каникул. Ул кыз да көзен бишенчегә барыр...

Сагынам мин авылны. Су буйларын, тал арасыннан йөгергән сукмакларны. Дусларны... Еракта зәңгәр тасмага ымсынып карыйм — калын кара урман шул — сигез чакрым чыгасы. Шосседа сулга борылып, вышка яныннан кергән арба юлы, көпчәк батып-чумып алган сулы чокырлар, анда йөзгән дегет тапларының салават күпердәй уйнап калуы төшләремә керә. Өндәп-дәшеп торган татлы омтылышым барын үзем генә беләм... Авылны дип, сабакташ кызны сагынам... Исемен үз алдыма да әйтә алмыйм... Лисапид белән җәлт кенә кайтып әйләнәсе иде! Ниятем чын булып тоела: җилләр җиләсенә кинәнеп, тизлек канатында ничек барам, барам! Кайтып җитәм, ул очрый, куышып уйнагандай, тота алмыйсың, дип үртәп, елмаеп ала да, тагын йөгерә, йөгерә, ерагая... Урман аркылы үземне генә җибәрмәсләр шул...

...Чокырчакта күргәч рәхәт бер кайнарлык кузгалуын, күз карашыннан сирпелгән илаһи көчкә тартылуым турында уйланам. Мәхәббәт булды микән ул, илһаммы? Илһам мәхәббәтне уяттымы, әллә — мәхәббәт илһамнымы? Бар илһамым белән мәхәббәт иҗат иттемме? Ни булса да, бәпкә саклаган сабый чагымда матурлыкка сокланып күңелдә уянган илаһи көч... Күп нәрсәләр белдем, илһамны мәхәббәттән, мәхәббәтне илһамнан аера алмадым бугай... Бәлкем, икесе бербөтендер? Һәркем үз күңел сәләтенчә иҗат итеп, мәхәббәте сәләтенчә илһамлана...

Зәңгәрләнеп сызылып-сузылып калган яшьлек урманнары, тойгыхисләре, хыяллар сагындыра. Мәхәббәтнең, илһамның тарту көче ул. Машиналар бармый, самолетлар очмый — күңел канатлары гына җитә ала ул көннәргә... Ә бит иярсез лисапид җитәрдәй генә ара иде!

## Бәхилләшүе булган икән...

Әнкәйнең үксеп елаганын күргәнем бар. Әткәй еламый дип белә идем, тәтәй вафат булгач күрдем. Бусы — икенчесе... Гадәттә, көләч, шаян әткәй ямансу иде ул көнне. Кичен, куенына сыендырып:

— Мин әти яшенә җитә алмам, улым...— дип куйды, тавышы калтырады. Күзләрен күрсәтмәс өчен читкә борылды. Һидият бабайның 54 яшендә дөнья куюын беләм... Нигә әйтте әткәй моны:

— Синең үсеп җиткәнеңне күрә алмам...— дип кабатлады.

— Ник куркытасың малайны,— диде әнкәй дә, шикләнеп.

Мин инде унынчы яшьтә, иркәләр чак түгелдер. Болай тулышып кочаклавы саубуллашу сыман... Әткәй тәне, әткәй исе шундый үз, кадерле. Аның янында рәхәт, тыныч. Канат астына сыенган бәпкә кебек мин...

Бәхилләшү сыман тоелды болай сыктавы. Аерылу мөмкин мени, дип әрнешеп сискәндем. Сәбәбен әйтмәсә дә, төшендем: сугыш та сугыш, башланмагае, дип өнне алалар... Авыл өстенә үрмәләгән шыксыз дәһшәт, боз болытыдай бу сүз, игенне теткәләр афәттәй... Олылар сүзе колакка керә, тынгысыз аларның җаны, шул шөбһә бимазалап тора. Берәр әйбер алу турында әнкәй сүз кузгатса:

— Әй, безнең гомергә җитәр әле... Булганының рәхәтен күрергә насыйп булсын,— ди әткәй. Гамьне качырган, тормышка дәртне сүрелдергән сугыш шомы... Кыямәтнең герман җиреннән ябырыласы сер түгел, ничә ел телдә шул гына:

— Безнең бодайны савар-савар да, ут булып өскә явар...

Ак җирлектә күпертеп ак чәчәк чигелгән урын япмабыз бар. Әткәй шуны ябынса, әнкәйнең йөрәге кузгала:

—Алмасана, шуны... кәфен сыман.

Соңыннан әнкәй:

— Мин ятуга йоклап китәм. Ә ул, төнлә уянсам да, әрле-бирле йөри, тәмәке тарта...— дип искә алды. Йортны, безне кайгырту үзенә калып, хәсрәтле уйлардан йокысы качкач, аңлаган әткәй хәлен:

— Ир аркасы — кала аркасы, җаным тыныч булган,— дип офтана. Иркәләнеп-шелтәләп әйткән сүзләре өчен үкенеп, югалту ачысын сизгәндер.

...Авылдан чыгып киткәндә, бәхилләшер чакта әткәй мине йомыш белән түбәночка җибәрткән. Йөгергән идем, килеп өлгерә алмадым, дип сызландым. Кайтмаска китәсен белгән, аерылу авыр булыр, дигән. Әнкәй моны соңыннан әйтте. Бик соң булгач...

«Әти яшенә җитә алмам...»— дигәндә — бәхилләшүе булган. Әтисе яшенә җитәргә дә унбиш ел калды... «Һәлак» дигән сүз «вафат»тан алдарак йөри... Кинәт башланса да, куркып көтелде сугыш, ир-егетләр гомерен алдан ук кыскарткан, тыныч тормыш, яшәү тәмен агулап торган...

## Ул мине күрмәде...

Сагыну — татлы тойгы... Ул кызны күрермен дип көн саен дәресне көтеп алу гына түгел лә — мәктәптән ел ярым аерылып тордым. Бүген мине күрүгә йөгереп килер дә:

— Кайттыңмы?— дип елмаер,— бүтән китмәссеңме?— дияр дә, сагынганын сизәрмен... Мин яңадан үз мәктәбемдә. Коридор кайнап тора, бәрелеп-сугылып малайлар йөгерешә, кызлар чуала. Мин а н ы эзлим. Каушыйм үзем: күргәч тә ни диярмен? Ул ни дияр?

Еректан күреп алдым. Әнә ул... Малайлар сөйләшә, көлешә — мин якын килергә курыккан кызга исләре дә китми ичмасам. Ник ул гына шулай сөйкемле, аерылып тора? Ашкынып көтүемне күрмәсен дип, читкә караган булам. Әнә ул якыная, йөгерүдән бит алмалары алсуланган. Ул гына шулай ягымлы карый, ул гына... Тыным кысыла. Ә ул берни булмагандай узды да китте! Күрмәде... Ашыгадыр, звонок булды. Ә ник күрергә тиеш — серемне, сагынуымны белми лә... Күрмәвенә эчтән генә шат та үзем, иркен сулап куйдым — барыбер сүз куша алмас идем. Бәлкем, ул да күрмәмешкә салышкандыр — дәрестә күз төшереп алыр әле? Әйләнеп тә карамады — бармы син, юкмы...

Ул мине күрмәде. Шулай да рәхәт миңа. Класста булуын белү рәхәт. Тәрәзәгә борылган булып, очраклы гына, гамьсез генә күз ташлаган булам. Ул күрмәсә, мин аны күрәм! Урман артында, зәңгәр офыклар энгерендә түгел хәзер. Тагын шуны да күрәм — арабыз, Кайбычтагыча, ерак. Унсигез чакрым гына микән әле? Хыялымда чакта якындарак иде...

## «Аңламыйсың, күңелем тәрәзәсен...»

Мәктәптә укыганда сәхнәгә менмәдем, уттан курыккандай кача идем: ничек йөзләгән кеше алдында чыгып сөйләргә мөмкин?! Сакаулык телгә аяк чалып торгач... Бүтәннәр өчен борчылып та хәлдән таям. Ә бит җырлыйлар да әле! Клубта олимпиада, безнең класс та катнаша. Әнә, Сыруржиһан, бит урталары чокырланып торган оялчан кыз, ничек сәхнәгә менде микән? Йомыш белән керсә дә, авызын томалап, әнкәй янына почмакка ашыгучан:

— Миңлебикә аптый...— дип пышылдап әйткәндә дә тартынып тора. Ә монда — танымассың, тыныч карап, салмак атлап чыкты. Моңаебрак калган сыман:

Аңламыйсың күңелем тәрәзәсен
Читтән кемнәр килеп какканын...—

дип, матур итеп җырлап җибәрде. Җырламый, эчендәге сагышын уртаклаша сыман...

Җырга көйләнгән, шуңа моңсу күренәдер. Ярату турында җырлап буламы? Күз алдымда үсеп киткәндәй булды — әнә ниләр бар күңелендә. Кемгә икән бу сүзләр? Мине телдән калдырган сабакташ җырласа яшерен ишарә дип торыр идем. Ул арада а н ы ң исемен әйттеләр. Нинди җыр сайлады микән?

— «Карак песи»!

Менә сиңа кирәк булса! Заһит микән, шаркылдап куйды. Шигырьне беләбез, аны җырлап та буламы?

Чоландагы ак майга
Иялəшкән күселәр...

Җырлый классташ, рольгә кереп, песигә бармак янаган итә. Ялгышмаса ярар иде, тирләп үк чыктым, туры карарга кыймыйм...

Мияу, мияу пескәем,
Хыянәтче икәнсең,
Саклый торган маены
Үзең ашап киткәнсең...

Шаулатып кул чаптылар, мин дә кушылдым. Җырдан ишарә эзлә, әйтерсең лә аның уенда син... Карак песи читтән генә йөри. Әкәмәт бу тормыш дигәнең, әлеге «ак май»ны шактый сакларга туры килде шул. Язмыш та шаян икән, кинаясе булган.

Сыруржиһанның күңел тәрәзәсенә чиртүче күрше Шәмәк егете булды. Еллар үткәч, сәхнәдән инде үз шигырьләремне укып төшкәч, күрше авылда бер сылу кыз килеп исәнләште. Сыруржиһан кызы икән! Бит уртасындагы сөйкемле чокырына чаклы охшаган. Бала чактагы теге концерт турында кызык итеп сөйләмәкче идем, өлгермәдем, тыйнак кына китеп барды — егете көтә, ашыктыра. Бер-берсен аңлашкан яңа яшьлек бусы — безнеке ядкарь генә инде... Күз алдымда балачакның күз камаштыргыч сәхнәсе, классташым, яшерен хисләрем.... Тәрәзәдән генә карыйм үткәннәргә, юк инде, кабат кичереп булмый ул хисләрне, сагынып кына була. Тәрәзә чиртергә инде кыюлык та бар, буй гына җитми 1941 елның язына...

...Һәркайсыбыз үз хисләре белән мәшгуль, күзләре үз мәгъшукасендә. Ә бит син аңламаган күңел тәрәзәләре дә калган икән. Театрда бер әби килеп сүз кушты:

— Таныйсыңмы?

Төбәп соравыннан сизендем, күптәнге таныштыр. Әнисенә охшатып таныдым... Исемен әйткәч, сөенеп куйды — сабакташ кызларның берсе. Кырык ел инде күргән юк иде. Хәл-әхвәл сораштык. Сүзне бүлеп, соңгы кыңгырау чылтырый, урыныма ашыгам.

— Мин сине гомер буе сагындым...

Миңа әйтелгән сүзләр иде бу. Уйламаган-көтмәгән кызлар авызыннан... Ни дияргә белмәдем, сүзсез киттем. Менә шулай — «аңламыйсың күңлең тәрәзәсен читтән кемнәр килеп какканын...»

Сәхнәдә кемнеңдер мәхәббәт тарихы. Соңгы пәрдә...

## Һәйкәлдә — эт...

Чапаев, Чкалов, Челюскинчылар... Атаклы кешеләр турында күп язалар, исемнәре телдән төшми, рәсемнәре гел күз алдында. Тагын үзең тартылган шәхесләр була, кай ягы беләндер якын алар. Академик Павлов турында урысча китап алган идем. Сәер кеше ул бер карасаң, бик үзенчә, дингә ышануын да яшерми, ә үзе — галим! Кешенең баш миен өйрәнә, шартлы рефлекслар дип, этләрдә тәҗрибә ясый. Миңа шул мәҗаралар кызыклы, галим турында ни күрсәм дә укып барам.

Сәер түгел диген — эткә... һәйкәл куйдырган! Пырдымсыз картның килешә-килешми дип тормыйча, үзенчә кылануымы? Һәйкәлдә юлбашчылар була... Шул урында горур басып эт торсын әле! Интектергән өчен ярлыкасын дип эшләткән ул моны. И. П. Павловны сурәтләгән рәсем бар: ике кулын йодрыклап язу өстәленә куйган. Бусы да гаҗәбрәк — бүтәннәр бит каләм тотып утырган була. Ахрысы миңа «алай түгел, болай ул!» дигән холкы ошагандыр. Кай ягы беләндер Зиннәт бабама тартым бугай...

Еллар узды, гомер авышты. Павловның үзсүзлеләнеп өстәлгә куйган йодрыклары ачылды — матбугатта чыккан хатларын укыдык. Ил язмышы хакында үз фикере булган, бөек дигән юлбашчы белән бәхәсләшергә җөрьәт иткән. Гомер буе уемда-фикеремдә булды — каян сизгән диген бала күңеле? Кылган гамәле эшендә күренгәндер. Өстәлгә төшкән йодрык, эткә һәйкәл дә — килешмәү, бәхәс билгеле. Юлбашчылар пьедесталендә этне күргән кешенең баш миендә дә «шартлы рефлекслар» эшкә җигелгән. Миллионнар баш мие белән идарә итәргә алынган ил башы үзе шартлы хәлдә калган...

Үлем түшәгендә ниләр кичергәнне дә әйтеп яздыра галим — соңгы минутынача фәнгә хезмәт итә. Культ дигән афәтнең һәлакәтен дә әйтеп калдырган. Үз тәҗрибәләре белән мәшгуль, сәясәттән читтә дип күрсәткәннәр, ә ул җәмгыятьнең «баш миен» дә алдан күрә алган. Гасыр башында илдә беренче булып Нобель премиясе алган ул — 1904 елда ук!

Әткәй туган ел бу, озын гомерле академик озак яшәү серен белгән — ак сакалын җилфердәтеп велосипедта, кышын чаңгыда егетләрчә җилдергән. Ә уе, уйлары тагын да җитезрәк булган икән, кешене уй яшәтә!

Сокланган кешеңә охшарга тырышасың. Кумирлар да гомер буе лаек булырга тиеш — алар да сынала, заман алмашканда какшамый калганы сирәктер. Павлов, Короленко... Бер караганда, көтелмәгән күршелек, әмма акыл ияләре буларак янәшә икән алар, бердәй үз иткәнмен.

Ә һәйкәлләр? Килде көне, барын да рәттән түнтәрделәр, җимерергә дигәндә Рәсәй маһир да, өлгер дә. Унҗиденче елгы революция шаукымы аударган балбалларны Павлов күргән, бушаган пьедестал баскыннарын да заман сулышы өреп төшерде — бусын без күрдек. Павлов куйдырган һәйкәл кымшанмый: җәфа чиккән эт үз урынында. Эт күрмәгәнне күргән миллионнар язмышында тәҗрибә ясалган чорга ишарә... Павлов түгел, дәвере сәер булган. Галимнең сәерлеге, бүтәннәргә охшамавы, ярашмавы нәкъ тиешлесе — дөресе икән.

## Буш блокнот

Елга башы урманыннан чикләвек корыгы җыеп кайтабыз. Кечкенә арба белән инде. Урманчы күрмәгәе дип, яна-пешә кырга чыктык.

— Кеше-кара юк, туктап тын алыйк,— диде әнкәй. Гүелдәү ишетеп күккә карыйм: парадтагы сыман почмаклап тезелгән өч самолет килә!

— Хәерлегә булсын, ешайдылар,— дип борчыла әнкәй. Ә мин кинодагыча, мотор гөрләвендә куәт-кодрәт тоям, горурланып күзәтәм. Күктә очсалар да, җир тетрәп кала! Кесәмдә Кайбычтан алып кайткан бик әйбәт блокнотым бар, карандашы да кыстырып куелган. Иң-иң кирәкле нәрсәдән башлармын дип йөрим, һаман буш көе. Вакыты шушыдыр — шигырь үзеннән-үзе язылырга тора:

> Безнең илнен чиксез җирендә,
> Самолетлар оча күгендә.
> Без дошманнан курыкмыйбыз,
> Батыр кызылармеецлар тора чигендә!

Дәрт-кодрәтем күк күкрәткән самолетларга тиң! Шундый итеп язармын! Әйтергә теләгәнем күп, күплектән сүзләр тыгылган... Ник болай, дип аптырыйм, тамагымда гарьлек төене. Юл түбән таба, күчәр җиңеләйде, ә күңелдә авыр... Шигырь юллары бирешмәде...

Блокнотны озак сакладым. «Беренче омтылыш», имеш, «тарих өчен»ме, яза алырымны исбат итәрмен дипме? Буш битләре үзенә тартып та, үртәп тә тора...

Кечкенә арба белән утын ташыйм, күктәге самолет белән рухланам... Җирдән аерылганмын шул. Чор җырлары тәэсирендә булганмын. Күңелемнең җирдә калуы хәерлегә икән, чын илһамга лаф орулар ят. Ашыкма, алда сугыш сагышлары... Дүрт ел эчендәге югалту ачыларын, кайгы-хәсрәтен кичергәннән соң гына килер шигырь. Күктән көткән, көтеп ала алмаган бу көн — 1941 елның мае иде...

## Әткәйгә үпкәләдем

Җәйге челләдә нәүрәптән сөт-катык алып мен дигәндә йөгерәм генә — анда салкынча, сөтле чүлмәк, гөмбәләгән такта исе. Яланаяк карга басып алуы кызык — «пешерә». Әмма бу җиләс рәхәтлекне язын тутырып калдырасы бар.

Нәүрәп галәмәт зур. Башта әткәй төшеп, ут ягып җибәрә. Тычкан тишекләренә тәтен тулсын, бөҗәк-мөҗәкләр бетсен дип ыславы. Капкачын ачып җилләткәч, себереп чистартып чыгарасы. Тупсадан кар сала башлыйбыз. Сусыл, авыр ул — кәрәздән бал саркыгандай, көрәктән агып-тамып бара. Кояшта җемелдәгән карны әткәй шакмаклап кисә, аннары рәттән алып ташый. Миңа шул пәхтәлек ошый, кызыгып эшлим. Шахтер көрәге ипле — егет чакта Донбасстан алып кайткан. Лампасы да бар, анда немецчә язылган — күмер мәгарәләренең серле ачкычы шулдыр күк...

Әледән-әле нәүрәпкә төшеп, тупса астына өелгән карны эчкәрәк күчерәм, таратып, тыгызлап менәм. Язгы сусыл кар исе, тәтен тәме кушылган чак кына баш әйләнерлек нәүрәп исе... Өскә чыккач, күз алларым әлҗе-мөлҗе килеп тора. Нинди якты, җылы, салам түбәләрдән чупыл-чупыл ешлап тамчылар тама: төнлә туңган боз пәрдәсен тишеп чупырдый, чыпчыктай сөенеп коена. Уяна табигать! Борынгы бабайлар Яңа елны — нәүрүз дип, тикмәгә язын бәйрәм итмәгән. Баш очыннан кыр казлары үтә, безнең бәпкәләр дә шулай тезелешеп үссен дип, каз оясына салырга коры салам чүплим. Язны алар башлап җибәрә сыман:

— Киек казлар! — дип, сөенче алгандай бер-береңә күрсәтәсең, кулыңны каш өстенә куеп, күзләрең талганчы, казлар зәңгәр күктә эреп югалганчы озатасың. Мондый татлы минутлар язын гына була...

Кыр казлары күңелне иләсләндерде, елганы шушы моңлы тавышлар уятадыр. Әнә, малайлар Чирмешәнгә боз акканны карарга, акмаса күсәкләр белән кузгатып, каерып, өсте-өстенә өелешеп челтәрләнгән боз бәллүрләрен коеп йөрергә чапты! Бабай белән тугани абый җәтмә күтәреп балык сөзәдер... Салихулла белән мин дә чүпләшер идем! Күзге кыйпылчыгы сыман яктырып сикерешәдер чабаклар, ташбашлар... Яңа балыктан язга кузгалган саф-салкын зәңгәр боз исе — ирек-иркенлек, яңарыш исе аңкый. Ә мин монда... Малайлар ерганак ера, буа ясый. Китә инде, китеп бетәр инде бозлар, күрми калырмын... Ә без — күрдек, дип мактанырлар... Сабантуй сыман көтеп алган бәйрәм бит! Шакмак-шакмак кисеп кар ташу кинәт кызыксыз булып кала, мәшәкатькә әйләнә. Күрә бит инде әткәй иптәшләр шабыр-шобыр узганны. Бар малайлар шунда лабаса! Нәүрәбе дә тула белмәде — гуҗ карын икән чистый! Тупса — авызын ачып һаман кар көтә... Төш тә тигезлә: тыгызлаган саен озаграк ташыйсы, күбрәк ташлыйсы... Мөлдерәмә тулсын дигәнме! Дигән инде, анысын беләм — басыла бит әле ул, аптыраганнан әйтәм.

— Башлаган эшне бетерик, — ди әткәй, — ярты юлда калмасын!

Ул да минем хәлне белмәгәч... Шундый үпкәлим, үземә үзем шундый җәл тоелам — кызганудан күңелем тула. Әткәйгә күрсәтми генә үпкәлим, соңыннан белер әле... Карандаш алып, чоланның ак юкә бүрәнәсенә язам. Берзаман китеп барсам, сагынырсыз әле (ә минем яракларга китүем инде чын сыман...). Шушы язуны күреп укыр әткәй, ник кенә дияр, иптәшләре белән дияр, уйнарга җибәрмәдем, дияр. Сагынып сулкылдаган әткәй-әнкәйне дә кызганам — ничек күңелең ташымасын. Әнә бит алар киек казларга түгел, мин очып киткәнне карап офыкка текәлгәннәр, минем моңлы тавышымны ишетәләр...

Яз иде, сәбәпсез ашкындырган, күңелне ташудай актарып-кузгатып мөлдерәмә тулган яз иде. Бүтән язлар болай түгел, бусы әллә нигә үзгәдер сыман... Хәзер аңлыйм шикелле: тулышкан хисләрне әйтергә сүз таба алмавым, берзаман шигырьгә бушанасы тойгылар бөелү — шул көчсезлегем җылаткан, шулай татлы авырттырып шигъри бәпкә борынлаган... Китәрмен, сагынырсыз дип алда көткән аерылулар йөрәккә каккандыр. Китүләр бик якында икән. Мин түгел, әткәй китәсе... Сугышка китте, кышын җылынырга утын китергән, чолдәдә сөт-катык әчеп әрәм булмасын дип җәйлек кар да салып калдырган... Бергә каршылаган соңгы яз икән.

Җәен әче төтен исе бетәргә тиеш иде дә, әллә күзне әчеттерә — яшьләрне агыза. Җылый бит, җылый дип үртәүче әткәй булмаганга ул... Теге чакта күңел нечкәрү — назлану булган, иркә бала үпкәсе. Сискәнеп китәм: ә соң эленке-салынкы йөри, киреләнә дип әткәй үзе үпкәләмәде микән? Дәшми генә кар ташыган иде... Күңелендә ниләр булган да, җанын ниләр борчыган? Сугыш дип язалар, сөйләшәләр иде, ил өстенә, ир башына нинди дәһшәт килүен белгәндер ул, кайткач сорармын әле. Чолан бүрәнәсенә сырлаган сүзләргә карамаска тырышам — андагы җыр кисәкләре өчен дә оят...

Киек казларның китүен әткәй окоптан карап озаткандыр. «Киткән казлар кире кайта, кайтырбыз абзыкайлар», — дип юангандыр. Ничә язлар үтте, әткәй күреп мактасын дип нәүрәпкә карны дыңгычлап тутырдым, җәйге эсседә кайтса, әле дә бар икән, дип исе китсен, дидем. Кайтмады... Ерак балачакта бер нәүрәп салкын сагыш калды, җәйге челләдә эремәс үкенүләр калды. Эчтән йоткан яшьләр дә эретә алмады, кыр казлары да баш өстеннән язын, көзен юксынуны яңартып очтылар... Әйләнеп кайтмаска дип үткәннәргә очкан көннәрем еракта инде. Сагынуларым да, үпкәләрем дә үземә генә калды...

### Сугыш...

Габдельхак җизни лесничий — кардонда яшиләр. Фазылгәрәй абыйдан хат килдисә, шунда йөгерәм — көткәннәрен беләм, сөенеп каршылыйлар. Абый ФЗУда — шахтада эшли инде, Горловка, дигән адресында. Кардон авылдан ерак түгел: башта кырдан, игеннәр арасыннан барасы, урман кергәч тә якын гына. Яратам мин сөенеч илтергә. Тын урман почмагы, аулак урын да тарта. Мунчала күле тымызык, кара суы тынлыкны тагын да куертып, әкияти төс бирә, монда могҗизалы хәлләр булыр сыман... Укыган китаплар тәэсиреме, әллә кан хәтере тоя: күлгә батырылган юкә кабыгы исе, төтен исе, аулак урман — ерак бабайлардан бит...

Җизниләр якын күреп тора, монда табын да үзгәрәк — кунак сые... Башны мендәргә төрттем исә, эреп китәм, агачлар шаулавы җай гына тирбәтә. Урман ыгы-зыгысыз яши, авыл түгел инде, моннан узучылар да сирәк...

— Сугыш! Сугыш...

«Нинди сугыш? Кемнәр сугыша?» Дөбер-дөбер аяк тавышлары, ишек ачып-ябулар... Куркыныч хәбәрне йокы аралаш ишеттем. Шаулашып кешеләр кереп тулды, шомланып сөйләшәләр:

— Радио әйтте: бомбага тоткан... Киев, Одесса, Львов...
— Десант ташлаганнар!
— Немец басып кергән....
— Менә, сауды-сауды да Гитлер... Үзебез симерттек.

Котым очып уяндым, як-ягыма карыйм, аңламый торам: мин кайда соң әле? Десант монда төшкәнме? Урман кисүчеләр сөйләшә икән. Җизни күренде, телефонны бора... Ә-ә, мин аларга кичен хат китердем бит. Караңгы төште дип, куна калдырдылар. Абый Украинада, бомбага тоткан җирләрдә... Ул нишләр?

Сугыш... Урманнан авылга сулышым кабып, күкрәгем кызышып йөгердем. Сөенеч китергән идем, яман хәбәр алып кайтам... Сугыш! Авыл инде белә, авыл инде купкан, шаулый. Бүген үк чыгып китүчеләр бар. Военкомат тиз өлгергән... Ашыгыч! Саубуллашып урам әйләнергә дә вакыт юк... Сугыш! Китүчеләр машина кузовына төялде. Ярхәм җизни шунда хәл итте:

— Арттагы урамнан булса да бер урыйк... Үкенечкә калмасын!

Үзе дә машинасы белән китә. РККА дип янбашына язылган «Ярхәм» кушаматлы аргамагын да алачаклар... Кузовка мин дә менеп кысылдым,

җизнине озатам. Иртәнге салкынча җил биткә бәрә... Китүчеләр җырлый, калучылар елый... Сугыш... Машина ашыга, тыгыз җилдә җырлар өзелеп кала:

Герман җире кара үлән,
Йә кайталам, йә үләм...

Китүче абыйларның кулы җилкәмдә, баш өстемдә кайнар сулыш... Сугыш, сугыш!

Йә кайтарбыз, йә кайтмабыз,
Сау булыгыз, туганнар...

Сугыш... Кара болыттай ябырылып, өермәдәй өерелеп, ир-егетләрне авылдан, кыр-болыннардан, сөенечле көннән, якыннары кочагыннан йолкып-кубарып чыклы иртәдә ут эченә алып китте... Җизни мине басу капкасы янында туктап төшерде. Киттеләр... Әле кайчан гына колхозның беренче машинасы сөенеч алып кайткан иде: җизни белән Җиһанша абый — Әгъзамның әтисе — беренче шоферлар... Хәзер машина — сугышныкы...

## Үкси-үкси көлгәнбез...

Тәкъдир сабырлыкны сыный да, бәяли ахрысы. Озата алмадым дип үкенеп йөргәндә сөенеч: әткәй чакырган! Казаннан! Авылдашлар күргән, җыелу пунктындамы, барып өлгерүебез ихтимал икән. Сәгате белән чыгып киттек, очып кына бармадык микән йөз чакрымны... Җитешербезме?

Үз йортлары белән яшәүче абзыйларда очраштык, Гражданская урамында. Әткәй рөхсәт алып чыккан. Сагынышканнар инде, күрәм лә... Кукмарадан тугани абый да килгән, ул хезмәт армиясендә. Тимер хутлы арбага пар ат җигеп, йөк ташый икән. Тугани аптый да Гыйльмулласы кырында тартынып кына аска карап, тыелып кына көлемсери. Табында без китергән авыл сые: каклаган каз, кызыл эремчек белән май. Хуҗалар кайдадыр, бүген без хуҗа, самавыр безгә җырлый. Бодай башаклары төшерелгән шешә дә бар...

Сөенештек, сәбәпсез дә көләсе килеп тора. Әткәй шат, үтә җанланып мәзәк арты мәзәк сибә, «тозлыраклары» да чыга. Без бар дип тормый, бу үзгәрешне күреп алам: солдатчадыр... Ашык-пошык җанлылык инде, вакыт бик аз бит:

— Онытып торыйк әле дөньясын! — ди әткәй.

Соңыннан төшендем: сугышны, аерылуны онытыр өчен шаярткан икән, җан тынычлыгы булмаган ул көлүдә. Без, беркатлылар, моны сизмәгәнбез... Көлү тулгагы Салих белән мине тәмам чыгырдан чыгарды. Бер-беребезгә карашабыз да хихылдыйбыз, һич тыела алмыйбыз. Таҗи Гыйззәтнең «Чаткылар» драмасын укыган идек. Гыйльмениса карчыкның тикшерүче урыска җавапларын, тылмач старостаның әкәмәт тәрҗемәсен искә төшерәбез:

— Вот бит, летом на травах гуляет, чикерт-чикерт, тырт-тырт...: — ди Салих. Мин өстим:

— ...против чорта, шайтан бумагы, калдонски бугамалится баранчуклары бает...

Тәгәрәшеп көләбез, яңаклар авыртып бетте. Бу нинди шаукым, туктап булмый:

— Если грехами умирает булса, там-та-ра-ра далуки дөньяда...

— ...нашенекы Мөхәммәтанский бух, как ваш свинья, тәмугта жарит будет, говорит.

Инде табында көлү тынган. Атаңнан яхшы түгел, дип, әнкәй пышылдый. Көлдек тә көлдек, ахрысы, гел бергә булырбыз, дип белдек. Әткәй белән ни сөйләштем соң? Юньләп тыңладыммы диген, бер тутырып күзенә карадыммы...

Башта тугани абыйны озаттык, тимер хут арбасына менеп утырды да, таш юлдан шыңгырдатып китте. Ул сугышка түгел, тылга — сугыш яшеннән узган. Әткәй мина әйтә:

— Безнең казарманы күрәсең киләме?

Анда бит ишек төбендә часовой, винтовкасы штыклы...

— Кертерләрме соң?

— Таныш ул, сөйләшеп куйдым.

Уздык тимер капкадан. Мылтыклы егет аяк кагып калды. Чыгарырлармы? Әткәйдән аерылып калсам, монда мине кем белә!..

— Менә, шушында йоклыйбыз,— диде әткәй, клубтай бүлмәгә кергәч. Ике катлы сәндерә-караватлар тезелеп киткән. Һәркайсына тигез итеп ак җәймәләр ябылган, юка гына мендәр, одеалы бар. Мондый пөхтә, чиста урын командирлар өчендер...

— Бусы — минеке,— дип, әткәй икенче каттагы берсен сыпырып куйды. Мендәрен күтәреп, әнкәй бәйләгән йон күлмәген күрсәтте, ышанмас дигәндер:

— Әнкәңә сөйләрсең. Безнең әйбәт монда...

Капкадан кереп-чыгып йөри ала, таныш эшен йөкләгәннәр — иши өләшеп тора икән. Ак халат киеп. Шуңа урыны чистадыр. «Монда әйбәт»,— ди дә... Артка тарап йөргән, күпереп торган чәчен кыркып алгангамы, ябыккан сыман... Яңаклары батыбрак тора, зураеп калган күзләрендә борчылу, иреннәре калынрак күренә. Ике битендәге элек елмаеп торган сызыклар тирәнәйгән, көлгәндә дә сагышлы... Кулларын иңемә сала да, читкә борыла — бугаз төене кыймылдап куя: әчтән җылый, яшен йотуы... Минем ул төен юк, иягемдә уенты да юк, ә бит әткәйгә охшагансың, диләр...

— Улым, син каласың минем урынга. Сеңелеңне кара, әнкәңне...

«Сеңелеңне кара» дигәне таныш, әнкәйне әйтүе сискәндерде. Дәшми генә тыңлыйм, мондый чакта әйтелә торган сүздер... Әткәй мине тимер капкадан чыгарды. Үзе теге якта, бик күп шинельлеләр арасында калды. Часовойга папирос биргәнен күрдем...

— Сезне озатырга чыгармын әле! — дип кычкырды, кул болгап. Тагын нидер әйтте, шау-гөрдә күмелде. Чыккач әйтер әле.

Иртәгесен көттек, эзләп тә бардык — часовой үзгә, сөйләшми, якын да китерми. Сырма кигән абзыйлар килеп тулган. Берсе әйтте:

— Төнлә эшелонга төяп озаттылар... Фронтка!

Безнең янга чыгар ара булмаган... Күп көлсәң, җыларсың, диләр, артыграк көлгәнбез. «Җылыйсы килгән бала атасы сакалы белән уйный» булып чыкты... Ни дип көлгәнбез әле: «Если умирает булса, там-та-ра-ра далуки дөньяда...» Бер дә ерак түгел икән ул мәхшәр — без авылга җәяүләп кайтып ирешкән арада эшелоннар чаптырып фронтка житкәндер...

Ник шулкадәр уйсыз-гамьсез булдым икән, дип үзалдыма оялып йөрдем. Авылдан чыгып киткәндә, улыма авыр булыр, дип, юк йомышы бар итеп, түбәночка озаткан. Мин тиле Казанга соңгы күрешүгә дә китап алып бардым, авыз ерып калдым... Әткәй ни уйлагандыр... Уйлаган ул — бу юлы да күтәренке күңелле булып уйнаган. Мин тагын «түбәночта» калганмын...

...Сугыш чоры кытлыгыннан күченеп-чәчелеп йөрүләрдән бик аз әйбер эләгеп калган. Әмма пар алюмин касәне әлеге очрашу истәлеге итеп саклыйм. 1950 елны ул хакта теркәп тә куйганмын:

«Казанда әткәй ике бокал биреп җибәрде:

— Кайткач дуслар, туганнар белән мәҗлестә күтәрербез әле! — дигән иде, насыйп булмады... Гомердә бер генә була торган тантанада — туемда күтәрермен, өмет тулы сүзләрен хәтерләрмен...»

«Әткәйгә хат» поэмамда (1957) шул хакта яздым:

Кайткач күтәрербез, дигән рюмкан
Мөлдерәмә итеп тутырдым.
Мөлдерәмә тулы күзем белән
Буш урнына карап утырдым...

Әткәй яшеннән узганга шактый инде. Әмма әткәй һаман да олы, сагыну юксынуда мин һаман баламын...

## «Без китәрбез, ахры...»

Көн саен олау-олау төялеп авылдашлар фронтка китә. Бу хәсрәтле «сабантуй» төркеме түбәночтан югарочка, басу капкасына тиклем шаулап бара. Без, малайлар, ияребез. Кабатлана торгач, тамаша кебегрәк булгандыр. Шул озатуларда гамьсез балачактан аерылдык... Әткәйләр китте — йортта ир заты итеп безне калдырып китте. Җырлары калды. Үзәк өзгеч бәхилләшү моңнары, яшьле күзләр, яшьле сүзләр. Тальянның сер бирмәскә тырышып үксүе... Кара кайгы тыгызланып, сөреме күңелгә төшәлгән: сагыш ташкүмере бәгырьне көйдереп һаман көйри, һаман яна. Ул күренешләр күңелдә сүтелә, гел сүтелеп бетә алмый, тамакта ачы төер булып тыгылып кала...

Авыл советы янына озатучылар җыелган. Хатип абый да китә. Уйлары авыр иде, кайтмасын сизенә иде. Сугышның дәһшәтен, гаскәр тәртибен белә — утка каршы иң беренче булып командир сикереп чыгарга тиеш... Ак күлмәктән, кара костюм кигән, елмаерга тырышып, егетләрчә сүз әйтә:

— Гитлерның эшләпәсен салдырып кайтырбыз! — ди, күтәренке рухлы күренә. Әмма авыр иде аңа, чыраена күләгә төшкән. Кузгалдылар. Яңадан килеп, Мәсгут белән мине, моңаеп калган энеләрен кочагына алып үпте:

— Фамилияне дәвам итүчеләр сез. Сынатмагыз!

Бик якыннан күрдем, бик аңладым... Күз яшьләре тойгыларны ачыграк күрсәтәдер. Ачы яшьләр кибәр, күңелдән эзе китмәс... Басу капкасы чик, теге якта — китүчеләр юлы, алар язмышы. Хатип абыйның соңгы җыры шул яктан яулык болгый:

Без китәрбез, ахры —
Казан, Мәскәү аркылы;
Өстемдәге ак күлмәгем
Кәфен булыр, ахыры...

Үзләре чәчкән игеннәр, кырлар белән дә күз карашы сыйдырганча колачлап-кочаклап хушлашкан алар. Еракдагы тонык кына күк күкрәве тынычсызлап-сызлап уйларын тарткан, алар инде бездән аерылган...

1941 елның июнь азагы бу. Мәсгут биш яшьлек сеңлесе, үги әнисе белән җәйге ялга кайткан хәлдә бүленеп калды... Дошман Ленинград капкасы төбендә. Хатип абыйның соңгы юлы да шунда туры килгән... Армиягә чаклы эшләп тә кайтты ул анда. Бабайның ике улы шунда төпләнеп яшәде, ә өлкәне сугыш башлангач алынып, озатучылар күз алдында баржаларын немец бомбага тоткан... Ленинградка безнең фамилиянең дә мөнәсәбәте бар. «Хатип абый ничек шунда күченеп калмады микән?» — дип уйлый идем. Мәңгелеккә калырга язган... Җырын да:

Без китәрбез, ахры,
Ленинград аркылы... —

диярлек. Ватан сугышы тарихына китте алар. Мәрьям апа тагын бер җырын искә төшерде:

Германия җирләрендә
Булмасын каберләрең...

Җыр-теләкнең бусы да рас килгән — үзебезнең җирдә калды...

Авылда басу капкасы юк хәзер. Сугышта югалганнарны эзләп китте мәллә... Яңадан бастырасы иде, мәңгелеккә күчкәннәрнең соңгы бусагасы шунда ич. Саф-саф тезелгән исемлекләрен шул баганаларда күрәм...

## Рәсемнәре ап-ачык...

— Ниемә миңа нимеч теле? Өйрәнмим! — диючеләр аз булмады. Китабын алып караган идек, бөтенләй күңел кайтты — безнең баш җитмәле түгел... Яңа килгән укытучы Шәриф абый Исмәгыйлев класска кереп, авызын шундый матур килештереп-бөрештереп әйтте немец сүзләрен — яраттырды да куйды. «Анна унд Марта баден»,— дип сиптерәбез генә. Җәй буе зәңгәр мыеклар чыкканчы коенганны искә төшерә, җае килсә-килмәсә дә шуны әйтеп куябыз. Китаптагы иң беренче җөмлә ул, беренче танышлык, шуңа истәдер.

Рус теле укытучысын, ничектер, фамилиясе белән әйтә башладык — Ежов абый, дип. Базыграк гәүдәле, кояшта янган йөзендә елмаю балкыткан ак тешләре, кыска җиңле ак күлмәге килешеп тора. Фамилиясе русча булса да, Кайбычтагы Алексей абый кебек — Тәрбит ягыннан, керәшен татары. Ул тирәдән укыган кешеләр, укытучылар күбрәк чыга, диләр.

«Шәриф абый» да «Ежов абый» дип, юк йомышларны бар итеп, класстан чыгармый торабыз, алар тирәсендә без. Күрәләр яратканны, эне-сеңелләредәй сөенеп керәләр үзләре дә класска.

Кинәт — сугыш... Башта Шәриф абый китте:

— Немецчә белгәннәр кирәк,— дип сөйләштеләр.— Разведчик, йә тылмач булыр.

Ежов абый да озак тормады, рус теленнән тылмач кирәкмәстер — инде рәттән алалар. Тора-бара үпкәләдек бугай немец теленә, янә суындык — сугышка да шул гаепле! Инде ничек фашист телен өйрәнмәк кирәк?

Яраткан укытучыларны алыштыру җиңел түгелдер яңа килүчегә. Ятсынып, элеккесен юксынып текәлә күзләр. Әле генә такта янында мөлаем абыйлар иде. Каты итеп, басым ясап әйтсәләр дә, көлемсерәп куярлар — үзебезнеке иде...

Фин сугышына без елап озаткан моңсу карашлы, уйчан Алексей абый янына тагын икәү барып басты... Һаман елмайган хәлдә, яшь-яшь алар. Тоныкланмый, саргаймый сурәтләре — күңелдә ап-ачык... Хатип абый кебек егетләр... Күпме яратуларны үтермәк булган сугыш. Үтергән дә...

## Ак сандык

Ибраһим абый, Гөлсем апа бездән өч өй аша гына. Әнкәйләр йомышка йөрешә, әткәйләр дус. Ибраһим абый тартынырак елмаючан, аз сүзле, үтә сабыр кеше. Агач эшенә маһир, чәчләре дә йомычкадай бөдрәләнеп тора. Беркөнне ап-ак сандык күтәреп кергән:

— Китап-дәфтәрләреңне сакларсың,— дип, минем алга куйды. Бик шатландым! Сандык — серле урын, әнкәй, тәтәйләр актарганда, әйберләрне кузгатып, таслап тутырганда иллә дә кызык — әллә ниләр килеп чыгар сыман борынгы заманнан... Мин дә сандыклы булдым! Капкачы тупсалы, юкә тактасы тип-тигез — салсаң су торырлык! Кемнеке икәне күренсен, эчке яктан капкачына язып куйдым:

«1937 ел, 22 март. Язучы Һ. Шәүкәт.»

Язасы да килеп тора — беренче классны бетереп киләбез лә!

Осталар юмарт була, кеше сөендерүдән тәм таба. Ибраһим абый өстәл артына буем җитәрлек итеп култыксалы биек урындык та ясап бирде. Ә сандык иң кызыгы, үз почмагым: китап, дәфтәрне, каләм-карандашны тезеп куям. Капкачында янә бер язу өстәлде:

«Һидиятуллин Ш. 1940 ел, 25 март. Язучы...» — имзам да сырланган. Язучы дигәнем туры килер дип кем белгән — язмышың да серле сандык...

Ибраһим абый сугышка киткәндә иптәшләре белән урам әйләнде, алар җырлаганда уйчан гына йөрде. Сүзсез генә китте, хәбәрсез югалды... Истәлек сандыкны шәһәргә күченгәндә дә калдырмадым. Вак-төяк нәрсәне бушаткач, бала чактагы «автографларым»ны күрдем. Сандык буш түгел икән — Ибраһим абый, әткәй исән көннәр хатирәсе... Сабыр холыклы күршебез хәтер сандыгымның бер почмагында түзем генә көткән... Онытмадым мин аны. Хатыны Гөлсем апа да күз алдымда. Колакка катырак — кешеләр гел күңелле нәрсәләр турында сөйләшәләр дигәндәй, һәрчак көлемсерәр... Берсе — аз сүзле, берсе ишетеп җиткерми, шулай да бик матур аңлашып яшәгән ир белән хатын. Елмайса да, эчендә нинди утлар янганны үзе генә белгәндер — сүнгән очкыннарның көле чәчләренә сибелгән...

Ибраһим абыйның үзе сыман кара бөдрә чәчле Рафисы бар иде. Улым кала, нәселем яшәр, дигәндер. Тик ул баланы Чирмешән тобасы алды шул... Коеныргa йөгергәнен күрдем, ах, җибәрмәгән булсам, дип үкенәм, мине тыңлый иде! Ул көнне булмаса, иртәгесен барыр иде — язмышны алдап буламы... Әтисе бу кайгыны белмәде — аны сугыш чоңгыллары йотты. Кызы исән, нарасый иде, әтисен хәтерләми. Очраткач, ядкаре турында сөйләдем — ак сандыкта ак шатлыклар, кара кайгылар да янәшә.

## Суган — сагышкамы?

Төштә суган күрсәң — сагышка, диләр... Ул елны колхозның яшелчә бакчасында гел булмаганча суган уңды: куш йодрык чаклыдыр, йомры-йомрыдыр, алтын-сарыдыр. Өндәге суганны юрамыйлар да, 1941 елның көзе иде...

Колхоз ул елны шактый файда күргәндер. Сатарга дип Казанга олаулар йөрде. Бер юлысында, шыгырдап пышылдашкан каплар, капчыклар өстенә кунаклап, әнкәй белән без дә калага киттек. Үр булдымы — төшеп тәпилисең, атның сулышын тоябыз ла. Юлның Осланга хәтлесе исемдә юк, Казан дип, нинди икән дип, хыялланып үткәнмен. Беренче бару ла!

Ослан тавыннан ачылган манзара хыял эше генә идеме! Еракта — түбәндә балкыган бихисап утлар, муенсадай тезелеп торганнары, йолдызлардай төрле якка сибелгәне дә чекерәеп торган якты иде! Менә нинди икән ул шәһәр! Өченче ел Кайбычка килгәндә электр балкышына ис киткән иде. Казан — әкият икән: офыктан-офыкка җелтер-җелтер җемелди, күренмәгәне, офыкка күмелгәне күпмедер!

Идел буена төштек, чиркандырып су салкыны каршылады. Соңгы паром киткән, өлгермәдек. Күрдем, дигәнең, калага кердем дигән сүз түгел икән, читтән кызыгып торыгыз, дидер... Төнгә дебаркадерда калдык. Көзге суның сулышы, җиле җелеккә үтә, кая анда йоклау — йөреп җылынасың. Яктысын якты монда, җылысы да булса!

Казан урамнарыннан үттек, ә менә эчтән күргән, фатир кергән беренче йорт онытылмас — Мөхәммәт абыйларда булды. Шәһәр манзарасыннан ким сокланмадым бугай. Ул аның иркенлеге, түшәмгә җитеп утырган әкәмәт гөлләр, шыплап тутырылган китап киштәләре, пыяла шкафлар... Өстәл, урындыклар да затлы, без күрмәгәнчә. Өске катка булмә

эченнән бормалы баскыч үрмәли. Менеп күрергә җае чыкмады, идәнгә кожаннар җәеп йокладык, ничә олаучы бит. Якташлар дип, ачык йөз белән каршылап, чәй эчерделәр. Олаучылар да рәт белә — сарайга капчыгы белән суган кертеләр. Суганы — профессорлар ашарлык кына шул. Әйтмәдем бит әле, Мөхәммәт абый чын профессор ул. Шуннан мәртәбәлерәк исем юктыр да. «Безнең Мөхәммәт!» — дип бик олылыйлар үзен, атаклы якташ. Галимлеген, гадилеген зурлап сөйлиләр. Казан каласында беренче төнем, баш куеп йоклаган почмак-түрем Щапов урамындагы йорт булды...

Беләм, бу йорттан кеше өзелми. Тау-тау эшләр, йөкләр, авылдашлар Мөхәммәткә бара. Мөхәммәт үзе дә Тау ягына кайтып йөри, халыкның хәле бик таныш аңа, йомыш белән килсәләр дә тиешле «тау»га бара Мөхәммәт. Аның сүзе үтә, ул юлын белә, законын таба — ул гына коткарыр! Дөнья булгач, нинди генә йомыш төшмәс диген. Һәркем аны үз гозерен үтәрдәй урында эшли дип белә. Әле дә исемдә, районга йөреп-йөреп тә рәт чыгара алмагач, Хәтимә апа да, ызбалык бүрәнә юлларга соңгы өмет белән аңа китте:

— Агачлар башлыгы Мөхәммәткә бармый булмас! — диде. Көлеп җибәрдем. Чыннан да, СССР фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институты... дигәнне каян белсен ди.

Казанга күчеп килгәч, Мөхәммәт абый белән җыелышларда очраша идек.

— Нихәл, якташ! — дип, гадәтенчә елмаеп кулын суза. — Минем әни Олы Бакырчыдан, синең әбиең Колларныкы!

Әллә ничек үтә ул гомер дигәнең... Бергәләп туган якка кайтырбыз, дип тә ниятли идек. Якташлар да безне бергә җыярга базмады бугай, үзебез дә ашыкмадык. Кала мәшәкатьләре үз әермәсенә бөтереп ала торгач, үкенечкә калды...

Казан бусагасын атлап кергән әлеге йорт янынннан үткән саен 1941 елның көзен хәтерлим, кабат керергә форсат чыкмады...

Казанга мин суган олавына утырып кердем. Әчесе дә, төчесе дә булгандыр. Әмма сагышлы дия алмыйм. Суганны мин болай да яратам — банан, шәфталу сыман «җәннәт җимеше» түгел, ул сине ел әйләнәсендә ташламый. «Суган турaганда елыйм, исемә төшәсең дә» дигән шаян җырны да яратам — сер бирмәгән халык. Елар чакта да яшь аралаш көлгән... Бәлкем, шуңадыр, унике елдан соң килгәч, беренче эш урыным «Чаян»да булды...

## Соңгы чик

Хатип абыйның һәлак булуы — 1941 елның 9 сентябрендә. Авыл советына килгән «кара пичәт»не — командованиенең рәсми язуын хәтерлим: «Сезнең ирегез... антына тугрылыклы калып, батырларча һәлак булды...» — диелгән. Бәлкем, ялгыштыр? Әле киткәненә күп ме генә... «Сезнең ирегез», диелгән, ә ул өйләнмәгән. Төрлечә юрадык: кесәсендә сөйгәненең адресы булды микән?

Олы Кайбыч кешесе Бари абый, фамилиясе Хәйруллин бугай, яраланып кайткан, авылдашларны очраткач сорашкан:

— Хатипның кемнәре бар? Алайса, апасы килсен, — дип әйтеп җибәргән. Кырык икенче ел, арыш башакланып килгән чак. Унсигез чакрым үтеп, Бари абыйның өен сорашып таптык. Ашыкканбыз — әле йокысыннан тормаган иде. Иркен бүлмәдә, гәрәбәдәй сары идәнгә җәелгән урыны. Без кергәч кузгалып, киенә башлады. Бәдәнле, таза кеше, кулбашы тирәсендә умырылып кергән тирән яра эзләре күреп алдым. Тизрәк Хатип абый турында беләсе килә...

Бари абый уйланып, гаепле сыман аска карабрак, әкрен генә сөйли, калын иреннәре дә яра эзләр кук — мондый хәбәрне җиткерү җиңелме... Әмма, вәгъдә иман, адрес алмашканнар: исән кайтсаң — туганнарны күреп әйт...

— Ленинград янындагы таулыкта, сентябрьдә... Немецләр якын ук килеп басты... Танклар, автоматчылар күп, үрмәләп менеп җиттеләр... Без аз калдык. Сергач мишәрләре бар ие, алар әйтте:

— Чигеник, Хатип, бетәбез...

— Приказ юк! Ярамый!— диде Хатип. Казанда ук командир итеп куйганнар ие...

«Безнең абыймы, ялгышмыймы?»— дип торган идем дә, инде таныйм: шундый иде Шәкерт абый, әйткәнендә торыр.

— ...Борылып карасак, Хатип чалкан ауды... Ике көннән ул биеклекне барыбер яңадан алырга туры килде. Безне тыңлаган булса... Шартлагыч пуля йөрәге турыннан кереп, аркасыннан чыккан... Авыз-борыныннан кан киткән... Ординарецы мишәр егете иде, яндыргыч шешәсе кулында шартлаган... Хатипның кесәсендә тотылмаган кулъяулыгы бар ие (Фәйтүнә апа бүләгедер?), битенә яптык. Икесен янәшә салып җирләдек, ашыгыч булды. Кабер беленмәслек итеп кәс тездек. Фашист туздырмасын дип. Кадер киче иде, мишәрләр дини халык, догасын да җиренә җиткереп укыдылар:

— И Хатип, болай кадерләп күмү безгә тияме әле...— диделәр.

(«Кадерләп күмү»— унөч яшьлек малайга аңлашылып җитмәгән иде, хикмәте булган: әле дә җир өстендә калган сугышчы сөякләре табыла. Ярты гасырдан соң...)

Бари абыйга карыйм да, уйлыйм: менә, исән калган, ярасы да төзәлгән. Хатип абый да кайта алыр иде, безнең алда басып торыр иде. Соңгы өмет тә киселде: үз күзләре белән күргән, үзе җирләгән кеше сөйли. Куен дәфтәрен, пәкесен, көзгесен, бер кыз карточкасын кайтып тапшырасы икән, госпитальдән күчеп йөргәндә югалтканнар...

Ышандырып сөйли дә барыбер күңелдә төен калды: ник чигенделәр икән? Ник калдырганнар абыйны? Нәкъ сөйләгәнчә булды микән? Ә бит яшерсә дә белмәс идек, булганны сөйләде. Рәхмәт әйтеп, кайтыр юлга кузгалдык. Тыныч көн, кояшлы басу юлыннан атлыйбыз. Әле генә ишеткәнне җыеп-сүтеп, төпченеп киләбез. Ничек итсәң дә, «һәлак» дигән сүз... Менә шунда инде, өйләнергә өндәгән якыннары:

— Елап калучылары күбрәк булыр иде...— дип юандылар.

Урманга кердек. Без дүртәү: әнкәй, Бибигайшә апа, Мәрьям апа, мин. Кызурак атлаган булабыз, бу тирәдә качкын күргәннәр, ди. Әнә, беркөннәрдә дезертирны авылдан казаклар чатына хәтле куып, урманга кергәч тотып алдылар. Ашарга эзләп килгән. Без дә йөгерешеп бардык. Яралы кулыннан шуышкан марлясын төзәткәләп, Галәтдин абый ярсыды:

— Без кан койганда, син монда...— дип башлаган иде, авыл советыннан бер абзыйның тегенәргә сукканын күреп:

— ...син дә монда... Тимә! Кыйнарга хакың юк, җилкә калынайтып ятасың!— дип кулыннан тотты. Фронтовик шул — авыл советыннан да курыкмый!

Дезертир — адашып авылга кергән ябага бүредәй куркынган карашлы. Җитүле җирән сакаллы, мескен иде... Юк, Шәкерт абый чигенмәгән, качмаган, ул горур егет! Күпме авылдашлар китте сугышка, кайта алмасын сизенеп китте — язмышыннан качмады. Кырык еллап идән астында, җир тишегендә дер-дер посып яткан мескен бәндәләр бар икән. Горурлыгы сынган, үзен югалткан алар... Кеше дигән кешенең чигенмәс чиге булырга тиеш. Абыебыз шул чиктә калган. Намусыннан чигенмәгән. Ленинград блокадасы башланган көн булган ул...

## Немецләр... Каратунда

Кара колонна булып агылып, көтмәгәндә килеп чыкты алар, япан кырга өелгән туфрак тавы артыннан күрми дә калганбыз... Немецләр! Берничә малай гына идек, болар бит таптап-сытып китәчәк...

Җиргә сеңеп, күзәтеп ятабыз — ни булыр? Ә алар агыла да агыла — безне күрмиләр. Немецләр... Озын буйлы таза ирләр. Мондый авылдашлар сугышка китеп бетте. Нишләтерләр? Курыксаң да, кая барасың. Явызга охшамаган үзләре. Алай дисәң... Як-якка каранып берничәсе үлән арасына посты... Качып калмакчылар! Авылга барып керсәләр — харап итәрләр... Болар исә бил каешын чишеп, хаҗәтен үтәргә чүмәште. Немецләр дә шундый ук икән, бар җирләре дә...

Колонна узды, тузан басылды, иркен сулыш алдык...

— Пленныйлар — чуен юлы салырга китергәннәр.

— Идел буе немецләре — безнекеләр бу!

— Нимес безнеке була диме?! Солдатлар сакламас иде...

Безнеке дә, түгел дә — Идел буе немецләре... Сугыш башлангач, аларга ышаныч беткән — төпләнгән җирдән куганнар. Армиягә дә алмыйлар — ничек мылтык тоттырасың — кай якка борыр бит әле...

«Немец» сүзе дә куркыныч... Ә бит безнең авылда да бар — «Афзал мимеч». Кушаматы ник андый дип башка килмәгән элек... Кич пожарный ызбасында сүз иярә сүз чыга:

— Мимеч — эшкә бик оста, маһир халык,— дип сөйли 1914 елда пленда булып кайткан бабай.— Безне дә чуен юлында эшләткәннәр ие. Унбишегерме кеше рельскә килеп ябышабыз — кыймылдатыр хәл юк. Ачлыктан киселдек, җүн житкән. Карап-карап торды да ике мимеч, рельсне ике башыннан алып күтәрде дә китте! Бездән көләләр... Ай-һай, мимечтәге тәртип, эшне җиренә җиткереп куя инде. Герман жиреннән мин чалгы алып кайттым. Корычы яхшы, шәп кисә. Кылычлары да үткен... Ә болар, безгә чуен юлы салучылар — әби патша заманында күчеп калган токым...

Пленда булуы хакында бер генә сөйләмәгән, хәзер бүтәнчәрәк тыңлыйсың. Чирәмне кайчы белән кыркып үстерәләр, ди. Сугышка китүчеләр дә: «Герман җире кара үлән»,— дип шуны җырлыйлар. Җиң сызганып чирәм кыркыган куллар автомат тотып кешеләрне кыра... Ни җитмәгән, шулай әйбәт яшәгәч, ник басып кергәннәр? Аларның да җыры бар, алар да җырлый... «Хальт» дип, эт өргәндәй өзеп-өзеп тешләп алган сүзләрдән ничек җыр була икән? Менә шулар токымы — Каратунда. Немец — немецкә каршы юл саламы? Тизрәк килсеннәр дип тырышмыймы, эчендәген кем белгән. Карга күзен карга чукымас.

Каратун, Каратун базары, дигәч, ул авылда тунлылар йөри, базарында кара тун саталар дип күз алдына китерә идем. Шунда — немецләр. Идел буеннан булса да, барыбер имәнгеч...

...Ярты гасыр инде Тау ягына поездлар йөгерә. Идел буе немецләре салышкан тимер юл Казанны якынайтты, юлны җиңеләйтте. Ул араны куна-төнә ат белән, йә җәяүләп үткән чакларны хәтерләүче сирәктер. Әсирләр сугыштан соң илләренә озатылды — немецләр дә, японнар да. Үзебезнең немецләрнең генә куылган-куптарылган нигезләренә үзләре салган юлдан кайта алганнары юк... Алар өчен сугыш һаман да бетмәгән. Гаепсезгә сөрелгән халыклар төрле җирләргә сибелгән. Нахакка рәнҗетелгән, каһәрләнгән Кырым татарлары кебек... Хаклык үзе бар ул, килеп кенә җитә алмый: юллары начар, юллары чуен түгел...

### Э-ва-куа-ция...

Башта эвакуация дигән ят сүз килде, аннары сугыш ягыннан хатын-кыз, бала-чагалар төялеп олаулар кайтты. Сугышка китүчеләрне озаткан арбалар ул көнне буш түгел иде. Безгә бу яңалык — тамаша, алар хәлен төшенсәк тә, бергә сагышларлык түгел әле. Ленинград-Мәскәү кайда да, без кайда... Дөрес, авыр улап-ыңгырашып, өйләрне селкетеп самолетлар үтә. Шулай да, сугыш ерак сыман иде. Баксаң, утлы давыл кагып-кубарып ташлаган кешеләр дулкыны безгә дә килә...

Кытлык, ачлык афәте юк әле, кайгыртып ярдәм итү, юату дисеңме — хәлләренә керде халык, үз булып, кушылып киттеләр, өйдәш булдылар. Авырлыкның моннан соңгылары беребезне дә читләп үтмәде.

Кайтучылар үзебезнең халык — татарлар иде. Бер көнне урыслар да узып китте. Озак юл килгән кызлар, хатыннар тау астында таллар арасында инеш күреп, анадан-тума чишенеп, суга ашыкты. Керсәләр, оят җирне томаларлык та түгел — су тубыктан гына... «Оят — Мәскәүдә кыйбат»,— диделәр микән, без шәмбә кабалый торган сап-сай ташлыкта аягүрә басып юына башладылар... Тузанга батып ничә көн кайтканнар — оятны уйлап торырлыкмы. Малай-шалайга нәрсә, читән артына ябырылып, тын да алмыйча яр астын күзәтә. Юынырга «булыша» торгач, читәннән ашып үскән зәһәр кычыткан пешергәнне дә сизми калганнар. Бу хәтлесен каян беләсең, дисәң, ни бит инде, мине дә чакты затсыз кычыткан...

Авылдан озатасы авылдашлар, ерактан килеп туласы «давылдашлар» агымы алда икән әле...

## Боразна астында окоп...

Ызба өстеннән узган самолетларны карап озатам: әнә ул, очкыч карынында сугыш бара, баш өстеннән уза бомбалар, ычкынып төшә күрмәсен... Болары инде кызык китергән «яраплан» түгел. Летчиклар күз төшерсә, бәрәңге бакчасында кызыл балчык чыкканны күргәндер. Авыл советы һәр йортка үз окобын казырга кушты. Ике күрше бергә дә ярый — без Низаметдин абыйлар белән. Әрбәлеккә көлтә ташый торган юл, алар да колхоз булгач, кирәге бетеп, сукмакка әйләнеп калган иде. Шул ызанны аркылы кисте окоп чокыры. Ишек ике яктан да — йөгереп чыгарга да посарга... Бармы — бар диярлек булсын, кушкач казыйбыз инде. Күтәрелеп бомбовозга карый кеше, күләгәсе йөзеннән үтә:

— Монда качып буламы...

Ашыктыралар: кем белә бит, әнә немес килә дә килә... Сталинград янындагы Камышинга җиткән, дөмбер-дөмбер туп тавышлары шуннан киләдер, шөбһәләнгән йөрәкләр белән бергә кага... Ә күрше абзый безнең якка керебрәк казымакчы, бакчасын бозасы килми: яңа бәрәңге өлгертеп ашарга әле исәбе...

Испалнитель, тәрәзә кагып, тагын бер әмер җиткерде: кичтән ныгытып томаларга — утның яктысы төшмәсен штубы! Ут алынгач карап йөриләр, сискәндереп рамга сугалар:

— Томалагыз! Якты күренә!

Сукыр лампаның ни яктысы, күпме генә саркып төште микән? Алай да, үзебез чыгып карый-тикшерә торган булдык.

— Бомба ташларлык ни бар инде, военный әйбер юк бит? Завод дип — тимерче алачыгын, склад дип буш келәтне бомбага тотсынмы?— дип көлүчеләр булса да, бу сүзләре урамга «төшми» иде. Тәртип тикмәгә түгел, картадан карап табарга тычкан уты да булыша, ди. Әнә бит, бер самолеты Идел күперенә җиткән, зениткалар куып җибәргән — бомбасын читкә ташлап качкан, ди... Радио, телефон юк авылда, хәбәрне чыбыксыз имеш-мимешләр китерә. Ни булыр, ни күрер газиз башлар? Сугыш әллә кайларда түгел, әнә кайда гына, бакча башында — самолетлар китеп күмелгән Коллар ягында... Боразна астындагы окоп — баласы гына, алда әле «атасы» — «окоп елы» булып телдә каласы...

## «Окоп елы»ның башы...

— Окоп казырга куалар!

Бу хәбәр «сугыш» дигәннән ким кузгатмагандыр авылны, бик яман шом салды.

— Эшкә яраклы беркем калмый!

Аңга килеп өлгерер ара юк, теләсәң нишлә, тиз генә җыенып китәргә. Клуб тулы хатын-кыз ах та вах килә, елаш-сыкташ, һәркемнең үз хәле хәл. Укытучыбыз Сәнгать абый — парторг, салкын клубта тавышы карлыгып беткәч тә кат-кат аңлата, үгетли... Безнең авыл кешеләрен читкә, еракка җибәрәләр, ә читләр монда килеп тулачак. Ник алай? Үз өеңнән йөреп эшләсәң ни була? Кышка каршы кияр кием, ашар ризыгы ни соң... Өйдә ничек тә үтә. Балалар өелеп кала, кем карар? Бернинди сәбәп исәпкә алынмый!

Чирмешәннең сул ярыннан, авылны кисеп, танкка каршы чокыр казылачак — траншея. Бөтен җиргә ДОТлар, ДЗОТлар, блиндажлар төзеләчәк.

— Монда җитсә, нимес танкы чокырга төртелеп каламы...

— Ничек ажгырып килә, каян гына узмаган, нинди елгалар, ермакларны!

Болары сак кына әйтелә, коткы таратучы диярләр дә — эшең бетте, окопны... үзеңә казырсың... Авылга бик күп солдат киләсе. Штабы, машина, тракторлар белән — хезмәт армиясе. Кая урнаштырырлар? Окоп казырга килгән йөзләгән кеше кайда торыр? Сугышка күпме ирләр китте, урман турарга, торф чыгарырга, тимер юл эшенә нихәтле хатын-кыз озатылды. Инде — окоп казырга. Урын буласы авылда. Шушы мәхшәр, кан елаштан соң халык төшенде: еракта сугыш безгә дә житешә. Немец танкларына каршы чокыр әзерләгәч...

1942 елны — «окоп елы» диделәр бездә. Тау ягында. Числалык елыннан иртәрәк — сугыш чыккан елның котсыз, салкын көзендә, без Яңа ел каршылый торган клубта хәвефле җыелыш белән башланды ул...

## Безнең капкада «4»ле саны

Авылга солдатлар килеп тулды. Мәктәп — аларныкы, укулар тукталды. Йорт саен солдатлар урнашты. Хуҗадан сорап-нитеп торыш юк, чыгып капкаңа бак — ничә солдат керәсе акбур белән сызылган. Цифрлары солдат буе — хәйләләп киметерлек түгел. Ул хакта уйлама да, класс тактасы түгел ул сиңа — эләгерсең! Безнең капкадагы «4»ле дә чекерәеп тора — югарочтан ук күренерлек, бигрәк тырышып язганнар. Йортына, гаиләсенә карап авыл советында хәл кылганнар, килүчеләрне урнаштырырга кирәк бит. Окоп казырга Мөрәледән килгән ике кыз бар, берсе Сәгадәт — Кайбычтагы күрше Фаизә апаның сеңлесе. Күреп, әнкәй үзе чакырган иде. Солдатларны да кушкач, без тугызау буласы. Гадәти авыл ызбасы: түрдә сәке, аш өстәле, урындыклар, эскәмия. Ишек катында сыерга лакан. Комган да шунда тора — юынырга. Мунчакта бозау, мич аралыгында бәрәннәр яфрак кетердәтә. Почмак сәке астында каз оясы. Өйнең чиреген мич биләп тора, аның караваы мич башында йокларга урын бар...

Безгә нинди солдатлар керер дип көтәм, күзем ишектә. Дүртнең берсе взвод командиры:

— Здравствуйте, апа! — дип, беренче ул ачты ишекне. Уртача буйлы, ачык йөзле, фамилиясе Журавлев. Аның артыннан иелебрәк атлаган озын буйлысы татарча исәнләште — Кудряшов, керәшен татары икән. Ябыграк, ач яңаклысы, бусагага басып үтте, башы тимәде — Мансуров.

Соңыннан кергәне өлкәнрәк, сүзсез генә ияк какты да ишекне япты, салкын кермәсен дип, ныгытып тартып куйды — Лапшин. Мансуров — укытучы икән, чемодан күтәргән — культурный. Башкаларның инде солдат биштәре, бавыннан тотып иңгә элгәннәр. Чишенделәр, урнаштылар. Бездә кыш чыгасы хәрби «өйдәшләр» менә шулар.

### «Ишек бавы — бер алтын...»

Кичен өйдә кеше күбәя... Башта солдатлар кайтса, ишегалдында казлар тавышын ишетүгә, Журавлев атылып ишеккә килә. Ачып кертергәме? Тот капчыгыңны, ике куллап тотып тора ул тотканы, үзе көлә-көлә сорый:

— Как фамилия?

Кызлар да чая җавап бирә, «кобылья» диме, оялып тормый. Русчаны аңлап та бетермим, ә Журавлев тәмам кәефләнә, ул яхшы аңлый — көткәнен ишетте бугай... Ишекне сөздерә-сөздерә шактый интектергәч, «җылынгач» кына өйгә үткәрә. Тегеләре туңып-күшегеп, арып кайткан, пыр туздырырлар дисәң, авыз ералар, күзләре дә көлә. Фамилия сорау боларга да ошаган. Журавлев югында кызларны Мансуров каршылый. Командир барында тыелып торган, аның да бик сөйләшәсе килә кызлар белән:

— Кертмибез, ишек бавы — бер алтын!

— Безнең апа — мең алтын! — ди Сәгадәт. Бу бит кияү каршылаганда әйтелә торган йола. Кергәч тә төртмәле сүзләр тукталмый, тик ачуланыш юк, уен гына. Кудряшов көлемсери, Лапшин дәшми, күкрәгенә кулын куйган да, акшарланган мичкә текәлеп уйга талган. Шул «экран»да хатынын, балаларын күрәдер, яшь-җилкенчәк егет-кызларның үз эше, дидер...

Уен бер яклы гына бармый, кызлар алдан өлгергән көннәр дә була. Ул чакта инде Мөрәле чибәре сайрата:

> — Ишек бавы бер алтын,
> Безнең апай мең алтын;
> Җылыныйм дисәң, бер алтын
> Бир, жизни, — тыш бик салкын!

Үзе чырык-чырык көлә:

— Как фамилия? — дип тә интектерә. Чатнатып русча сөйләгән була, кыюлык бар үзендә. Шатурда — торфта эшләгәндә откан сүзләре ярап тора...

Кичләрен кызык була, өшеп-туңып кайтканнар җылынып житә. Салкында бүрәнә шартлый, сискәндереп ала — суык бабай «мылтык ата». Сугыш барын онытмагыз, дигән шикелле. Журавлев язу-сызуларын карый, көндәлек эшкә йомгак ясый да, тынычланып, сәкегә менеп аяк бөкләп утыра. «Апа, ачуланма», — дип әнкәйгә ымлый да, кызлар белән ике арада мәзәк сүз, тапкырлыкта ярыш башлана... Тик йокларга ятканда гына урын житми иде:

— Рәттән җәегез! — дип фәрман биргән була командир. Шаяртып сөйләнсә дә, тәүфыйкълы иде Мөрәле кызлары. Әнкәй белән киңәштеләр дә, дүрт егетле өйдән авылдаш кызлары янына күчәргә булдылар. Йорт аша гына, үпкәләп чыгу түгел. Сәке тар булса, күңелләр иркен дә, кыз баланың үз әдәбе, үз урыны бар. Эштән соң Сәгадәтләр кич утырырга керә, элеккечә кызык була. Фамилия сораулар, «ишек баулары» кабатлана: йоласын юксынудыр, яшьлекнең бер уены гына, чынлап кияү-кәләш булып фамилия алыштырыр чак түгел. Вакыты җиткән-житүен, кызларның алмадай пешкән чагы... Шулаен шулай да бит, бит алмасына салкын «үпкән» эзләр генә өстәлә — «окоп елы» тамгалары, нинди заман икәнен әйтеп тора...

Моңа хәтле «салкын кыш» дигәнне төрлечә әйттеләр:

— Зәмһәрир суыгы!— диде әбиләр.

— Очар кош туңып таш булырдай,— диде бабайлар.

— Тәкерек җиргә төшкәнче бозга әйләнә!— диде абзыйлар.

Зәмһәрир дигәнгә әлләни исем китми, ә менә егылып төшкән кошларны күрдем. Төкерек боз булганны да күп сынадык. Бу елгы салкын турында һәммә кеше бер төсле әйтер:

— «Окоп елы» салкыны...

1942 елның исеме булып калды ул. Гомердә булмаган салкын, диделәр. Урамга чыгуга, пешереп, өтеп ала! Чеметкәнен тоеп, йон бияләй белән уып өлгерсәң ярый ла... Сизми дә каласың — борын очың, битең агарып куя... Шуңа күрә каршыга килгән кешене кисәтеп:

— Битеңне у!— дисең. Ашыгып ышкый башлый. Әкренләп кызара — югала ак тап. Соңарсаң, карала... Очрашкан кешеләр бер-берсенең күзгесе — күзәтеп, искәреп тора. Анда да яшьләр шаярта:

— Тешең өшегән!— дип теш агарта. Башта сискәнеп алданасың. Ә бит дөрес тә сыман — теш тә ак. Егет-кызлар суыкта да елмаеша...

Өйдән-өйгә йөгереп үтү түгел, көне буе япан кырда, кискен җилдә лом, кәйлә белән туң чокыйсы... Солдатлар ни барын шинель астыннан кия. Кудряшов ябынып йоклаган одеалын җылы көе җайлап кына өстенә урый. Каешын бугач, ипле була. Лапшинның җиңсез арка җылысы — сырмасы бар. Сәгате җитмичә кырдан җибәрмиләр. Җир казуның, тигәлрәге — чокуның нормасы бар. Кайткач, өшегән авызлар йомшагач, зарланып алалар:

— Ай-һай, җире — таштыр!— ди Кудряшов.

— Бакырчының җире — тимердер, лом астыннан очкын чәчри!— ди Мансуров.

— Киледә кисаптай төя торгач, чикләвек чаклы куба инде...

— Борчак хәтле диген!

Учак ягып эретәләр — күпме генә йомшата — туң бик тирән киткән, үзәккә үтте! Җирнең дә үзәгенә үк үткән инде әллә — башка елларда алай ук булмый иде. Аяк-куллар өшү, салкын тиеп егылулар — күпме кеше имгәнде ул дошмансыз окопларда. Иң зәһәр дошман — салкын иде... Күрмәгәнгә — күрсәтмәсен, күргәнгә күркәм сабырлык бирсен.

Солдатлар белән беррәттән, төрле авыллардан җыелган хатын-кызлар да туң кимерә — таләп бер. Салкынны бергәләп каһәрлиләр дә, фронтны кайгырталар:

— Ничек түзәләр микән анда... Без әле җылы өйгә кайтып авабыз...

Файдалы ягы да табыла:

— Кәкерәйсен әле фашист мәлгунь! Шул кирәк аңа! Таракан кебек катсыннар!

Салкын гел безнең яклы — фашистны гына өшетә икән... Әнә бит, шулай диләр дә:

— «Икенче фронт» шушы инде — салкын безнең союзник!

Җылы җәй — хыял, өмет, тик шикләнү дә бар:

— Җәй көне нимес тагын ыргылыр...

## Журавлев Сталинградка китә...

Күтәренке күңел белән, көлә-елмая кайтып керде, туктаусыз сөйләшә, шаярткан итә, үзе әйберләрен җыештыра. Иптәшләре сүрән, уйга калганнар.

— Кайчан?

— Менә хәзер, җыендым-киттем!

— Кай тирәгә микән?

— Сталинградка, диләр...

Журавлевның фронтка китүе. Мондагы эшләрдән котылам, дип шатлануымы, әллә борчылуын яшерүе...

— Кайнаган су юкмы? — дип сорады, ипи кисәге ашады — юлга чыгасы. Киенде, саубуллашты да, бусагадан атлады. Ачык чырайлы, ихлас егет иде. Тиеш чакта ачуланса да, кайтып төшәр, шаяртып куяр. Миңа ул командир түгел, каш җыерып та карамый, энеседәй күрә. Ияләшенгән, ул киткәч, күңелсез булып калды. Сугыш ерак түгел, менә ничә көннән ул эченә керәчәк. Командир беренче булып бара — исән калырмы? Хатип абыйның ике айдан ук үлгән хәбәре килде... Кичкә таба, әнкәй кайтып кергәч, билгеле инде, яңалыкны әйттем:

— Журавлев сугышка китте. «Апа, спасибо!» — диде.

— Ашадымы соң?

— Ипи ашады. Кайнаган су сорап алды.

— Ә бәрәңге? Мичтә, чуенда... Ник алып бирмәдең?!

— Уйга да килмәгән...

Онытканмын. Әллә каушаудан инде. Мин дә җыенганын карап тордым, иптәшләре белән бергә. Бәрәңге суда гына пешсә дә, калкып күренгәне кызарган, кетердәп тора... Журавлев искә төшә дә, күңелне үкенү тырнап ала: эх, ничек искә килмәгән?

— Үзе дә әйтмәгән инде...— дим әнкәйгә.

— Кеше сугышка китте. Атаң да кемгәдер фатирга керәдер, аны да шулай онытсалар...— дип офтана әнкәй. Тагын да кыенрак булып китә. Сталинградта кайнар бәрәңге буламы әле, юкмы...

Журавлевларның Сталинградка китүе хак икән. Адресны алганнар иде, хатлары гына булмады. Язып өлгермәгәннәрдер... Берәрсе очрамасмы дип, баштарак сораштыра идем, белүче булмады, үзләре дә хәбәр бирмәде. Вәгъдә иткәннәр иде юкса. ДЗОТның үлем уты белән кистереп торганына каршы барган шул алар... Монда өши-туңа әзерләгәне торып калды, кирәк җирдә анысы булмагандыр да әле...

## Кизләү өстендәге ДЗОТ

Бики тауда, кизләү өстендәге ДЗОТның амбразурасы безнең тәрәзәгә туп-туры төбәлгән — күзгә-күз карашып торабыз... Ут сиптерә башласа, җир белән тигезләр бит... Чын бу — уен түгел. Окоп казучы солдатлар, төрле районнардан кубып, туң җирне чокырга килгән йөзләрчә кешеләр дә, берсе дә уен эш түгел...

ДЗОТ бүрәнәләре ничә колачлап та җитмәслек, юан-юаннар, кабыгын каезлап, әрчеп, шомартып, җиренә җиткереп кар өстендә бурадылар. Тирән казылган оясына төшереп утырткач, кайсы бүлемнәргә таш тутырдылар. Өстендә аркылы-торкылы бүрәнәләр әллә ничә кат, катлам-катлам таш-туфрак өеп куелган. Тау биегәя төште, шом ояларды аңа...

Сталинград әзерләткән, ДЗОТның кирәге чыгар, дип исәп тотылган, күз төшкән саен борчып куя... Фронт ерагайган саен куркынычы кими, юашланды ДЗОТлар, ДОТ лар. Ниһаять, язын эчләренә кереп карый алдык, амбразурадан челтәр пәрдәле тәрәзәбез, тамчы гөлнең тамам-тамам дип торган кып-кызыл чәчәкләренә хәтле күренә. Шөкер әле, шундый кайнар тамчылар чәчрәмәде...

— Кирәкмәгән җиргә казыткannар! — дип сүз куертучылар бар.

— Шул хәтле кешене өшетеп-интектереп...— дип тә куялар. Хәзер инде ни сөйләсәң дә була. Теге чакта фашист кая җитәрен кем белгән?

Карлар эреп, җир ачыла төшкәч, без малайлар Каенсар тавына сибелгән блиндажларга «разведкага» киттек. Трофейлар да табыла: лом,

кәйлә, көрәк, носилка... Алары хуҗалыкта ярады — тикмәгә былчыракка чумып йөрдекме. Блиндаж бүрәнәләре дә әкренләп сүтелде, каядыр урнашты. Танкка каршы траншеялар, туннары эреп, читләре ишелә башлады. Кирәксез алар хәзер. Җир тәнендә, ямалып килгән яра сыман, кызыл балчыклы ярлар...

## Сынаулар бетте! Сынаулар алда...

Мәктәп канаты астында, шау-шулы булса да тын почмакта — ваемсыз булганбыз. Нәрсә ул дәрес әзерләү, контроль эштән, сынаудан шүрләү! Шулардан котылдык та, башка — уй, күнелгә борчу керде. Тормыш биргән мәсьәләнең җавабы дәреслек артына язылмаган, укытучы да юк — үзең чишәсе.

Ак келәтне җыештырып, укып-язып утыру өчен элекке прилавкада урын әзерләдем. Язганым: җырлар җыю һәм көндәлеккә: «Бүген көн болытлы, кояшлы» дип теркәп бару. Уйлар-шөбһәләр күңелдә кала. Мәктәп гадәтеме, аерыла алмыйм кәгазьдән — ап-ак билгесезлектән яңалык көтәм. Ни икәнне үзем дә белмим.

Бригадир мин укып бетергәнне бик зарыгып капка төбендә көтте бугай. Ниһаять, дип, әнә, кәлиткәне киереп ачып килеп керде. Елмаюы капкага сыймас, куанычын яшерми ул. Юк-юк, сынауларны «отлично»га биргәнгә түгел, әһә, син минеке хәзер! — дип керә ул. Мәктәп төшкә хәтле иде, төштән соң:

— Зиратлар башына — сабанга!

Аның хәлен дә аңлыйбыз: кеше кирәк, бар эштә безнең ише үсмерләр. Атларны Салихулла белән бергә җиктек. Белмәгәнне ул күрсәтә, камытдирбия, сабан тирәсе минем өчен яңа, әтисенә ияреп колхоз эшенә йөргәннәрдән түгел — элекке кибетче малае. Парлап җиккән атка ике дилбегә кирәкми икән, ялгыша яздым. Аның каравы, үземә бригадир тезгене бик җиткән...

Колхозда төрле эшләр башкардык. Һәрберсенең үз кызыгы, әмәле бар, төшенәсең, җиренә җиткереп эшлисең. Әмма ни хикмәттер, монда үземне вакытлыча хис итәм... Нәрсәгә ышанам, нигә өметләнәм, кая атлыгам? Әткәй кайтыр да, үзгәрер дөнья, дигәнмен — укуым ялганып китәр. Тәкъдирдә бүтәнчәрәк икән — соңгы хаты инде язылган, юлда, килеп ята... Мәктәп сынаулары бала-чага уены булып артта калды. Алда — тормыш сынаулары, сугыш елларының кискен сораулары. Син инде бала түгел, син инде укучы түгел — үз тормышыңны язучы...

## Без менәсе таулар

Җәен дә, кышын да җәяүләп Казанга баргаларга туры килә. Бер әйләнү — ике йөз чакрым. Җәяү дигәч тә, нужа арбасын, йә чанасын тартып барасы. Кич кунмый житеп булмый. Мулла иле тирәсендә бугай, фатирга керәбез. Ярты юл чамасы микән, артыгракмы, «уфалла»ның спидометры юк, кем белсен.

Исең китмәле безнең халык: ике тәгәрмәчле шушы арбага нинди исем тапкан бит! «Уфалла» — зарланып-сыкранып түгел, сер бирмәс җорлык белән әйткән. Юкса, «җиңел арба» гел авыр була, таудан төшкәндә генә әзрәк ял бирә... Кул алмашып әнкәй белән икәү тартабыз. Сизәм, мине күбрәк ял иттермәкче, тик моңа карышырлык көч калмаган...

Җәйге эсседә, тузанлы юлдан көне буе атлыйсың. Бетмәс-төкәнмәс, туйдыргыч юл, аның һәр адымын санап үтәргә кирәк. Алда күренгән Бишбатман тавы һаман якынаймый. «Уфалла»ны кемнәр әйтә, кемдә

хәсрәт — шул әйтә» дип, мөнәҗәт көенә сузып-сузып куя әнкәй. «Уфалла»ны кемнәр тарта, кемдә нужа — шул тарта»,— дим эчтән генә.

Гел моңаеп кына үтелмәгән лә юллар, йөкне җиңеләйтеп көлешеп тә алалар. Сәхнәдә бөтерелеп сөендерер өчен, мөлаем-иркә тавышы белән сайрар өчен яратылган нәзәкәтле яшь укытучы турында сүз булып ала. Бишбатманны беренче күргәч тәмам коелып төшкән:

— Әле бу тауны да менәсеме...— дигән дә Ләбибә, елап җибәргән. Аның бу сүзләрен гел шушында искә алалар. Асыл зат чибәркәйнең хәленә кереп әйтү, «Шулай инде, җанкисәгем, менәргә туры килә, елап тау сөзәкләнмәс»,— дип, үз-үзенә көч биреп алудыр. Без менәсе тауга кем менсен... Аның каравы үтелгән-сүтелгән юлларга биектән сүз салгач, җиңел була!

Ослан тавыннан карагач, хәзер инде Казан балкып-шатланып каршыламый, дөм караңгы ул якта: кала утларын яшерә — дошман күзеннән яшерә...

Шәһәрнең бер тыкрыгында немец танкларын күргәч, имәнеп киттем: чиркангыч тәреләр ыржайган, свастикалы самолет та шунда. Фашист билгесен кәгазьгә төшерергә дә ярамый, ә монда, урамда, ап-ачык ята... Фронттан кайтарылган икән. Тагын бер безнең уттан үтәсе, кызыл йолдызлы танк ясарлар. Урамга ташлау урын юктан түгелдер: күрегез, дошманны җимердек, менә ул аяк астында — танклары, ватык самолеты — канатсыз!

Казанга кышын томанлы-салкын көнне тезелешеп баруыбыз күз алдыма килә. Чана — «уфалла» түгел, үзе шуа, җигелеп тартырга була, кулга тотасы юк. Берең арттан таяк белән этеп килә. Ару-талу белән бергә ачу җыелган, чана да мөгезе белән тез астына сөзеп, йә үкчәгә басып куйса... Бара да бара хатыннар бер-бер артлы. Кәрванга маржалар кушылды, «знакум»нар да калага сәфәр. Урысчалары чамалы булса да, нужа теле уртак, аңлаша әнкәйләр. Йомарлам май, ит бара чанада. Арткannан түгел, җитешмәүдән илтә базарга, балалар авызыннан өзеп илтә — налогка, заемга түлисе...

«Художник булырга монда укыйлар микән?» — дип, зиннәтле бинага галәмәт биек имән ишекләр ачып караган идем дә, чигендем — әйтерсең лә култыклап түргә уздырырга җыеналар... Хыялым исән торсын, ябыйм тизрәк...

Хыялым дигәннән, шул Мулла илендә микән, кайтыр якта фатирга кердек. Мин унөчтә булсам, әйдә сигез яшьләрдәге сабыр, уйчан малай бар. Әниләр сөйләшкәндә аның янында булдым. Китаплар алган идем. Берсен, Кави Нәҗми хикәяләрен, бүләк итеп калдырдым. Соңыннан искә төшеп кызырткан бер гамәл булды: истәлеккә дип яздым. Ниндидер тиле уй: берзаман шушы язуны табарлар әле... Ирешәчәк ниятләр хыялда гәүдәләнә, диләр. Шигырь яза идем микән әле? Әлбәттә инде, ул китап күптән юкка чыккан, абзыйга әверелгән малай да теге очрашуны оныткан. Минем истә — соңыннан оялуым сәбәпчедер... Үз китабымда булмаса да, беренче автограф...

## Аягүрә йоклап йөрүчеләр...

Йокы ястык теләми, без идек ул аягүрә йоклап йөрүчеләр. Тәкатең калмагач, нишлисең... Пар ат белән сөрелгән җирдән барам. Тырма тешләренә үлән җыелып әвәләнә башлаганчы, йә постромка бавы өзелгәнче, кантарга абынып чабата башы чыкканчы атлыйсын да атлыйсың. Әле таң сызылып кына килә, уянып җитмәгән кырлар томанюрган астында талып-изрәп черем итә... Ә син аяк өстендә, ерак басуга килгәнсең, кулыңда әллә ничә ялгаулы-төенле дилбегә. Салмак кына, бер җайга киләсең, дилбегәң тартылыбрак торуын тоясың... Бушамаган, димәк, барасың, йокласаң сиздерә ул дил-бе-гә, дил-дил-бе... Менә шул

арада күзләрең йомылып — йоклап аласың! Чеметемләп-чеметемләп электерәсең, җыясың черемне. Йокы мичкәсе булганга түгел, мичкә бушаганга... Бу арада төнге сменага йөрелде, көндезен дә килә бригадир: кеше җитми, безгә кушмый, кемгә барсын? Йокы ул кинәт, авыр капчыктай баса, күз алларың йомшак кына томаланып кала... Бер йокың өч-дүрт адым буладыр инде. Мохтаҗның йокы ямаулыклары... Өзек-төзек «тырмалап» җыйган йокылар берәр чакрым җыеладыр әле... Ча-кы-рым, ча-ча... Тагын күз йомылган!

Аяк өсте йокларга да осталык кирәк. Авыз ачып йөрсәң, беттем диген. Йөзләгән тешле тырма, артын уйната-уйната, кантарлар өстеннән сикергәли, аягыңа төшүе — котырган эттәй батырып алып җир буйлап өстерәп китүе бар. Кантар канга буялган чаклар да булмады түгел. Атлар бик ажгырып тормый анысы, туктау дигәндә сизгерләр. Алар да төнге сменадан кайткан, эчләре-эчкә ябышкан, гыжлап сулаганда кабыргалары гармун күрегедәй йөри... Алар да барган уңайга черем итеп ала: парлап җигелгән, алмаш-тилмәш уңайрактыр ул.

Йокласаң да күзең ачык булсын. Әнә беркөн мин эшли торган кишәрлек башында икәү көтә. Ерактан таныйм, берсе — укытучыбыз, теге... кызның әтисе! Каушый калдым. Икенчесе — сыйфат комиссиясе Афзал абый:

— Тырма тешләрен чистарта тор! Җыелган чүпне җир башына тарттыр!

Укытучым исә бүтән сыйфатка игътибар итте. Кулын җилкәмә салды да, умыртканы санагандай бармакларын йөгертеп үтте:

— Егет кеше — сер бирмәскә тиеш!

Яклап әйтүе булдымы, шыр сөяктән көлебрәкме? Ни уйларга да белмәдем. Алар киткәч, җилкәмне капмалап карыйм — ябык шул, кычыткан суы эчеп ни... Егет кәмәше. Хәер, унбишенче яшь лә!

«Аягүрә йоклап йөри», — дип, оешмаган, уңмаганга әйтәләр. Без оешкан идек, уңган — кояшта янган идек, йоклавыбыз да — тырышлыктан! Аннары, гел аягүрә йокламый идек. Иң рәхәте, тәмлесе атка атланып барганда. Бер җайга тирбәлеп, оеп кына киләсең... Тәнең бишектәге чагын тансыклаган, шуңа татлыдыр бу йокы... Ат сырты ястык түгел инде, әлбәттә, палас җәйгән сәке дә түгел — сырт кылычы киндер талкыгычтай каезлый, туный — синең сөякләр дә үткенлектә калышмый бит... Аптырагач ян белән атланып карыйсың, ничек кенә боргаланмыйсың — кая юньле йокы! Атның камыты сугып, муены-түше чи иткә калса, ат сырты синең «утыргыч»ка суга. Бер дә көлке түгел, бәла ул — ерак басуларга ат җитәкләп җәяү йөреп булмый лабаса, кичкә таба аяк атларлык хәл калмый болай да...

Йокы, йокы, йокы... Безнең хыялларның берсе иде... «Тәмле йокылар йокладым сабый чакларда гына», — дип, ни икәнен белмәгән, бүселеп йокы симерткән чакта җырлаганбыз. Ә хәзер... төш күреп тә өлгермисең, төшсез безнең йокылар — күз ачып йомган арада төш ярылып өлгерәме... Әнә, ерак басудан кайтып, атны кәнүшнигә илтеп, өйгә ирешкәнче төн куерган. Мендәргә башны төрттем генә, ул ара да булмый, әнкәй уята:

— Тор, бәбкәм, тор... Әнә, Ситдыйк Рифкате кәнүшнигә китте!

Әллә бу Рифкатнең йокысы килми микән? Мин кайтып җиткәч тә әле аның тау «тарттырасы» бар... Ашау белән йокы икесе бер чама — такытоты инде. Фронттан кайтканнар сөйли: анда да шулай көне-төне поход барганда солдатлар аягүрә йоклый, ди. Безнең сыман... Ә бит үзебез дә солдатлар сыман икән!

### «Икенче фронт»

Кулындагы гәҗитне селкә-селкә, Харис шалашлар арасына йөгереп төште:

— Малайлар, сугыш туктаган! Менә, монда язганнар, тыңлагыз...

Сүзләрен йота-йота, ашыгып-кайнарланып сөйли. Берсеннән-берсе уздырып шап та шоп биешкән бәләкләр тынып калды, кызып эшләгән малайлар шалаштан атылып чыкты. Харис район газетасына төртеп-төртеп күрсәтә:

— Менә, менә — Коминтерн таратылган!

— Сугыш туктаган, дидең бит?

— Туктый инде, болай булгач! Партия беткәч, Гитлер сугышны туктата!

— Партия бетә, димәгән ич?

— Коминтерн беткәч, партия дә калмас...

Харис мавыгучан, шәрран ярып сөйли... Куркыныч сүзләр әйтә, ничек инде ВКП(б) бетсен ди? Аннары ни була... Ай-һай, шулай ук микән? Җыйнаулашып кат-кат укысак та, җиде класслы баш җитмәде төбенә төшәргә...

— Гитлерны алдар өчен Сталин хәйләседер?

— Америка, Англия «икенче фронт» ачсын диптер?

— Ачылды инде «икенче фронт», тылда ачылды — кырыла халык ачтан...

Бусы инде аптыраганнан гаҗиз, кәтә-кәтә кәтек булгач, союзникларга үпкәләп әйтелә. Инде 1943 ел, «икенче фронт» ачылса менә, сугыш та бетәр иде...

Шалашларга таралдык, коры куаныч булып чыкты Харис хәбәре. Гомергә шул — кабынып да абынып.

Бу хакта оныткан идем. Элегрәк булса, онытмасам да язмаган булыр идем, сабакташның исемен әйтмәс идем... Харис хәбәре расланасы гәҗит ярты гасырдан соң киләсе икән — партиянең эше бетте. Гитлер да, Сталин да, хәтта Харис авылдаш та юк инде... Ә сугышның яңалары кабынып тора, сугышлар тукталмый әле. Ил эчендә «икенче» генә түгел, әллә ничәнче фронтлар — сугыш утлары кабынып-кабынып йөрәкләрне пешергән, җаннарны кыйган болгавыр еллар бу...

## Атның да паспорты бар...

Ел азагында колхозда инвентарь барлау үткәрелә. 1943 елның декабрендә, хисапчы буларак, мин дә катнаштым. Салкын, ә ялан кул язарга кирәк: арба-чана абзар-кура тирәсендә, сабан-тырмалар да карга күмелеп ята, камыт-дирбия келәттә. Бары шул инде: ватылып-җимерелеп, таланып-тетелеп беткән... Барлау вакытында белеп шаклар каттым: атның паспорты бар икән! Кушаматы, төсе, туган елы язылган. Бездә булса иде! Койрык бозга каткан шул — паспортлы атны паспортсызлар җигеп йөри...

Атларның да хәле мөшкел. Иртән кәнүшнигә төшкәч, күтәрәмгә калганнарны бергәләп аякка бастырабыз. Аякландыра барасың — ава торалар... Яңадан күтәр: корсак астыннан ике дилбегә үткәреп — дүрт малай, бишенчең — койрыкка... Ябык булса да — авыр сөяк, койрыклар шытырдый. Бастыргач, кузгалып китәләр тагын. Чәчүлек төяп кырга чыгасың, сабанга җигәсең. Ерак басуда егылса, күтәрешер кеше килгәнне көтеп аласың...

Арык инде атлар, бот сөякләре тырпаеп тора — дилбегәне салып йөрерлек. «Дядюшкин» кушаматлысы бигрәк шыр. Харис белән алмашлап җигәбез, «дилбегә элгеч» дип шаяртабыз, үзебезнең иңнәр ни элерлектер... Әмма нәрәт куа — чыбыркы белән куа. Солы белән куасын беләбез дә... Харис бер көнне чыгымчылаган атын кузгата алмагач:

— Колагын чәйнәдем... — ди, аптыраганнан көлеп. Кирелектән түгел, хәлсезлектән инде бахбай. Ниләр генә күрми ир егеткәй белән ат ба-

шы! — Постромка баулары кырык төенле, өзелгән саен койрыктан кыл йолкы... Элек урамда уйнаганда: «Ат койрыгында нәрсә?» — дип сорыйлар да, «Аллаһеәкбәр — дога кыл!» — дип, әйберенне кесәгә салалар иде. Инде атлар үзләре аллаһеәкбәр...

Кайда ул юртакларның сабантуй, кушкапкада җилдән житез очкан дөлдел чаклары! Эре сөякле, нәселлесенең янбашына «РККА» дип тимер кыздырып басылган, алар фронтка озатылды. Күтәрәмгә калганнан ни җәбәлә... Сәламәт ат гомер буе аяк өсте, аунап-пошкырып буыннарын гына язып ала. Авыру малкай гына ята. Җигәргә килгән атың тоякларын як-якка ташлап катып калган чаклар да булгалый тора...

Ат башы өчен үз башың белән җавап бирәсең — кайсы кадерлерәктер әле дәүләт каршында... Колхоз малы дигәндә закон каты: төрмәдән — расстрелга хәтле. Үлгән атны Чирмешәннән ветврач килеп акт төзегәнче саклап торалар. Ветсанитар Гарифулла абый — Харисның әтисе, атның башын, йөрәген алып өлгерергә тиеш — үлгәнлеккә дәлил... Ачлыктан шешенгәннәр урап алган, тын гына көтәләр. Чормадагы чабагач бауларына чаклы пешереп ашалган... «Минингит» дигән баш авыруы таралды. «Ат кайгырсын, атның башы зур», — дип шаярткалны беләм, аның да башы авырта икән...

Ат итенә өмет баглап торучылар янында Миңнулла абый да күзгә чалынды кебек. Ябыккач, тагын да озынрак, чайкалып, түнеп күләгәдәй тора. Карарга килде микән? Сәмруг кошка атланып очканда, диңгез өстендә хәлсезләнә башлагач, бот итен кисеп биргән баһадир турында әкият сөйләгәне бар. Куркыныч иде әкият, имәнгеч иде, чынлык тагын да хәтәррәк...

Йогышлы авырудан үлгән атны, әле суынып та житмәгән көе, тизрәк авылдан ерактагы үләт чокырына илтеп күмәргә куштылар. Нәрәтне үтәргә Корбангали белән киттек. Көн кичкә авышты, тирән итеп чокыр казыдык, үлчәп-чамалап карадык, авыл малае аны гына белә. Арбаны якын китереп, икәүләп атны төшерү әмәлен таптык. Тик менә күмеп бетергәндә... сеңерләре язылып, аяклары җир өстенә калкып чыкты. Нишләргә? Чокырны тирәнәйтергә соң инде. Беребез тоягыннан баса, икенчебез балчык көе. Булды. Кайтырга борылдык. Әйләнеп карасам, атның аяклары әкрен генә күтәрелә, тоягындагы балчыклары коела... Әйтерсең лә, йөреп бетермәдем әле, дип торып басарга җыена. Бер-беребезгә караштык та, урман буендагы эңгер-меңгер кырдан авылга ашыктык. Паспортсыз инде, малкай, син дә хәзер — беркая китә алмассың...

Корбангали сугышка алынды, гаскәр паспорты — хәрби билет. Кеч-кенәрәк буйлы, үзе елмаеп, шадралары көлеп торган, кай чакларда яшь әтәчтәй кабынып та куючан, мәзәкчән егет иде. Хат-хәбәре килеп торды, элемтәдә, ут астында чая йөри дип, ординарецы турында командиры язган, батырлыгы өчен әллә ничә орден биргәннәр. Бу яңалыкка сөенеп йөргәндә үлгән хәбәре килде... Биле авыртып, бөкерәеп калган әнисе тагын да сеңә төште. Корбангали... Язмышы исемендә булганмы? Бер оч малайлары идек, ике яшь кенә аермабыз. Сугыш вакытында бу да күп — бәрәү ут сызыгында, бәрәү яшәү ягында... Энесе Әкрәметдин белән без Корбангали атларын җигеп сукага йөрибез.

Ат дигәндә, әткәй колхозга житәкләп төшкән алмачуарны әйтми кала алмыйм. Колхозда атларны элекке хуҗасы исеме белән йөртәләр:

— Әнә, «Гали» белән «Ярхәм»не җигәрсең! — дип, нәрәттә атап әйтелә, болар авыр йөк тарта торган эшкә йөри.

Җизни үзенең «Ярхәм»ен туксанынчы елда да искә ала:

— Нәселле иде. Читкә китеп эшли башлагач та, кулга кергән беренче акчаны әтигә җибәрдем, әйбәт тарантас, дирбия ал, дип. Ул чакта тарантас хәзерге машина кебек абруйлы иде!

Ике улы «Жигули» белән кайткан, үзенеке — Рәшитнеке ишегалдында, ә ул авылның беренче шоферы, тарантасын сагына! Ир-егетнең күңелендә иярләнгән ат ятар, дигәннәре шулдыр...

«Гали»не күргән саен, «безнеке» дип, горурланам: ни житте түгел лә! Әмма атыбыз мине танымый... Малайлар алдында борылып бер кешнәп куйса ни була! Суырылып колхоз йөген тарта, иялəшмəгəн ул миңа: улагына солы салып, ялын тигәнәктән аралап, сызгырып су эчерсәң, белер иде. Мин кечкенә чакта илткәннәр кәнүшнигә. Хәзер аны көн саен бер кеше җигә, куалый...

Бүтән атлар күтәрәм чакта да күпердән такыр-токыр тояк тавышлары тәгәрәтеп үткән алмачуарым әле дә күз алдымда. Ачлык күперен ул да үтә алмады. Бу «Гали» дә сугыш корбаны... Шул ук елны әткәйнең соңгы хаты килде... Корбан Галиләр, Корбангалиләр, исемнәре төрлерәк булса да, язмыш бер...

Паспорт алыр яшь җитте, тормыш безнең җилкәдә, без тартасы дөнья йөген. Колхозда йөз төрле эш көтә — фронт икмәк сорый. Хыяллар, өметләр күңел тулы. Паспорт кына юк. Китәргә акылы булса, атларга да тәтемәс иде ул...

...Ат дигән ветеранның да кирәге бетте, сугыштан соң батыр — кадерсез... Нужа йөген бергә тарткан юлдашларны сагынам, юксынам. Район газетасында «Ат югалды» дигән белдерү күрсәм, соңгы малкайлар да баш ташлап китте микән, дип торам. Паспорт та бар, инде игътибар юк... Бәлкем, нәкъ менә шуңа — бәгырь кырысланганга заманасы күтәрәмгә калгандыр... Тагын без күтәрәсе.

## Сайламаган саз...

Фәкыйрьлек кимсетә, миңгерәтә, кешеләрдән читләштерә. Тормыш — ормыш, кырыс, авыл — тырыш, гайрәтле нәсел нигезен дә файдалы җиргә кора, йомшак-җебегәнгә кайтышрак урын кала... Шәпине дә чогырчак сазламыгына кысканнар. Бәрәңге бакчасын су басканга мантый алмый диләр дә, дәртсез, үз хәленә күнеккән ул, язмыш хөкеме белән килешкән. Хәерчегә җил генә түгел, су да каршы — язгы ташу, җәйге яңгырлар үзәк чокырыннан төшеп үзәккә үтә. Ялангач тәнгә эт талагандай иске тун элгән абзый җылына алмый интеккән. Исеме дә таланган — Шәфигулладан Шәпи калган. Чәпәгәннәр «Шәпи»не, хәллерәк агайга базмаслар иде. Сазга гына түгел, балага да «баткан». Бөтенләй ялкау түгел икән үзе... Мохтаҗлык баткагыннан кем йолып алыр?

Чирмешән агымы белән түбәндәрәк, Тәкәрлек сазлыгына Сабирҗан абый нигезе баткан. Буразнасында җәен дә су, яралган бәрәңгесе дә чери. Елның елында шулай, миңгерәми хәлең юк — таяныр җирең саз... Ходай тәгалә күк капусы ачып бәхет яудырса гына. Ә бит иң якын бәндәсе булырак, иң әүвәл Сабирҗанга иңәр иде могҗиза. Мулла абзыең да тартә арасына кереп, саваплы «уфалла»ны бисмилла әйтеп иплe-тәртипле генә тарткан заманда Сабирҗан фани дөньяви шөгыльгә вакыт сарыф кылмас, бар уе, бар гамәле, вәгазе — ахирәт булыр... Күзләр шар ачык, тыңлаучысын да күрмәс — күккә текәлгән, мәңгелеккә. Сирәк тешләр арасыннан шарлавыктай сүз коела. Кайчан күрсәң дә шундый хәлдә, куллар күкрәктә — көрәктә түгел. Әкәмәтрәк алла бәндәсе, диебрәк карыйлар аңа. Дөньяда гаме булмагач, тамагына ни каба, нинди тәгам җыядыр? Үзе изге зат булды ди, нужа кимсеткән сабыр Сабирасы, балалары бар... Ходай тәгалә авырлыкны яраткан бәндәмә бирермен дигән-диюен...

Малае Вәяскарнәй белән беренче класска йөрибез. Укырга хирыс түгел, әтисе күбрәк үз сабагына тарткан. Бер көнне укытучысы Сылу апа килә:

— Авырый мәллә? Ник укырга йөрми, малаегыз кайда?

Сабирҗан абый ирендә әвәләгән догасын бүлми генә, тәсбихын сынар кулы белән тарткан көе кисәү ала, мич янына килә. Кәҗә бәрәннәре ябa торган куышлыкка кисәүне сузып, мичтән күмер тарткандай:

— Әгузебилләһи минәшәйтанирражим, чык, Вәяскарнәй, алла боерса! — ди. Малай, укытучы килгәнне шәйләп, чарасын күреп өлгергән икән. Арты белән чигенеп чыга, тик аны укытучылар әкияттәге шалкан кебек тартсалар да икенче класска чыгара алмадылар. Барлы-юклы сәләмәсе белән мәктәптә күренәсе килмидер, шелтә ишеткән җиргә кем атлыгып торсын.

Тәкәрлек, Чогырчак — нужа сазлыгыннан кем коткарыр дигәндә, кайгыртучы бар, совет влачы вербовщик булып кулын суза:

— Яңа җиргә күчеп китегез! Юлын түлибез, сыер бирербез, йорт салырсыз! — дип кызыктыра. Кай якка булса да «Яңа җир» диләр. Тагын яңа җир ачканнар, кеше кирәктер, дип беләбез. Анда нишләр микән болар? Вербовщик-яучының да планы бар, аяк урынына тояк, сан булсын да җан булсын. Күчерергә дә ансат — буш тагарак җиңелрәк... Иң тырышларын, кулак тамгасы сугып, буяулы йортларыннан бушлай гына сөргәннәр инде я ң а  җ и р г ә...

Килә дә китә җиңел аяклы-җиңел куллы вербовщик, авылдан гел суыра да тора. Каерып алган азау тештәй, йорт урыннары актарылып кала... Нужа таратты татарны. Нужа-вербовщик, налог-нужа белән дәүләт үзе таратты. «Нинди иркен минем туган илем»нең барлык почмакларына сипте — милләт ирегенең чиреге генә туган җирдә...

Тәкәрлектә бер бакча урыны буш калды: тирәли тоткан рәшәткәсен сатып киттеләр — юллык бәрәңге булыр... Очсыз-кырыйсыз шпал-рәшәткәләр узып ничек барып ирештеләр микән, югалып-таралып бетмәделәрме? Ишеттек, шөкер, әле күптән түгел, кызымы, малаемы, Себер ягыннан авыл советына хат язган: нәсел-ырудан кемнәр исән, дип сораган, хәтер өзелмәгән икән әле.

Үз сазлыгыннан арынсаң да, чит җиргә «батып» каласың — бер киткән кайта алмый шул, туган якка юллаучы яучылар күренми, анысын оештырмыйлар. Шулай да кайткалыйлар. Сугыштан соң Гыйльфан абый Үзбәкстаннан күченеп, нәкъ шул тәкәрлек сазлыгын сайлап утырды. Көлде авыл халкы:

— Сусыз якта сазга сусагандыр!

— Укымышлы кеше, укытучы — үз ихтыяры белән лычма суга нигез сала...

— Аннан бит җиде җир читенә качалар!

Авыл советы персидәтеле Солтан да:

— Бакалар оясына килеп утырдың, Хафизов! — дип кисәтә. Гыйльфан җирдә казынуын белә:

— Син килерсең әле кыш көне кыяр сорап! — ди, кыяр-кыймас сөйләшми, тавышы көр чыга. Авыл Солтаны да үзенчә акыл бирә бит:

— Ә син авыл советына килерсең: мондагылар җылап йөрде, бүтән пажма бир, бәрәңге чери, дип. Минем әйтүем булсын!

Үзбәкстан кояшында янган-ысланган, кипкән җимештәй Гыйльфан үзсүзле булып чыкты. Кырпы бөреген маңгайдан этәреп, кәс каезлый. Афзал хәзрәт бажасы, Коръән сүзен дә яхшы белә, заман китапларын да. Үзе һаман сазлыгында чокчына. Үзбәктәгечә арыклар ерып бакча башыннан аккан Дымбылат кизләвеннән... су үткәрде, дөге чәчәргә исәбе...

— Саташкан мәллә?! — дип, бот чапканнар иде дә, телне тешләрлек булды. Кыяр, помидор, шалкан гына түгел, кавын-карбыз тәгәрәп үсте дә пеште, карлыганны әйткән дә юк. Ә бер көзне Гыйльфан каракүл бөреген маңгаеннан этәреп алма тешли иде. Солтан авылдаш та, бүтәннәр дә сорап килерлек, алып китәрлек булды. Ходайның рәхмәте, сазлык та бирешер икән! Сабирҗанның күктән ялварганы кабул булдымы, Гыйльфанның баш күтәрми эшләвеме...

Еракларга таралган татар ят зиратларда күмелеп кала... Милли рухны саклый алган кайнар йөрәкләр анда да тырышыр — татар югалмас. Мал-мөлкәтле булыр, иман гына сау булсын. Сазлыкның иң яманы шул — рухсызлык йота...

Татар язмышы «мөһаҗир» дигән бер сүз белән билгеләнә иде — башка җиргә, чит илгә күчүчеләр дип. Дөньялар болгана, бәхетсезлек илдән куса, илгә дә куа икән — агым туган якка борылды — татар язмышына да «качаклар» дигән куркыныч сүз кагылды. Кайта качаклар «Татарстан» дигән кочакка. Бәхет эзләп нинди «Яңа җир»гә китсәң дә, «иске җир»дән — ата-бабаң җиреннән генә табасың икән аны...

## Яшьлектән качалармы...

Эңгер-меңгер чак иде. Габдулла капка баганасы янына килде дә, тыпырдый башлады, кулларын биленә куеп чүгәләп тә ала.

— Ни кыланасың, яшьти?

— Биергә өйрәнәм...

Багана каршында биесәң, тизрәк өйрәнәсең икән. Синнән булмый, мин булдырам, дип үртәү, аңардан уздыру микәнни?

— Әйдә, син дә...— ди Габдулла, сулышы кабып.

Бер дә андый теләгем юк. Ә ул, тырыша торгач, тәки рәтен китерә. Бүтән иптәшләр дә бии белә, кай арада өйрәнгәннәр? Әйтәм аны, багана тирәсе такырайган... Һәркем үзенчә бии — «өйрәтүче» баганалар төрле булгандыр... Борый Әгъзәмы уртага чыкса, көләсе килә. Бик тә җитди кәперәеп, кулларын картлар сыман артка куя да, борып җибәргән уенчыктай зырылдап әйләнеп тәпәнләп китә! Менә-менә сөртенеп егылыр кук, аумый — тиз йөргәнгәдер. Кыяфәте дә мәзәк: елмаеп ерылган иреннәр юкарып кысылган, кызарган тәкәббер борын югары чөелгән! Биюченең аяклары хуҗасы турында сөйлидер. Бар инде, бар Әгъзәмда чытыклык-мактанчыклык, әнә бит, куен дәфтәрендәге исемлекне яшерми дә, сөйгән кызларын исәпләп бара!

— Урамда сөйләшеп торган бер кызны теркәп куя хисапчыбыз! — диләр шунда эләккән кызлар.

Биюдә холык чагыла шул, әнә Габдулла сабыр гына, нәкъ урынында китереп басар, эреләнмәс, вакланмас та — ничек бар шулай, ис китәрергә ниятләнмәс.

Мин дә тикшергән булам, ә соң үзем? Һәркем үзенчә кыландыра, мин генә баганадай. Тораташ аяклар холкымны күрсәтә: кыюсыз, оялчан, ди... Дуслардан читләшә барам бугай, китапларың белән калмагаең... Бер кичне Салих белән Габдулла, Әкраметдин кереп, китаплардан аерды. Юк, сөйләшеп утырырга килмәгән болар:

— Әйдә, киттек!

— Кая? — дигән булам, беләм инде...

— Кызлар янына!

Коелып төштем. Сизенә идем бу көннең бер җитәсен, биергә өйрәнү — шуңа репетиция икәнен. Ә минем анда барасым килми. Таныш кызлар үзе, бергә җыелгач тартынам. Шаярып, телгә үткенләнеп китәләр. Ни сәбәп тапсам таптым, чыкмадым. Китап кызыгын да алып киттеләр: иртәгә ничек калырмын?

Иртәгә җитте. Укыган китабым белән мавыктырмакчы булдым, тыңладылар, тик максатлары бер:

— Бүген сине дә алып чыгабыз!

Заемга яздырган шикелле кысрыклый болар — мәҗбүри кубарып алдылар өстәл артыннан...

— Бүген кемнәрдә кызлар җыела? — дип белешкәч, киттеләр югарочка. Тәрәзәдән бик ымсынып карыйлар — юк икән. Минем бәхет! Икенчесендә ике әби йон яза... Киттеләр арттагы урамга. Бер ызбада тәрәзәләр яктыра. Кызлар җыелган... Иң соңыннан, болдырга посып калыйммы дигәндә, игътибарлы дуслар җиңнән тартты.

Өйгә кердек, сәке йөзлегенә кызлар тезелешкән, эскәмияләрдә — без. Зыр-зыр Зәлидә — ничек башлары әйләнеп егылмыйлар? Бу миңа турникта әйләнү сыман бер сынау. Чиратың житкәч, нишләмәк кирәк, бер буталып чыктым. Кагылгалап-сугылгалап булса да туктый да алдым... Әшмени бу! Түгәрәкле уен, «моржа ябарга» чыгулар. «Жәза» дигәнен малайлар бик теләп үти — күтәп кенә торалар. Минем өчен генә чын жәза. Ничек инде кем туры килә шуның белән, нәүбәт өчен генә «сандугач сайратырга»? Караңгы чоланга чыккач, шулай тиештер дип, кармаланып таптым да, колакмы-борынмы ялап кердем шунда. Ишеткәнемчә, йоласын үтим...

Тәмәке тартучылар тәнәфескә кузгалгач, ашыгып мин дә иярдем. Керергә дә атлыкмыйм. Йолдызлар күзәткән булып тордым да әкрен генә сыздым. Куа чыгучы күренмәде... Әй, рәхәт булып калды шушы котылу! Айлы төн нинди матур — менә кайда ул чын аулак. Ник шул хәтле егет-кыз жыелырга, сиңа бит берәү генә кирәк... Шушы төндә аның белән икәүләп йөрсәң иде! Миңа хыялый дөньям татлырак. Мәшәкатьсез дә, монысында мин кыюрак...

Төн урталары узган иде, әнкәй тастымал ябып чүлмәктә аш калдырган — улы «кызлар яныннан» кайткан төшкә. Тиеш иде микән качкынга бәрәңге шулпасы, әмма карын ачкан — «төнге смена»дан кайткан ла...

Иртәгәсен дуслар тагын керде:

— Кая югалдың? Ник иртә киттең?

Бүген ычкынуы читенрәк булыр... Юк, кызыгын таба алмадым кичке уеннарның, һаман шул бер зыр-зыр:

— Әлләләлем, Зәлидә,

Гөлләләдем, Зәлидә...

Авылда андый исем юк, кайдадыр бардыр, кем икән ул? Гел биергә ярата микән? Мине каушаткан исем бүтән... Яшерен мәхәббәтем иясен бер-ике тапкыр күреп тә калдым: ул да әйләнә, сөйләшә егетләр белән. Әле ярый «жәзага» туры килмәде. Кинәнеп бәйрәм иткәннәр арасында ялгыз «багана» мин — тартынуым әкияттәге сихерле көч сыман кыршаулап-тыеп тора...

«Кайчан үтәр аулак өйгә йөрүләр...» — дип интегәм. «Яшьлек» диләр, үтәр диләр, үтсен иде әле... Мин дә ул жырларны жыям, кыю яшьтиләр мәхәббәт мажараларын сөйли, исемнәрен әйтеп уртаклаша — миннән мәңге булмас. Яшьлек миңа йөк икән ләбаса, өнәмәгән мәшәкать икән... «Кайчан үтәр...» дигәнрәк уй тумады микән әле аптыраган башымда? Гажәп тә түгел, читен хәлдән тизрәк котыласы килә ул...

Безнең яшьлекне сугыш көйдерде. Бар кадәресен дә юньләп тоя алмадым, бусына үзем дә гаепле. Күңелдәге шигърият юанычы алдагандыр, илһамым — мәхәббәтне алыштыргандыр? Әллә аклану эзлимме? Барыбер шигърияткә рәхмәт. Яшьлегем гомер фасылыдай үтмәде, чак кына соңрак, әмма озак чәчәк атты ул. Биергә өйрәнү, дусларга ияру дә, күп кызлар жыелу да кирәкми икән... Яшьлектән качалармы? Үз йөрәгеңнән качып буламы — ул бит хыялын-парын эзли...

Аулак өйләрдәге бер уен искә төшә: «Алдым чыбык, киттем чыгып, бара-бара барып кердем фәләннәргә...» дип башлыйлар да, яраткан исемне әйтәләр... Уенның чыны миндә үзгәрәк булды: алдым каләм, яздым шигырь, киттем чыгып, бара-бара барып кердем мәхәббәт иленә! Аның стихиясе, ирәге, илһамыннан аерылмаска дип кердем...

Ә яшьлегем, жил-жил килеп әйләнә-әйләнә биен, миңа тәкәббер елмаеп һәм кызганып карый-карый, еракта калды... Зәлидә дигән серле исем — яшьлегем икән, менә кем булган ул Зәлидә... Шул көйгә бөтерелеп баш әйләнсә, икенче якка борылып, бию бөтерчеген «сүтәләр» иде. Гомердә алай булмый — язмышка уралган елларга кире кайта

алмыйсың: мин яшьлектән түгел, яшьлек миннән качкан. Әлләләмем, яшьлегем, гөлләләлем, яшьлегем...

## Тәртә арасына җигелеп

Атлар аз, соңгы чиккә җитеп бетәшкән... Колхоз үгезләрен, хуҗалык сыерларын җигәргә фәрман булды. Мөгезлегә ат камыты ярамый, үзгә кирәк. Җигеп караган кеше юк, баш бирәме әле калын муен? Рыдванга көлтә төяп кайтканда, күпергә житкәч, су күргән үгез шунда каера. Дилбегәне кулга урап, аяк терәп тарткан таза егет тә тыя алмый — ярдан тупма-туры төшеп тә баскан. Бүселгәнче эчкәч, икенче яктан менеп тә киткән. Көлтәләр коелган, таралганмы — анда йомышы юк. Сыер дуласа аттан яман, диләр, үгездән берсе дә уздыра алмый. Сыер күндәм малкай, аның җелеген суырып — савып та хәлен алганнар. Ятсынып тәртә арасыннан чыгып кына аптырата: ат урынына ялгыш бастым, дидер. Ат урынына, һәм дөрес иде. Буш буй йөреп күнеккән үгез моны авторитетына кизәнү дип бәяләде булса кирәк...

— Көч та бар икән шайтанда! — дип сөйли үгез җиккән егет, акланган сыман. Авыр төйи башлагач, алар да сабырланды.

— Гайрәтең шиңәр, юашланасың ул җигә башласалар! — дип көлә чая хатыннар, мөгез җитмәстәй җиргәрәк басып. Ә сыер дигәч, үзләре дә тынып кала. Өметең-ышанычың шул инде — арбага, сабанга җик... Еланнан яман сугыш аждаһасы — тылны да канга чыгарып имә, бернинди им дә юк...

Һәркем үз сыерын җигеп эшкә йөри. Кәрван тезелеп, Каратун станциясенә икмәк илтәбез. Олауларда хатын-кыз, дилбегә тотканнар. Камыт баулары шартлап өзелү, чәкүшкә төшеп көпчәк чыгу, башка мәшәкатьләр үтеп, тимер юлда тукталдык. Капчыкларны өсте ачык вагонга менгезеп бушатасы. Атынып-тирбәлеп торган басмадан хатын-кыз менәме, менә аламы? Күрүгә, кулларын селкә-селкә чигенәләр:

— Гомергә менәсем юк! Башым әйләнә, аягым тотмый... Терәп атсалар да булмый! Нанаыкаем, берочтан безнекен дә бушатып куй инде! — диләр. Мәрьямзифа аптыйлар капчык өстендә утырып төшәргә генә, әлбәттә, без төйисе-бушатасы. Арттан тезелгән бүтән колхоз олаулары да ашыктыра:

— Тизрәк, җәһәтрәк! Көттермәгез!

Капчыкны арба читенә китерәсең дә, җилкәңә аударып иплап кенә атлыйсың — бер кунаклагач, бара ул җай гына. Тар басмадан вагон өстенә күтәрелү беренче әле... Сер бирдем юк, апалар янында кызлар да бар... Чү, такта авыр йөктән сыгылып-тирбәлеп уйный... Калку-бату җаена атламасаң, ияр күрмәгән җайдактай капчыгың-нием белән чөя дә ташлый... Уртак агымда — бүтәннәр булдырганны, син дә калышмыйсың. Комбайн бункерыннан барган уңайга олавыңа капчыклар төяү дә булмастай күк иде, булды бит әле.

Сыерлар да тәртә арасына ияләште, колхоз эшеннән кайткач, үз сукасына җигелде. Сугыш барыбызны да җикте. Хатыннар, кызлар бергә сука тартып, бәрәңге утыртабыз. Кулалмаш — һәркайсының казылган бакчасы көтә. Бергәләп күңелле. Уен-көлке, бер-береңне үртәү-шаяру, иһаһай да миһаһай! Көлү дә шул, атка охшатып кешнәү дә. Ипле генә бер тол хатын, тәртә арасына кергән дә, мәзәк ясап, аягы белән гайрәтле айгырдай җир тырнап, «кешнәп» җибәрә. Кинаясе бик аңлашыла: атны сагынган, картын сагынган...

Йомшак җылы туфракка яланаяк бата-бата барганда, кызларга караштырып алганда, дәрте-җегәре белән безнең яшьлек җигелгән иде. Бүтәннәрен хәтерләмим, ә менә шомырт кара күзләр бигрәк текәлеп, елмаеп, нидер әйтмәк була, ымсындыра... Әйтмәде, күзләр сөйләште... Сүзсез дә

аңладым, ул да төшенде. Ул күзләр, туфракта басып торган яланаяклы кыз әле дә керфек какмыйча текәлеп тора... Мин карашларымны читкә алдым: кеше алдында шул хәтле ачыктан-ачык «сөйләшергә» ярыймы — хәзер аңлап алалар ич...

## Саламда электр буламы?

Сөләйман абыйның чибәр, чая кызына өйләнеп куйды бригадирыбыз. Хәсән абыйның болай да ерык авызы яңа бер канәгатьләнү белән җәелергә генә тора. Күз тимәсен, пар килгәннәр: бер-беренә карашып, елмаешып кына йөриләр, кеше алдында да тыела алмыйлар. Кавышуны хупламаган кеше юктыр, аулак өйләрдә ахирәтләре бәхетләренә сөенеп:

— Әлинур, гөлинур,
Хәсәннекс Бибинур!

— дип, такмак әйтеп зәлидә әйләнәләр, чыркылдашалар. Кызыгу да юк түгел — фронттан исән кайткан шундый егет насыйп булсын әле!

Хәсән абыйның менә шул чуп-чупай айлары — чупчуп үбешеп үтәр «баллы» көннәре. Нинди эшкә кушса да, иң күңеллесе сезгә, дигәндәй әйтә нәрәтне:

— Ну, егетләр, аулак җиргә, кызлар белән бергә төн куна барасыгыз киләме? Оештырам!

Кая икәнне белгәнче үк риза инде егетләр. Эше дә җиңел икән — Биябашы тегермәненә барып, берничә капчык бодай тарттырып кайтасы. Башта «уфалла»да тартып барасы — анысын сүз арасында гына белдерә. Кызларны да шулайрак көйли:

— Бер, җилләнеп, егетләр белән ял итеп кайтыгыз әле, гел эшләргә димәгән!

Барыбыз бергә җыелгач, тагын да ачыклый төшә. Гәрчә бусы бригадир вазифасы булмаса да, булыша:

— Егет-кыз парлашып җигелегез, шулай җиңелрәк ул — тартып караганым бар! — дип каш сикертә. — Кызга җиңел булсын дип, егет тарта, егет өшәнмәсен дип кыз да тырыша...

Ашыгыч икән — уракчыларга иртәгә үк шул оннан икмәк пешертәсе. Бодайны елга башындагы ындырдан төяргә, юл өстендә, ике урман арасында ул — ярты юлда инде!

Ындырга барып ирешкәнче, җилгәреп тутырганчы кич булды.

— Төнгә карап, иген белән урманга керәләрме? Ни булмас хәзерге заманда? Иртәгә кузгалырсыз. Җәйге төн чыпчык борыны чаклы гына ул! — диде каравылчы бабай. Үлчәүче абзый үзенчә куәтләде:

— Бодаегызны да, кызларыгызны да алып калырлар, шул булыр...

Бу форсатка сөенде генә егетләр:

— Тегермәндә утырганчы, салам эскертендә кунабыз!

— Җылы саламны кочаклап йоклыйк әле...

— Бодай капчыкларын диген...

Салам кочакларга ниятләми болар, бодайның да каравылчысы бар... «Аулак ындыр» булмакчы бүген. Кызларга да кызык:

— Уртак эскерттә кырау төшмәс әле, — диләр.

Аулак өйләрдән күпме качтым, инде монда килеп каптыммы? Урман якын булса да качып булмый... Шомарган малайларга уен гына, минем тәҗрибә юк шул. Тартынам да. Ә сүздә сер бирмим анысы, арттырып та җибәрәмдер.

Саламны йолкып-суырып алып, эскерткә ояладык: кызлар, малайлар рәттән теҙеләсе... Кем янына кем туры килер? Сиздерми генә күз төшергәләп, ничектер үзеннән-үзе кара күз янына туры килдем... Күз төнлә күренми дә, сүзе ялтырый:

— Җылынып йоклыйсы бар икән әле! — дигән була, салам кабартакабарта. Мин, мөгаен, якынрак елышырга, кулны... каядыр сузарга тиешмендер. Бригадир да «егетләр» диде бит... Япан кырда йолдызлар чекерәеп торган төн иде, салкынча чык сулышы сизелә. Мин күршемә елышам, сикереп торыр да, ачуланып: «Кагылма!» — димәсме? Дими. Салам җылыттымы, орыныр-орынмас кыз янында ятумы, кыюсыз гына кагылумы? Рәхәт бер дулкынлану сиздем, тәнемне кайнар дулкын пешереп, йөрәкне татлы чеметеп узды... И-и яшьлегем, саф саламда баш әйләндергеч кырлар иркенлеген тойдырган төн... Таныш булмаган хисләр уятып, тәнгә электр тогы йөгерткән мизгелләр... Йокладык микән, йоклаганга салыштыкмы? Таңда кузгалдык. Төн үткәнгә мин шат та: шуннан ары нишләр идең... Салам оя җылы була икән ул. Кызлар арасында урман арасы да куркыныч түгел...

Бардык тегермәнгә, тарттырдык бодайны, кызлар җылы оннан боламык пешерде. Кайтыр юлга чыктык. Онга әйләнгәч, бодай әллә җиңелрәк тә? Боламык хисабына түгелдер инде! Хәсән абый әйткәнчә, парлап җигелдек кучәргә. Кайнар кулы кагылып китә кайчакта. Шул кара күзнең инде, ничек килдек, шулай парлашып кайтабыз. Ниләр сөйләштек — истә калмаган, бик рәхәт юл иде... Ярый әле авылда тегермән эшләмәгән, ярый әле Хәсән абый шундый нәрәт биргән. Ярый әле электр тогы йөгерткән салам туры килгән, шунда йокладык — йокламадык...

Күп еллардан соң кайткач, кырларны әйләндем, алтын саламнарны җилләр туздырган, ындырның эзе дә юк. Бәлкем саламдагы җылы оя да минем күңелдә генә калгандыр? Тик бер нәрсәгә, яшьлектән хәбәр шикелле сөендем, хәзерге кызлар да:

— Әлинур, гөлинур,
Хәсәннеке Бибинур!

— дип такмаклый иде, Зәлидә дә һаман шулай дәртле әйләнә. Бәхетле пар күптән инде Сафа абый белән Мәрьям апага кода-кодагый, оныклары сабантуйда көрәшә. Сирәгрәк булса да бәхетле елмая әби-бабай: таныш электр чаткылары сүнмәгән әле!

## Салпы якка салам кыстырып...

Хәсән абый төнлә килеп йокыдан уятты. Башка вакыттагы сыман шаяртып та тормады, борчылган иде, ашыга:

— Каршурман ындырында өмә! Безнең бригададан кеше юк... Комиссия килгән! Тиз генә барып кушыл, көлтә төйи кер, сизми дә калырлар...

Көне буе эшләгәнне белә, коткар дип килүе — ничек баш тартасың? Чит ындыр, анда булганым юк, шау-гөр сугу машинасы ишетелер әле дип, зиратлар яныннан үргә күтәрелдем. Таң алды, тып-тын. Кайда ул ындыр? Салам эскертләре күргәч, эчке җылы керде. Якынаям, җемелдәп ут күренә, тик сәер тынлык борчый. Гаеп табып комиссия туктатканмы? Кайтып киткәннәрме?

Ерак кырда ялгызым, урман якын, шикләнебрәк барам, дилбегәне сүзсез генә кагып алам. Килеп житкәнче аңлый алмадым ындыр хәлен. Менә атым туктапып калды. Карасам, салам өемнәрендә кешеләр йоклап ята. Әкәмәт тә, сәер дә күренеш: көлтә сыман кайсы кайда тәгәрәшкән — кинодагы сугыш кырыдай... Инде таң яктыра, ачыграк күрәм:

хатыннар, кызлар, егетләр, бабайлар саламга чумган да, изрәп йоклый. Ник берсе башын күтәрсен... Исән-саулар микән, дип шикләнерлек.

Учакка күмгән бәрәңге исе килә, уяу сакчы шундадыр, барып белешим. Биш-алты ат бергә килеп, җиргә иелеп солы кетердәтә. Арадан узыйм дисәм, көтелмәгән хәл булды... Кинәт аякларымнан эләктереп өскә тарттылар! Башым җиргә тияр-тимәс асылынып торам... «Каравылчы?!» Аптырап өскә карасам — атларның югары күтәрелгән башларын күрәм, сискәнеп төрле якка чигенәләр: бергә китереп бәйләнгән тезгеннәргә эләккәнмен. Өркеп башка басмагайлары... Атлар акыллы җан иясе, җайлап дәшкәч тынычлап, янә көшелгә иелделәр. Көчкә арындым тышауларыннан. Адәм хуры булырсың... Бәла аяк астыннан йөри, диләр шул...

Учак янында беркем юк. Көлдән күренеп торган бәрәңгене алып ашадым, атны солыга куштым. Үзем дә өмәчеләргә кушылдым — рәхәтләнеп саламга сузылдым... Эш беткән, көлтә җыелган, сугып саламы да өелгән — шәп эшләгәннәр. Йокы ястык теләми, бигрәк тә иркен кырлар исе килеп торган, суынып өлгермәгән яңа салам булганда. Өмәдә төрле бригада кешеләре — танып та бетермим. Иртән уянып, атларны кайту ягына бордык — эшне бетерешеп кайтам мин дә... Хәсән абыйга әйттем:

— Комиссия булмады ич?

— Шулай мени? Ярый алайса, саламда йоклап кайтуың һәйбәт булган әле. Бик ошагач, әнә, Якуб дустың белән салам өяргә йөрерсез. Зиратлар башындагы ындырга. Үзегез өйгән эскерт башында йокларсыз!

Саламнан — саламга... Өеп торулары ничегрәк микән? Булдырып булырмы? Хәсән абый бу эшкә үзе дә кызыккандай сөйли, яралы кулы гына хут бирмидер төсле:

— Салам өю — чиста эш инде! Өр-яңа, җиз сыман, юк-юк, алтын сыман салам бит! Үзегез дә беләсез, җидене бетергән: сабан-тырма артыннан муклашкага абына-сөртенә тузан йотып йөрү түгел инде!

Кызыга калдык, чыннан да, бик җиңел тоела башлады. Уебызны белгәндәй, бригадир дәвам итә:

— Әйе, әйе, сәнәккә эл дә чөй генә, яңа салам белән теш казып ята бир. Әнә, Ситдыйк Рифкате йөгерсен әрле-бирле салам тарттырып — ул тиктормаска бик таман! Аннары, ул бит әле алтынчыда гына түгелме соң?

Иң зур дәлиле калгандай, кеше ишетмәсен, дигәндәй, өстәп куя:

— Аның әле машинасы да җимерелгәли... Үзегез аунарлык — күләгә булырлык өеп калсагыз ярый...

Кыскасы, Якуб белән икәү «чиста, җиңел эш»кә алындык. Бригадирның салпы якка нинди саламнар кыстыруын сизмәгәнбез... Әйтәм аны читкә — Тәүгелде ягына борылыбрак сөйләде — ирен читендә булган икән астыртын көлүе...

## Салам җиңелме?

*I*

Эскерт куясы урынны билгеләдек, салам тарттыручылар килә дә шунда аударып калдыра. Сәнәк белән тигезләштереп торабыз. Дөрес әйтә бригадир — җиңел эш бу. Сугу машинасы кәҗәләнсә дә, борчылдым юк — безгә нәрсә, без әзер, булса — өябез.

Бер мәлне күч түбә тулды, инде саламны эскерт янында калдыралар. Булдырмастай түгел — моның хәтле өймәгәнгәме, каралтыга чөймәгәнме, ел саен ике-өч олау салам кайта торган иде ишегалдына. Иләмсез дәү-озын эскерт үсә дә үсә, буйдан-буйга йөреп, караштырып-тараштырып алабыз. Берзаман өстән сузылып алырга Сатира аптыйның тырмавычы җитми башлады... Баш очына күтәреп, үрелебрәк өскә ыргытабыз. Шул икән иң кәттә чагы — атлар килә тора, аларга борылырга урын кирәк...

— Күмеләсез! Кыймылдагыз! — дип, ак тешләрен күрсәтеп китә тузанга баткан Ситдыйк Рифкате, атын чая гына юрттырып. Хәсән абыйның «чиста эшен» җилкәбездә тоябыз: кылчык, башак дигәнең, вакланган салам чәчкә тула, колак-борынны томалый, баштанаяк коендыра... Сыпырырга һич вакыт юк, салам калынлыгы булса да ял итеп аласы иде дә... Салам түгел кыл да сыймый торган чак, җен шикелле бөтереләбез! Инде бригадирны да кыскартып «Хәсән» дип кенә искә алабыз, «җан»сыз гына. Авыз тутырып өстәгәне бүтән сүз.

Сатира аптыебыз гәүдәгә сөбханалла булса да, эскертне тигезләпныгытып баштан-башка җитез йөри, безгә дә куәт-дәрман биреп ала, саламга авып китсә, фронттагы иренең өйдә чагын сагынып, шаяртып өлгерә. Кылчыклы эскерттә түгел, мамык түшәккә чумып тирбәлер чагы шул...

Хәсән абый салам өюне — җир сукалау түгел, дигән иде. Дөрес әйткән... Сабанда ичмасам, атларны ял иттергәндә, сөргән җирне адымлап сутый чутларга вакыт була. Капчык ташу дигәне дә салам өюдән җиңелрәк — сәнәккә элеп югары чөясе түгел...

Кеше арасында сынатасы да килми. Кайчан соң төш җитәр? Бу хәтле дә кызу, бу хәтле дә озын көн булыр икән... Җитте төш, үтте дә. Инде кичкә чаклы түзәсе: әллә сәнәк сабы шыгырдый, әллә бил, әллә икесе бергә?.. Күз аллары әлҗе-мөлҗе... Ниһаять, колакларны тондырып, дөньяны дер селкетеп дулаган сугу машинасы дигән шайтан калдырчасы, туктарына үзе дә ышанмагандай, тынып калды. Шундый тын икән бу дөнья... Шулай җиңел микәнни гәүдә дия алмыйм — күтәргән салам авырлыгы аякларга хәтле төшкән. Үтте бу көн. Иртәгә дә түзеп булырмы? Ситдыйк Рифкате атка атланып кайтып китте... Сукага, ерак басуга йөргәндә артлар каезланып бетә, дип зарлана идек, монда төзәлер инде. Куллар гына сөялләнеп, канап иткә чыкты... Сукага чыксак, анысы да төзәлер.

«Мамык җиңел ул, йөз потын да күтәрәм!» — дигән, имеш, бер адәм. Салам да мамыктай җип-җиңел, килсен — күтәреп карасын, без карап торыйк, ни әйтерен тыңлап карыйк...

## «Җенледер бу!»

Сугу машинасында Нурулла абый дисәләр, белеп торасың — тын алырга ирек бирмәячәк! Выжылдап йөгергән, күз иярми әйләнгән каешлар ындырдагы һәр кешегә тоташкан, барысын да куалый. Өстәлгә көлтә биреп торучылар, бавын кисүчеләр, машинистның кул астына шудыручылар, барабаннан атылып чыккан саламны җәһәт алып торучылар, агылган бөртекне себерке белән әрле-бирле сыпырып кибәктән аеручылар, тагын кемнәрне — барысын да әлеге киң каеш кызулый. Ат куучы малайларны, «күзлек» таккан, әйләнчек булгандай килеп сарган атларны сугу барабаны әйләндерә... Көне буе туктамый каһәр — ыулдый да гүелди, суырып кына тора көлтәне, җелекне суыра! Чәйнәп ташлап, төкерә генә, әз булды дигәндәй ажгырып, гужланып-бирәнләнеп тагын сорый: ачык авызыннан шомарып ялтыраган тимер тешләре ыржайган... Тау-тау көшел өелә тора. Төшкә кайтмый эшләгәндә шул таудан безгә дә яртышар кило ипи тия... Чәчкән, үстергән, җыйганнан соң бары шул гына, һәммәсе — дәүләткә, фронтка!

Ындыр табагы тоташ бер машинадай гөжелдәп эшли икән, аны биетеп торучы, әйдәп-әйдәп куучы — Нурулла абый. Чыдасаң — чыда, чыдамасаң — юк... Үзе янганын да белмәс. Җенле кешедер бу, билләһи, машинаны да, безне дә дөртләп кабынырдай кызулап эшләтә. Өлгер генә! Чүмәлә, кибәннәрне олау-олау кабып йоткан ачәрвах пәһлевандай туймас бугаз — сугу барабанын көне буе «ашатасы» бар. Каешы ыч-

кынып, әзрәк тын алсаң иде, йә барабан тыгылып... Чыдар чама бетсә, андый әмәлен дә беләләр — көлтәгә сынган сәнәк сабы тыгып җибәрергә була. Бусы инде тәмам бетәшеп, барабан үзенне суырырдай булган соңгы чиктә. Анда да машинистның сизгер күзе күреп, күзлеге тузанланса да кулы тоеп ала... Аны барысы да үзара тетә генә. Көлтәне теткәннән ким түгелдер, һи, хатыннарның тел барабанына эләксәңме!

— Дуамал тәре, дулаган бу Торна, бетерә инде! Үзебез машинадан чыккандай, сугылган көлтә булдык бит инде!

Ачу килгәндә кушамат та ычкына. Сөйләшеп эч бушатып та булмый — машина шавы басып китә, сүзләр дә барабан аша көлтә белән оча — коры тота каты куллы абзый! Шуның өчен зарланалар, һәм... яраталар. Горурланып, кызыгып мактыйлар, авыл кешесенең югары бәясе шулдыр:

— Җенледер бу! Җеннәре эшләтәдер! — ди. Андый кешеләр бар безнең, төрле эштә күрдем, комбайнчысын, тракторчысын, печән чабучысын да, иләк иләүчесен — иген җилгәрүчесен дә. Игенче аеруча күтәренке рух белән дәртләнеп алган чак — урак өстендә бигрәк тә.

Әнә ул, очучыныкы ише, тузан-кылчыктан саклый торган күзлеген чишеп ала, алъяпкычын сала, ындыр тына... Нурулла абый, сабан туе батырыдай, сүзсез генә кайтып бара. Кашларында — кылчык, тагын да кырысрак итә. Салмаклыгы — арыганнан, мина ул олы хезмәтен тоеп атлый сыман. Төрле эшләрдә йөри, ә менә «сабантуе» — ындырда. Гайрәт күрсәтер мәйданы шул, үзе дә көтеп аладыр.

Нурулла абыйның беркемдә булмаган гадәте бар: борын тәмәкесе исни. Күрәсең, ындыр тузаныннан төчкереп арыну кирәктер. Ә безне тәмәкесез дә төчкертә... Мин дә булдым аның кул астында. Ат куарга да йөрдем, көшел көрәдем, көлтә ташыдым, салам тарттырдым, өеп тордым. Аның «кубызына» биедем, хәлдән таеп егылырдай булгач сукрана идем, хәл алгач — соклана идем... Барыбыз да шулай эшләсәкме, дәүләт машинасы да шәбрәк әйләнер иде, байлыгы да көшелдәй өелер иде, мин-синәйтим!

## Кече юлның тузаны...

Бригадир Бики тауга ындыр табагы кырырга җибәрде. Якуб белән янәшә туры килдек. Күрәге ялт иткән — үткендер, ипледер, очып кына йөри. Минем күгәргән көрәк үлән тамырына төртелеп туктый. Якуб уйнап кына кәсне юнып-каезлап чыкты да, авызын ерып тора. Шактый тирләргә туры килде, сулуым капты. Әтисе өйдә шул, таянычы бар аның, күнеле күр. Гәүдәгә иплe, очраган саен көчен күрсәтеп ала:

— Нихәл, малай! — дип кулын суза да, үзең сыгылып төшкәнче, бармакларың берегеп ябышканчы кысып тора, бик канәгать булып шаркылдый. Гел шулай. Ошамый бу гадәте, әйтеп тә карадым, әллә оныта, әллә үзенә бик ошый, кул сузганда алдан ук көлеп куя:

— Нихәл, малай!

Әтиләр үзен өстен тоя... Сөйләшкәндә сизелми алай, хыяллар тиң безнең, менә анда «кул кысышу» ошый мина, анысында бирешмибез.

Җир сукаларга караңгыдан-караңгыга бергә йөрибез. Уй-өметләр гел якты да, шушы саф таңдай сызылып киләчәк көтәдер. Офык аръягында ул бәхет — колхозда булмасын беләбез. Хезмәт көненә — «җилтруд», гомерең җилгә узар, укымый да калырсың. Иң зур хыял — уку! Кем булырбыз димибез, ничек унны бетерәсе, дибез. Югары уку йортлары хыял өчен дә ерак әле. Урта мәктәп унсигез чакрымда — Кайбычта, институт — йөз чакрымда, Казанда ук. Анда сузылырга мөмкинлек күренми...

Олы юллар ерак, олы юл тузанын бәхетлеләр таптый, без — кече юлда... Сабан сөрәбез, тузанына сызып сутый саныйбыз. Бусында без

оста, җир сөрүгә караганда остарак. Саннар, сызымнар — дәреснең дәвамы... Каты әрем сындырып сыза-сыза инде сутый түгел, китәр көннәрне саныйбыз, китәр юлларны сызабыз — сентябрь җитәр... Атларыбыз хәл алгач кузгалабыз, авызда — әрем ачысы, төрәннәр чиелдап-зарланып кайрак җирне кимерә. Басу юллары ел саен яңабаштан сөрелә, югала тора, без сызган теләк-омтылышларга каты кантарлар каплана. Юл тузанындагы хыяллар күмелә килә...

Тагын бер ел үтә, басу юллары яңадән терелә: узар җиренә узган авылдашлар, сөрелгән җир өстеннән юл сызган тәгәрмәч: олы юллар чакырган, дөнья чакырган. Кече юллар, уҗым белән бергә, уҗым арасыннан кабат калыккан! Безнең хыяллар да яңара, юллар тынычсызлый, тузан томаныннан яктыга чакыра. Якуб белән мине тормышта үз кыйблаңны табарга омтылу якынайтты.

Рухи омтылышы белән авылга сыймас дәртле малай ул, еракка китәр Якуб. Әтисе дә өйдә, тылы нык, тормышлары житеш... Кече юллардан агыла яшьләр, әнә Хөсәеновлар, өч туган, өч сәләтле егет тимер юлга елышты. Тимер юлны, армия сыман, дәүләт кайгырта — киендерә, ашата. Әхәт, Харис, Ислам китте, урнашты, авылга кайтып-китеп йөрсәләр дә, читтә төпләнделәр. Җирдәге соңгы тукталышлары да тимер юл эргәсендә... Хыялга җиттеләрме, әллә станциясен үтеп киттеләрме... Ялтырап яткан рельслар арба көпчәгеннән сүтелеп төшкән тимер шиндәй. Үтелгән юллар, сүтелгән хыяллар... Хыялга җитәргә дә канат кирәк. Канатларга көч кирәк. Көч бирердәй замана кирәк. Күпме хыял, күпме язмыш, күпме сукмакларны юлга чыкканчы ук нужа тузаны басты...

## Үткәннәрнең салават күпере

Күк капусы ачылганда теләгән теләк кабул була, ди. Гөлт итеп кабынган арада ничек өлгермәк кирәк? Аны бит әле күрәсе бар... Күзләр болай да күктә анисы, зәңгәр төпсезлек тыны белән үзенә тартып тора... Йолдызлары кү-үпме! Яктырып елтырап, өмет-омтылыш уята, чакыра... Ашкына күңел, шикләнә дә... Күккә карадыңмы — хыяллар өермәсе урап ала, җиңел канатларында тирбәтеп киләчәккә алып китә. Чиксез күкләр — киләчәгең сыман...

Бәпкә үләнгә чалкан төшеп каурый болытларны күзәткәндә яткан җиреңне тоймыйсың, онытыласың — син дә галәмнең бер җисеме, илаһи көч җирдән аерып-кубарып алган ла, йолдызлар арасыннан очырта...

Очырып йөртерлек җиңел, каурые ныгымаган сабыйлар... Күрми калдык, ахрысы: күк капусы ачылган да ябылгандыр. Тәрәзә утларын томалагандай, сугыш пәрдәсе каплады аны... Без омтылган күкләр шомлыга әйләнде: немец самолетлары Идел күперенә килгән. Немец безгә күктән үрелеп Казанга җитсә, җирдән Сталинградка җиткән чагы...

Бәхет юрамалары гел күктә икән — салават күпере астыннан чыксаң да бәхетле булырсың, ди. Әй йөгерәбез, күлдәвекләрне чәчрәтә-чәчрәтә ашыгабыз! Менә җитәм, менә җитәм сыман, ә ул читенә-читенә ерагая. Тау башында дип менсәң, арырак авыша: булдыра алсаң, җитеп кара, дип ирештерә. Офыклар ерак, анда ук йөгергән юк... Шунда ул безнең салават күпере, шунда ул бәхет капкасы! Тагын явар яңгыр, калкыр да балкыр салават күпере. Җылы яңгыр астында үсә-үсә йөгерербез әле!

Салават күперенең өстеннән дә, астыннан да бомба төягән самолетлар оча. Болары — безнекеләр, сакларга оча, кара тәрелесе килеп бомбага тотмагае... Киләчәккә, бәхеткә үткәрәсе аллы-гөлле хыял күперен чәлпәрәмә китермәсме? Күкне кара тәреләр — җаның өшеп китә торган чиркангыч үлем тамгалары капламасмы?

Бәхет көткән күкләрдән бәхетсезлек килде — сагаеп карыйбыз. Зәңгәрлеген пәрдә каплый, ачлыктан күз аллары караңгылана. Җиргә төбәлсәң дә томалана, ачлыктан киселгән — миңгерәгән күләгәләр арасында син дә йөрисең, кеше кайгысына, үз хәлеңә дә битарафсың — беркем, берничек үзгәртә алмас... Чын дөньямы бу — өнме, әллә саташулы төшме? Гәүдәң монда йөри, син аңа гамьсез-ваемсыз гына читтән карыйсың...

«Баш ташлап әллә кайларга китәр идем!» — дип тәмам гаҗизләнгән адәм баласы. Беркем беркая китә алмый. Күңеле белән киләчәккә китсә генә. Өметең — киләчәк дигән хыялый дөньяда, җисмең генә шунда күчәсе...

Сугыш вакытында безне киләчәккә өмет, ышаныч коткарды. Килгән әҗәл, без — күләгәне генә күргән, аңа бит җисмең — рухың бергә кирәк. Ә рухыбыз киләчәктә.— Киләчәккә буе җитми әҗәлнең. Бүгендә генә хакимлек итә ул. Бүгенгә генә хөкемдар... Менә шулай котылып калдык сугыш чоры үсмерләре... Үсәр чак иде, хыял канатлары күңелне үстергән, рух карыны ач булмаган!

Ахрысы, Бүгендә эшләп, Киләчәктә яшәдек без. Күпме гомер шулай үткән. Хәзер салават күпере күрсәм, алга — Киләчәккә түгел, артка — Үткәннәргә борылып карыйм... «Сизми дә калдым гомерне: бер капкасыннан кердем, икенчесеннән чыктым...» — диган иде Зиннәт бабам. Киләчәккә җитеп күргән салават күпере шул икенче капкамы? Якынаймый торсын әле — үткәнемә китәм, шул исәпкә Бүгенемне озайтам... Әкәмәт бу адәм баласы: омтылган киләчәктән үзе качкан үткәнен юксынып кайта... Үткәннәрем — Киләчәгем... Ә Бүгенем? Бүгенемдә рәхәтләнеп, яшәү шатлыгын тойган чагым булдымы, кайсы көннәрем ул?

## Шифалы сүз

— Гайшә апый, әнкәй чакрыган ие, сыерыбыз көтүдән күңелсез кайтты...

— Хәзер, наным, хәзер! — ди ул, яртылаш әрчегән бәрәңгесен табакка шудыра да, кулын алъяпкычына сөртеп, безгә ашыга.

— И бәгырькәем, ни хәлләрең бар, малкаем-матуркаем,— дип эндәшә ул кәрә-керәшкә сыерыбызга. Тегесе дә зарлангандай мөгри, борылып корсагына карап куя.

— Моңсу кайтты шул,— ди әнкәй, кайгырып. Ә Гайшә апаның йөзендә борчылуның эзе дә юк, ачылып-чәчелеп, дигәндәй, күзләре белән көлеп, сүзләре белән елмаеп, бигрәкләр мөлаем итеп, җаннарың эреп китәрлек итеп бертуктаусыз сөйли ул. Догадыр, аңламамдыр дип, әлләни колак та салмаган идем. Догасы шул — кәефне көйләү, юату, ярату, тынычландыру сүзләре... Саф татарча, үзебезчә ул сүзләр шундый җайлап-көйләп әйтелә, бәет сыман, шигырь шикелле. «Минем кулым түгел, Гайшә-Фатыйма кулы» дигән җирендә кулына карыйм: урак урганда сеңер киселеп бармаклар өскә каерылып калган. Бармагы үзенә кәкре дигән, аңа гел менә туры килми, бик ярдәмчел ул. Шул бөгелмәс бармаклар белән җай гына, йомшак кына, сөеп-сыйпаудадыр шифасы... Тәмле сүзләр белән иркәләп сыерны әйләнеп чыга. Аны тыңлап мин тынычланам, әнкәйнең хафасы басыла. Ә сыер шул арада күзләрен тутырып карый да, койрыгын селкеп, кузгалып китә, ләгәндәге суга үрелә... Сүз белән, мөлаем сүзләр догасы белән имләде күршебез! Сүз иясенең җан җылысы, изгелеге бар икән, бака, елан имгәч тә сихәт бирә торган көче бар. Ихлас булганга файдасы тигән, җыелыштагы фанер трибунадан орды-бәрде ташланган агач сүздән нинди җәбәлә булсын!

Гайшә апа димләү такмазасын әнисеннән отып калган, буыннан-буынга шулай күчә килгән — дога итеп ятланган. Үзенең баласы юк, инде

ул им-том сүзләрен белүче юктыр да... Ә үзем соң, язып алган булсам? Ничәмә буын саклаганны югалтырга хәтерсез-гамьсез бер буын җитә. Шөкер әле, халык хәтере өзелмәгән — халык иҗатында калган алар. Гарәп телендә безгә җиткән догалардан элегрәк, әби-бабайлар телендә туган, өй тирәсендәге телсез җанияләре дә ияләшкән телдә ул. Сүзнең ни файдасы булсын дип, көлебрәк караганбыз. Була икән, яхшы сүз — җан азыгы, кеше күңелен сүз белән имләүчеләр була. Әдипләр дә шулар рәтенә керә ала. Әлеге әйтемнең «яман сүз — баш казыгы» дигән өлеше дә бар, халык тәҗрибәсе күптән сынаган: яман сүз казыкка әверелеп башка төшә...

Гайшә-Фатыйма кулы, дигәннән, шушы Гайшә аптыйны беләм, Фатыймасы багучы авылдаш дияр идең дә, анысы борынгы изге җан, шәфкать-миһырбан иясе икәнне Латифа тәтәмнән ишеттем, ул да имләгән саен телгә ала иде. Гайшә аптыйның исеме ничек туры килгән! Миңнулла абый белән алар өлкәнәйгәч кавыштылар. Ул да әкият сөйләүче, күңелләрне көйләүче бит. Ике толны шушы уртаклык бер иткәндер, пар иткәндер. Илаһым, күпме ул милләтемнең сабыр күңелле изге җаннары — әбиләр, бабайлар, күрдекме без аларны, төшендекме, бәяләдекме бу дөньяда?

## Сыерның моңлы күзләре...

— Корбанга пар тояклы терлек чалу фарыз,— дия иде Латифа тәтәй.— Кыямәт көнне атланып сират күперен кичәрсең, ди... Кылдан нечкә, кылычтан үткән ул күперне күз алдына китерүе дә куркыныч:

— Атланган сарык ычкынып китсә, ай-һай... Асты тәмуг уты...

— Гөнаһлы адәмнәр егылыр, ди, китап. Корбан чалган савaплы була, алла саклый аны...

Әкиятләр, дини йола, гореф-гадәт минем өчен барысы да бердәй: «ярый» белән «ярамый»ны аерып биргән кагыйдәләр. Кайчан була әле ул ахырзаман, дип тә юана идем эчтән генә — безнең заманда булмас... Дөньялыкта да була икән кыямәт... Сугыш үзе шул түгелме? Менә-менә өзелермен дигән кылдан нечкә, кылычтан үткен мохтаҗлык елларыннан сыер-сарыклар алып чыкмады мени?

Март — шарт узган, март — юмарт көннәр... Нигез туфрагы ачылып, кипшенә башлаган, тавыклар җылыдан изрәп күзләрен йомган, рәхәткә тиенгән. Сыер да хөҗрәп, кояшны сеңдереп тора. Йа хода, тире дә сөяк ләбаса... Ничек җан асрап калган ул салкын кышта... Шул, иртә-кичен өйгә кертеп, туралган саламны бәрәңге кабыклары катнаштырып, көрпә сипкәләп тамак ялгатабыз. Авызыннан узганны җиленнәреннән бозау суырып кала...

Печән, салам ягы такырайды, уйсыз ишеп төшерү кая — учмалап, чамалап кына саласың. Күпме кала, күпмегә җитәр, юл өзегендә бетеп куймагае... Кая барырсың да, нәрсәгә алырсың? Сатып алган — сарымсак, күпмегә җитә. Чеметемләп-йолкыштырып бәбәнәгең канатып җыйган үлән лә. Салам да исәпле: астына җәяргә алдыннан калмый... Кышын әнә, ястык сыман кабартып, селкеп сала идек. Ятып тәгәрәп карыйсың — уфылдап ауган сыер малкайның кабыргасын бозлы «алма» авырттырмасын... Күзен, язын аяклары пычрак изә, көне-төне юештә — сизрәгән салам түбә яңгыр тотмый...

Тышта терлек тилмерә, әйдә — үзең ач... Сыер, сарыкның күзе гел ишектә, шунда килеп кычкыра — бозау, бәтиләрен юксынып, әзрәк сый эләгәсен белеп, кыбырсып көтәләр. Әрсезрәк сарык бәрелеп-сугылып аяк арасыннан үтәргә чамалый... Беләм алар хәлен, бу йортта, бу урамда, бу авылда, бу илдә һәр кешенең, бар мал-туарның ашыйсы килеп тәкате корый, уенда шул гына, шул гына...

Сыер бездән ризык көтә, без — сыердан... Бозавыма дип, төшерми тартышкан сөтен юмалап-сыйпап сава әнкәй. Мунчагы тарттырып бәйләнгән бозау буыла-буыла әнисенә омтыла — авызыннан күбекләр тама. Без дә түземсез, без дә җылы сөт көтәбез. Ничә бозау булып чыга инде? Иртә саен усалланып көткәне, һәммәбезне читкә кагып, талап имгәне, чүлмәк күтәреп йөгерткәне — налог дигән комсыз, мунчаксыз ачәрвах... Иң соңыннан бозауны куша әнкәй, койрыгын чәнчеп ул сөенеп-чапылдатып, тәмләп суыра инде, төртә-төртә имә, түземсезләнә, ябыгып җиңеләйгән әнкәсен аудармагае...

Сыерның мөлдерәп торган зур, кара күзләре балачагымнан тутырып-тутырып карый. Моң тулыдыр алар... Моңлы чаклар шул, ат урынына җиктек, сөтенә кан төшкәнче кудык — ничек моңлы булмасын кара күзләр, акыллы күзләр.

Сыерны бака, йә елан имсә, җилененнән канлы сөт килә. Сугыш-аждаһа имде, зур авызлы налоглар суырды, кызыл сөт килгәнче талкыды... Сугыш чорына атка атланып кердек, сыер алып чыкты. Сыер аркасында исән калдык, ачлык-дошманнан сыер коткарды...

Ничек моңлы булмасын ул күзләр — хуҗасы хәлен төшенгән лә малкай, аңа да авыр, йөрәгеннән кан сауган, хәсрәт еланы ябышкан еллар... Сугыш авырлыгын бихисап җанлы һәм җансыз әгъзалары белән, бар табигать бердәй күтәрде... Фронтка җибәргән хатларда, үзебез белән бергә сәлам җибәрелгән... ([illegible]) беррәттән, мал-туар хәлен белдерә идек — исәнлек бер-беребезгә бик бәйле иде...

Ачлыктан интегергә мәҗбүр булган, салкында күшеккән, яңгырдакарда җәфа чиккән малкайларны искә төшерәм дә, кызганып күңелем әрнеп куя. Алар алдында гаеплебез сыман... Бергә нужа күрдек, иза чиктек, ни дисәң дә үзебезгә рәтләнгән тормыш та әлекте. Сыер килеп җитә алмады, атлар җитә алмады — хәлсезлектән кимсенеп, гаҗиз юлларда дерелдәгән хәлсез аякларында басып калдылар...

Һиндстанда сыер изге терлек санала. Бер бәйрәмдә өйгә кертеп, үз урынында йоклата икән хуҗасы... Васфикамал аптый белән әнисе — ике ятимә, мохтаҗлык тинтерәткән ике карчыкның сыерлары өйдә кышлый иде:

— Ызбаны җылыта,— диләр... Үз куышына йомылып тереклек иткән картлык хәлен кем белсен иде дә, беркөнне:

— Сыер идән астына төште, идән җимерелде...— дип күршегә кергәннәр, ярдәм сораганнар. Аптырап та көләсең...

Сыерның моңлы күзләре... Сыер күзенә карап уйлана идем. Әллә аның хәлен җиңеләйтергә теләп, әллә үз хәлемне уртаклашып... Хәзер заманалар үзгә, кая ул сыер күзенә карау? Дөнья куа кешеләр, йөгерәкабалана, туктап сөйләшкәндә дә күзләре йөгерә — бер-берсенә карарга да оныта. Үзем дә шулар арасында. Әллә күздән моңнар түгелеп беттеме? Тормыш дигән сират күперен дә моңсыз-җансыз кичеп булмыйдыр? Ахирәт түгел, тереклек, яшәү үзебездән дә корбан сорый, фидакарьлек сорый...

## Нужа печән ашата

Бер караганда, үлән ашау авыл баласына яңалык түгел инде. Кар китеп, аяк асты кипшенүгә, бәпкәдән элгәре тыкрыкка үзебез борын төртәбез. Урамнарда яшел чирәм, бәпкә үлән, кәҗә сакалы, мәчтүрә (мәче борчагы) үсә. Җир төмен әйтеп торган ак түгәрәк «кабартманы» учка җыеп:

— Кара әле, минем нихәтле! — дип, йомылдырасың гына. Кәҗә сакалын «ирен яргыч» дибез — әрчегәч иренгә тидерәсең, пешкәндәй кабара да чыга. Авыз түзә икән, аңа берни булмый. Кырдан каки җыябыз —

авыз сулары килеп, әчкелтем-төчкелтем тәмен кыш буе котәсең. Тугайда киндер орлыгы, шома шепкән! Болын әнисе, урман балтырганы. Бала-чак — исләр, төсләр, тәмнәрнең салават күпере ул.

Җир тәме, җир җиме, җир име булган — чир-сырхаудан саклаган, «яшел бөти» — догадай булган. Тикмәгә димсең, иске авыз, яңа ризык — зеңгелә кач, дип бисмилла урынына әйтәбез. Күзе ачылмаган нарасый анасы күкрәген тапкандай, тәпи басканчы ук, мүкәләгән хәлендә җир күкрәгенә үрелә. Витаминны ишетеп белмәсәк тә, иң кирәклесен суырып-йолкып имгәнбез. Вакыты җиткәч, әнкән аера — беренче нәүмизләнү шулдыр. Дөньяви ашамлыкка күнектерәләр: чүпрәккә төйнәлгән ипи була ул, йә буш имезлек. Алар да юкта бармак суырасың. Мәм-мәм кирәк адәм баласына. Җир-Ана күкрәгеннән, сөте-сутеннән гомергә аерылмый ул.

Бәпкә саклый-саклый алар белән бергәләп чемченәбез, яшел чирәмпалас безгә, әкияттәге «җәел-җәймә!» — шул табында ризыкның җан асрый торганы, үстергәне! Колхоз ташлаганда, дәүләт үгиләгәндә, «ач үлемнең куркусыннан җил җылаганда» да Җир-Ана үз итте, үлән тамырына тотынып калдык — ачлык зилзиләсе йолкып-очырып китә алмады. Нужа печән ашата... Сутлы үлән коткарып калды безне.

Иң авыры — 1944 елның язы булды. Бәрәңгене кыланыбрак «икенче икмәк» диләр, ул чакта бердәнбер иде. Игенне кырып-себереп фронтка озатабыз — мыскалы, әчмухасы да калмый. Ә бакча бәрәңгесе чиреде. Кабакны тамакка ялгап, язга чак ирештек. Тышта кояш, күнелдә болыт: яңа өлгергәнче ничек җан асрарга? Һәр нәрсәгә, ашарга ярыймы бу, дип эзләп-эзләнеп карыйсың...

Хәвеф-хафа март иртәсендә уятты, тәҗрибәле «урман анасы» Сафиябану аптый безне дә ияртте. Аерым хуҗалык ул, өйдә дә ялгыз, урманда да берүзе. Таянычы юк — үзенә ышанырга өйрәнгән. Урман телен, табигать телен шуңа да яхшы беләдер. Ач үлемнең ачы дәһшәтен — егерме беренче ел ачлыгын кичергән, әле генә утыз өченче ел үткән... Чикләвек бөресе, агач мүге җыеп калырга кирәк, ди, аннары урманга кереп булмас. Кар тирән дә, өсте бозланган — иртәләрен йөрерлек әле. Сулышыңны эчкә тартып, җиңелрәк булырга тырышып сак кына атлыйсың. Җиңеллек болай да бар — бигрәк тә корсак шәрифләре тирәсендә...

Чикләвеккә килгәндәй ярышып, тырышып җыйдык урманның бу «җимешләрен» дә. Кояш җылытып, бот төбеннән чумгалый башлагач, биштәрне бөреп бәйләдек тә, кайтыр якка борылдык. Кеше-кара агыла башлаганчы, тагын килербез, дип сүз куештык — өлгереп, эләктереп калырга кирәк...

Март иртәләрен яратам мин: яз әле үзе килеп җитмәгән, ә сөенечләре инде монда: тамчылар шул мизгелләрне саный, кояшлы җил кар өстенә үтә күренмәле якты-шома челтәр үрә, кырга офыктан-офыкка чаклы куанычлы нур түшәлгән. Шушы чакны күреп канатланырга тургай да туган якка ашыга, җәймә хәтле җир ачылса, шунын гөмбәзендә — биек зәңгәрлектә талпына, әллә җыры белән карны эретә?

Күңелгә котелмәгән куаныч, бәхет килерен тоеп әсәрләнү. Әллә офыктан иңгән илаһи нурлар, әллә минем күңелдән кырга ташыган... Әле үзем төшенмәгән, тоя гына башлаган яктылык — туачак җыр канатлары мине дә тургай итеп күтәрәме?

Илһам тургаен бүлеп яңадан шом үрмәли: ничек исән калырга, ничек яңа бәрәңгегә барып ирешәсе? Йөрәкнең хәлен алып, тынны ешайтып торган каушау-шөбһә күләгәсе кояшлы кәефкә төшә...

Сафиябану аптый аз сүзле, аска карап үзалдына берәр сүз әйтеп куяр да атлый бирер, үз дигәнен итәр — үҗәтләнеп, җиргә карап тормыш йөген тартыр. Дөньясы белән бәхәсләшкән сыман гел ачулы. Үзенчә яшәргә ирек бирмәгән өчен сөзеп карыйдыр — колхоз белән характеры килешмәгән, шуңа күрә аерым... Сугышка да, бу хәленнән котылу көткәндәй, үзенчәрәк карады шикелле. Әйткән сүзеңне, әйтереңне дә сулы-

шыннан беләләр, авылда бигрәк тә сер булмас. Ә сугыш аның шат елмайган, пиджак өстендә ак якасы көләп торган дәртле егетен — Газизжанны йолкып алды, кара пичәтле кәгазьгә алыштырды. Анда да Гитлерга түгел, Сталинга ачулы булды карчык... Бу хәленә күнеккән идек, анысы безнең эш түгел, дия идек. Белмәгәнгә күрә каты эрпеле, керпеле күренәдер, әмма шул кабык астында йомшак күңел, миһырбанлы, ярдәмчел җан. Бәрәңге кабыгын киптереп төйгән соңгы «онын» бирер, ул да булмаганда, киңәш-табышлары белән булышыр. Читен чакларда әнкәй тәрәзәдән, тау башындагы шул йортка карый:

— Сафиябану аптыйның уты бар! Киңәшеп төшим әле!

Ут дигәнең кечкенә өлгеле ян тәрәзә төбендә кагынган төнге күбәләк инде, исән-имин икәнен белдерергә җитәрлек кенә... Унлы лампадан кысыла-кысыла кимеде шул утлар: җиделе, бишле, өчле, сукыр лампа... Чыра да яндырдык. Өмет чырагы сүнмәде, өметнең чыбыклары киләчәккә тоташкан — анда көтә рәхәтләре!

Чикләвек бөресен, булса булсын инде тәмлерәк дип, агач мүге кушып пешергән идек тә — сөендермәде. Әче иде, коры иде, тәмсез иде. Анда да юатты Сафиябану аптый:

— Булып торсын әле ул... Кар ачылгач, сәрдәгә йөрербез.

Сәрдәсе, урман сүлен имеп ышыкта үскәнгәме, йомшак, сусыл иде, аңа тиз ияләштек, капчыкны баш өстенә күтәреп күп ташыдык. Мөгрәп сыер көтә, аңа саласы, калганы — казанга, үзеңә. Чөгендер яфрагын да кочак-кочак җыйдык, малкай белән уртагыннан ашадык. Сугышка хәтле: «Яхшы азык калганчы, яман корсак ярылсын»,— дип тук фикер йөрткәннәр. Без корсакка «шәфкатьле булдык». Ул диетик ашлар белән күпме азык янга калган — юкса кибет киштәләре хәзер шулай «сыгылып» торыр идеме? Хәер, гел болай тормас заманалар, өметсез шайтан ди. Өмет бар әле!

## Таш әйләнми, баш әйләнә...

«Мойте руки перед едой, чистота — залог здоровья!» Сары калайга матур итеп язылган акыллы киңәшне Кайбычтан алып кайтып, юынгыч өстенә беркеткән идем. (Русча сүзне сирәк күргән малайларга мактанган сыман). Сугышка хәтле бездә лозунг, плакатлар һәммәсе татарча иде: «Урамда тәмәке тартмаска! Штраф 5 сум». «Штраф»ы — «пожар» дигәндәй, русча үзе, бердәй куркыныч. Пожарын күргәләдем, ә менә штраф түләгән тәмәкечене белмим...

«Мойте руки перед едой...»ны кат-кат укып ятладык. Тик үзебезчә көйләнгән авыз тиз генә бирешми... Ленинградтан кайткан Мәсгут тәгәри-тәгәри көлә: шундый ватып-җимереп бетергәнбез урыс телен. Әмер музыкасына елан̆дай буйсынган тасма телләр булышлыгы белән чит тел әкренләп үз кубызына биеткән...

Ә менә безнең авылда, киресенчә, татарлашкан урыс гаиләсе бар — тегермәнче Чумкалар. Авылдан читтә, үзләренә бер утрау сыман яшиләр. Йортлары гына аерым, үзләре авыл белән бергә. Чумканың Семка, Семен икәнен соңрак белдем. Әткәй Семен дия иде шул. Иңгә кулларны салып, җырлашып утыруларын хәтерлим:

Таң атканны шундин таныйм —
Күктәге аклык белән;
Сез дусларны тәбрик итәм
Бүгенге шатлык белән!

Әткәйнең яраткан җыры бу, кәефле чакта сызып җибәрә ул аны. Шаян сүз, мәзәк гөрләп тора табында. Тәнәфестә идәнгә утырып, аяк терәшеп

уклау тартышып алалар. Кайчан ничек: көчлерәк, чаярагы аяк өстенә бастыра. Дөньяда телләр дә шулай ярышып-тартышып яшиләр...

Тегермән ташлары туктталган еллар килде. Таш әйләнми, ачлыктан баш әйләнә... Колашага салыр бөртеге юк, тегермән бурасыннан пырак онын каз канаты белән сыпырып-җыеп алдык. Таш оны катнаш, теш арасында яман чытырдый, чәйнәр хәл юк, әз-мәз әвәләштереп йотсаң гына. Теш арасында чытырдаган еллар... Нишләмәк кирәк, күбрәк алабута тарткач, Чумканың калын кашына кунарлык та он булмаган. Ә иртән юынган саен теге язуга күз төшә: ашар алдыннан юынсаң — сәламәт булырсың... Юынган саен ашасаң иде аны. Акыллы киңәш эчне пошыра башлады, каерып аттым ахырда. Мәсгут безнең әкәмәт русчабыздан көлгән иде, без дә тәрттерәбез:

— Сугышка кадәр Ленинградта иркә малай булган, ди. Табын янында: ашыйсым килми, кирәкми, дип ялындыра икән. Әти-әнисе курка калган: нечкә тамак өзелеп китә күрмәсен... «Йә, бәпкәчем, тырыш инде, кабып кына җибәрче — бер тәңкә акча сиңа!» — диләр икән...

Бу хәбәр, чыннан да, безгә кайтып ирешкән иде. Ул көннәр хәзер Мәсгутнең үзенә дә әкият сыман. Җирдә кышлаган бәрәңгедән кәтер пешерәбез, исеме: «мәтык» — мә, тык! Мәсгутне кыстаучы да юк, бер сум да юк, әтисе дә юк — блокадада калды. Куллар чиста булу гына җитми, еллар чиста булу да кирәк икән.

Күп сулар акты, тегермәннәр бетте... Семен агайлар Казанга күченгәч, каладашлар булып куйдык. Танышлар очрагач, сорашам: фәлән агай ни хәлдә, төгән бабай исәнме? Балачакның җор тегермәнчесен дә онытмыйм. Вафат, диделәр Семен Марковны. Картлар китә — нишләмәк кирәк. Урыны җәннәттә булсын, дидек гадәт буенча. Кайсы җәннәттә — ул бит урыс? Авылдаш-каладаш ачыклады:

— Җаны-тәне белән татарлашкан. Иман китереп, догалар укытып яшәгән. Васыяте — мөселманча күмегез, дигән — төшемдә ходай тәгалә шулай иңдерде: ак сакаллы, чалмалы унике карт Коръән укып, күтәреп киттеләр... — дигән.

Семен агайның үз диненнән язуы хатыны өчен фаҗига була. Тетя Татьяна гел урысча сөйләшер иде, татарча аңламый, муенында тәресе елтырый, киенүе, яулык бөркәнүләре дә үзенчә. Коеп куйган марҗа, ә Семенны татардан аерып булмас иде: иман җан-рухны, йөз-кыяфәтне, килеш-килбәтне үзгәртә икән... Ата теле дип тикмәгә әйтелми. Татьяна үз телен, үз динен саклый. Бәгырен әрнеткән нәрсә шул: Шурка, Петька, Валька-Валентина, Таися туган телне белми... Җитмәсә, бусы татарга кияүгә чыгып куйган. Гаҗиз ананың:

— О проклятье, дети не знают языка матери! — дип әрнешеп әйтүен бик аңлыйбыз. Нишләмәк кирәк, татар хатыннары күптән инде шулай ачына...

Тәгам җыяр алдыннан кулларын юып, бисмилла әйтеп икмәк алган Семен, олылап ике куллап сындырып капкан. Үзе тегермәннең таныш гөрелтесенә колак салган: келтер дә келтер әйләнә җай гына. Аккан сулар, аккан Чирмешән ташларны әйләндерә-әйләндерә. Семенны да Чумкага әйләндергән...

## «Ач үлемнең куркусыннан...»

Ачлыктан киселгән кеше ябыгып, сулып-саргаеп соң чиккә житә дә, күзгә күренеп... «симерә» — тулыша башлый. Иң хәтәре шушы инде — шешенү... Менә, капка төбендәге бүрәнәдә ике агай утыра. Балагын күтәреп, аягына бармак белән басып карый да:

— Батып калмый әле, — ди берсе.

— Ә минем батып кала шул, — ди икенчесе, — кичәдән бирле...

Тыныч, гадәти сүз сөрешләре яшәү белән үлем хакында: шешенгән тәнгә баскач, күтәрелмәсә — эшең харап... Кем коткарсын, кая барасың — һәркемнең үз хәле хәл. Кеше инде үзе дә битараф, мие түнеп, тынып калган. Баш миенә дә азык җитми, ул да ач — һава белән туенып тора алмый... Күз инде хикмәттә дә, хәтта икмәктә дә түгел — өмет өзелгән. Яшәү арбаң тау астына тәгәри, туктар иде әллә, тел өстенә салыр нәрсә юк...

Ишетәсең: фәлән кеше тыкрыкта авып калган, җан биргән. Котылган... Чаң кагучы, куркыныч хәл диюче юк — тыныч фаҗига. Һәркем үз гаменә баткан. Ач карын да базмыйча, өметсез генә, сыкрап-сыктап, сызлап тора. Берәзлексез тоеп йөрисең. Бу яздагы сыман өзелгән юк иде. Ә бит көне кояшлы, бәрәңге утырттык, борынлый да башлаган, көтеп кенә аласы. Бәпкә борынлагандай сөендек: көнгә ничә чыгып карыйм бәбәнәкләрен...

Ач кеше үзенчә күрә, дөньяны икегә бүлгән ул: ашарга яраклыга, ашарга яраксызга... Агачка, үләнгә, әйберләргә төбәлгән эзләнүчән күзләр. Ә бит кояш элеккедәй якты, яз кояшы, коймa буенда, читән яннарында үләннәр тернәкләнә. Һай, кычыткан түгелме соң? Куе яшел яфраклары челтәр-челтәр булып ачылган! Әле кичә генә юк иде. Бигрәкләр матур икән ул яшь кычыткан яфраклары! Чаккан өчен үчләшеп, Чапай булып, талчыбык белән селтәнә-кыра идек. Сәбәпсез кыйнау-кыерсытуга рәнҗемәде микән... Чәнти бармак чаклы кычытканны өзеп-өзеп учыма җыям: әнкәйгә күрсәтим — сөенсен! Бер-ике көн көтсәк, калкыбрак, яфраклар язылыбрак китәр иде дә, көтәр чама юк. Бу көнгә җитмәүчеләр дә булды. Кычытканга тотынып калдык без, күзгә чәчәкләр күренмәде...

Тормыш-тереклек әкеренәйсә дә, ачлык дип тукталып калмый: иген чәчәсе, бәрәңге утыртасы бар. Карлы-бозлы су ерып стансадан күтәреп кайткан чәчүлекне хатыннар, инде «уфалла»га җигелеп, кырга ташый. Бодайны агулап чәчәләр. Шулай да авыл күзеннән күмелгәч, тирә-юньгә каранып — әнә ике кирпеч, ерганакка уелган учак — бер уч бодай куырып аласың... Ул дымсу бөртекләрнең калайда өртелеп-кабарып килүләре! Ходайның рәхмәте, әллә агуы көчсез, әллә ачлык көчлерәк, әллә куыру коткарган — зыяны тимәде. Нужа печән дә, агу да ашата — ач карынга бар да ризык.

Соң чиккә җителгән шул — стансадан чәчүлек баш өстендә кайтты, авыздан югары — кагылмадылар. Шул бодайны күтәреп, хәер сорашып узган төркемне күргән иде юл өстендәге авыллар... Бусын инде кечерегез — орлыкны җиргә җиткерергә дә хәл кирәк бит.

Калайлы учакны җитәкчеләр дә күрә, басу күзәтеп әйләнгән вәкилнең дә күзе очлы. Күзәтергә, тикшерүне көчәйтергә! Чәчүлек илтүчеләрне озата бар, тубал аскан бабай артыннан ияр: кыр озын, куак, үзәнлекләр бар, күздән югалып торган арада нишләмәс ач адәм... Орлык ач карынга төшәр дә, җир карынына эләкмәс — чәчмәсәң, ни урырсың? Авыл активы аякка бассын — күз-колак булсын. Контрольгә кеше күп кирәк — хисапчы буларак мине дә куштылар, «җилтруд»ны кайчан санасаң да югалмас...

Нишләмәк кирәк, кырыс заман, халыкның котын алган «карар» — каргалган карар кансыз: бер уч иген өчен дә төрмә... Ә бит үз басуындагы чеметем бөртек җан саклап калырга соңгы чара да... Шул көннәрдән өч вакыйганы искә алсам, үземне дә гаепле сизәм.

...Ике хатын чәчүлек борчак тартып бара, бергә эшләгән Хәтимә апалар, мин ике кулымны селкеп барыйммы — булышам. Чәчүчебез Сафи Дунай. Башы турыдан-туры гәүдәсенә утыртылган кыска муенлы абзый. Кушаматы матур — Дунай буйларына бәйле дип уйлыйм. Егет чагында гармунчы булган, үзен дә үртәп җырлаганнар:

И дуләме, дуләме,
Сафи Дунай үләме?
Үлә булса килсен әле,
Биетеп китсен әле!

Килмәсә дә ялынмыйбыз
Такмагыбыз күп әле!

Дөнья баскач, гармунын онытканнар азмени. Гармун урынында бүген — чормадан алып төшкән борынгы тубал. Елтырап күзгә карап, авызга кермәк булып торган борчакларны шунда агыздык. Бик кабып карыйсы килә дә — ярамый... Аякларын аерыбрак басты да, җир буйлап китте агай. Тигез селтәнеп, бармаклары арасыннан борчак сибеп бара. Бер тубалга үрелә, бер җиргә селтәнә, кайчакта өскәрәк җибәрә... Әйләнеп килеп җитте тубалын тутырырга, еш-еш сулыш ала, тын җитми аңа, ә борын тишекләрендә... борчак, авызга чөйгәндә эләккән. «Ник каптың?» — диимме, авызына кизү торыйммы? Пырхылдамый чак тыелып калдым, «контроль» дәрәҗәсен төшермәс өчен:

— Ничегрәк микән чәчүлек? — дигән булып, чеметеп кенә бер-ике борчак алып кабам — белсәләр иде ничек ымсынып торганны...

...Икенче хәл карурман буенда булды, бодай чәчкәндә. Чәчүчеләр — арттагы урамнан ике агай. Таза, гайрәтле ирләр иде, бик ябыклар хәзер, хәлсезләр, буш капчыктай шәлберәеп калганнар. Ачлык миңгерәтә, картлык та басадыр. Ә муенда — тубал. Киттеләр җир буйлап. Урман буена җитәрәк, мөселманча тезләнеп... нишлиләрме дисәң, ашык-пошык бодай тутыралар. Состы болар, малай-шалай дип санга сукмаумы, күрми диләрме? Әйтергә дә оялам, әйтми дә булмый — орлыкны кире бушаттылар... Хәлләрен аңлыйм, тик нишләмәк кирәк: урман — колак, кыр — күз... Урманнан күзәтергә атка атланып менгәннәрен күреп, танып калдым: болары миңа контроль, урман буе аулак бит... Агайларга әйтеп акланып кына булмый.

...Өченче хәл Марҗа елгасы буенда булды. Егермеләп хатын-кыз көрәк белән җир казый. Хәлсезләр, кая ул кайрактай җирне каерып алырдай көч — чокып-чокып баралар. Үз бакчасында чирек гектар җирне җәйләндереп чыккан инде алар... Ясмыклы капчык авызын чишкәч дәррәү ябырылдылар. Берәр учтан да күпме кими... Сосып бетерәләр ич, тизрәк чәчәргә кирәк! Тыеп буламы, җиргә ятып, кантарлы туфрактан да чүплиләр. Ач бит барыбыз да, сер бирмәсә дә, һәркем үз хәлен үзе белә...

Идарәдә кисәткәннәр иде: сез чәчтергән җирне тикшерәбез, нинди тишелеш — бөртек күпме төшкән, шунда ачыкланыр, дип. Ясмык чүпләүчеләр әллә каян күренеп торадыр, персидәтел килеп чыкмагае — җавапны мин тотасы... Бу кишәрлектә сыңар ясмык та чыкмас инде, такыр калыр. Ичмасам, юл буенда ук... Йомыш тапкан булып, соңыннан бернichә тапкыр килеп карадым. Башта кара җир күреп кот алынган иде, аннары, ходайның рәхмәте, андый да уңганы булды микән ясмыкның! Әллә бик тырышып «сирәкләү» килештеме? Ә бит алар көрәк белән кырны актармаса, ачы әремнәр генә чаларып, җилфердәп утырыр иде...

Әлеге урынның «Марҗа елгасы» дип аталуы шуннан — язгы ташуда юлаучы хатын баткан икән заманында, соранып йөрүче булса кирәк. Фаҗигале үлем тәртибе буенча — шунда күмелгән. Ачлыктан бетеп, вакытсыз җир астына кергән авылдаш апалар, сеңелләр, балалар күпме зиратта — моннан күренеп кенә тора каеннары... Ач үлемнең куркусыннан җил елаганга бер дә охшамаган — кояшлы, тыныч көн...

## Ялчек юлы

Әткәй атта юртып үткән имин юллар, тигез еллар безгә җәяүгә калды — Ялчек тагын да ерагайды. Ике кулны селкеп йөрү булса бер хәл — куллар «уфалла»га береккән — җәплекәч өстери. Йә үзебез суккан кирпеч, йә утын — урманнан инде бер кайткан ул, җелегеңне суырып. Юл хәлен атлы да, җәяүле дә түгел, «уфалла»га җигелгән бала

белә: кайда үр менәсе, кайда тау — башың жиргә тигәнче, үпкәң авызыңа килгәнче бөгелеп тартасы. Йөрәк сикереп-сикереп чыгардай булып кага, чигәләрне төя. Тик беркая да китә алмый — «уфалла»ның моторы ул... Кайчан жиргә утырып, аякларны сузып хәл жыярбыз, дип алга карыйсың. Жәяүлегә янчык та авыр, ә монда бит капчыкка да сыймый торган йөк.

Тәгәрмәчләр дегетләп — әйбәтләп майланган, эшкә йөргәндә дегет лагунынынан өлеш чыга. Тамак кына коры... «Барганда алып барам, кайтканда миңа ышанма!» — ди икән бәрәңге. Барганда да юк әле: сәрдә, кычыткан, чөгендер яфрагы алып бара, кем әйтмешли — «кәжә пылавы...» Алабута алып кайтырга тиеш — «кәтер»е кесәдә...

Ризыкка сүз әйтергә ярамый — гөнаһ, диләр иде. Гайбәте түгел, гадәте — алабутасы авыр иде, теш арасында чытырдый, эчне киптерә... «Уфалла»ны юлда калдырып, әрем арасына йомран сыман юлдашлар чүмәшкән, кулларында чыбык... Ашасаң — азык түгел, чыксаң — язык түгел, дип, шулай интеккән әйткәндер.

Алай да, алабутага рәхмәт әле, иген уңмаганда ул уна. Хәтәр елны сизенеп чыга, күкрәк киереп үсә. Учыңда уып, өф итеп өреп бак: чем карадыр, чиелдап-елтырап күзеңә текәлгән: «Әһә, жанкисәгем, мин кирәк булдыммы, ялынычың төштеме, тәкәббер карый идегез»,— диме, әллә кызганамы...

Шактый гомер үткәч, мәртәбәле банкетларда кара уылдык та алабутаны хәтерләтә иде. Беребезнең:

— Моңардан сугыш вакытында да туйган инде! — дип шаяртуын кем ничек аңлагандыр. Мондый табында бик хасиятләп төрле үләннәр дә куела, нәзәкәтлек белән, чеметеп кенә алган буласың, вегетариан аш дип, диета хакында зыялы сүзләр булып ала. Сәламәтлеккә файда, ашказанына жиңел икән, гомерне озайта. Кордашлар:

— Без сугыш чорында киселдек шул, гомер кыскаргандыр,— дип офтанса, юатам:

— Киресенчә — кимендә ун ел ашказанын ял иттердек. Диетада булдык,— дим.— Сыер сыман... Безнең гомер шунда озаеп калган!

...Бусы Ялчек юлыннан, 1943 тән сиксәненче елларга барып килү... Сүзне ялгап — тамак ялгап килү булсын... Шул киләчәккә өмет баглап тарттык бит авыр йөкне. Ялчек юлыннан шактый йөрелде. Берничәсе аерата истә... Жәй рәхәте — арбада, кыш рәхәте — чанада, диләр дә, без жигелеп тартканда икесе дә бердәй михнәт иде.

## Дөньяда күмәч бар микәнни!

Күчәребез жиңел: паласка төргән ике күпчек кенә салдык. Юл уңса, кайтканда авыр булыр, дип исәпли әнкәй. Андый авырлыкка без шат инде: ничәшәр чиләк бәрәңге бирерләр икән?

Байтирәктә ничәмә йортка життек, капкадан уздырмыйлар, чыгып та карамыйлар — юк, кирәкми аларга мамык мендәр. Көнгә чыккач, капка кагучы күп шул, түрләр тулган инде... Безгә мендәр бик кирәк тә, бәрәңгесе кирәгрәк. Йокы ястык теләми, корсак мәми сорый — коры сәкедә дә аунар идем әле, ди. Баш астына бишмәт бөкләп тә ятар идек, бәрәңгесе булса. Чикмәнлесе бигрәк тәмле! Әле ул күз алдында чуваш чикмәне кигән хәлдә тора... Чишенделәр безне чишенделәрүен. Әйберең үтсә, шат инде. Әнә, сеңелемә Ленинград күчтәнәче — кызыл сандалиен әнкәй ничә тәрәзәгә сузып карады, баш кына чайкыйлар. Төш узып, инде өмет өзгәч, бер хатын ялындырып кына, бездән булсын яхшылык дигәндәй, ике күкәйгә алмашып бирде. Бусы да ярады, авызга тәгам алмаган идек, ике сандалины кабып йотканны сизми дә калдык, кече телгә дә йокмады. Әллә күкәс бәләкәй иде, әллә ачыккан авыз ашыкты...

Йорттан-йортка йөри торгач, берсендә ишегалдына керттеләр, баздан чыгарган бәрәңге кояшта кибенеп, ялтырап ята... Бусы — үзләренә, безгә дигәне лапаста — черек-мерекләрен шунда ташлаганнар. Тырыштык инде, әйбәтрәге чәчүлеккә ярар диебрәк, сайлап тутырдык. Күпереп торган ике мамык мендәр өчен берничә чиләк бәрәңге...

Кабаланып бәрәңге чүпләгәндә өйдән чыккан хуҗаны күрдем. Бригадир йорты дигәннәр иде, үзедер. Ничек сугышка бармады микән — тап-таза кеше? Гаҗәбе ул түгел — каерып кына киселгән, мамык мендәр сыман кабарып торган... ап-ак күмәч! Яраббым, күзләрем алдашмыймы, дөньяда күмәч бар микәнни, исән микәнни?! Ак күмәчтән күз алларым караңгыланып китте... Яктырганда инде бригадир аны кесәсенә шудырган иде — кырда карын ачса дип алуыдыр. Миңа шул кайткач сөйләргә генә калды. Теге, әткәй базарда күреп кайткан, бер урыс ашап торганны, дигән мәзәктәй. Бусында — чуваш агай...

Күмәче — Байтирәктә, безгә — «ярлытирәккә» шул мәзәге генә. Бәрәңгенең үзен юксынып та, җәлләп тә җырлыйбыз, ул мескен, күпергә чыгып асылынган, мондый язу калдырган ди: «Иртә дә мин, кич тә мин, учакта мин, пичтә мин. Чыдый алмыйм һич тә мин, асылынам кичтә мин...» Җырлыйбыз дигәч тә, чамалабрак инде, бәрәңге янәшәсенә асып куюлары бар...

Сугыш елларында безне Чувашстан җире коткарды дияргә була, рәхмәт үзләренә. Көлсу туфраклы дип, аларга налог азрак салына, икмәк үзләренә дә кала икән. Ярый әле «тутар тус»лардагы кебек кырып-себереп китмәгәннәр, кая барып егылыр идек?

## Буш кайту

Мендәр-ястык ялындырып үтсә, кирпеч һәрчак кирәктер дип, бу юлы уфаллага кирпеч төяп киттек. Мендәр түгел, шактый саллы. Исән-имин генә барып ирешсен. Күршеләр әнә бакча казый: утыртыр да, безнең чәчүлек һаман Ялчек юлында. Бакчаң сузаеп калса, аяк сузасың хак башында...

Ярты юлны үткәч, утырып тамак ялгадык. Төенчектә «мәтык» коймагы. Кырда җир казып, былтыр калган бәрәңгене эзлисең, крахмалга әйләнгәне дә килеп чыга: кершән кебек ак, кояшта җемелдәп тора. Шуны пешерсәң, үтәли күренә торган, бик тәмле мәтык була. Үзебез дә үтәли күренә торганга әйләнеп бетмәсәк ярый инде...

Ху-уш, барып та ирештек, инде «кызыл малны» урнаштырасы. Ул кирпечләр тук өйләрне безнең утын белән җылытыр, хуҗаларга күпереп торган күмәч, битләре килгән кабартма пешерер!

Хуш, диделәр шул безгә, килү бушка булды — кирпеч үтмәде... Кирпечне кире алып кайттык, саны артмаса да кайтыр якка авыррак иде. Әмма сыйфаты әйбәт икән, җиренә җиткереп эшләгәнбез: утыз чакрымнан артык шылтырап әйләнгәндә дә ватылмаган иде. Барысы да бөтен көе кайтты...

## Җан биргәнгә — җүн бирә

Җан сакларга кайда нәрсә юнәтеп була, белешеп-«иснәнеп» кенә торасың, бар кайгырткан, сөйләшкән — шул. Әнкәй ишеткән, крахмал заводыннан бәрәңге түбе алып була ди, утынга алыштыралар икән. Киттек без дә корырак, күркәмрәк утынны чанага салып. Чират иде капкасына — безнең ишеләр тезелешеп көтә. Колхозлар ферма терлекләренә ташый. Безнең нәүбәт җиткәнче, эңгер-меңгер төште. Зур

икән заводның түп җыела торган җире... Элеккесе каралыбрак тора, яңалары аграк, ерганак булып агып чыга. Бозлы судан үрелеп, сыгып-сыгып аласың да, йомарлап — капчыкка. Кул әрнегәнгә түзәсең инде, ашкынып җыйганда кызышып та китә. Су белән, тир белән баштанаяк юешләнеп юлга чыктык: кайта-кайта өстә кипшенер әле киемнәр...

Туктап тын алганда күккә карадым — йолдызлы төн икән. Көндезге юештә киреләнгән чаналар җырлап чаба. Чананың «уфалла» кебек кушаматы юк шул. Үзебез дә өйгә ашкынган ат сыман... Соң гына кайтып ирешсәк тә, бәрәңге түбен пешереп карадык, язгы өзекне ялгарлык иде. Иртәгесен дә бар шатлану шуның өчен булды. Тагын барыйк дип сүз куештык. Тик яз өлгеррәк булды, ашыга төште, кар астына су йөгертте, юллар гөбердәп бата иде — юл өзелде...

Инде ничәнче хәвефле язда юллар өзелде. Кышлык бәрәңге, кабакның бетеп килгән чагы. Юл өзелгәндә дә өмет өзелмәде: җан биргәнгә юнь бирермен, дигән. Алай да, ходайдан көтеп ятма, үзең казган, дип кисәтә өлкәннәр.

## Хикмәтле «лорх»

Таптадык инде Ялчек юлын, такырайтып бетердек. Сугышка хәтле алган әйберләрнең күз төшәрдәен бәрәңгегә алыштырып тордык, өйнең мамыклары шул якка очты...

Күршеләр бәрәңге утырта. Ник сузасыз, соңарасыз бит дия башладылар. Чәчүлек юк димисең, сер бирмәгән буласың. Кеше-кара күргәнче, иртә-таңнан чыгып киттек. Әткәй кайткан төшкә, дип саклаган юрганга да чират җитте. Бәхет йокламаган икән, ходайның рәхмәтле чувашына туры килдек. Мөлаем хатын иде, бәрәңге пешереп ашатты, берәр стакан сөт тә куйды. Ире фронтта, кайткан төшенә зәңгәр сатин тышлы матур юрган булды, дип сөенеп калды.

Кулы җиңел булды ул хатынның. Бу баруыбызда юл уңды, әнкәй әйтмешли, фәрештәнең амин дигән чагына туры килгәндер. Юрган хакы ниндидер «лорх» дигән сәер исемле аксыл-сары бәрәңге иде. Күргән-белгән сорт түгел, ай-һай, уңармы, бакча тутырып шуны утырттыгыз, дип баш чайкады күргәннәр. Бүтән чарабыз юк иде... Әмма баш чайкыйсылары көзен икән әле. Бәрәңге төбен көрәк белән каерып торып таратып җибәрдек — илаһым, әллә иллеләп инде, эредер үзләре! Тоташ сап-сары буразнаны күршеләр килеп карады, кызыктылар, күз тимәсен, дидек. Менә әкият! Зәңгәр юрган сал да, алтын сары бәрәңге җыеп ал! Безнең авылга «лорх» бәрәңгесе шулай керде. Кызыгып, чәчүлеккә сораучылар булды, шулай таралды ул. Тату булсаң, бөтен авылга бер юрган җитә икән...

Вакытлар узып, район газетасында эшләгәндә, авыл хуҗалыгын «тирәнрәк» өйрәнгәч, Зур Совет Энциклопедиясендә Лорх дигән... галимгә юлыктым. Теге үрчемле, чыдам бәрәңгене шул галим китереп чыгарган икән. Сурәтенә чын рәхмәт хисе белән карап тордым. Зиннәт бабама охшаш кебек күренде. Рәхмәт сиңа, Александр Георгиевич, дидем. Исән-саумы икән дип, гомер теләп тордым аңа. Социалистик Хезмәт Герое, СССР Дәүләт премиясе лауреаты, профессор. Бәрәңге профессоры! Менә бу галим, ичмасам. Юкса, профессорлар арасында да ник бәрәңге ашаганын белмәүчеләр аз мени. Аңа багышлап шигырь дә бастырдым, үзенә җибәрим микән дидем. Ярар инде, күңелләрдә калган, үзе белмәгән яхшылык, рәхмәт запасы булу да кирәк кешегә...

Икенче өстәмәм — кырык елдан соң Ялчек якларына кайтуым турында. Бусы инде Казан аркылы... Ике ел рәттән әдәбият-сәнгать атналыгында булдык, сугыш елларында йөргән авылларны уздык. Байтиракне бик текәлеп карадым, шактый вакыт узган шул — таный алмадым... Әллә

бүтән авыл идеме? Бәлкем, авылыннан бигрәк, өметләнеп караган тәрәзә-капкаларны гына күргәнмен ул чакта... Ә таллары, бигрәк якын, безне дә танымыйсыңмы, дип моңланалар... Кичерегез, талкайлар-тирәккәйләр, тукның күзе хикмәттә, ачның күзе — икмәктә, диләр, ул көннәрдә сезгә бик җентекләп карамаганмын шул.

Авыл кешесенең, шәһәрдә җиде ел яшәсә дә, авызыннан сала бәрәңгесе күренер, имеш... Яшермим, күренсен әле бәрәңге, «икмәктән олы түгелсең» диләр, бәрәңгедән дә олы түгел без. Ялчек юлыннан кырык елдан соң моңаеп, сагышларымны эчтән тынып узганда шул хакта уйландым. Әткәйнең чуваш «туст»ына багышлап язган шигыремне, «Авани, тус!» — дип, сәхнәләрдән укып йөрдем. Илле ел элек күргән бер мөлаем караш та онытылмый.

Ялчек юлына әле дә тузан кунмый, күршеләр ярдәмләшеп яшиләр. Аман юллардан имин еллар узсын...

## «Чукынчык»

Персидәтелне районнан пешереп-өшкереп кайтарганнар — кызуы безгә дә тиде:

— Тирес чыгару аз! Төзәтергә кирәк!

Читават белән хисапчыны, ягъни мине орыша. Тиресне без чыгармыйбыз да, сводка безнең кулдан чыга: мәгълүматны бригадирлардан мин җыям. «Пред»нең кызарынып-бүртенеп эчен бушаткач, сүгенеп куя торган гадәте бар. Әле дә шуны ишеттек:

— Чукынчык! — диде. Әллә безгә бусы, әллә район тарафына.

Үзе артында аны шулай атап йөртәләр дә:

— Теге «чукынчык» кайтмадымы әле?

— Кайтты да, керми торуың хәерле, кәефе юк — йомышың уңмас...

Сугыштан бронь белән кала килгән, хатын-кызларга җитәкчелек итә торгач өйрәнде микән аларча сукранырга? Ә «бронь» сүзен баштарак «борын» дип белә идем. «Борын» белән калган, дигәч, ни булды микән, сугышка ярамастай күренми бит борын шәрифләре дип баш ватам — кызылрак, дошманга еракган күренер, дип алмыйлар микән? Анда бит иң әүвәл курок тарта торган бармак кирәк. Ә аның ун бармагы да аллага шөкер, кыска-юантык булса да, бөгелә торгандыр, үзенә таба кәкре дигәннәре комачау түгелдер — безнең борын төбендә уйнаганда, төртептөртеп сөйләгәндә гел туры була ул бармак!

— Сводка бүген үк төзәтелгән булсын штубенки! — диде әле дә. Әмер кискен иде, тирес чыгаруны арттырырга кушылды. Нәрәткә килгән бригадирга сүз кушам:

— Хәсән абый, бүген ничә олау чыкты?

Дәшми. Өзеп кенә «юк» дигәнче, кисәтеп өлгерәм:

— Ишеттең бит «пред» ни дигәнне?

Ишеткән, тик ашыгып төшми. Кичә дә чыкмаган тирес, уена да кереп чыкмаган, бүген дә юк. Аның кайгысымы. Мин белгәнне ул да белә. Чана салулаган юл читләренә, күпер төпләренә аударыла инде, кәнүшнидән ерак китә алмый — кар сөреп йөрерлекме атлар?

— Яз инде, ни... егерме олау.

— Көнгә күпме тиешен беләсең. Әле үтәлми калганы күпме!

Түшәмгә карап уйланган була бригадир. Икәүләп тирес «җыя» башлыйбыз:

— Хуҗалыклардан юкмы? — дип, янә бер чыганакка этәрәм.

— Ну, тагын фермадан бардыр...

Фәлән-фәлән олау өстәлә. Тырыша торгач, үзебез дә җанланабыз, дәрт керә, күзгә күренеп арта бит, цифрлар матурлана! Биш бригадир белән шулай, заемга яздыргандай кыстый торгач, йомры-йомры күңелле

саннар оешты. Шикле түм-түгәрәк булмасын дип, берәмлекләр өстибез... Әзер сводканы күргәч, рәиснең авызы ерылды:

— Тырышсагыз була икән, чукынчыклар! — дип, киң күңелләнеп мактап та куйды, күзләрен миңа текәде. Керфек какмыйча, уйсыз-буш бәбәкләрен тирәвенә гел ияләшеп булмый. Өстәп язган буш нольләр сыман иде алар...

Куен кесәсендәге вазелин тартмасыннан сабы киселгән пичәтен алды да, телен чыгарып башта шунда басты... Киресенчә төшкән «Ирек» колхозын төкерегә белән йотты да, түгәрәк пичәтне кәгазьгә шапылдатып, кыйммәтле цифрлар таралмасын-очмасын дигәндәй, ике кулы белән нык кына, озак кына басып торды. Күзләрендә «телеңне тыя бел!» дигән янау очкыннары... Башта үз теле буялды ла...

Йомышы төшкәннәргә урамда, кырда, кәнүшнидә булсын — пичәтне шулай телендә юешләтеп ала. Ул моны бер горурлык белән башкара: күрәмсез, нинди гади сезнең җитәкчегез, ягъни, мәсәлән, кәгазь корты түгел — прастуй кеше, дигәндәй тантана белән карап тора. Аңлаган кеше аңларлык — язмышың шушы пичәттә, шушы вазелин савытында...

Кош тизәге, көл җыю да шактый артты ул көннәрдә... Кош тизәге — кетәктә, көл — учакта, моржага ут капмаса, корымы да бар. Җил очырмаса, яңгыр үтмәсә... Нәүбәттәге киңәшмәдән персидәтел кәефле кайтты:

— Мактадылар! Үрнәк итеп куйдылар! Зур үзгәреш — тәнкыйтьнең файдасы, диделәр. Кисәтүем бик вакытлы булды!

Капылт кына саннар кабарганны күреп: «Сиздем эшеңне, коярмын тешеңне!» — димәгәннәр, юкка шүрләгәнмен. Аларның да хисап бирәсе бар, Казан да кысадыр. Казан тулы шундый саннар микәнни, «чукынчыклары» кыса торгач? Менә шулай, бик яшьли күз буяуда катнашкан булып чыктым. Күптән инде без саннар белән эш итмибез. Әмма түшәмгә карап... җир ашлаучылар бетми бит, бу өлкәдә булмаса бүтән тармакта. Исәпкә — бар, санга юк үзләре, чукынчык!

## Әвен җылысы

Иргеннәрне җыю шактыйга сузылды. Карлы басуда тырпаешып, җил-буранга кушылып шыелдаган ябык арышларны чалгы белән чабарга йөрдек. Бөртегеннән бигрәк, гектар чуты — мәгълүмат өчен кирәк булгандыр. Андагы суык, андагы туңулар — җелекләргә үткән иде. Кинәнеп эшли торган булса, җылыныр да идең. Ялан кырда, аның да түрендә — җил уйнаган үрендә. Ялгыз карамадан башка берни юк, ышыкланыйм дисәң, кая сыенасың? Тик торсаң да яман — соңгы җылыңны өреп чыгара җилләр. Авылга ерак, өйләгә дә якын түгел...

Шул чакта бик кадерле булып җылы исе һәм төсе — күксел төтен килде... Әвен дигәннәр иде, сызылып кына шуннан чыга икән. Базына төшкән идек — җан рәхәте! Оҗмахка тикмәгә елның иң җылы фасылы сайланмаган. Әвенче карт мичендә утын өсти, без рәхәтләнеп җылынабыз, күшеккән куллар әкренләп языла. Югарыга карасаң сайгаклар тезелгән чатыр бу, өстендә сары көлтәләр. Ничек очкын чәчрәп ут чыкмый... Күтәрелеп җиткәнче сүнә икән. Алла сакласын, чыгып та өлгерә алмассың, күзем тия күрмәсен, тфү, тфү! Әвенче үз эшен белә, ул тыныч. Мин бу җылыны, бу рәхәт исләрне кайчандыр тойганмын төсле... Кибәннәр елышып утырган ындырыбыз бар иде бит. Бики тау астында — инеш аръягында, күперне чыккач та. Такыр ындыр табагында чабагач тыкырдатып иген сугалар. Кыш... Әвендә кипкән көлтәләр булган икән, шул ис хәтеремдә! Кибәннәрен эшләр җиңеләйгән чорга — кышка калдырган игенче, иң әүвәл яңгырларга хәтле җыеп-җыештырып куйыйм дигән. Кайсылары ничәшәр ел торган — маясы шулай сакланган. Үзенә күрә келәт инде ул кибәннәр. Тирәләрендә, яңа яуган кар өстендә, тычкан

эзләре, куян эзләре бар иде... Аерым хуҗалык чактан шулар хәтеремдә калган икән.

Япан кырда офыктан-офыкка сыеша алмыйча бәргәләнгән үткен карлы кыш патшалыгында чатыр корып әвен поскан, базы тулы җәй. Шул җылы белән без эшне очлап, авылга да кайтып ирештек. Бабайлар тәҗрибәсен — әвенне искә төшергәч, көздән үк базын казыткан, утынның корысын китерткән картларга рәхмәт инде.

Куллар өшер дәрәҗәдә туңгач, сөм тоймый башлагач, иң читене — җылыга кергәч: тәннән салкын киткәндә әрнешеп сызлый. Ул мохтаҗ еллардан соң алай ук туңган юк шул, мамыклы җылы чор килде. Ятимлектән әрнегән җанның сызлануы да басыла төште бугай...

Туңып әрнегән кулыңны тының белән җылытмак булып өргәли идең. Өмет, ышанычың белән елларны җылытмак булып яшәгәнсең... Без эшләгән ул басуларда әвеннең эзе дә калмаган, хәзер инде белүче дә юктыр. Ул иң соңгы әвенне мин онытмыйм. Искә алгач та күңелләр җылынып китә... Ялгыз карама ата җилдә әле дә туңып торадыр...

## Зәңгәр күзле Фәтхелислам

Бөдрә таллы Чирмешән борылышына авылдан аерым утрау булып өч йорт сыенган. Якублар белән кара-каршы Фәтхелисламнар. Безнең бәрәңге бакчасы да шунда койрык белән сузылган, эшкә барсак-кайтсак та, бер тирәдә без. Берара Фәтхелислам белән икәү Казаклар чатына бер кишәрлектә җир сөрергә йөрдек. Атланган төшләр уелып беткән, сөяккә-сөяк туры килгәндер, ян белән теркәләсең. Сүзгә бирелеп кенә онытсаң инде. Шушы бергәлеккә күләгә төшкән бер хәл булды...

Бригадир бу юлы сукага үземә генә әйтте: урман буенда калган җир бар, бетереп кайт, сабан-камыт шунда, диде. Киттем ялгызым гына, җырлап. Берзаман атка атланып Фәтхелислам килде. Кызык булды: аңа да әйткән бригадир, икебезне бер сабанга җибәргән! Икебез дә камытка ябыштык: мин җигәм дә, мин җигәм! Башта шаярып, аннан чынлап торып китте тарткалаш! Авылдан шактый ерак без, кайтып йөрисе килми, тагын кайсы басуга куша бит, әрле-бирле көн уза! Фәтхелислам усалланып үзенә тарта, зәңгәр күзләре зәңгәр боз сыман. Дус диген... Камыт аңарда калды, ул җикте атларны. Кайтып киттем, ә күңелдә үпкә... Шулай да, оныттык моны, кенә кумадык: эш өчен тарткалаштык ла. Малайлык инде, һәркем үзенекен итмәкче.

Малайлыктан чыгып барабыз икән. Фәтхелислам 1927 елгы иде, армиягә алдылар. Инза шәһәрендә снайперлар мәктәбендә укыды, хат алыштык. Ашыктырганнар, кай арада өйрәтеп, сугышка керткәннәр диген, үлгән хәбәре дә килеп җитте... Зәңгәр күзле дус монда да өлгеррәк булып чыкты, сугыш камыты аңа эләкте. Теге көнне миннән тартып алмаса, сөрәсе җире, миңа рәнҗүе калыр иде, ярый ла юл биргәнмен дим.

Йортлары яшел тәкәрлектә, кушаматы — «Акчарлак» иде. Чирмешән буена кунаклаган өчен шулай куштылар микән? Әллә әтисе ак кашлы, ак керфекле булгангамы? Кушаматы да матур бит, үртәгәч ник ачуы килде микән? Ник үртәдек икән, диген... Акчарлакның күзләре нинди була — зәңгәр микән? Сугыш бетә-бетә дип торганда, соңгы пуляларның берсенә барып өлгергән Фәтхелислам... Озаграк укыткан булсалар, тиздән кайтып, камыт өчен тарткалашканны көлеп искә алыр идек: муен булса, камыт табыла икән бу дөньяда, дияр идек. Башлар гына сау булсын, дип тә өстәр идек әллә...

Урман юллары. Урман кисәргә җибәрүләр ел саен бер куркытып ала. Бригада оешып, кыш буена китәсе лә, кыш буена, үзенә дүрт-биш кубометр утын салу гына түгел. Быел нәүбәт безгә дә житте. Фронтка кирәк — паровозлар утын ягып йөргән чак, шахталар көтә. Таләп кискен, тәртип каты: авыл советына задание җиткерелгән — кеше тап, фәлән кубометр агач кисеп озатылсын! Өс-башың ничек, кар ерып эшләрлекме, өйдән читтә яшәргә азык-төлек бармы — анысы синең хәсрәт. Тиз генә җыенып, китәргә тиешсең, икеләнеп, зарланып торырга юк. Утызлап хатын-кыз, ир затлары — Салих белән без икәү. Ярый әле бергә, җан тынычрак. Таза егет, мәлен-әмәлен белә, урман эшендә батыр. Ни барны төенләп, бәрәңгене җылырак төреп, талчыбыктан үрелгән әрҗәне чанага салып, икәүләп җигелдек. Әңгер-меңгер житкән иде, буран да кузгалып тора. Әмма район кушкан, андагы буран яманрак, тыгызлыйлар:

— Бүген үк чыгып киткән булсыннар!

Бурап-бурап юлга буран салган, кар ерып чана өстерибез. Бу якка йөрүче сирәк, чана юлы төшмәгән. Буран көчәйгәннән-көчәеп, күзне ачырмый, җиле кисә. Юлны югалта башладык, адашмагаек... Төн, караңгы. Көч-хәл белән Биябаш авылына ирештек: шунда кунарга, таңнан кузгалырга булдык. Авыл советы сводка биргән, без инде урман эшендә...

Һай ул өй җылысының рәхәте, кайнар мичтә җылыткач кулның татлы-әрнүле җемел-җемел килүләре... Түзәсең, бер генә түзмәгән, әрнер дә бетәр, аннары җиңел булыр. Әрнүле еллар да шулай бер үтәр... Өтте инде, кисте ачы бураннар. Дәреслектәге шигырь телгә килә:

Урамда буран,
Мин өйдә торам,
Тәрәзә аша
Тик авыз ерам...

Тәрәзә аша гына ерыла икән, салкын бөрештерсә, өшегән авыз таслапҗайлап сөйли алмый. Кыш буена китәбез, ят кешеләр арасына, авыр, хәтәр эшкә... Җан тыныч түгел, әмма буран канны кайнарлатты, мәхәббәтем дигән татлы серемә биреләм. Имеш, китәм, имеш, яратканым кала:

Тал бөреле, тал бөреле,
Тал бөреле була икән;
Җан яраткан, күңел тарткан
Яр бер генә була икән...

Шушы бик таныш җырны, әле генә үз тынымнан тугандай, көндәлегемә язып куям. Җан яраткан... Анысы да хыялда гына. Мин киттем, ул аулак өйдә егетләр белән зәлидә әйләнә, «моржа ябарга» чыга... Көнләшү сыман нәрсә йөрәкне чеметеп ала. Ә соң, әкәмәт, хакың бармы — ул үзе дә белми... Урамда түгел буран — минем күңелдә. Хыялның да «тәрәзә аша тик авыз еруы» ихтимал. Ник шул хәтле «мәми авыз» мин, дигән «кыю» фикер килә — үкенү мәшәкатьсез шул...

Күңелдә бүтән борчу калка: чыгып китәр алдыннан гына авыл советы миңе бригадир итеп билгеләде: учетчик, бригадир ярдәмчесе булган, исәп-хисапны беләсең... Урман — иген кыры түгел, ничек булыр? Ярый әле, өйгә кышлык утын әзерләп, ташып калдырдык.

Әлеге буранлы көн 1944 елның 18 ноябре дип теркәлгән. Берсекөнгә урманда 16 яшем туласы — метрикам булмагач, тәгаен белмәгәнмен...

Урманда буран. Бер караңгыдан икенче караңгыга чаклы урманда без: агачлар шәйләнә башлаганда киләбез, карурман булып кушылгач — кайтыр юлга. Балта — билдә, пычкы — иңдә. Якты көндә баш кү-

тәрми эшләгән, агач еккан, метрлап тураган, ташып өйгән кешеләр кайта... Гәүдә ватылган, аяк-куллар җилдә шаулаган агачтай гүләп-зыңлап тора, төптән кискәндәй аварсың төсле. Ничек кенә кайтып егылырга... Шушы газапны кабатлар өчен таңда янә ашыгып кузгаласы. Үз хуҗалыгыңа утын әзерләгәндә чиге бар, берничә көннән бетәчәк. Үпкәң авызга капланып, йөрәгең кызып-кызышып, күз алларың томаланганчы җиргә иелеп пычкы тартасың... Бетмәс-төкәнмәс интегүдән арынып, кайчан бер тураеп агач башына карармын, пар күтәрелгән бүрек белән битемне сыпырып, күкрәк тутырып сулармын? Иге юк, чиге күренми: иртәгә дә, киләсе айга да, кыш буе газап көтә. Урман кисү, таш кисүгә тикмәгә каторжаннар куылмаган. Без шундыйлар рәтеннән алайса...

Менә шул эштә солдаткалар, үсмер кызлар. Йортта ир заты барында алар урманга баш тыкмаган, арба-чаналарда көйле шыгырдап, таза ис аңкытып имән яркалар ишегалдына килеп кергән, күңелле булган. Кайчакта каралтыда кулдаш булып пычкы тартышсаң да уен гына — ир кулы нык, ипле йөрткән, авырлыкны сиздерми генә үзенә алган. Инде шул пычкылар урманда: еллар буе каралмаган, кулдашың да йолкып-йолкып тарта, син дә аңа салынасың — бер-береңне талкыйсың... Пычкы тоткалары, балта бушаган, үтмәс тешләре кысылып беткән. Күгәргән балталар, кисүдән бигрәк, сугып сындыргыч тукмактыр... Менә шулар белән эшлә, норма тутыр. Күбесе буш кул белән килгән, аптырап тик тора агач белән янәшә... Ярый «лучковый» дигән пычкы бирделәр — нәзегрәк агачларга «теше үтә»...

Кышкы урманда кар билдән: ерып-йөзеп йөрисең. Агач аударганда төбен таптыйсың, ботаклар тазартканда, буын-буын кискәндә кәүсә буйлары такырлана, әрле-бирле ташып өйгәндә тәмам ындыр табагына әйләнә...

Урман кисү — балта чабу, пычкы тарту гына түгел. Менә, агач төбенә килеп бастың, кай тарафка аварга тиеш ул? Төшәр җире нинди — терәлеп калмасмы? Кай яктан ләке аласы? Әмәлен белгән кеше бер карау белән чамалый. Хатын-кызның урманчылыгы шундый гына — килә дә чажчоҗ, каян туры килде, шуннан кисә башлый. Тик гөрселдәп авасы юкә янәшә өрәңгенең карын коеп кочаклый да, аерылырга теләмичә селкенеп-дулкынланып тора... Кисүчеләр читкә качып, кызыксынып шуны күзәтә, башларында нинди уйдыр... Ярдәм кирәк боларга, күсәк кирәк — әкрен генә агачларны каерып шудырасы, җиргә егып саласы — баш очында әҗәл булып тормасын.

Кышның бураны — чеметеп-чәнчеп алган кары була, җебеткән юеш көннәре дә... Ни булса да без урманда, ышыкланыр урын юк. Аяз көнне дә күктән кар ява — агачка балта белән суккан саен өстеңә, яка эчләренә тула.

Тәңкә карлар яуганда урман бик матур, матурлыкны без дә күрәбез аны. Өстеңә явып, тирләп-пешкән аркаңа сеңеп торса гына җайсызрак. Урман тавышлы, урманда кеше күп, яңа кишәрлек ачып эчкәрәк үтәбез. Йөзләгән хатын-кыз, яшүсмер эшләгән карурманда корбансыз булмады: агач ава, кешеләр ава... «Агач баскан!» Бу яман хәбәр дәрманны суырып, тез буыннарын дерелдәтеп ала. Бәла — аяк астыннан чыга, диләр, урманда исә бәла күбрәк өстән төшә — фронттагы кебек. Баш очымдагын мин дә күргәләдем...

## Моң

1945 ел безгә урманга килде... «Каршыладык» дия алмыйм, бәйрәм итәр чак түгел — гамәлдә юк. Бәйрәме булмаса да, Яңа елны ике ай көттек. Урман әле дә кочагыннан ычкындырырга ашыкмый. Ниһаять, форсаттан файдаланып, күндәм чаналарны авылга бордык. Бераз хәл

алырга исәп. Кешеләр дә алмашына — алай җиңелгәрәк килә, көч янара. Бусы бригадирга кагылмый, диделәр, урман юлын, исәбен белгән бирәү калырга тиеш...

Яңа елның икенче көнендә кайттык. Тәмам тынычланып, учак төтене сеңгән көндәлекне онытканмын. Каләмгә тартылу — шигырьгә иң якын килгән чак иде. Ул көнне яхшы хәтерлим. Шау-шулы вакыйгалар истән чыга, ә күңелнең тәэсирле бер халәте гомергә кала. Тойгы-вакыйга буладыр ул!

Ак бураннарга уралып, йомшак сыйпап иркәләвен тоеп дөнья тын калган. Кырыслык, авырлыклар кыскан җаның иркенлек тели, бушану көтә. Моңлы, сагышлы күңелнең татлы сызлаган чагы. Яклаучысыз, ятим бала өчен гадәти күренештер. Яшәүнең олы мәгънәсе, кадере ачылган көнем бу. Шушы ак-саф мохитта мин дә кирәкмен, әйтер сүзем бар. «Моң» дигән шигырем шул көнне язылды — 8 гыйнварда. Менә ул:

Язам әле җырларымны,
Укырсыз, калсын монда.
Әйтерсез, булган баланың
Башы кайгы һәм моңда.

Гаепләмәгез елларны,
Еллар гаепле түгел.
Нәрсә әйтергә белмәгәч,
Әйтә моны тик күңел...

Сагынырсыз кайчак мине,
Һәм укырсыз җырларны.
Күреп җырдагы кайгыны,
Каһәрләрсез елларны.

...Искә алып әгәр мине,
Укысагыз җырларны,
Җырларым аша күрерсез
Мин яшәгән елларны.

Шул көнне язылган «Истәлегем туган җиремә» исемлесе дә бар. Ерак китмәсәм дә, туган авылымнан читтә уйлану-юксыну тәэсиредер. Булачак аерылуны сизенүме...

Беләсезме, безнең яклар,
Ике урман арасын,
Сагынган чакта телгәли
Шул йөрәгем ярасын...

Кояш чыкса, күтәрелә
Елга өстеннән томан,

Шунда гына, якын гына
Туган ил тора сыман.

Белмим ник алай икәнен,
Туган ил якын була,
Әллә шунда үскәнгәме,
Өзелеп сагындыра...

Тәүге шигырьләрнең очын эзли торгач, юлыктым мин аларга, «тәшенке» дип, санга сукмаганмын... Шигырь чишмәм саркып-саркып кына борынлады. Тоя идем, төшенеп кенә җитмәдем шикелле. Хыялымны да, мәхәббәт белән бергә яшерә идем. 1944 елның 22 августында көндәлеккә теркәлгән шундый юллар бар: «Бүгеннән соң... шигырьнең язылган числосын куярга кирәк». Моннан алда да нәни-нәни парчалар бар...

...Яңадан урманга китәргә җыендык, култык астыннан сүс бауларны үткәреп чанага җигелдек, әле эш бетмәгән. Тик бу юлы минем авыр юлны җиңеләйтеп, үзем өчен күк капусы ачылган, канат булган илһамым-моңым юлдаш иде...

...Урман кисүчеләр бригадиры итеп колхоз идарәсе, авыл советы Һидиятуллин Шәүкәтне җибәргән иде. Бу юлы «бер миндә ике мин» — Шәүкәт Галиев тә бара... Бу хакта персидәтелләр белми. Хәер, тегесе дә, бусы да бушлай йөри... Рәсми дөньяда бабам исеме, хыялымдагысы — Галиев — беренче шигырьләрем белән уйга килгән. Бу хакта 1950 елгы язмам бар. Район газетасына кереп бер ел эшләгән егет чагым яза (стиле заманынча купшырак булса да, нияте ачык):

«Минем фамилиям Галиев... Шигырьләремдә — шул. Үземә псевдоним эзләп маташмадым, әтием исеме торсын, аның истәлегенә һәйкәл булыр. Таш басмада күрәм дә, «син яшисең, әтием», диям. Бу исем белән эндәшкәндә тыныч кала алмыйм... Иҗат итеп яшим, минем белән аның исеме яши, истәлеге изге, горурланып кабатлыйм...»

Икебезнең исем янәшә торганда гына тулы ул, инде тулаем шуңа күчкәнмен, күнеккәнмен. Ә бит ул — минем икенче гомерем. Беренчесендә — Һидиятуллин мин...

## Салкын карда кайнар учак

*«1945 ел, 21 гыйнвар.*
*Карамасар урманы... Эшкә бардык.*
*Менә шунда...»*

Көндәлектән

«Менә шунда...» дип, серле генә өзеп куйганмын. Болай да онытылмаслык шул, оялу хәтергә уела. Уңайсыз хәлдә калдым, кыз каршында сынаттым...

Кышкы урман, чатнап-чатнап учак яна, дәртләнеп кабынып, каефле үрли. Пычкы чыжлавы, балта тукылдавы, шаулап-шапылдап агачлар ауганы ишетелеп тора, буранланып-тузгып ботаклардан кар коела. Көндәлек эш — моңа күнегелгән. Ә менә учак янында ял сирәк тия. Бигрәк тә өч десятникның бергә килеп тату гына утыруы... Көнлек кубометрларны ачыклагач, мин дә җылыга теркәлеп торам, учак безнең делянкада.

Утка карап уйланырга яратам, күңелне тын хыялларга тарта, үзенчә көйли. Ак кар өстендә кызыл учак... Кырыкмыш тай сыман сикеренгәләп йөргән Гөлчирә-десятник тә килеп утырды. Сырма чалбар кигән, башында бүрек, тиктормас чәчләре бөдрәләнеп-ташып чыккан. Иреннәре утлы күмер, чем-кара күзләрендә чатнап-дөртләп кабынган чая утлар... Бар торышы белән үзе дә тере учак ул, көлмәгән-чыркылдамаган чагы юктыр! Учак — читтән матур, якынрак килсәң — пешерә. Гөлчирә-учакка үрелеп кул җылытырга сузылучыны сизеп торабыз — десятник егет. Кыр сумкасы аскан, хәрбиләрчә кырыс кылана. Кылыч борынлы, чытык чырайлы чандыр начальник. Өченче десятнигебез — киң явырлы, шадра керәшен егете. Тач менә чегән инде! Үзе дә шул хакта сөйләп тора:

— Чегәннәр килгәч тә үз итте: «Әйдә, безнең белән!» — диләр. «Юк, минәйтәм, авылдан китмим!» «Алайса, монда тылмач бул!»

«Нинди тылмач?» — кызык тоелды бу миңа. Өй борынча йөрибез. Мин таныштырам:

«Оста багучы, бик рас китерә!» — дим. Чегән хатыны үз telendә мыдырдый, мин «тәрҗемә» итәм. Чегәнчә белүем — кытай, итальян чамасында, ишеткән дә юк иде... Менә ул, күрше апайның уч сызыкларында алтын балдаклы бармагын йөртә-йөртә үткәнен, киләчәген әйтә... Йорттан-йортка, шулай авылны әйләнеп чыктык. Даны таралды, халыкны шаккатырганы — үткән тормышны рас әйтеп бирүе!

«Каян шул хәтле белә диген? Кызың Шатурда торфта икән, ди».

«Ә миңа ФЗУ дагы малаеңнан хат килгән, ди!»

«Кара сарыгың югалып табылган — насыйп мал, ди.»

«Зөя төрмәсендәге ireңә сохари илткәнсең, дип тора бит, билләһи әгәр.»

«Ә үзе безнеңчә бер кәлимә сүз белми. Булганын уч төбендәгедәй күргәч, буласын да рас китерәдер?»

«Китерә инде» — минем ярдәм белән... Әнә бит, кәҗүнни йорттан яхшы хәбәр килер, авыл белән шатланырсың, ди. Сугыш бетәсен әйтә. Мондый да дөрес әйткән багучыны күргән юк иде, ди авылдашлар. Кемне мактыйсын белмисез, ачык авызлар, тылмач булганга белә ул, дип бик кычкырасы килә дә — бу хакта авыз ачарга ярамый... Авылдашларны мин шәп беләм, кулларына карыйсы юк — имән кайрысыдай инде!

Табышлы багучылар мине дә буш итмәде. Бик кыстаганнар ие дә, ризалашмадым. Бүтән авылларны болай ук белмим лә. Миңа — дөресен сөйләрлек булсын, мин бит алдап бер сүз дә әйтмәдем, бераз юаттым гына. Чегәннең чибәр кызына да кызыкмадым — үзебезнеке үз инде!

Керәшен чегәне кабак орлыгыдай сары тешләрен күрсәтеп көлеп ала, «әйе бит?» дигәндәй Гөлчирәгә карый, утлы күмерләрне әйләндерә, сызгырынып-көйләп куя.

— Син, әкәмәт, тәмам чегәнсең икән ләбаса! — дип, бармак янаган итә Гөлчирә-чибәр. — Җитте алдашу турында сөйләргә, хак дөресенә күчик: «почталы» уйныйбыз!

Минем өч начальник кәгазь-каләм алды. Төп башына утырып, берберсенә хат язалар. Мин катнашмыйм, тиеш тә санамыйм, андый уеннарда каушап-югалып калам. Учакка чыбык-чабык өстәштерим... Менә безнең десятник-кылыч борын язуын бөкләп, эре генә Гөлчирәгә сузды. Утырган төштән генә — кыз торып, үрелеп алырлык итеп. Шундый ул. Гөлчирә белән дә начальник булып сөйләшә. Кызыбыз хатын укыды, көлемсерәп куйды да, җавап яза. Көтә егет, бармакларын кыр сумкасында биетеп. Яза кыз, үзе елмая, бит алмалары чокырланып тора каһәрнең. (Мин җырлар җыям: «Чәйләр салып эчәр идем битең чокырларына...» дигәне дә бар...) Язып бетерде дә, учак аркылы үрелеп... миңа сузды! Күзләрем ялгышамы, учак төтененнән йотлыга яздым. Мин бит уенда түгел! Аптырап кәгазьгә күз салсам: «...яратам» дигән сүз ярылып ята...

— Китер монда! — дип торып басты җавап көткән түрәм. Шуны уйлапмы, утлы күмердәй пешергән хаттан котылырга теләпме, тизрәк тегеңә суздым... Йолкып та алды, күз төшергәч, йомарлап утка да атты. Иләсләнеп букчасын янга чөеп, кар ерып китеп барды. Аны гына тыңларга тиешләр, мәхәббәт тә нәрәт кәгазенә язган әмердәй үтәлсен, дидер...

Минем хәлем хәл, Гөлчирәдән оят. Ничекләр үкенгәнемне үзем генә беләм. Кызлар хатын чит кулларга тоттыр инде. «Җебегән!» — дип үземне битәрлим. Ә Гөлчирә шелтәләп сүз әйтмәде, карашы белән дә сиздермәде. Тыңламас чәчләрен төзәткәләп, шаян җыр көйли-көйли участогына йөгерде. Бит алмалары тагын да кызарган: әллә учактан, әллә уйнапкөлеп сөйләшкәнгә... Ә бәлкем, барыбызны да үртәп, шаяртканды́р? Минем күзләрдә дә соклану күргәндер, битарафлык түгел...

Керәшен-чегән моңсуланып калды. Ахрысы, дәртләнеп сөйләве Гөлчирә өчен булды. Дүртебез дүрт тарафка киттек, учак ялгыз калды.

Моннан соң да бергә эшләдек. Теге уен турында ләм-мим — «почта» ябылды. Бер көнне кылыч борын белән чегән тылмачы Гөлчирә турында сөйләшеп алды:

— Яшен киметеп күрсәтә — аңа унсигез генә түгел!

— Егерме үк бардыр инде!

«Карт кыз» икән, тиң түгел, янәсе. Йөзем... ныграк өлгергән булып чыкты! Чибәр-чаяларга күз төшә, әмма минем бит күңелдә кабынган үз учагым, яшерен учагым бар. Уйнап та, чынлап та хат та язмыйм, андый кыюлык юк миндә. Хыялымны читтән генә күзәтәм. Нәрсәгә өметләнәм, ни көтәм? Язмышны сынаган сыман... Бәхет өчен керәшергә кирәк, ди бит китаплар?

Яшьлегемнең кайнар учагы әле дә күңелне җылытып, җилфердәп талпына. Ялкыннар — хатлардан күчкән сөю сүзләредер... Килде бер көн, мин дә, ишеткәнемчә, туй алдыннан «үткәнгә барлык күперләрне яндырам» дип, кызлар хатларын төн уртасында мичкә яктым... Аның хатлары әле дә бар, сабакташ та саклаган мин язганнарны.

Яшьлек үкенечләре, сафлык, гөнаһсызлыгы... Ут хатларны ялкынлы уттан алып яңартып булмый шул. Янган ул еллар, янган ул гомерләр, ак кар өстендә кызыл күмерләр генә көйри... Күперләр күмер булса да, утраулар калган — хатирәләр көле астында кайнар очкыннар көйри...

...Әйе, Гөлчирәгә инде, «егерме үк бардыр...» Бардыр, керәшен-чегән юраганчадыр, минем күз алдында һаман шундый ул. Авылын да белә идем, безнең Тау ягыннан ул. Тагын бер килеп очрар да сыман иде...

## Беренче паспорт

Жир сөрдек, чәчтек, урдык, икмәк ташыдык — кулдан үтмәгән эш калмагандыр. Әмма хыяллар киләчәккә — максатка ашыга, канатлар гына юк... Ятимлекне сыңар канат, диләр. Паспорт та канат икән, ансыз район үзәгенә дә оча алмыйсың.

Көтмәгәндә бәхет елмайды, колхоз яшь кадрлар: ферма мөдире, ветфельдшер укытырга тиеш. Уналтыбыз тулган, миңа — өч айлык, Салихка алты айлык паспортка рөхсәт булды, идарә шулай хәл иткән. Хәстәренә керештек — Кайбычка барып карточкага төшәсе. Салих әйтә, чаңгы белән тиз дә, җайлырак та булыр. Көне кояшлы да, җил каршы — өтеп ала. Ярый әле юлның яртысы җылы: «урман — мукшы ызбасы» дип белеп әйткәннәр...

«Кызыл байрак» артелендә карточкага төштек. Җил кискән битләр ничек чыгармы дисәк, андый нечкәлекләр беленми, бармак очы тиклем генә сурәте. Затлырак булсын дип, Бибигайшәападан шәкерт абый кәчтүнен сорап торган идем, сыңар якасы гына күренә — пичәт төшәсе урынны кыеклап ак калдыралар икән. Авылга кайтып, яңадан Подберезьега — хәзерге район үзәгенә барасы булгач, Кайбычтан шунда киттек. Шактый ара, тик безне инде өмет йөртә. Анда «колхоз квартиры» бар — бер абзый белән килешенгән, шунда кереп йокладык. Туу турында таныклык кирәк. ЗАГСтагы марҗа татарча белми, урамга чыгып, гарәпчә таныган бабайны эзләдек. Рус авылы булса да табылды, гозергә карышмый авыл кешесе, үзе дә йомыш белән килгән. Шактый актарды, ахырда тапты. Марҗа таныклык язды. Карасам, «Таукат» диелгән — безнең исемнәр ят, аңлаешсыз аларга. Төзәтергә ярамый, ди. Паспорт язучысы хәлгә кермәсә, эшләр харап иде.

Ниһаять, хыял кошыбыз кулда! Маяковский әйткәнчә үк горурланырлык түгел инде — учка куярлык юка кәгазь — өф дисәң дә очарга тора. Бөкләп дә куен кесәңә сал, шушы синең беренче паспортың, югалтма. Чыпчык канатыдай кәгазь таяныч булыр. Габделхак җизнинең кайгыртуы әле бу.

## Рус теле, сыер теле һәм латин теле...

Буадагы республика колхоз мәктәбенә практикларны теория белән «дагалау» бурычы йөкләнгән. Өч айда мин һәр яклап белемгә баеп, ферма мөдире булып кайтырга тиешмен. Барлык фәннәр дә рус телендә — шунысы котны алды. Сиздермәсәң дә, шул хафа эчтән кимереп тора. Күнегәсең икән, бик төпле өйрәтәләр, хәтта хисапчылар төзисе еллык азык балансын да эшлибез. Юк азыкка — нинди баланс дип, җан асрарга хуҗалыкларга таратылган сыерларны, күтәрмәгә калган атларны күз алдыма китерәм.

Бер военком хәрби әзерлектән керә, Сталинның җиде удары турында бик тәфсилләп сөйли. Истә калган ике вакыйга терлекчелек дәресендә булды. Менә күргәзмә әсбап — сыер макеты. Өстен ачсаң, эчке әгъзалары: үпкә-бавыры, ашказаны, йөрәге — һәммәсе җайлашып-ярашып үз урынында, тиешле хәлендә тора. Укытучы шуны зур өстәлгә бушатып буташтыра да, янәдән урнаштырырга куша. Кем ничек сабак үзләштергән? Бер кыз һәммәсен сыйдырып, башлы-мөгезле капкачны япкан иде, «йөрәк» артып калды...

Безнең йөрәккә борчу салганы, иң мингерәткәне, русчасы өстенә, терминнарны латинча ятларга тиешбез! Рус, латин телләре өстенә тагын... сыер теле дә өстәлде! Искиткеч ачышым шушысында булды. Авыздагы тел дигән нәмәстәкәйне ит кисәге дип бик ялгышканмын. Тел күрсәтеп кызларны үчекләгәндә авызымда нинди катлаулы әгъза тирбәлгәнне белмәгәнмен. Наданлык бәласе! Тикмәгә генә тиктормас түгел — әллә ничә мускуллы икән. Тел өсте, асты, уңъяк, сулъяк мускуллары... Һәркайсын, русчасы белән бергә, латинча әйтергә тиешсең. Хикмәти хода, минем башка сыймаган бу кадәр латин сыер авызына ничек сыя микән?

Сыерның сөте — телендә, дигән халык. Әллә шуны тупма-туры мәгънәдә аңлап, фән әһелләре җентекләбрәк өйрәнергә булдылар микән? Сыер теленнән сөт алу өчен улакка нидер салырга кирәк ләбаса! Эчләре эчкә, тышлары да эчкә ябышкан — кабыргасына «инвентаризация» ясарлык хәлдәдер... Бердәнбер ябыкмаган төшләре — мөгезләр, яхшылабрак карасаң, мөгаен, алары да сыза төшкәндер... Мөгезнең дә латинчасы бардыр әле?

Күргәзмә әсбаптан тел схемасын карыйм да, авызларын югары күтәреп мөгрәгән сыерларны ишетәм — түбәдән салам төшмәсме дип ымсынып көтәләр. Төшәсе төшкән шул инде: сыер ялагандай калган...

Латинча ятлаучы, булачак мөдир теленә дә нидер салырга кирәк бит. Бусы мине бигрәк борчый: «азык балансым» очы-очка чак ялганып, өзеләм-өзеләм дип тора...

## Буранлы юллар, ураулы юллар...

«Бүген Буадан авылга кайтып киттем. Әй буранлы да иде соң... Бик ардырды... Әллә кайлардан әйләнеп кайттым...»
9 март 1945 ел.

Көндәлектән.

Тәүгелде кызы да җыена иде, бергәләп кайтырга булдык. Иртән чыксам, күз ачкысыз буран. Күренмәде кызы, тимер юл ягалый китте микән? Нишләргә? Кайтмый да хәл юк — кичәдән бирле тәгам капмадым... Юлны да белмим. Ялчеккә шоссе бара, анысын беләм. Буран күмәрлек түгелдер, юл катысын ничек тә югалтмам, дип, тәвәккәлләдем. Беләм, урау булыр, Чувашстан аша. Ялчеккә житсәм — юл таныш.

Атаклы март бураннары: кары — сылана, җиле — кисә. Аптырагач аркан әйләнеп атлыйм. Биткә сарган карны сыпырып, уч төбем белән җылытам. Атлыйм да атлыйм, узып та китмиләр, каршы очраучы да юк. Буран дип чыкмыйлар. Онытылган, ташланган юлдан барам шикелле. Авыллар да очрамый. Кешесез юл күңелсез, шомлы. Дөрес барасыңмы — сорашып та булмый... Берничә адымнан берни күренми. Упкынга төшәме бу юл, күккә менәме? Буран эченнән атлыйм, кайчан, кая житәрмен — бу юлдан беренче үтүем. Алга барамдыр бит? Ниһаять, бер авылга кергәч, белештем — дөрес икән. Керен су да эчмәдем. Эчәсе килми, әшарга сораучы мин түгел инде...

Буран да буран, барам да барам. Көннең кайсы вакыты, төш узгандыр. Якты да кайтып ирешәсе иде, караңгыга калсаң — харап, япан кырда нишләрсең... Буран сыртлап салган, юл катысыннан язмыйча, чак эләгеп киләм. Йомшакка төшсәм, шып туктыйм, як-якка аякны күчереп карыйм, ялгап китәм... Кабаланырга, каушарга ярамый — юлны язарсың. Туктарга да ярамый — мәлҗерәп-оеп, мәңгегә йоклавың бар... Атла, атла, алга, алга...

Якты көн буе кайттым. Көн озынлыгы унбер сәгать ярым чамасы. Тәмам арып җитүнең ни икәнен караңгы төшкәндә белдем. Ачыгып күз алларым караңгылана дип торам. Тәүгелде урманы... Инде аз гына калды... Юлны кишәрлекләп бүләм: әнә теге ат алмасына җитәм дә, туктап хәл алам. Чана салулаган үргә менәм дә, ял итәм. Аяк өсте хәл алам, утырсаң тора алмассың. Үземне әйди-әйди киләм. Кайтып кына җитим, өй җылы, әнкәй бәрәңге пешергән, өлгерим. Сәкегә сузылып ятармын...

Көн буе буран ерып, җил сөзеп атладым, тирләп ял иткән булмады. Соңгы тәрәшләләр дигәндә, бурап-буралап өелгән кар тавына җиттем: үзебезнең тыкрык! Инде төн, хәзер тәрәзәдә ут җемелдәр... Ишегалдына кердем, болдырга бөгәрләнеп буран яткан, җил уйный, ә ишек бикле... Хәерчегә җил каршы... Монда утыру да ярамас, тирләп, йончылган көе, туңып үләргә мөмкин... Тау башындагы почмак тәрәзәсендә уты-йолдызы күренгәч, тынычландым: әнкәй Сафиябану аптый янында!

Мендем ул тауга да. Әнкәй анда. Өй җылы. Сафиябану аптый бәрәңге кабыгы пешерә, парлы-әчкелтем истән таныйм. Киптереп, төеп он итә ул аны. Чүлмәк табакка аш состы. Шундый тәмле булыр икән! Зарыккан карынга кайнар йөгерде. Таудан төшәрлек хәл керде...

Озак кайттым Буадан, кайтып ирешә алмам, карлы-буранлы юлның очы булмастай иде. Бер гомер кайттым сыман, яхшы хуҗа этен дә чыгармас көн иде. Мин чыктым. Ачлык-хуҗа чыгарды, нужа куды. Кемнең кемдә ни гаме бар, кем күргән — кая киттең, адаштың ни, югалдың ни — каян эзләргә дә белгән кеше юк...

Үз дигәнемә ирештем, туктамадым, үзсезлелек булышты. Үҗәтләнеп басмадан суга үрелгән малайны үземдә таныган чаклар әле дә була — холык-гадәт гомерлек икән... Буранлы юлдан атлаган үсмергә инде балам, оныгым кебек кайгыртып, шөбһәләнеп карыйм: адашмагае, хәлсезләнеп егылмагае... Әмма ерак киләчәктән бер телем икмәк тә суза алмыйм, каршысына бара алмыйм — бу көннәргә ул үзе килеп җитәргә тиеш. Үзе! Ә җитәрен беләм, киләчәктән күреп торам. Ул чакта исә киләчәккә өметем-ышанычым буранлы юлларга маяк иде!

...Бер атнадан Салих та кайтып төште — бер генә игәрчегә артык иде шул алганы.

## 1945 ел, 9 май

Татар хатынының күзеннән яше чыкса да, авызыннан инрәү тавышы чыкмый. Йөрәктә кату калса кала, яулык читен тешләп түзә, әрнү өнен эчкә йота.

...Йокы аралаш ишеткән хәвефле авазлар гайре табигый иде: үрсәләнеп-үкереп, нидер әйтеп-әйтеп берсе җылый, икенчесе кушыла... Башымны күтәрсәм, фатир хуҗасы әби урамнан кереп мендәргә капланды, кызы Майсәрә, юата-юата, үзе дә тыела алмый... Хатын-кыз җылавы бәгырьне өзә, әнкәй үксегәндәге үрнүләр яңара. Ни булган бу йортка, нинди каза килгән? Фаҗига, коточкыч хәлдер... Пожармы? Үлем-җетемме? Йокымнан айнып як-ягыма карыйм — тәрәзәдән төшкән кояш күзне чагылдыра. Мине күргәч, әби сулыгып-тотлыгып нидер әйтмәкче:

— Су-гыш... су-гыш...

«Нинди сугыш?!» — дип котым алына...

— Сугыш беткән...— дип, тагын ыңгырашып җибәрде.— Безнекеләр кайтмас...

Иренең үлгән хәбәре килде шул, Майсәрә апаның кияве дә һәлак булган... «Сугыш беткән? Җиңүме?» Өнемме-төшемме, килдеме ул көн? Минә беренче минутлары шулай, шатлык белән кайгы катыш. Әткәй... ул да кайтмас... өмет өзелде. Әле фронтта кебек иде. Хатип абый, Сафиулла

абый... Менә шушы кояшлы май көнен күрә алмадылар. Җиңү килер дә, сугыш ташы йөрәктән кубар, җип-җиңел булып китәр сыман иде.

Сугыш башлану хәбәре таңда куркыткан иде, бетүе дә сискәндереп уятты. Шул ике арада дүрт елга сузылган караңгы, авыр төне...

9 майда көне буе бәрәңге бакчасы казыдык. Мәрхәмәтле, имин кояш астында тирә-күршеләр дә туфрак әйләндерә. Әнкәй дә жылый-жылый жир казыйдыр. Мин кайткач, тагын җылар... «Җиңү!» дип бертуктаусыз шаулый радиолар, урамда шатлык авазлары. Бик хәтәр ут капса, халык урамга ташып чыга. Пожар сүнгән шатлык иде бусы. Левитан тавышы тәннәрне чымырдатып, күзләргә яшь китерә... Шаукымга бирелеп, мин дә көндәлегемә күтәренке-шапырынулы гәҗит сүзләре тезәм...

«9 май. Бүгенге көн минем көндәлектә генә түгел, бәлки бөтен дөнья тарихында үзенә бер аерым югарылык, онытылмас булып урнашырга тиеш. Чөнки дүрт ел диярлек дәвам иткән бу каты сугышта совет халкы бөек полководец Сталин һәм безнең большевиклар партиясе җитәкчелеге астында җиңеп чыкты.

Бу сугышта совет халкы һәм татар халкының батыр уллары, төрле милләт халкы, туганнарча кулга-кул тотышып, үзләренең илен басып кол итәргә теләүче фашист варварларга каршы әле дөньяда һәм сугышлар тарихында булмаган тиңдәшсез батырлыклар күрсәтеп сугыштылар. Бу безнең өчен гади сугыш түгел иде. Бөек Ватан сугышы иде.

Ләкин башкаларын язмыйм, моны һәр газета битләрендә укырсыз. Шулай да, их, шатлыклы булды! Уйлап кара әле — сугыш туктады. Ничә елдан бирле зарыгып көткән көн, ниһаять, килде! Ул күрсәң иде халыкның шатлануын.

Миңа бу сугыш башланганда да, туктаганда да өйдә торырга туры килмәде...

Әйтеп карыйм да, сугыш туктады дип, күңел ышанмый.

Белмим, безнең әткәй кайтырмы икән?

Сугыш туктады, ләкин әткәй кайтмаса, миңа ни кызык кала дөньяда...»

«11 май. Их, кеше кайтыр, безнең әткәй кайтмаса нишләрмен. Их! Бер тыныч җирдә йөрәгемдә булган нинидидер әрнеп торган нәрсәне басар өчен туйганчы җылыйсы иде. Бер эчем бушап китәр иде...»

Көндәлектән бу язманы 1991 елның 9 маенда укыйм. Соңгысын укыганда күңелем тула. Таяныр, сыенып иң кадерле кешесен — әтисен югалткан 16 яшьлек чагымны кызганып күңел нечкәрә, хәсрәтем яңара. Туйганчы елый алмаганмын, бу көнгә дә калган...

1945 елның 9 маенда минем беренче гомерем тәмам... Әткәй, якын туганнар, авылдашларым кайтырына өметем өзелде, бергә яшәгән түгәрәк дөньям тәмам. Иҗатым чыганагы буласы икенче гомерем башланыр — хыялымнан илһамым белән яулый-яулый үзем ирешермен. Бусында да ярдәм кулы сузар дуслар, иҗат остазлары күтә. Үзем ирешермен, «үзем» дигән сүземдә — сугыш афәтеннән калган якыннарым, Олы Бакырчының тузгытылган мәчет урынындагы уртак һәйкәлгә взводлар сыман саф-саф тезелеп торган уяу хәтерем — йөз алтмыш тугыз авылдашым...

Җиңү көненең мул кояшлы иртәсеннән тагын бер күренеш искә төште:

— Безнең абый исән! Безнең абый кайта! — дип сөенеп, сикергәләп йөргән иде күрше кызы Фатыйма. Әтисе Галәветдин, әнисе, куана-куана жир казыйлар: чибәр кызлары буй җиткән, уллары кайтыр — ике туй күтә. Шул табыннарга булыр бу бәрәңге дә. Күршедә әниле-кызлы ике тол кайгырышканда уңайсыз да сыман...

Атна үтте микән, егеттән хат та килеп төште. Җиңү көнендә язган! Фатыйма җиң сызганып өйне җыештырып, юыштырып йөри, тулы бәхете аны тагын да матурлаган. Дөньясы тигезләр, бәхетләләр сөйкемле була, эчтән яктырган — күрергә күңелле...

Янә атна үтте микән, военкоматтан пакет китерделәр. Бик якында шул алар, хәбәр тиз йөри: күрше егете һәлак булган...

— Хатадыр бу, хата... Тугызынчы майда язган хаты килде бит!..

Хафа иде, иң үкенечлесе шушыдыр... Күңел белән инде кайтарып ук житкергәч, жил капканы ачып, кочагына алдым дигәндә тартып алды сугыш — беткән сугышның кургашы...

## Әйтелгән васыять

Бабай васыятен язып алган әткәй, үзенеке — юк. Кырыкны тутырмаган ир ул хакта уйлыймы. Сугыш мәхшәреннән исән чыгармын, дип өметләнә, хатларында язганы — очрашу турында.

Өзелгән гомер, яшәлмәгән еллар, әйтелмәгән сүзләр... Улы, кызының буй житкәнен күрмәгән, туйларында утырмаган, оныкларына сөенече тоймаган. Исән яшьтәшләрен күрәм — әткәй дә шулай йөрер иде... Ни әйтер иде ул миңа, безнең балаларга? Тормышта акыл өйрәтеп кенә торалар мени, дөнья куып йөгерә кеше. Гадәти көнкүреш булыр иде, тигезлек дигән бәхетнең кадерен дә белми йөрер идең...

Әткәй юклык гомер буе сиздерә, әрнү, сагынулар юлдашың — язмышың... Менә, үзебез балалар үстерәбез. Тәҗрибә кирәк, бакча үстерү генә түгел лә, күреп үсмәсәң, белеп бетерерлек түгел. Улым уникегә житкәч тойдым мин моны. Шул яшьтән үзем әтисез, шәхси тәҗрибәм өзелгән... Узды бу каушау, жан таянган ноктаң — рух берлеге бар, әтиеңчә — үзеңчә дәвам ит, икеләнмә, диде эчке аваз...

Инде әткәйдән соңгы ярты гасырлык тәҗрибәм булса да, хәзерге улым яшендә мәңгелектә калган әткәй рухы белән яшим. Тормышяшәешнең хәтәр сынауларын намус, әхлакның әткәй-әнкәйдән күчкән сыйфатлары, әби-бабадан килгән йола-гадәтләр — терәк. Ничә яшьтә булсаң да, гомереңнең кайсы фасылында да яраклы, аңында, канында, жанында ул, вөждан уяулыгында...

Без — әти-әнинең варислары. Алар — элгәрләрен дәвам иткән. Заманнар үзгәрә, ай-һай, баш әйләнгеч текә борылышлар, тының кысылырдай очышлары һәм упкыннары бар! Әмма жан исән — буыннан-буынга, гасырдан-гасырга тамырларда аккан кан яңара килә: киләчәккә иман-васыять бара! Кемнеке — анықы, сынатмыйк. Әткәйнең язылмаган васыятьләрен бергә яшәгән еллардан, тормышыннан күрәм: әйтелгән алар, яшәлгән гомер белән әйтелгән!

## «Кайбыч, Кайбыч... Казан сөлгесе»

Олы Кайбыч та Олы Бакырчым кебек кадерле миңа. Хатирәләр күңелне рәхәт җилкендереп, татлы сагынулар кузгата... Дөньямның түгәрәк-тигез, имин чагы — балачагымның сугышка чаклы ваемсыз ике елы, әткәйле ике ел, дуслар-иптәшләр, данлы урта мәктәбе. Икенче килүемдә — яшьлегемнең сигез елы, китапханәләре, хыялыма юл ачкан район газетасы редакциясе. Рухым сыенган төбәк, сусаган җанга азык булган китап-хәзинәләре... Җиңү елында илһамым ачылган Кайбычым ул, мәхәббәтем канатланган дәвер... Ачлы-туклы чаклар дисәм — ил белән лә, бер мин генәме? Киим дисәң — кием юк, кимсенеп үтте иң матур чаклар дисәң дә гөнаһ булыр. Хыял-өметкә бай идек, киләчәккә житәрлек омтылыш, ышаныч бар иде. Кыен чагымда якты йөз күрсәтеп сыендырган, почмак биргән кешеләренә бурычлымын — бурычым төшемә дә кирә...

Кайбычым — кадерле төбәгем, истәлекле елларым, хәзер ничек кенә үзгәрсәң дә, күңелемдә яшьлек сурәтеңне саклыйм... Әйе, әйе, минем яшьлегемдә син дә яшь идең, дәртле идең, электрлы урамнарың балкып, гөрләп тора идең. «Калды ич, калды ич, Казан сөлгесе» дигән җырны ничә тыңласам да «Кайбыч, Кайбыч...» дип ишетәм... Шундый житди сүзгә дә мәзәк килеп керүен әйт инде, ә бит танылган артистыбыз, чыннан да, шулай дип җырлаган икән! Ул үзенчә ишеткән, шулай дип белгән... Минем язмышка бигрәк туры килеп тора: «Кайбыч, Кайбыч...» «Казан сөлгесе»нә тоташкан: Олы Бакырчымнан, Олы Кайбычымнан ары, соңгы мәхәббәтем — Олы Казанымда тәмамланыр юлым...

Кайбычка район абруе яңадан кайтты. Безнең авыл гына чикләреннән читтә кала, шатлыгым тулы булмады. Кайбычның элекке даны белән бергә яшьлегем, мәхәббәтле елларым да кайтыр сыман иде... Безнең авыл — Апаска якынрак шул, йомыш белән йөрергә юл уңай ул якка. Миңа Кайбыч якынрак дисәм, Апас үпкәләмәстер — беренче мәхәббәт онытылмый...

## Тау ягында Дымбылат бар

Әүвәл заманнарда безнең якларда алпамшалар яшәгән, ди. Бабайлар Каенсарга күрсәтә:

— Алып бабай чабатасын каккан туфрак ул!

Күз алдына китер: чабатасы нинди дә, үзе нинди! Мактанырга була, тик «безнең як» төшенчәсе үзе дә Алыптай зур икән: авылың, Тау ягың — татар иле... Каенсар атлы таулар да бездә генә түгел, тәкърлектугайлар да күп. Ә менә Дымбылаттай кизләү беркайда юктыр. Дөнья гизгәннәр дә сокланып тора, көн саен килгәннәр дә күзен ала алмый:

— Сөбханаллa, агымын кара!

— Күз тимәсен, чиләк төбен төшерерлек!

Ырымын саклап җеп кисәге агызалар, бисмилла итеп суын авыз итәләр. Алып баһадир сусынын басарлык та шул. Би-ик тирән катламнар үтеп чыга, алкын суы шундый салкын. Тешеңне сындырырлык, диләрме? Сындырмый ул, киресенчә — сынмый торган итә. Бала чакта шифалы суын эчеп үскән картлар да тешләрен балкытып йөри — үз тешләрен!

Баһадирлык илгә-көнгә кылган изге гамәлдә икән: Дымбылат бабай халык күңелендә Алып белән янәшә. Кизләүне якты дөньяга чыгаручы бит ул. Бусы инде тач үзебезнеке, йорты да шушы тирәдә булган. Бу хакта язу калмаган, һәйкәл ташы да юк. Мәрмәр дә туфрак була, чыдам чуерны да тарих мүге баса, вакыт барын да янәдән ком итә. Иң чыдамы — хәтер һәйкәле. Колак салыйк әле, ни сөйләшәләр су юлында:

— Әлхәмделиллаһи шөкер, Дымбылатыбыз бар!

— Шифа эзләп Каф тауларына барасы түгел!

— Патшалар өстәленә куярлык!

— Шаулама, тиле, аннары безгә тәтемәс!

— Дымбылат бабайга рәхмәт!

Үзенә тарта иде, бала чакта көн дә Дымбылат күрергә йөгерә идем — шавын тыңларга, агымын күзәтергә. Безгә якын гына ул. Еракка киткәч тә, туганнар, авылдашлар белән бергәттән кизләү хәлен сорашам:

— Ничек анда безнең Дымбылат? Һаман шулай агамы?

— Шөкер генә, картлар карап-тәрбияләп тора.

Кайткач та иң әүвәл төп йортым, туган нигеземә, аннары Дымбылатка барам. Йөзләрне узып, миңа җитсә дә, һаман җегәрле, яшь ул, дәртле. Читтәгеләр кизләүгә дә күчтәнәч алып кайта: тастымал, сөлге, чүмеч, тустаган, чәшкә-чокырлар эленеп, тезелеп тора куышында. Сусаган юлчы рәхим итсен. Кизләү агымына куйсаң, су тормас —

гажәпләнмә, чиләккә сыймаган агым сикереп кенә кача, шаярта... Кучтәнәч кайтарыр балалары күп аның. Таралыштыгыз, дип тә үпкәләми, үзе дә гомер буе читкә китә-китә туган туфракта яши бит ул Дымбылат. Кайларда булсак та, чыганак башы — күңел кизләвебез Каенсарда. Сирәк кайтасың диләр, минем бит киткәнем дә юк... Хикмәтле кизләвем — җәйге челләдә сусынны басса да, сагыну сусавын арттыра гына...

Тау ягында, Олы Бакырчымда Дымбылат бар, дәүләт саклавына алынырга тиешле табигать һәйкәле: кешеләргә хезмәт итеп яши торган һәйкәл. Кыйблага карап аккан кизләү изге була, суы шифалы, дигән борынгылар. Дымбылат кыйблага карап ага. Туган ягым, кыйблам минем, бар изгелекләр башы синдә, илһамым кизләве синдә...

## Чикерткәгә пүлән ташламагыз

Авыл таңнан төнгәчә аяк өстендә — ал белмәс, ял белмәс, мең төрле мәшәкать дип йөгерер. Аның каравы, төне тын. Шылт иткән тавыш юк. Арып-талып, аяксыз калып изрәп йоклый мәхәллә. Күктәге Ай да, уятмагаем дип, туктап калган. Урам-тыкрыкны, тугай-үзәнне тынлык оеткан — ишегалды, ызбалар тулы тынлык. Тирән тынлыктан колаклар чыңлый, мин дә йокының мамык түшәгенә сеңәм... Шул чакта, инде ярыйдыр дигәндәй, базмыйча гына чикерткә тавыш биреп карый. Тора-бара кыюлана, ызбаны чырык-чырык белән тутыра. Матур гына челдере чыра телгән, ярык-яңгыравык булып үрти. Ничек туктатырга бу әрсезне — мич арты сандугачын? Кул астында ни бар — шуны тондырам! Тынды дисәм, янә керешә... Йокы качты, ачу уянды: тавышка төбәп пүлән ыргытам!

Шулай була торган иде элек. Чикерткәле ызбаларны калдырып калага күчендек. Нужа йөген тартып интеккән авылга сирәк кайтыла — читтән торып сагыну мәшәкатьсез бугай... Бу юлы кайтуыбыз «бик сәбәпле» — Ярхәм җизниләр өй җиткерде, өй туена чакыралар. Казаннан Фарук, Тәскирә, Можгадан Фәрит гаиләләре белән кайтты. Төпчекләре Рәшит башкарып чыккан йортка җыелдык. Бер дә арттырусыз — мәхәллә салган яңа мәчет белән бер. Безнең шәһәрлек, анда үткән кырык ел пакъ бусаганың теге ягында калды. Юкә бүрәнәләр юкә балдай ак, мүкләгән сүсе пакъ — саф татар өе, кем әйтмешли, болындай инде — исе белән дә, зурлыгы белән дә! Һәй, үтте бит гомер таш тартмаларда, монда без авылныкы, үз хәл-халәтебезгә кайттык...

Хуш исле өйнең түренә урын җәйделәр. Яңа өйдә күргән төшне хуҗаларга юрыйлар, дип уйлап кына өлгердем, тынып калган өйдә өзелеп сагындырган, җанга якын аваз ишетелде... Соң, җанкисәгем, сайрар чикерткәм, син лабаса бу! Әле мич тә юк, хуҗалар күченмәгән, ә ул — өлгергән! Дөбер-шатыр иске өйне сүткәннәр, бүрәнәләр тәгәрәгән, йомычка очкан, нигез яңарган, ә чикерткә качмаган — ташламаган төп йортны! Әнә ничек сөенеп-сөенеп, өйгә иминлек теләп сайрый ул — көйле өйнең үз көе. Шулкадәр үз икән, кадерле икән, урынлы икән, кирәкле икән! Туган авылымда, туганнарымда яңа өйдә бәхетле идем мин: елмайганымны хәтерлим, шундук йоклап киткәнмен... Төш тә күреп өлгермәдем, чикерткә моңы сабый чагыма кайтарып, авылымның бишек җырыдай, нарасый йокысы белән йоклаткан...

Иртән чикерткә тавышын тансыклап тыңлавым турында сөйләдем.

— Берсен тартмага салып, малайга биргән идем теге кайтуда. Шәһәрдә ашатып-эчертеп яшәтмәкче иде...— дип көрсенде Фәрит.

— Соң, ни булды?

— Чыгып качкан... Югалды. Нәүмизләнде улым...

Үз өен, үз илен юксынгандыр чикерткә. Читтә, читлектә сайрамый — урман исле, бал исле таныш бүрәнәләр кирәк аңа. Таш диварлар тынын

кыскандыр... Үзебез дә адашкан чикерткәләр инде без: гомер буе мүкле бүрәнәне юксынып җырлаучылар...

Ярхәм җизни нигезендә Рәшит калды. Умартачылыкка укыса да, абыйлары ягына үрелеп-үрелеп караган чаклары булгандыр. Тик ул шәһәргә китмәде. Әти-әнисе шушы нигездә картайган — таш диварларга күчерергә соң инде. Гореф-гадәтебез дә төпчекнең язмышын тәгаенләгән. Тузмасын-таралмасын нигез, морҗасыннан тере төтен күккә үрмәләсен, ата-бабадан суынмый килгән җан җылысын сакласын, бакый йортка күчкәннәр рухы тыныч булсын...

Чикерткә күпме яши икән? Миңа калса, безнең балачактан гына түгел, ерак бабайлардан бирле, иске йорттан яңасына күчә-күчә, сайрауларын өзмичә яши алар. Мәшәкатьсез «мал» — ни ашый да ни эчә, ничек җан асрый... Әллә җыры белән тукмы, өйнең иминлеге ризыкмы аңа, шул яшәтәме — рух кошларымы алар? «Төн кошы» дип кимсетмик...

Чикерткәгә пүлән ташламагыз...

Чикерткәле нигезләрне ташламагыз!

Чикерткә сайраса — бәхеткә, диләр, йорт-җиргә иминлек теләп сайрый икән ул... Бәхет кошын әкиятләрдән, әллә кайлардан эзлибез, баксаң — мич артында икән ләбаса! Суынмасын мичләр, уяу морҗалар коймак исем таратып тәмле төтеннәр изәсен — борынгы учакларда бүгенге күмерләр көйрәсен... Тургайларга афәт килә, кырлар җыры кими бара. Өй тургаена — серле вә хикмәтле йорт иясе чикерткәнең үзенә дә бәхет телик...

*1990—1992*

*Голицыно — Переделкино — Малеевка — Займище.*





## Фәрит Габдрәхим

### Бөек Иванга ачык хат

* * *

*«...мин ачык хат язам, Батый, сиңа».*
Салих Баттал.

Мәшһүр шагыйрь Салих Баттал
Батыйга язган хатын.
Аңа Батый якын булса,
Минә миңа — син якын.

Һәркемнең үз табынганы,
Һәркемнең үз иманы.
Һәркемнең үз падишасы,
Һәркемнең үз Иваны.

Бәхәсләшмим, сүз дә юктыр,—
Батый — мәшһүр җиһангир.
Татарларга мең-мең аймак,
Мең-мең улус җыйган ир.

Төзегән ул Алтын Урда...
Без аңа лаекмыни?!
Үзара ызгыш-талашсыз
Яшәүче халыкмыни?!

Валлаһидыр! Безнең татар
Булса кечкенә түрә,
Чабатасын (күрәмсездер!)
Иң башта элә түргә.

Һәркайсы кенәз йә морза,
Баеса — ала хатын...

Иван-патшам!
Сиңа юллыйм,
Кабул кыл ошбу хатым.

И гали зат!
Мәрхәмәтлем!
Гамәл-уйларың хактыр.
Йөрәк чәнчи, кул калтырый:
Язам беренче тапкыр...

Үкенәмен — моңа кадәр
Булганмын ласа тинтәк:
Әллә күпме такмак яздым,
Сине ерткычка тиңләп.

Имеш, синең тууың ук —
Табигатьнең хатасы.
Имеш, килгәнсең дөньяга,
Тотып җәллад балтасын.

Янәсе, син түгел патша,
Патшалар булмый аңсыз.
Дәрья-дәрья кан эчсәң дә,
Булып калгансың кансыз.

И падишам, кичер мине,
Баш орам синең алда:
Юкка рәнҗеткәнмен икән,—
Барча сүзләрем ялган.

Ничек мине җир күтәрә,
Ничек сукмый каһәрең.
Ничек бирми түзәсеңдер
Җәзаңның иң зәһәрен.

«Табалмассыз эзләп мине
Җирдән-күктән,— дисеңме.—
Мин юк инде. Гүр иясе
Булдым күптән...» — дисеңме.

Юк, ышанмыйм!
Синсез дөнья
Булыр иде күңелсез.
Булдың, барсың, булачаксың,
Син, падишам, үлемсез!

Бар хакимнәр көнләшерлек
Синең гадәтләреңә.
Бар артистлар көнләшерлек
Синең сәләтләреңә.

Үләсең дә тереләсең
Без коллар бәхетенә.
Төрле кыяфәткә кереп
Менәсең тәхетеңә.

Дөнья белә: вакыт җиткәч,
Алдың Петр исемен.

Әби патша булдың хәтта,
Үзгәрмәде җисемең.

Син — Николай Император! —
Юк берни көнләшерлек.
Сталинның үзе булдың, —
Юк сиңа тиңләшерлек!

Син бүген дә тәхетеңдә,
Кояш та чыкмас синсез.
Булдың, барсың, булачаксың,
Син, падишам, үлемсез.

* * *

*«Нишләр инек, Ленин булмаһа...»*
Рафаэль Сафин

Нишләр идек, син булмасаң, патшам,
Шәмнәребез сүнәр иде җилдә.
Синнән акыл сорамыйча гына,
Яшәр идек үзебезнең илдә.

Казан, Хаҗитархан вә Кырымны
Талап китә торган идең кайчак.
Син бит бөек! Талау килешмидер,
Ясак кирәк түләтергә, ясак!

Син Алланың кашка тәкәсе бит,
Мөгез-сөңгеләрең гаять үткер.
Сөз Казанны торалмаслык итеп,
Кызлар күптер анда, мөлкәт күптер.

Ни кылансаң да килешә сиңа,
И кинәндең Казан каласында:
Мөгез-сөңгең белән, Кашка тәкәм,
Чөйдең олысын да, баласын да.

«Калмасын нәселе дә татарның!» —
Җан кыюдан патша арыймыни?!
Татар — уңган, имеш. Урыслардан
Уңганрак булу ярыймыни?!

Нишләп әле татар итек кия,
Ә син, патшам, ыштыр-чабаталы.
Синең гавам ач-ялангач торсын,
Татар, имеш, булсын йортлы-атлы.

Әй, бабамнар, ифрат гаеплесез:
Рөхсәт сорамыйча күршегездән,
Инсафлырак яшәгәнсез ләса,
Бөекләр бит түбән калган сездән.

Кашка тәкә, мөгез-сөңгеләрең
Татар җанын, әйдә, үтсен тишеп.

Бөекләрдән өстен булмакчылар
Асалмаслык булсын кабат бишек.

Яуыш, Япанчылар кул күтәргән,
Бирелергә түгел, «Илем!» диеп.
Колшәрифләр Коръән тоткан килеш
Каршы чыккан «Динем!», «Телем!» диеп.

Иван-патшам, сине мәсхәрәләп,
Явыз, дидем. Тирән ялгышканмын.
Мәрхәмәтлем! Алдың бары сиңа
Каршы чыккан Яуышларның җанын.

Башсызлар бит башсыз кала шулай.
Камай морза булып чыкты башлы.
Серләреңне, Казан, ачып салды,
Булды шулай дәрәҗәле-ашлы.

Башын игән башлы Камайларның
Бәхетләре ташкан — баштин ашкан.
Телең-динең биреп, раслагансың
Юмарт икәнеңне, Иван-патшам.

Башкортлар да зерә башлы булган,
Сугышмаган үз Казанын яклап.
Ярты юлдан кайткан, әдәп саклап,
Башкорт түгел татар кебек ахмак.

Баш ордылар, патшам: «Ал үзеңә...» —
Тотындылар бердәм үтенергә.
Киләчәктән кемдер аваз салды:
«Туры килмәгәс үкенергә!»

Үкенмәдең, патшам, үкенүләр
Бөекләргә яттыр. Ә син — бөек!
Үкенгәндә башкорт — тиз көйләдең,
Тегe мөгез-сөңгең белән чөеп,
Ә соңыннан аркасыннан сөеп.

«Көчлеләнең к...те тегермән тарта!» —
Башкорт та сине эчкерсез сөя.
Канат астында тотканың өчен,
Ясак озата ул сыртлап төяп.

Әй, бабамнар, ифрат гаепле сез:
Сугышкансыз, диеп: «Илем! Иркем!»
Бөек урыс, ятып сазлыгында,
Симертергә тиешмени черки?!

Казан ауды — киртә җимерелде,
Киңлекләргә хәзер юллар ачык.
Урыс душасыдай киң киңлекләр
Чакырганнар: «Безне басып алчы!»

* * *

Ярый әле син булгансың, патшам!
Кол булудан мәхрүм калыр идек.
Алтын минутларны әрәм итеп,
Иренмичә чалма чалыр идек.

Гайрәт өстәр «ярты» урынына
Кулга бик еш Коръән алыр идек.
Куанышып, Ермакларга түгел,
Кол Галигә һәйкәл салыр идек.

Рәхәтләндек кол булганнан бирле:
Ата кызны белми, ана-улны.
Баш ватмыйбыз кая барырга дип,
Күрсәтәсең безгә уңны-сулны.

Үзең тапкан малны алу — бәхет,
Бөгеп билне, сузып хәлсез кулны.
Хужа яман типкәләсә генә,
Күңелкәе була тугры колның.

Рәхмәт сиңа, мең-мең рәхмәт, патшам,
Кызганмыйсың бездән җәза-җәбер.
Ышанасың безгә: үзебездән
Казытасың үзебезгә кабер.

Башка сыймый, моңа кадәр ничек
Яшәгәнбез икән капмый хәмер.
Үзегездән күбрәк чөмерәбез
Сезнең милли эчемлекне хәзер.

Рәхмәт, патшам! Синең ярдәм белән
Телебезне телдек телем-телем.
Авылыңнан чыксаң, кирәге юк,—
Пүчтәк булып чыкты татар теле.

«Иң бөек тел җирдә — урыс теле!» —
Күңелләргә шигарь куйдык элеп.
Син көләсең бездән «тилеләр!» дип,
Сөенәбез шуңа: «Әйе, тиле!»

Кашка тәкә! Бигрәк мәһабәтсең,
Әллә синең сакал җирәнгәме?!
Татар кызы тарап кына торды,
Сакалыңнан синең җирәнмәде.

Мәшәкатьсез... җайлы... Тормый хәзер,
Марҗаларың кебек, ыштан киеп.
Кумый сине тәһарәтсез диеп,
Качмый синнән печтермәгән диеп.

Кыз-кыркыннар сиңа чиксез гашыйк,
Киленнәрдән ява мең-мең рәхмәт.
Бианага-биатага хәзер
Татлы сүзләр оча: «Убыр! Зәхмәт!»

Ире юкта, аулак чакта хәлне
Белеп чыга теге шаян Әхмәт.
Кашка тәкәм! Синең гадәтләрне
Үтәп яшәүләре шундый рәхәт.

Кичер мине, хуҗам! Ахмак сорау
Ярып чыкты күңелдәге ярны.
Әйткән идең еллар аръягында:
«Калмасын нәселе дә татарның!»

Син сүзеңдә торалмадың, бугай,
Шуңа җыя алмыйм ушым-исем.
Әбез исән! Яулап алдык хәтта
«Коллар» дигән бик югары исем.

Бердәнбер көн сүнде мәллә үчең,
Җитмәдеме мөгез-сөңгең көче?
Ялгышамдыр... Җитә көчең бөтен
Җан иясен кырып салыр өчен.

Ах, төшендем!
(Бакчы, кол башы да
Уйлый белә икән берни тикле.)
Бөек патшам, дөрес хәл иткәнсең:
«Болар барсы да итек-читекле.

Тикмәгә түгел. Уңганнар, димәк.
Безнең дә булыр читек вә икмәк...»
Юкәдән эзләп йөрим чикләвек,—
Үзебездә икән бөтен хикмәт.

Ярый әле кол иткәнсең, патшам
(Тыя алмыйм шатлык яшьләремне),
Без байлыктан туеп сикергәндә,
Ачка койрык чәнчеп яшәр идең.

Тамчы шигем дә юк, булмас иде
«Кашка тәкә» дигән мәшһүр атың.
Башкалар күк җәяү йөри күрмә,
Без бит синең күндәм-чыдам атың.

Рәхәт булып китә, тизлек арта,
Касыкларга тисә шпорларың.
Безнең итек сиңа таман булды,
Сүтеп аттың керле ыштырларың.

Сиңа түгел, фәкать үзебезгә
Батар өчен тирән баз казыдык.
Чиксез мәмләкәтең бинасына
Салыр өчен тау-тау таш ташыдык.

Ыштыр нәрсә? Мөгез-сөңгеләрдән
Ясап куйдык хәтәр мөгез-көпшә.
Ядрә вә туп... Ракета көпшәсе...
Син теләгән төшкә төгәл төшә.

Бар да курка — димәк, яраталар...
Синең көчтән көнләшерлек Атлант.

Җәяү йөри күрмә, Иван-патшам,
Атлан безгә, колларыңа атлан!

* * *

*«Томаннар күмгән кайтыр ягымны.*
*Кыялар текә, чоңгыллар тирән...»*
Хәсән Туфан

Имеш-мимеш хәбәр йөри,
Йөри хәбәр бик хәтәр.
Ошбу хакта язу түгел,
Уйлау куркыныч хәтта.

Мәрхәмәтлем! Синең алда
Гафу үтенәм башта.
Син белмәгән берни дә юк,
Яшермә миннән, патшам!

Имеш, каты чирләгәнсең,
Чирең, ди, бөеклектән.
Мәтәлгәч «СССР» дигән
Дәүләти биеклектән.

Ушка килеп, көч-хәл белән
Торып баскач, иң тәүдә:
«Кашка тәкә булмыймын» дип,
Иткәнсең, имеш, тәүбә.

Татарны «кол» исеменнән
Мәхрүм итүче Указ
Әзерлисең, диләр. Бәхет
Тидеме безгә бик аз?!

Биш гасыр да тулмаган бит,
Өйрәнеп беткәч кенә,
Колларыңның холыклары
Көйләнеп беткәч кенә,

Дөньяны кабат түңкәреп,
«Кеше» булырбыз ничек?
Кан-яшьтән торган дәрьяны
Ничек чыгарбыз кичеп?

Туры басып йөреп булмас,
Без сораудай бөгелгән.
Бар микән ясаучы табиб
Операция билгә.

Без — без инде, ә үзең соң,
Ә үзең соң нишләрсең.
Ашыйсың килгән чакларда
Терсәкнеме тешләрсең?

Туры килмәсме урарга
Кабат ыштырларыңны.

Саргаюыбыз ихтимал
Сагынып шпорларыңны.

Имеш-мимеш чынга чыкса,
Очрашырбыз бик сирәк.
Хуҗа колсыз яши алмый,
Колга да хуҗа кирәк.

Бусы чәчкә генә икән...
Йөри тагын бер хәбәр.
Йокылардан яздырырлык,—
Хәтәр дисәң дә хәтәр.

Ялварамын: гөнаһларым,
И Ходам, ярлыкагыл!
Патшам!
Мине патша итеп,
Булмакчысың икән... кол.

Бу соң нәрсә?
Мин — син, син — мин?
Алышумы «баш на баш»?
Кимсетмә! Булмады минем
Атканым ашыңа таш.

Беләсең ич, мин дә кидем
Олуг ханнар җиләнен.
Үптең керсез чабуларын,
Эчтән генә җирәнеп...

Юк, теләмим! Мин дә бер көн
Бөеклектән чирләрмен.
«Кашка тәкә» атлы ханны
Күптән инде җирләдем...

Киңәшем бар: син үзеңә
Патша да бул, кол да бул.
Бигайбә! Мин дә үземә
Хан да булыйм, булыйм кол.

Бөек патшам! Уйлап бак та
Мин колыңа хәбәр ит.
Инәләмен, яза күрмә:
«Булачак Хуҗам Фәрит».

# ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

*«Татарстан белән Башкортстан арасындагы дәүләтара килешү»нең үтәлешенә бер караш.*



**Айдар Хәлим**

# ГОМЕРЕМНЕҢ УН КӨНЕ

СӘЯСИ АЧЛЫК КӨНДӘЛЕГЕ

Айдар Хәлим исеме укучыларыбызга күптәннән таныш. Ул, Тукай әйтмешли, «коеп куйган шагыйрь» генә түгел, танылган драматург та, прозаик та. Әдипнең иҗат гомерендә публицистика, ил-дөнья вакыйгаларына карата үз вакытында кайнар сүзне батырып әйтә белү маһирлыгы — үзенә аерым бер урын биләп тора. Аның публицистикасы тормыштан, үз биографиясеннән аерылгысыз. Милләт азатлыгы өчен көрәш мәйданы уртасына ташланган Айдар Хәлим соңгы елларда хәтәр вакыйгалар эчендә кайнады, күп әдипләр дәшмәү — алтын, дип тыныч култыкка посып яшәгәндә иң четрекле мәсьәләләрне — татар-башкорт арасындагы мөнәсәбәтләрне куертуның эчке, яшерен сәбәпләрен ачып салып дөньяга гадел аваз бирде — мең авырлыклар белән бу китабын Литвада бастыра алды.

Айдар Хәлим хәзерге көндә зур күләмле әсәрен төгәлләп килә. Чор-дәвернең кардиограммасын чагылдырган бу язмада әдипнең үз биографиясе, шәхси уй-хыяллары да, милли көрәш фонында мөнбәргә менгән кайбер шәхесләрнең, сәяси җитәкчеләрнең битлеген ачып чын йөзен күрсәтү дә, әдәби мохиттәге һәртөрле каршылыклар, намусына хыянәт иткән каләм әһелләренең эшчәнлеге дә тәфсилле сурәтләнә. Давыллы холкына хас булганча, Айдар Хәлим чордашларына бәһа биргәндә рәхимсез дөреслеккә омтылам дип, урыны-урыны белән артык усалланып та киткәли, чама хисен арттырып та җибәргәли. Әмма ни генә булмасын, фәлсәфи уйланулар, лирик чигенешләр, бәхәссез документлар, аяусыз гомумиләштерүләр белән сипләнеп барган бу әсәр — замана сурәте булырлык. Без татар публицистика тарихына олы кораб булып керәсе бу әсәрнең кыскартылган бер өзеген журнал укучыларына тәкъдим итәргә булдык, язучының күңел карлыгачына хәерле сәгатьтә! — диик.

**Марсель ГАЛИ**

# Калфак астында

## Беренче көн, җомга

Тынлыкны ярып, сәгать чылтырады. Дүрт сәгать утыз минут. Төнем минем бу минутны көтеп, йокысыз үтте. Сәгатьне исә, йокымсырап китсәм дип, болай гына уятырга куйган идем. Таң аткан. Күк йөзе өметле генә яктырып килә. Төнлә яуган кар-яңгырдан соң юеш асфальт чуен сыман ялтырап ята...

Октябрь ае өчен гадәти булмаган авыр, җылы киемнәремне кисенә башлыйм. Буровойдан кайткан сырма чалбар, сырма бишмәт, аның өстеннән резин плащ, аякларга — җылы оекбашлар, кирза итек...

— Чыкма, дим... Һичкенәләр дә рөхсәтем юк... Йөрәгемнең нинди икәнен беләсең...

Минем кебек төне буе йокламаган хәләл җефетем соңгы тапкыр гозерен әйтә. Бу хакта бәхәс ике ай дәвам итә инде. Гамәлдә, гомер иткән хатыным да, унсигез яшьлек кызым да мине тулысынча аңлыйлар, әмма, теләктәш булсалар да, бер гаепсезгә еллар буе яман сүздән төшмәгән якын кешеләренең «тагын да адәм көлдерүен» теләмиләр. И сабыйларым!.. Мин аларны бер мәҗүси сөю белән сөям. Төшенәм, хатынымның хәле минекеннән дә авыррак. Ул бала өчен дә, минем өчен дә, үзе өчен дә икеләтә җаваплы.

Кичтән үк әзерләп куйган әйберләремне эчке бүлмәдән тышкы ишек катына ташый башлыйм һәм сигезенче каттагы фатирым тәрәзәсеннән аска — подъезд алдына күз ташлыйм. «Москвич» килеп туктаган. Молодец, Ирек! Әмма нигә Кадерле күренми? Әллә бер-бер хәл булдымы? Кире уйладымы? Кеше буларак, мин аны аз беләм. Минем белән бергә сәяси ачлыкка чыгачагын ул берничә көн генә алдан әйткән иде. Монда реактив романтика белән генә әллә ни кырып булмый. Сизенәм, Кадерле — буш куык, чиле-пешле романтик түгел. «Йөрәк минем инфарктан соң, Айдар дускай, түзә алганчы, ике-өч көнгә булса да сиңа иптәш буласым килә», — дигән иде ул. Мин, әлбәттә, чиксез куандым. Уфа бит бу, Уфа!.. Рәсми исәп белән әйткәндә, җиде миллион татар, бер миллионлы шәһәр алдында мондый адымга бару — бу бит безнең милләттә булмаган, күренмәгән, аңлашылмаган, димәк, бөтенләй «кирәкмәгән эш». Уфа татар мәдәният мәркәзенең сәяси ачлыкны әзерләү буенча яшерен штабы утырышында миңа кечкенә язу килгән иде: «Утырышта чит кеше юкмы?» Татар хәрәкәтенә теләктәшләрдән анда бер-ике «чит», әле мин белеп бетермәгән кеше булса да, мин гомуми уй-планнарны яшереп тормадым. Чөнки рәсми рәисе профессор Марат Рамазанов исәпләнсә дә, фактик житәкчесе Кәрим Яушев булган һәм нибары биш-алты очраклы кешедән торган Татар иҗтимагый үзәгенең безнең сәяси ачлык акциясенә каршы булуы, «көрәшне бары тик парламент юлы белән генә алып барачаклары» билгеле иде миңа. Хәбәрнең КГБ һәм МВД органнарына да билгеле икәнлегенә шикләнми идем. Мин гомуми колактан бары тик ачлык игълан итү урынын һәм көнен генә яшердем.

Минутлар еллар сыман озак үтте. Дүрт сәгать кырык минут. Тагын ярты сәгатьтән без милләт хакына вахтага басарга тиеш. Бу ярты сәгать эчендә безнең әле ничә борылыш, ничә чатны үтәсебез бар?! Хәтердә остазым Сибгат Хәкимнең «Кырыгынчы бүлмә» поэмасыннан юллар калкып чыга:

Тыңгысыз чат, тынгы бирмәс җанга,
Үзем тынгач, шушы чат тынар,
Тукай тавышы, кычкыра күк Тукай,
Бер генә сүз яңгырый: саттылар...
Базарларда печән, он сатылган,
Җир сатылган, кеше сатылган...

Юк, булмас! Мин яңадан тәрәзә катына килəм. Карлы яңгыр астында, автомобиленә кадакланып, Ирек Әхияретдинов мине көткән. Искиткеч зыялы, төгәл егет. Күптән түгел маржасы белән аерылды. Черниковкадагы бер мәктәптә татар сыйныфы оештырып, кызын шунда татарчага өйрәтә. Өйләнергә татар кызы эзли... Күк йөзе актарылып, юеш асфальтка капланган кебек күренә миңа хәзер. Тагын өч минут көтәчәкмен. Кадерле белән булган соңгы сөйләшүләрнең берсен хәтерлим. «Хәлләребезне аңлатып, Ельцинга хат язган идем. Кулыңны куеп җибәрмәссеңме?» — дигән иде ул миңа. «Нигә үзең җибәрмисең? Кайчанга

кадәр үз җаваплылыгыбыздан куркачакбыз?» «Мин бит бәләкәй кеше, аннан ярымхәрби заводта эшлим... Үзең беләсең». Юк, булмас. Кадерле бит әле теге хәтәр заманнарда Үзәк Комитетларга хатлар язган, аларны завод ксерокcларында күбәйткәне өчен күзәтү астына алынган кеше. Анын шундый бер хаты минем архивымда саклана: «Башкортстан составына көчләп кертелгән татар халкы алдында ике юл бар: татарлар күпләп яшәгән элекке Уфа губернасы районнарын Татарстанга кушу, йә Башкортстан эчендә үз милли мөхтәриятләренә ирешү. Безнең үз язучыларыбыз, композиторларыбыз, рәссамнарыбыз, газета-журналларыбыз, китап нәшриятебез булырга тиеш...»

Мин, аркама капчык йөкләп, сак кына ишекне ача башлыйм. Хатын сикереп тора һәм тупсага аркылы ята:

— Чыгармыйм!.. Җибәрмим!

Мин аны күтәреп алам һәм тынычландырырга тырышам:

— Кирәк, җаныкаем, кирәк! Аңлыйсыңмы?!

— Бар! Мин синең янына эз дә басмаячакмын!

Белгән догаларымны укып, амин тотам һәм фатирдан чыгам. Гильотина пычкысы төймәсенә баскандай, лифт төймәсенә басам һәм аска убылам...

Бирелгән иде шундый көч — кимсез Тукай затыннан.
Киерелгән иде шундый үч — анты Гали батырдан.
Алдадың, ләгънәтле ялган! Актардылар эчләрем.
Тапшыралмадым милләткә миллион атлы эшләрем...
Килер көн, гяур көл иткән җир-тормыш чәчәк атар;
Хокугым яулыйм мин — татар! Ни ләззәт әйтү: татар!
Ля иляһы иллялләһу! Мин сезнең өчен үләм.
Таң атканда тәкбир әйтеп, ишектән чыгып киләм...

Лифттан чыгуга — Кадерле! Мин аны кочаклап алам.

— Раяны тынычландырып тордым, малай. Хатын-кыз бит... Кичә — риза, бүген — икеле-микеле...

— А-а-йдар а-а-бый, д-д-винули? — ди Ирек гадәттәгечә матур тотлыгып.

— Ку, Ирек!

«Москвич», кар-яңгыр суын чәчрәтә-чәчрәтә, әле уянып өлгермәгән Уфа урамнарыннан Салават һәйкәле тарафларына — милли хәрәкәт көрәшчесе Роберт Яруллин фатирына таба җилдерә. Анда безне көтәләр. Кичә егетләр ялгыз яшәгән Робертның шыр ялангач бүлмәсендә унбиш минут эчендә чатыр корырга өйрәнделәр. Киң эшләпәле, бармак юанлыгындагы дюбельләр, чүкечләр, баулар, транспарант, таләп-чакырулар һәм башка кирәк яраклар — барысы да әзер. Ятарга урын-җир, раскладушкалар, термослар — җыя башласаң, байтак җыела икән ул. Нурфаяз Шәрәфиев, Мәҗит Нугаев, Роберт Яруллин безне дүрт күз белән көтәләр иде.

Әйберләрне төяп, без ике машинада Совет мәйданына юл алдык. Минем иң курыкканым — мәйданга керә алмау иде. Информация чыккан хәлдә органнарның бу урынга сак куячаклары көн кебек ачык иде. Дөрес, без бу акцияне көннән-көнгә кичектерә килдек һәм, ниһаять, бик җаваплы вакытка — Башкортстан Югары Советының дәүләт мөстәкыйльлеге һәм Телләр турындагы Законын кабул итәчәк сессиясе ачылырдан җиде көн алга — 5 октябрьгә тәгаенләдек. Совет мәйданы — Уфаның иң стратегик ноктасы. Анда кереп булмаса, чатырны КПССның Башкортстан Өлкә комитеты алдына куячакбыз. Шуңа күрә, хакимиятне саташтырыр өчен, без сәяси ачлык урыны итеп Черниковка белән Уфа уртасындагы Ленин мәйданын сайлавыбыз турында ялган хәбәр дә җибәргән идек. (Соңыннан расланyынча, органнар безне чынлап та Ленин мәйданында көткән һәм аны почмаклатып, бер взвод милиция белән ураткан булып чыкты).

**Көндәлекләрдән. 19.02.86.**

*Төрле регионнардан газитләрдә хәбәрләр чыга: һәр республикада иҗтимагый-сәяси һәм милли оешмалар оеша. Аларны ни өчендер «формаль булмаган» оешмалар дип атыйлар. Кем тапкан икән мондый «сәер» исемне? Гомумән, кемнәр эзләп таба шундый «милләтара мөнәсәбәтләр», «формаль булмаган оешмалар» кебек атамаларны? Әйе, милли мәсьәлә юк, ә менә «милләтара мөнәсәбәт» бар... Ничек кенә аталмасын, Уфада татарның мондый «формаль булмаган оешмасын» тергезеп җибәргәндә яхшы булыр иде... Әмма кемнәр белән? Кемгә чишелергә мөмкин? Хәер, мин алтмышынчы еллар азагында Түбән Камада татарның беренче мондый оешмасын оештырып җиңк күргән идем инде. Бу эшне, бәлки, Казан башларга тиештер? Шулай да аннан мондый хәбәрләр ишетелми...*

Мин үземнең кайчаннан алып һәм нинди басым астында яшәгәнемне яхшы белә идем. Бу хакта рәсми җитәкчеләрнең миңа турыдан-туры әйткәннәре бар иде. Хәтердә, моннан ике ел чамасы элек, 1988 елның апрель азакларында, «Дружба народов» журналында «Язык мой — друг мой...» исемле мәкаләм басылып чыгар алдыннан, мин бу хакта Уфада бары үзем генә белгән кеше буларак, язмамның бер нөсхәсен күтәреп, Башкортстан прокуратурасында һәм КГБ сында булдым. Эш шунда ки, мин милли мәсьәләләрне тавыш-тынсыз, урында хәл итү өчен чаралар эзләдем. «Советская Башкирия» газетасының бүлек мөдире Иван Тряпкин бу мәкаләне дүрт санга әзерләгән дә иде. Әмма редактор вазифасын башкаручы Вячеслав Устинков аны басарга курыкты. Өлкә комитетының идеология буенча секретаре, үз гомерендә үзе теләп бер китап, бер кульязма укымаган «рухи җитәкчебез» Әхнәф Дилмөхәммәтов мәкаләне басудан тыйды. Яклау эзләп, имештер ки, мин ин җаваплы кешеләргә барам. Республикадагы милләтара мөнәсәбәтләрне адәмчә кысаларга кертү прокуратура белән КГБ эше түгелмени? Нәрсәдән куркырга? Киресенчә, ачыктан-ачык сөйләшергә һәм хәл итәргә кирәк! Әмма мин никадәр беркатлы булганмын, хәер мин аларның бу мәсьәләдән йөз чөерәчәген алдан ук белә идем инде. Гомеребездә бер тапкыр күрешмәгән прокурор Кравцев (ул соңыннан СССР Генераль прокуроры Трубинның урынбасары итеп күчерелде — күрдеңме безнекеләрне!) мине бик яхшы белә булып чыкты.

— С чем пожаловали?

Мин аңардан мәкаләне укып чыгуын һәм матбугатта күрсәтү өчен юридик этәргеч бирүен, ягъни прокурорлык күзәтүен тәэмин итүен үтенәм. Мин бер бөек җинаять эзеннән прокурорга килдем. Ул җинаять — шәхес иреген кысу. Шәхесне шәхескә, милләтне милләткә каршы котырту. Бер милләттән Тәңре-милләт, икенчесеннән вак, Кол-милләт ясау. Берсеннән мәңгелек дус, икенчесеннән мәңгелек дошман образы әвәләү. Тын юлларын бикләп, бер милләтне икенчесенә хезмәт иттерү. Кешеләр арасында гына түгел, милләтләр арасында да сорыкорт милләтләр тәрбияләү.

— Так, причем я? — диде Кравцев, маңгаен җыерып. — Обращайтесь в Союз Писателей, в «Советскую Башкирию»...

— Устинков — великодержавный шовинист, — дидем мин. — Он никогда не пропустит статью о «давно решенном» национальном вопросе. Нужна помощь со стороны органов законности...

— А вы кто — интернационалист?! — Кравцев каһкаһәләп көлде. — Вы же травите народ на народ! А, кстати, почему татары сами не открывают школы, журналы и издательства?

Ары таба сөйләшеп торуның мәгънәсе юк иде. Мин КГБга киттем. Мине милләтара мөнәсәбәтләр бүлеге начальнигы — «төп күзәтчем» полковник Фәсим Ямалиев кабул итте. Ярты сәгать вакыт үтмәде, ул Башкортстан КГБсы рәисе полковник В. Поделякинның минем белән танышырга теләвен җиткерде. (Озакламый, гадәттәгечә, Мәскәүдән китереп утыртылган кәгэбэчы полковник генерал дәрәҗәсе алып һәм Рәсәй КГБсы рәисе урынбасары итеп үстерелер — күрдеңме безнекеләрне! Владимир Иванович Поделякин, психология фәннәре кандидаты, чынлап та бик нечкә психолог, үз эшенең остасы булып чыкты. Мәкаләне укып чыкканнан соң, без аның белән милли мәсьәләләр буенча алты сәгать буе аяусыз сүз алыштык. КГБның үз оясында минем үземне шулкадәр иркен тотканым өчен уңайсызланган татар Ямалиев, вакыт-вакыт урындыгына сеңеп, юкка чыга иде. Ә Поделякин түземле. Әйтеп бетермәгәнен күз кысып аңлата. Шактый уңышлы оешып барган татар милли-азатлык хәрәкәтен шундый ук уңыш белән таркатуда Союзда беренче буларак Уфада һәм тулаем Башкортстанда нечкә экспериментлар үткәргән Владимир Иванович, күз кысып, миңа болай ди:

— А вы ничего не бойтесь. Будьте смелее. Вы давно находитесь под нашим колпаком...

**Көндәлекләрдән. 07.08.87.** *Бүген «Кызыл Таң»да Фәрит Гәбдерәхим янында көтелмәгән һәм кызык танышу-очрашу булды. Мин килеп керү белән әдәбият бүлегендә Мәсгут Салихов һәм Марат Фәтхелисламов дигән яшь егет пәйда булдылар. Беренчесе белән күптән түгел генә Фәрит таныштырган иде. Бик тә милләтпәрвәр кеше күренә. Фронтовик. Лаеклы ялда. Марат белән шунда таныштык. «Безгә татарларның формаль булмаган оешмасын оештырырга кирәк», — диде Мәсгут абзый. «Тсс!» — дип мин аның авызын томаладым һәм Марат белән икесен күршедәге буш күрше бүлмәгә алып кереп сөйләштем. Мин аларның кем һәм нинди кешеләр икәнлекләрен белмим. Белгәннәрен кайн табасың? Андыйларны*

*көтеп купме вакыт уткәрергә мөмкин? Башларга кирәк. Ышанам, бүгеннән башлап Уфада һәм Башкортстанда татар милли азатлык хәрәкәтен оештыру буенча ачыктан-ачык көрәш башланачак...*

Кабул итү бүлмәсеннән кызкай кәһва ташый. Берничә мең квадрат метр мәйданны биләгән, подвалларына, көне килсә, бөтен Идел буе һәм Урал төбәгенең барлык акыллы башларын сыйдырачак мәрмәр бинада тынлык. Беләк юанлыгы кабельләрдән телефоннан сөйләшкән рыясыз адәмнәрнең йөрәк тавышын тыңлыйлар. Болай гына. Хәбәрдарлык өчен. ҮКның махсус карары белән шул заманның биш миллионына төшереп Уфада салынган «региональ» КГБ бинасының түбәсендә ерактан һәм якыннан тыңлау антенналары. Кеше түгел, танк колоннасы үтәрлек биек һәм калын броня ишекләрдән урам тупигына чыккач, халыктан яшереп, төнлә куелган бөек чекист Дзержинский һәйкәле.

— Значит, бывшего первого секретаря Башкирского обкома Шакирова могу отдать под суд народов? — дим мин тагын да батыраеп.

— Не сильтесь,— ди Поделякин нәзакәтле генә елмаеп.— Не тратьте время попусту. Ведь у вас и других дел предостаточно...

Әлбәттә. Мин милли аңы булган егет һәм кызларыбызны татар азатлык хәрәкәтенә кертеп, ә Поделякин меңләгән штаттагы һәм штаттан тыш хезмәткәрләрен җигеп, аларны сафтан чыгарып тора.

— О посещении нашего ведомства такими крупными птицами, как вы, завтра в девять утра будет доложено первому секретарю обкома товарищу Хабибуллину. Я передам ему вашу просьбу о необходимости публиковаться в «Советской Башкирии»...

Без җылы хушлашабыз. Кирәк чакта тагын да килергә кушалар. Никадәр хуш күңеллелек!

Әмма мәкалә чыкмый. Ә минә минем «үз теләгем белән» КГБда кабул ителүем турында хәбәр Башкортстанның барлык газеталарында басылып чыга. Никадәр нечкәлек!

* * *

Ниһаять, без Совет мәйданына килеп керәбез. Тып-тыныч. Андый-мондый сакчыллык та сизелми, милиция нарядлары да күренми. Мәйдан уртасындагы чәчәк түтәле янәшәсеннән, әгәр элекке Министрлар Советы бинасыннан карасаң, сул кулда (урынны алдан сайлаган идек), асфальтта чүкечләр белән чен-чең килеп, егетләр чатырны урнаштыра башлады. Кадерле белән без тимер өчаякларга ныгытылган «Сәяси ачлык тотучыларның таләпләре»н куеп маташтык. Ун-унбиш минут үтеп тә өлгермәде, чатыр әзер иде. Иң тәүдә раскладушка, мендәр-юрган, термослар һәм башка кирәк-яракларны керттек. Аннан мин Нәүрүз бәйрәме уңаеннан татар милли хәрәкәте үткәргән митингта мөфти хәзрәтләре Тәлгат Таҗетдин бүләк иткән Коръәнне алып кердем. Кинәттән «Башнефть» бинасы башындагы сәгать сукты. Биш сәгать утыз минут икән. Коръән дә кергәч, сәгать тә суккач, безнең өй эче яктырып киткәндәй булды, күңелләр дә ничектер тынычланды. Егетләр белән бергәләп, дога кылдык. Шулай итеп, сәяси ачлык башланды. Инде бу юлдан, бу урыннан безне беркем дә кузгата алмаячак. Амин! Без кочаклашабыз. Мин бүгеннән башлап тәмәке тартмаячакмын. Егетләр безне ташлап китмәячәк. Алар — кизүдә. Кизүләр хезмәте белән көрәштәшебез Зөфәр Хәйбрахманов җитәкчелек итәчәк. Тегенди-мондый сәяси һәм хәреф хаталары китмәгәнме, дип, мин «таләпләр»не яңадан укый башладым.

*— Татар телен башкорт һәм урыс телләре белән беррәттән дәүләт теле итеп игълан итү;*

*— «Нефтяник» мәдәният сараен татар «Нур» театрына бирү;*

*— Татар мәдәният мәркәзе һәм иҗтимагый үзәгенә КПССның Башкортстан өлкә комитетының ике катын бирү;*

*— татар яшь тамашачылар театрын ачу;*

*— татар балаларын кичектергесез рәвештә туган телләрендә укытуга күчерү; татар балаларын «интернационалист» миссионерлар түгел, татар мөгаллимнәре укытырга тиеш;*

*— «Дружба народов» журналында чыккан «Язык мой — друг мой...» мәкаләсен (1988, 6) кичектергесез рәвештә башкорт, татар һәм урыс телләрендә басып*

*чыгару, әсәр буенча Ростов киностудиясе төшергән һәм Үзәк телевидение экраныннан Үзәк Комитет тыйган «Как стать экстремистом» фильмын Башкортстан телевидениесе буенча күрсәтү;*

*— Тугандаш Әзәрбайҗан, Латвия, Литва һәм Эстония территориясеннән совет гаскәрләрен чыгару;*

*— Башкортстан Югары Советы рәисе Рәхимовны, мәдәният министры Әминевны, мәгариф министры Гардановны, КПСС өлкә комитетының матбугат секторы мөдире Тимербулатовны, Башкортстан радио һәм телевидение комитеты рәисе Кильдинны — татар халкы мәнфәгатьләренә каршы көрәшүче көчләрне — отставкага җибәрү.*

**Айдар Хәлим, Кадерле Имаметдинов.**
**5 октябрь, 1990 ел».**

Шулай итеп, без плацдарм яуладык. Машиналарыбыз шундук шылды — номерларын күрә күрмәсеннәр. Мин, кичтән үк ашказанын юдыртып яткан кеше, һаваны тәмләп карыйм. Ул ниндидер әрем балы, сәер татлы тәм белән аңкый кебек. «Кузгала тәмле һава...» — дип кабатлап куйдым мин аксакалыбыз Сәйфи Кудаш шигырен.

*Архивтан. «Уфада яшәп иҗат иткән күренекле шагыйрь Сәйфи Кудаш 99 яшендә вафат булган. Бу турыда соңарып хәбәр ителде. Күренекле шәхесебезне үзләштерә күрмәсеннәр диптер инде, шагыйрьнең җеназасына татар язучыларын чакырып тормаганнар».*

*«Татарстан яшьләре», 10.08.93.*

**Көндәлекләрдән. «13.08.93.** *Бертуган Кашаповлар исәбенә «Аргамак» журналы каршында оешкан безнең «Алтын Урда» концерт бригадабыз Павлодар далаларыннан кайтып төшүгә, Уфадан кайгылы хәбәр — Сәйфи бабай үлгән... Мин аның белән соңгы тапкыр былтыр җәй очрашкан идем. 99 яшьлек тере «музей» уктугыз яшьлек егетләргә биргесез яну-ялкынлану белән «Аргамак» журналының беренче (1991, октябрь) санында ук «Тисә — тиенгә, тимәсә — ботакка...» дигән искиткеч көчле мәкаләсе белән катнашкан иде. «Син, энем, үзеңнең нәрсә сөйләгәнеңне белебрәк сөйлә», — дигән иде ул аны соңгы елларда тәмам пычракка батыру өчен тырышкан әрсез публицист Газыйм Шафиковка. Татар дөньясы әле беренче китабын 1917 елда ук чыгарган асыл улын югалтты. Аның искиткеч архивы, егерме меңнән артык хатны үз эченә алган йөзләгән папкалары белән нәрсә булыр? Башкортстанның тарих, тел һәм әдәбият институтындагы наданнар кулына күчеп, череп, юкка чыгармы? Әллә Казан аны үзенә алдырырмы?» Һаман да шул «кысылмыйбыз», — диярләр инде. Тукайдан соң сирәк кабатланган моңсулык...»*

Әмма бу әкияти халәт озак дәвам итми. Милиция УАЗы мәйданга тәгәрәп килеп чыга һәм безнең куышыбыз өстенә үк менеп диярлек туктый. Әчегән помидор кебек тулышып, энә белән төртсәң, шартлардай коңгырт-кызыл йөзле капитан симертелгән гладиаторны хәтерләтә иде. Бәләк танау. Сәйлән күзләр. Бу күзләрнең гомерендә бер тапкыр Байронны да, Тукайны да укыганы юк. Әмма «үз кеше». Татар. Илеш-Дүртөйле сөйләшендә урыс телен шактый бозып, ул безгә беренче тарихи сөйләм ычкындырды:

— Ыхту эздись? Зәчим эздись?

— Без, Советлар Союзы гражданнары язучы Айдар Хәлим һәм эшче Кадерле Имаметдинов, милләтләр тигезлеген яклап сәяси ачлык игълан иттек.

— Эздись нильзә!

— Ә кайда ярый?

— В Воркута!

— Рәхмәт.

— Ыспасибо сыт не бүдишь! — Офицер шаркылдап көлде. Өч мильтон чатыр ишеген ачып карадылар, аннан эленгән язуларга күз төшерделәр. — Вәләй әтсуды!

— Без беркая да китмәячәкбез. Сәяси ачлык бары тик шушында дәвам итәчәк.

— Ха! Типыр мы все галудные! Дүрәки вы и вчу, вәт ышту я скажу! Помирайте галудные!

Машина ишеге шарт ябыла. УАЗ, көпчәкләре белән ырылдап, китеп бара.

Башланды. Башлана башлады. Бу — беренче жиңү иде. Әмма беренче мондый җиңүне татар дөньясында Чаллы милли-азатлык хәрәкәте житәкчесе Зиннур

әфәнде Әһлиуллин яулады. Шәһәр советы бинасы каршында унике көн сәяси ачлык тотты ул. Казаннан Чаллыга килгән Борис Ельцинны һәм Шәймиевны үз янына чыгарга, әңгәмә корырга мәҗбүр итте. Ә без бу көннәрдә «Кызыл таң»ның кеше күрми торган урынында булса да, Зиннур Әһлиуллинга теләктәшлек белдерә һәм Башкортстан татарларына хәбәр бирә алдык. Һәм менә без икенче булып калыктык. Безнең арттан, 1991 елның 35—40 градуслы эссесендә, кара асфальтка милләтебез каһарманнары Фәүзия Бәйрәмова, шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов, актер Илдус Әхмәтҗан, язучылар Зәки Зәйнуллин, Газинур Морат, Заһит Мәхмүди, Әхәт Мушинский, Азнакай якларыннан Фазыл Вәлиәхмәтләр чыгар һәм ундүрт көн буе халык дингезе һәм эрегән сумала эчендә кайнар...

Министрлар Советы бинасын чәүкәләр камап алган. Әле алар көньякка китеп бармаган мыни? Безне көткәннәр мәллә? Күңелдә шигырь ярала, әмма язарлык түгел — чатырда караңгы, тышта сибәләп кенә яңгыр ява башлады.

Бу мәйданда без барыбыз да ирексез. Шартлы рәвештә генә Башкортстан дип аталган татар-башкорт республикасында бүген татарга каршы алып барылган сәясәттә шундый ук ирексез гади башкорт халкының бер гаебе юк бит. Нәрсә белә дә, нәрсә уйлый ул? Совет мәйданын «Буйсындырылмаганнар мәйданы» дип атыйсым килә башлый. «Площадь непокоренных».

Егетләр тышта йөренгәләп тора. Кадерле алар белән. Мин, башкорт халкына изгелек эшләү урынына, бөтен көчләрен шушы изгелекне явызлык итеп, татарга каршы юнәлтү турында баш ваткан әһелләр утырган биналар, ягъни Совет мәйданы хакында уйланам. Әйе, урын гаять дөрес сайланган. Артта — татарны аңгыралату өчен башкортча гына китап чыгаручы китап нәшрияты. Китапларын сата алмагач, ел саен дистәләрчә мең сумлык китапларны списать итеп, кошчылык фабрикаларына чебеш аяк астына җибәрәләр. Бер-ике татар бар анда, әмма «башкортса һөйләшәләр». Бераз арырак КПССның Киров райкомы. Шул тирәдә үк КГБ резидентурасы.

**Көндәлекләрдән. «27.11.87.** *Татар хәрәкәте активисты булып киткән Марат Фәтхелисламов, инженер егет, миңа бүген болай диде: «КГБда мин полковник Фәсим Ямалиев белән очраштым. Әгәр сез татар мәдәният клубына җитәкче итеп Айдар Хәлимне сайласагыз, бездән өмет көтмәгез». Кызык, кайдан танышкан бу егет КГБ полковнигы белән? Нигә полковник кадәр полковник бер очраклы танышка мондый җаваплы фразаны әйткән? Һәм нигә моны минем үземә әйттерәләр? Их, кадрлар, милли хәрәкәткә кадрлар җитешми, теш кысып, турыдан ярмаска, һәркемне сакларга, якларга туры килә, шайтан алгыры!»*

Якында гына Башкорт педагогия институты бинасы. Шунысы кызык, Казандагы югары уку йортлары гел генә «Казанский» исемен, ә Уфада гел генә «Башкирский» исемен йөретәләр.

Казан дәүләт университеты. Башкорт дәүләт университеты. Казан авыл хуҗалыгы институты. Башкорт авыл хуҗалыгы институты. Кызык бит! Башкорт педагогия институтында, әлбәттә, башкорт филология факультеты һәм кафедрасы бар.

Куышымда ниндидер тавышлардан айнып китәм. Автомобиль тормозы. Авазлар:

— Голодовку объявил, говорят...

— Зачем?

— Кто?

— Какой-то Хаким что ли...

Мин беренче тапкыр термостан кайнаган чишмә суы эчәм. Җанга җылы йөгерә. Сигез сәгать кырык биш минут икән. Чуендай авыр киемнәрем белән урыннан күтәреләм һәм тышка чыгам... Мәйданны «Башнефть»кә эшкә килүчеләрнең «Икарус»лары биләгән. Кайда карама — халык. Алар безнең чатырны күреп, аптырап кала һәм, кызыксынып, тирәләп йөри, безнең язуларны укый башлый...

— Дөрес язганнар...

— Противопоставляет народы! Под суд его!..

Милиция майоры. Танышабыз. Фәрвәз Исламов дигән кеше икән.

— Сезнең куркынычсызлыгыгызны саклау безгә тапшырылды. Тәртипне милиция наряды саклаячак. Әгәр инде ситуация үзгәреп куйса, анда күз күрер,— ди ул ачыктан-ачык һәм кулны кыса.— Тазалыгыгызны сакларга иде, Айдар абый...

— Рәхмәт, туганым.

Бүген иртән, сәгать җидедән торып, көрәштәшләрем Сәид әфәнде Еникеев һәм Зөфәр әфәнде Хәйбрахмановлар төркеме мин биргән җитмеш-сиксән адрес буенча Уфа, Татарстан һәм Союз буйлап, шул исәптән Башкортстан Эчке эшләр министры Хәсәновка, КГБ рәисе Поделякинга, безне сак белән тәэмин итүләрен үтенеп, телеграммалар бирергә тиешләр иде. Димәк, алар тиешле җирләргә барып та җиткән.

— Кая соң ул үзе?

— Әнә басып тора, диләр...

Аю күргән кебек, минем тирәдә өерелә, рентген нурлары белән капшый, тикшерә, шикләнә, ләгънәтли, үз итә һәм ярата башлыйлар. Күрмәгән күзләре белән үбә, күргән күзләре белән төкерә, инкарь итә, бәхәсләшә һәм кочаклый. Һәм бу манзара ун көн буе дәвам итәчәк. Хәтердә — бу хәбәрдән кайнарланган ике татар апасы кулны кыса:

— И-и туганкаем! Нык торыгыз... Бездән, татардан да бар икән!..

Кемнәр без? Нинди каһарман, нинди батыр булыйк ди без?! Без бары тик иң гади кешелек бурычын үтибез. Без башкача булдыра алмыйбыз, чөнки бу кадәр түбәнчелеккә төшәргә ярамый. Татарны милләт итеп ялгаган җеп менә-менә өзелергә тора. Без аны күрәбез. Күрә торып та, күз йомарга һәм берни күрмәгәндәй, күз йомып, күши башларга без бары тик корсак колы — сыер түгелдербез бит?! Тукай — милләт намусы безне шулай тәрбияләдеме? Мәйданда ятканда күз алдымнан Тукай, Гаяз Исхакый, Җәлил кыяфәтләре беркайчан да китмәс. Татар шигъриятендә иң яраткан поэмам — Сибгат Хәкимнең «Кырыгынчы бүлмә»се тагын телгә килә:

Килде шагыйрь, Тукай килде җиргә,
Язганнары безгә бүләге.
Күрсәт, тарих, бар кайгысы белән
Татар халкы сыйган бүлмәне...
Үлде бөек токым... Кем дә әйтмәс:
Улларыңнан син, дип, уңмадың.
Халкым, алда улларыңны сакла,
Авыр чорлар кичерә улларың...
Мәктәбем дә, телем дә ул, Тукай,
Тукайдагы кебек тел кайда?
Мең елдан соң да бер синең, илем,
Кайтасыңны беләм Тукайга...

1985 елның апреленнән милләтебез Тукайга кайта башлады. Әмма шушы гүзәл әсәрнең авторы мәшһүр шагыйрь, остазым Сибгат Хәким генә бер ай элек, көтелгән үзгәрешләрне күрә-ишетә алмый, якты дөньядан китеп барды...

Ә мәйдан кайный. Хәбәр, күрәсең, бөтен Уфага таралып та өлгергән. Шактый гына танышлар да күренә башлады. Танышлар шундук безне электән күргән, күрешкән, хәл белешкән һәм күрмәмешкә салышкан танышларга аерылды. Кешеләр төркем-төркем булып безнең «Таләпләр»гә килеп туктала, үзенчә бәя бирә, моңа кадәр бердәм булган «совет халкы» төрле сортларга бүленә. Милли аңсыз булу коммунизмның нигезен тәшкил иткәнен ап-ачык күрәсең. Коммунизмны урысча укып, урысча сөйләп, урысча язып, урысча кино-телевидениесен карап төзү урыслар һәм милләтсез манкортлар өчен иң гадел юл икән. Бу — беренче сорт. Ә менә үз телеңдә укып һәм сөйләшеп коммунизм төзү — милләтчелек икән. Болай эшләргә теләүчеләр — икенче сорт. Безнең «Таләпләр» кеше аңын мизгел эчендә уята, ул гүя үзенә каршы үзе фетнә күтәрә, ягъни чистара... Читтән караганда, безнең чатыр тирәсе су тегермәнен хәтерләтә: агымсу килә, бөтерелә, китә... Килә, бөтерелә, китә...

Ниндидер фотограф аерым бер тырышлык белән мине алдан-арттан, уңнан-сулдан төшерә башлады. Бу озын буйлы кешене мин газета фотокорлары арасында күргәнем юк иде. Бу шундый үҗәтлек күрсәтә башлады ки, кайда барсам, минем арттан бара һәм — шалт, шалт, шалт! Бу мине туйдырды.

— Син кайдан, комитеттан мәллә? — дидем мин КГБны күздә тотып.

— Әйе, — диде ул һич яшермичә.

— Ул чакта тагын берне чәкет, — дидем мин киң елмаеп. — Сездә минем сурәтләр болай да аз иде инде...

— Рәхмәт.

Без, Кадерле белән кирәк-яракларны алып, Министрлар Советы бинасы бәдрәфендә тешләребезне чистартып чыгабыз. Табиблар безгә һәр ике сәгать саен тешләрне чистартып торырга кушты. Бу ихтыяҗны үтәмәсәң, ач торган ашказанга бактерияләр үтү куркынычы бар икән. Әлегә, әлбәттә, бу куркыныч

янамый, шулай да үзебезне беренче сәгатьләрдән үк шуна көндерергә тырыштык. Аннан йөрештереп алу туктаусыз урында яту, йә булмаса ат кәмите ролен үтәүгә караганда кызыклырак.

Әлегә кадәр телеграмм биреп азапланган егетләребез һәм кызларыбыз килеп җиткән. Аларның йөзендә горурлык. Риф Гомәров, Зөһрә Баязитова, Галия Батыршина, Зөфәр Хәйбрахманов, Җәвад Мәһәдиевләр... һәм, әлбәттә, җитмеш биш яшьлек ветеранбыз Сәид Хәнәфи угылы Еникеев. «Кошларны төрле тарафларга исән-аман очырдык,— дип пышылдый ул минем колакка.— Мәркәз кассасыннан биш йөз акча тотылды...» Мин аңа сокланып карыйм. Күпләр безнең көрәштән, аны күтәрә алмый, китәр. Ул китмәс. Ул ташламас. Озын буйлы, яшьләрчә чая күзле, Рим легионерларына хас борынлы бөек мишәр. Гомер буе партократия һәм тоталитаризмга каршы көрәшкән каһарман йөрәк. Атаклы Еники морзалар нәселеннән.

Чатырны ачып карарга, хәтта ниндидер тикшерү үткәрергә теләүчеләр дә күп булмакчы. Без монысын исәпкә алып җиткермәгәнбез. Роберт Яруллин кайдандыр ак шнур табып килә. Егетләр, күпмедер ара калдырып, җиргә тимер сөңгеләр кагалар һәм шнур белән чатырны уратып алалар. Алмашлап сакка басалар.

Кемдер мине арттан кочаклый, аннан бүрәнә әйләндергән кебек үзенә әйләндерә һәм кулны кыса. Бәрәч, Леонид Павлович бит бу! Софронов!

— Успехов тебе, Айдар. Духовно с тобой, а телом — нет. Начальник!..

Үзе ыржаеп көлә. Тагын бер мәртәбә иңемә дустанә суга да, баскычлардан йөгереп үзе эшләгән департамент — материаль-техник тәэминат идарәсенә кереп китә. Идарәнең начальнигы булып Софронов күптән түгел, КПСС өлкә комитетының беренче секретаре итеп Шакиров урынына Мәскәүдән Ревмир Хәбибуллин куелып бераз вакыт үткәннән соң гына эшли башлады. Шакиров тираниясенә каршы беренче булып баш күтәргән, аның тарафыннан төрмәгә утыртылган кеше ул Софронов. Уфа шәһәр комитетының элеккеге икенче секретаре. «Правда» газетасының Уфадагы үзхәбәрчесе Владимир Прокушевның бөтен дөньяны шаулаткан һәм Шакиров диктатурасының җимерелүенә китергән атаклы «Преследование прекратить...» исемле мәкаләсенең каһарманы. Сәерсенде Уфа: мона кадәр Шакировны хөкемгә тарттыру белән янаган Софронов көтмәгәндә генә ошбу идарә белән җитәкчелек итә башлады. Нәрсә, сындырдыларммы? Вазифасыннан алынса да, яшерен рәвештә икътисади киңәшчесе булып калган Шакировның киңәшен тотып куйдымы аны бу урынга Хәбибуллин? Мәкаләгә килгәндә, аның миңа билгеле өлеше дә шактый гыйбрәтле. Төрмәдә чакта Софронов Үзәк Комитетка хат артыннан хат яудыра. Әмма фәтвасы булмый. Ахыр чиктә ул хатыны аша Венгрия социалистик эшчеләр партиясе беренче секретаре Янош Кадарга мөрәҗәгать итә. 1956 елгы вакыйгалар чорында Леонид Софронов Кадарның шәхси сагында хезмәт иткән була. Венгрия җитәкчесе турыдан-туры Михаил Горбачевка мөрәҗәгать итә. Горбачев исә, әле күптән түгел генә Башкортстанда, Шакиров белән бергә Илеш игенчеләрендә кунакта булган булса да (Р. М. Горбачеваның бертуган сеңлесе Людмила Максимовна Уфада яши, теш врачы, ире — татар.) мондый абруйлы лидер үтенечен аяк астына сала алмый — Үзәк Комитетка килгән хатларны «Правда» редакциясенә тикшерүгә тапшыра. Әмма мәкаләнең юлы озын булып чыга. 1987 елның гыйнварында ук редакция секретариатына тапшырылган мәкалә бары тик 14 май санында гына дөнья күрә...

1987 елның август урталары иде булса кирәк. «Книга печали»ның беренче ике нөсхәсен Үзәк Комитетка һәм «Дружба народов» журналына тапшырып кайткач, өченче нөсхәсен яңа гына бу урында эшли башлаган Софроновка керткән идем мин. Аңарчы кульязманы Фәннәр Академиясенең Башкортстан бүлеге җитәкчесе академик Генрих Толстиковка укыткан идем. Поделякиндагы кебек чынаяк-чынаяк чәй эчтек, әмма Толстиковтан мин татар һәм башкорт халыкларының хәленә кергән бер генә кәлимә дә ишетмәдем. Саф күңелле булып кыланган урыс колонизаторы иде ул. Инде менә Софронов нәрсә әйтер? Алар бит, башка милләтләрне бары тик урыс ярдәмендә генә бит юарга өйрәнгәннәр дип тәрбияләнгән «өлкән туган», татар-башкортны монгол токымы дип кенә белә. Өч-дүрт айдан соң без аның белән очраштык.

— Монда минем өчен яңалыклар ифрат дәрәҗәдә күп,— диде ул елмаеп.— Уңышлар сезгә. Берәр бүлеген чыгарырга ярдәм итәргә дисезме? Була ул. Мин иртәгә үк Дильмөхәммәтовка шалтыратырмын. Кирәк икән Үзәк Комитетка — Снежкога чыгарбыз. Мин ярдәм итәчәкмен!..

Әмма кирпеч һәм цемент мәсьәләләренә кереп баткан «өлкән туганыбыз» ярдәм итмәде, хәтта качты. Хәер, мин аңа үпкәләмим. Җылы сүз өчен дә зур рәхмәт.

Кадерле Имаметдинов бер төркем башкорт студентлары белән сүз көрәштерә. Мин читтән тыңлап торам.

— Нигә бында татарга театр? Казанда бар бит...

— Халык монда яшәп һәм эшләп, театр карарга Казанга барсын мыни?

— Бәй, Казанга китегез...

— Әгәр миллион ярым татар Казанга күчеп китсә, мондагы промыселлар, заводлар туктап калыр бит? Сәхнәдән башкортча кем җырлар? Кем иген үстерер? Кадрларыгыз юк бит...

— Бында — Башкортстан! — дип кәперәя логикасы житешмәгән студент. — Башкортстан — башкорттар өсөн!..

— Көчеңне артык әрәм итмә, — дим мин якын килеп Кадерленең колагына. — Көрәшләр алда әле...

Зөфәр безне чатырга чакыра. 23 нче хастаханәнең баш табибы урынбасары Константин Михайлович Лапин килгән икән. Без аның белән җылы күрешәбез.

Бу искиткеч мәдәни, мөлаем кеше, махсус табибыбыз булмаганлыктан, артабан да килгәләп, безнең саулыкны карап торды. Әлегә ул безнең пульсларны тикшерде, гамәли киңәшләр бирде. Мондый шартларда кирәклек ихтималы булган байтак кына дарулар да китергән ул. Бигрәк тә Кадерле өчен. Әйткәнемчә, аның йөрәк белән эшләр хөрти.

— Иң мөһиме — ашказанын чиста тоту, аңа бернинди дә инфекция үткәрмәү, — ди ул. — Димәк, кич белән көн саен ашказанын юдыртып торырга кирәк. Зарарлы микроблар тешләрдә үрчеп, авыз аша керә. Шуңа күрә, егетләр, тешләрне даими тазартырга кирәк... Совмин шифаханәсенә барып, алдан ук сөйләшеп куярга иде сезгә.

Лапин китеп бара. Без Зөфәр сагы астында үзебездән түбәндәрәк, Пушкин урамында урнашкан шифаханәгә юл алабыз. Тагын да кар катыш яңгыр ява башлады. Өстәге болай да авыр киемнәр ифрат дәрәҗәдә авырайды. Без язучылар, композиторлар, гомумән, барлык иҗади халык, шушы шифаханәдә исәптә торабыз. Монда барысы миңа таныш. Таныш кынамы? Мин килеп керү белән һәркемнең йөзенә елмаю балкып чыга торган иде теге «әйбәт» заманнарда. Әмма бу юлы безнең киемнәрдән сәерсенгән регистратор хатын кычкырып җибәрде:

— Баш врач Ишмөхәммәтов чит кешеләрне кертмәскә кушты!..

— Мин чит кеше түгел, унбиш ел монда дәваланам...

Хатынкай мине танып ала. Мин аңа гозерләремне аңлатам. Ул Ишмөхәммәтовка йөгерә.

— Баш врач: «Ачлык тотучылар республика санэпидстанциясе шифаханәсенә барсыннар, диде», — ди ул уңайсызланып.

«Башнефть» шифаханәсенә киттек. Заманында, Урал-Себер магистраль нефть үткәргечләре идарәсендә өлкән инженер булып эшләгән елларда, мин анда дәвалана идем. Безне күрү белән өлкән шәфкать туташы:

— Процедурныйга түгел, бәдрәфкә дә чит кешеләрне кертмибез! Спид, малярия, тиф! Тьфу-тьфу! — дип читкә төкеренде. — Чыгы-гы-ыз, чы-ы-ык!

Без мәдәният министрлыгы һәм китап нәшрияте бинасына юнәлдек. Безнең үтенеч бик кечкенә — ачлык тоткан көннәрдә үзебезнең адәми ихтыяҗларны үтәү өчен бәдрәфкә кереп йөрергә рөхсәт алу. Якаларына аркылы-торкылы кисешкән штыклы винтовкалар билгесе кадаган сакчы хатын миңа, үз профсоюздашларым эшләгән бинага кертми.

— Хту? Куда? Бәдрәф? Никакуй бәдрәф ниту! Фуляган какуй!..

Кечкенә проблеманың халыкара низагка әверелүе мөмкин иде. Безнең чынбарлык исә кирәккәндә эшне зурга җибәрү, кирәкмәгәндә йомып калдыру буенча иң уңдырышлы туфрак инде. Шулай итеп, юыну-кырыну, теш чистарту һ. б. өчен бая кереп чыккан иске Совмин бәдрәфеннән дә кулай урын калмады. Вахтеры да үзебезнең кеше.

— Кертмәскә куштылар. Комендант белән сөйләшеп карагыз әле...

Комендант безне аңлады. «Бәдрәф ирекле, әмма листовка, ялган акча басмагыз», — диде ул. Без көлештек. Мин аңа бер анекдот сөйләдем. Брежнев үз гомерендә бер генә бүләктән баш тарта. Һиндстанга баргач, аның танавына, һиндләрдәгечә, алтын бөҗра кидертергә булалар. Нәселле үгез сыман. «Юк, мин мондый зур наградага лаек түгел», — дип җавап бирә Леонид Ильич.

Намусны рәнҗетә торган кыланышлары өчен әрнеп, без Башкортстан саулык саклау министры Турьяновка, Совмин шифаханәсе баш врачы Ишмөхәммәтовка

протест телеграммасы суктык. Никадәр «җитди» мәсьәлә бит! Әмма хәл үзгәрмәде. Ун көн буена без иртәсен дә, кичен дә ашказаннарыбызны юдыртудан мәхрүм булдык.

**Архивтан:** *Мәскәүдән китереп утыртылган Чакмагыш татары Ревмир Хәбибуллинның Башкортстандагы иң «бөек эше» утыз җиденче еллардан соң күрелмәгән масштабта мине эзәрлекләүне оештыруы булды. Ел ярым чамасы канитель тартканнан соң, нә сәяси, нә икътисади әзерлеге булмаган беренче секретарь Хәбибуллин өлкә комитетының тулы составы белән отставкага очырылды. Безгә бәдрәф бирдертмәгән КПСС Үзәк комитеты әгъзасы Ревмир Хәбибуллинның бераздан башка сөйкемле эшләре дә ачылды:*

*«КПССның Башкортстан өлкә оешмасының контроль-ревизия комиссиясе президиумында.*

*... Р. Х. Хәбибуллин иптәшнең 1987 елның сентябрь-декабрь айларында алты кешедән торган гаиләсенә өч квартира: берсен Пермьдә, икесен — Уфа каласында алуы ачыкланды. 1987 елның сентябрендә ул Уфа каласында хатыны белән биш бүлмәле квартира — КПСС өлкә комитетының кунакханәсен били... ремонт барышында аны үз теләге белән дүрт бүлмәле итеп үзгәртә. Октябрьдә ул энисен һәм кызын өлкә комитетының яңа төзелгән йортта торак алучы хезмәткәрләр исемлегенә кертә, аларга ике бүлмәле квартира бүлә. Ноябрьдә ул Пермьдәге дүрт бүлмәле квартирасын улы белән килененә яздыра, әле генә Уфада квартира алган энисе белән кызын ордерга керттерә... Хәбибуллинның хатыны Л. З. Сафинага «РСФСРның атказанган юристы» дигән исем бирү фактын тикшерү барышында шул ачыкланды: Башкорт АССР Верховный Советы Президиумының бу мәсьәлә буенча 1989 елның 11 декабрендә кабул ителгән карарына, президиум әгъзалары белән сөйләшеп тормыйча, аның элекке председателе Ф. В. Солтанов иптәш кул куйган... Контроль-ревизия комиссиясе президиумы үзенең карарында, Р. Х. Хәбибуллин юл куйган эшләре өчен каты партия җәзасына, хәтта КПСС әгъзалыгыннан чыгарылырга лаек, дип билгеләде...»*

*«Кызыл Таң», 6 октябрь 1990 ел.*

Чатыр янына житеп килгәндә, кемдер миңа кычкыра:

— Айдар агай! Айдар агай! Без зә сыгабыз!..

Үзе кул болгый, үзе шат елмая. Үзе өйдә генә яланаяк кия торган чүәкләрдән. Карасам, Артур Иделбаев. Култык астына бөгәрләп, матрас тыккан да, мәйдан аша Октябрь революциясе урамына табан чаба. Нәрсә булган? Кайда чыгалар? Артур Иделбаев — университетның тарих факультеты студенты. Башкорт яшьләрен оештырып йөрүче. Шактый акыллы, заманча фикерләүче егет. РСФСР Югары Советы депутаты, «Башкортстан кызы» журналы мөхәррире Гөлфия Юнысова һәм филология фәннәре кандидаты Мирас Иделбаевның улы. Ул бернична тапкыр тарих факультетында минем белән очрашу оештырырга тырышып карады. Булмады. Ишеккә кыстырып киткән язуы болай иде: «Булмай. Айзар агай. Укытыусылар һеззең менән осрашыузы теләмәй».

Бер сәгать үтмәгәндер, ялгышмасам, Риф Гомәров хәбәр житкерде:

— Башкортлар Ленин урамындагы «Нефтяник» сарае каршына тирмә корган. Артур Иделбаев житәкчелек итә. Суверенитетны яклап имза жыялар...

Мин сәгатькә карыйм. Халык дингезендә айкалып-чайкалып, вакыт үткәне сизелми дә икән: көндезге ундүрт сәгать. Соңыннан бу акциянең безнең сәяси ачлыкның абруен кимет, ике милләтне капма-каршы куе һәм бәрелештерү өчен КГБ оештырганлыгы ачыкланды. Афәрин, тиз эшлиләр егетләр. Нәрсә әйтәсең? Иртәнге тугыздан нибары биш сәгать вакыт үткән, әмма барысы да әзер. Мәдәният министрлыгы складларыннан атлар сыйдырышлы тирмә дә табылган. Бизәлгән дә. Тик шунысы гына сәерсендерә: нигә башкорт хәрәкәте имзаларны безнең ачлык игълан итүгә кадәр жыя башламаган? Моның өчен үз башың булу кирәк шул.

Әнә баскычтан вәкарь белән генә мәдәният министры Салават Әминев менеп бара. Хакы бар. Соңгы вакытта министрлыктан барлык татарларны чүпләп бетерде бит ул.

Чатыр тирәсендә халык тагын да ишәя төште. Күрәсең, хәбәр чынлап та тирәнгә үтеп керә башлады. Вакыт-вакыт кемнең нәрсә сөйләгәнен аңларлык та түгел. Безнең егетләр төркемнәр уртасында бәхәс алып бара, аңлата, күз-кашын жимермичә фикерләр төрлелеген якынайтырга тырыша. «Түземлек күрсәтегез, тупас булмагыз», — дигән идем мин аларга кисәтеп.

Бер маржа минем жиңемнән эләктереп ала һәм илһамлы пулемет кебек миңа ут яудыра башлый:

— Так спокойно жили, зачем ты травишь народ на народ?! Зачем татаро-башкирских детей должен учить только мусульманин? Куда вы без русского языка? Нет, мы национализм не допустим!..

Ана икенчесе кушыла. Талаганда кумәклек хисе гадел булу хисенә әверелеп куя:

— Тут нас голодом морють, а они нас политикой һолодовкой травють! Бездельники — и все туть!..

— Ишь, театр захотел. Ты сам — театр паршивый!..

Каракучкыл йөзле, маңгае минле татар абзые безгә ярдәмгә килә. Ул тирән белемле кеше булырга охшый. Әмма ана сөйләргә бирмиләр:

— Колбасы нет, мяса нет — вот что надо требовать! А он — вывода войск из Литвы, Азербайджана... На кой нам сдались эти фашисты?

— Талоны отоварить нечем!

Йә, хода, монда нәрсә генә ишетмәссең?

Зөфәр яңа хәбәр алып килде: башкиристлар тирмәсе янында кымыз һәм азык-төлек сата башлаганнар. Суверенитет өчен егерме имза җыйганнар да ди инде... Шунда ук икенче хәбәр дә алынды: бүген төнлә безнең чатыр өстеннән йөк машинасы җибәрмәкчеләр, имеш. Мин бу хакта майор Исламов белән киңәшәм. «Борчылмагыз, барысы да тәртиптә булыр», — ди ул. Шунда ук «тирмә» сүзен дөрес әйтә алмаган бер урысның кызык тәгъбире хәтердә калган: «Тут Айдар Халим палатку разбил, там башкиры тюрьму поставили...» Күләргә генә кеше юк. Миңа чынлап та кызык булып китте. Миңа бу мизгелдә урысның «тюрьма» сүзенең төрки «тирмә»дән, ягъни «караңгы, ябык урын» дигәннән килеп чыкканлыгын аңладым.

Октябрьдә караңгы иртә төшә. Күз бәйләнергә дә озак калмады. Мин сәгатьләр буе чатыр эчендә ятам да, сирәкләп мәйданга чыгам. Чыгу белән халык уратып ала. Күп сөйләшергә, борчылырга мәҗбүр буласың. Кадерле исә көне буе куышка кергәне юк. «Көне буе аяктасың, бар, кереп, ял итеп ал...» «Юк, — ди ул. — Арымадым...»

Сәгать кичке дүрт белән җиде арасы беренче көннең иң авыр, иң хәлиткеч мизгеле булды, минемчә. Көндезен мәйданда тыныч яшәгәнбез икән. Кадерле дускай! Министрлыклар, заводлар, оешмалар, югары уку йортларыннан кайтучы эшчеләр, хезмәткәрләр, студентлар һәм профессорлар; башкорт академия театрына кичке спектакльгә баручы актерлар һәм тамашачылар; кайдандыр пәйда булган мөгтәбәр мәсжед картлары һәм әбиләр; КГБ бинасыннан төнге информация җыярга чыккан филерлар һәм шулерлар; эшлеклеләр һәм эшлексезләр; ябык һәм ачык авызлар; сау-сәламәт һәм гарип-гораәбәләр; бер сүз белән әйткәндә, күп катлы, биек йортларда яшәсә дә, подвалда яшәгән кебек яшәгән йомык Уфа халкының чуар массасы безнең таләпләрне укып, миенә сеңдерә, тыныч итеп күршесе белән мөгамәләгә керә, сеңдерә алмаса, гөлт итеп кабына, шаулый, даулый, жикеренә башлый иде.

Мин, Кадерлене култыклап, мәйдан буйлап йөри башлыйм. Ул кырык өченче калып аяк киеме кия, шул калыпны эзләп үзе дә, хатыны Рая ханым да хәлләрдән тая. Мин егетләргә аңа яраштлы киез итекләр табарга куштым. Киез итексез булмаячак. Чатырга керү белән калын ирләр тавышы яңгырады:

— Бында сык! Асыктан асык һөйләшәйек!

Кадерле, чатыр япмасын бераз кысып, тышка күз сала:

— Тирмәдән «дусларны» җибәргәннәр шикелле. Байтак күренәләр...

Бу дөрес булып чыкты.

Чатыр ишеге тупас рәвештә тартылып ачыла һәм табак битле, чабата кашлы адәм бар мәйданга аваз сала:

— Нимә эштәп сыкһын ти ул, ана бит тыгынып ултыра! Ас тора, имеш!

— Улай казылык һогонһам, мин дә ас ултырам ул! Ха-ха-ха!..

Чыгу белән кара албасты мине өермә кебек бөтереп ала һәм фанер такта сыман кипкән гәүдәмне җилтерәтә башлый:

— Кем һин?! Кем һин?!

Егетләрем мине аралап ала.

— Гражданин, — дим мин.

— Гражданыңа сыстым! Башкортмо, татармы?

— Татар.

— Юк, һин башкорт! Һатлык йән башкорт һин, бына кем! Башкортстанда татарзар юк. Татарзар — Татарстанда! Һине башкорт кына язуысы итте!

Моның белән сүз көрәштереп тору кирәкмәс тә иде. Әмма ул бит үзе сыман егермеләп кешене алып килгән. Аңлатырга кирәк. Бәлки аңларлар.

— Башкорт та татар халкы кебек хокуксыз, алданган халык. Без сезнең хокукларны да яклап бу мәйданга чыктык. Милләтемә килгәндә, мин — татар.

Мине татар атасы һәм анасы тудырды, тәрбияләде, татар мәктәбе адәм итте. Язучылыкка килгәндә, мине табигатем һәм талантым язучы ясады...

— Ә һин талантһыз! Талантһыз!

— Анысын киләчәк әйтер...

— Ә һин ниңә башкорт телендә яззын, бәдбәхет? — Кара түмәр тынгы бирми жикеренә иде. — Ниңә татарса язып язуусы булманын?!

Эшнең зурга китәчәген чамалап алган егетләр милиция ярдәмендә мине бу тозактан йолып алдылар. «Кайда күрдем мин бу кешене,— дип жәфаланам мин.— Кайда күрдем?!» Ул безне жиде көн буе бимазалар, жиде көндә жиде провокация оештырыр, әмма мин бу бик таныш кешене беренче тапкыр кайда күрүемне әле булса искә төшерә алмам...

Халык алдында бирелгән мондый житди, әмма провокацион сорауга жавапсыз калу ярамый иде.

— Бу минем туган жирем,— дидем мин.— Авыр заманнарда туган жиремдә туган телемдә ижат итү, китап чыгарудан мәхрүм ителгәч, мин тугандаш төрки тел — башкорт телендә дә ижат иттем. Әмма мин татарча уйладым, әсәрләремдә татар, гомумтөрки идеясын үткәрдем. Хәзер, заманалар яхшыга үзгәрә башлагач, бервакытта да аңардан китмәгән милләтемә кире кайтам. Әйтегез әле, монда нинди жинаять бар? Кемгә зыян китергәнмен? Башкорткамы, татаргамы?

Кинәттән икенче бер табак битле мине кочагына кыса башлый:

— А-а-а, это ты что ли Айдар-Борис?! Ты еще отсюда не удрал? И-их, как я тебя люблю!..

Һәм ул мине шытырдатып кыса. Минем сөякләрем кораб мачтасы кебек ыңгырашып куя. Монысын инде таныйм. Күптән түгел таныштырды ул барлык татар милләтен үзе белән. Ринат Шәйхетдин улы Баимов. 1961 нче елгы әзмәвер. Саф башкорт. Башкортча белми. Магнитогорскидан. Уфа сәнгать институтының V курс студенты. СССР халык артисты, композитор Заһир Исмәгилев кызы Ләйләнең икенче кияве.

— Бәй, бар үзеңдең Казаныңда татарса яз!..

Монысы — күптәнге танышым, жирлексез һәм игелексез татарым Марат Рафиков. Башкортстан телевидениесенең элеккеге дикторы. «Башкортстанның иң чибәр ир-егете»,— дип үзе турында үзе дан таратканнан соң, хатын-кыз белән чамасыз уйнап, эшеннән куылган. Ташкент якларына чыгып сызган һәм кире әйләнеп кайтып, башкорт милли хәрәкәтенең актив «штыгы»на әверелгән «үз татарымыз» Марат Рафиков.

Ринат Баимов турында урындагы газеталар «умартачы һәм слесарь» дип язалар. Заһир агай Исмәгилев өстәленә ул нинди бал куядыр, слесарь буларак, кайда, нинди, кем кранын төзәтәдер, анысын белмим. Башка кешесе булмагач, башкорт яшьләр хәрәкәтен ул житәкләргә маташып карады.

Ринат Баимов... Мин аны беренче тапкыр 1989 елның 15 октябрендә «Нефтяник» сараенда мең ярым кеше катнашлыгында үткәрелгән гомумтатар митингысында күрдем. Безнең хәрәкәттә искиткеч зур роль уйнаган шушы корылтайны өзү өчен гаять зур көч куйган шәхес бу. Ул чакта әле, һаман да Сибгат Хәким сүзләре белән әйткәндә, «Казан әле, Казан уянмаган» иде. Үзенең оештырылу формасы, төгәллеге, эчтәлеге, батырлыгы белән бөтен Идел-Урал төбәген тетрәткән шушы жыелыш бөтентатар хәрәкәтенә бәялəп бетергесез этәргеч бирде. Моннан соң Башкортстанда яшерелеп киленгән татар темасы бөтен республика, хәтта ил күләменә бәреп чыгачак... Әйе, митингның нәкъ уртасында, Казанның Явыз Иван тарафыннан яулап алынуына 437 ел тулу уңае белән киң халык катламнары белән бергә, партия функционерлары, КГБ офицерлары, шымчылары һәм сексотлары шыплап тулган залны аякка бастырып, бер минутлык тын торуны игълан итүне әзерләү йөзеннән (Уфа шәһәр советында, рәсми рәвештә беркемгә дә әйтмичә, без митингны нәкъ шул көнгә туры китерергә тырыштык, сәяси надан житәкчеләр шуңа каптылар да!), мин үземнең сыналган көрәштәшем Сәид Еникеевка сүз бирел, ул «канлы Казан буйлап, толымнарыннан сөйрәтелгән татар кызлары» турында сөйли генә башлагач, залда сызгырулар яңгырады һәм бер әзмәвердәй егет сәхнәгә сикереп менеп, теленә ни килде, шуны кычкыра башлады:

> Родина моя! Любовь моя!
> Родина моя! Любовь моя!..

Үзе бии, әллә нинди кыланышлар ясый. Зал үрә катып калган иде. Алдагы рәттә утырган «үз татарымыз» Марат Рафиков:

— Долой татарских националистов! — дип кычкырды.

Мин моның алдан уйланылган провокация икәнлеген төшенеп алып, ишек катында катып калган милиция полковнигы Таиповка, граждан киемендәге дистәләгән офицерларга:

— Алып чыгыгыз! — дип кычкырдым.

Ләкин алар сәер рәвештә хәрәкәтсез иделәр. Сәхнәдә биегән Ринат Баимов үзен йөгәнсез сизеп, президиум — ә анда шәһәр советы җитәкчеләре дә утыра! — тирәсендә өерелә башлады.

— Алып чыгыгыз! — Зал да шаулый һәм таләп итә башлады. — Алып чыгыгыз! — дим мин кабат-кабат.

Ниһаять, Таипов һәм граждан киемендәге офицерлар, теләр-теләмәс кенә урыннарыннан кузгалып, аны залдан алып чыгалар. Әмма ул берничә минуттан кереп утыра — провокаторларга штраф та салынмый, алар кулга да алынмый... Сәид әфәнде янадан сөйли башлый. Ул тәмамлауга, миннән мондый адымны һич тә көтә алмаган залга — бу бит нинди заман, аннан гайре уйланылган акция 437 ел эчендә беренче тапкыр эшләнелә! — мөрәҗәгать итәм:

— Кадерле туганнар! Явыз Иван тарафыннан җинелеп, Рәсәй империясе нигезенә түшәлгән, әмма беркайчан да рухы сынмаган татар халкының милли азатлык, прогресс һәм гуманлык өчен башын салган, Санкт-Петербург, Метрострой, Днепрогэс, Магнитка һәм Амурдагы Комсомольск сазлыкларында черегән, большевизм һәм фашизм концлагерьларында һәлак булган йөз меңләгән уллары һәм кызларының якты истәлеген бүген, Казан алынуга 437 ел тулган көнне, басып, бер минут тынлыкта искә алуыгызны үтенәм!..

Шушы 437 ел коллык чорында татар тарихында беренче мондый көтелмәгән искә алу иде бу... Залны гүя яшен суга. Әмма ул тиз айный. Минем арттан бөтен президиум, аннан залдагы гади халык дәррәү баса. Халык белән бергә аптырашка калган КГБ офицерлары, партия функционерлары, шәһәр советы җитәкчеләре баса...

Менә бит, биш йөз ел буе тупланган милли проблемалар турында сөйләсәң, таләп итсәң, нинди генә ярлыклар алмыйсың. Бишбүләктән булган «үз татарымыз» хәбәрче хәтта чыгыш башында әйтелгән бисмилланы да «дини фанатизм» дип атый. «Амбиция, национальный душок», йә хода, нәрсә генә юк!

«Перестаньте играть в самостоятельность республик!» 1921 елда Наркомнац коллегиясе утырышында Мирсәет Солтангалиевнең Сталинга ыргыткан шушы репликасы Солтангалиевнең генә түгел, меңләгән «солтангалиевче»нең гомерләрен кыйды. Әмма мәсьәлә хәл ителмәде. «Что же такое местный национализм? Если местный национализм есть проявление борьбы против великодержавного шовинизма, это не национализм, а это просто борьба с проявлением великодержавного шовинизма». Солтангалиевнең РКП(б) Үзәк Комитетының милли секциясендә пәйгамбәрләрчә янгыраган бу сүзләре большевистик урыс миссионерларын акылга утыртмады. Сумгаитлар шуннан башланды түгелме?

Ә менә Татарстан Югары Советы Президиумының элекке рәисе, безнең Чакмагышыбыз татары, Салих абзый Батыев икенчерәк сөйли: «В 1552 году татары были присоединены к Русскому государству. С этого времени татары, долгие годы страдавшие под гнетом золотоордынских и казанских ханов, вошли в состав развивающейся в более прогрессивном направлении страны непосредственно связали свою судьбу с русским народом».

Татарлар өчен татарның үз Алтын Урда һәм Казан ханнары урыс «ханнарына» караганда күпкә начаррак булганнар икән!?.

Татарстан Югары Советы Президиумының шулай ук элекке рәисе Камил абзый Фасеев та икенчерәк сөйли: «...присоединение земель Казанского ханства к русскому государству, хотя осуществленное с помощью оружия, путем слома сопротивления ханских войск, местных феодалов, духовенства и фанатически настроенных элементов, было воспринято основной частью татарского населения с надеждой на лучшие условия жизни».

Әйе, ирекко караганда корсак кадерлерәк, ди фән докторы. Шулай димәсә, ана бу исемне ул чакларда кем бирә дә, югары түрәлектә кем тота?

**Телеграмма.** *«Москва, Верховный Совет России Хасбулатову*
*Москва, Президенту России Ельцину*

*Стыдно осознать зпт что Российская империя под видом миротворческих сил ввела танковые армады против бесправного ингушского народа и крошечной Чечни тчк Естественный процесс распада империи неостановим тчк Остановите кровопролитие тчк Примите закон о деколонизации народов России зпт тем самым*

*Россия встанет в ряд цивилизованных государств зпт вы же завоюете всемирное уважение тчк В противном случае все народы империи встанут в защиту ингушского и чеченского народов зпт которых вам не задушить тчк Айдар Халим главный редактор журнала «Аргамак» 12 март 1993».*

**Көндәлекләрдән.** *«22.11.89. Шунысы кызык, митингта булган вакыйгадан соң, мине «изге теләк» белән Уфа, Башкортстан татар хәрәкәтеннән аеру, ягъни «зур талант» булмавым сәбәпле, Казанга күчеру тенденциясе көчәйде. Кемнәрдән генә әйттермиләр бу фикерне! Ничек кенә хәбәр таратмыйлар! Имеш, без фатирны алыштыргандыз икән. Имеш, без күчеп тә киткәнбез икән. Казаннан да импульслар килә башлады. Рәсми рәвештә беренче булып Татарстан китап нәшрияты директоры язучы Ринат Мөхәммәдиев искә төшерде. Егерме ел басылмый торганнан соң, ул миңа кульязмамны әзерләп җибәрергә кушкан. Рәхмәт аңа. (Телефоннан сөйләшкәндә кульязманы 10—13 табак күләмендә әзерләргә килешенер, әмма өч табак күләмендә 1400 данә тиражда басылып чыгар. «Йөрәк ташы», 1991.) Шулай ук моннан егерме ел элек Түбән Камада татар дөньясында беz оештырган беренче «неформал» оешма — «Кама таңнары» әдәби берләшмәсен тар-мар итүдә, минем Татарстанны ташлап китүемдә төп гаепле кешеләрнең берсе Рахмай Хисмәтуллинның мине һәм җырчы Фән Вәлиәхмәтовны «Җидегән чишмә» берләшмәсенә очрашуга чакыруы аеруча игътибарга лаек. Минем хакта язу өчен ул Уфага хәтта журналист улын да җибәргән. «Перестройка» кушкач, үзгәрәме әллә?*

*Уфадан мине кудыру өчен җирле башкорт матбугаты да телгә килде. БССР Югары Советы рәисе М. Рәхимов, «Урал» башкорт милли үзәге рәисе Р. Шәкүрев, Башкорт яшьләре Союзы рәисе Р. Баимов исеменә Ринат Баимов үзе язган «Җәмәгатьчелекнең ачык хаты» басылып чыкты.*

Кемдер кесәгә нидер тыга, кемдер этә-төртә. Бәладән баш-аяк. Ринат Баимов сөйләр-сөйләр дә китәр. Егетләр мине бу өердән аралап, чатырга алып керәләр. Ә тегенең тавыш көр ишетелә:

— Наш славный предок Салават Юлаев!.. Наши славные предки первыми вошли в Париж! Наши славные предки...

Куышыбызга, йомгак кебек күренмичә тәгәрәп, бер кеше килеп керә.

— Энем! — ди ул мине кочаклап алып. — Мин — Баймактан!.. Юлык авылыннан. Ул якта бердәнбер татар авылы ул. Мирхәйдәр Фәйзи яшәгән. «Галиябану»ны да шунда язган!..

Чатырда караңгы. Шырпы кабызып, мин аның йөзенә карыйм. Өлкән яшьләрдәге, йөзенә дала туты яткан мөлаем кеше.

— Беләм, — дип мин. — Алтмышынчы елларда, Баймак газетасында практика үткәндә мин ул авылда бер генә сәгать булган идем...

— Шулаймыни?! — ди ул куанып. — Нигә ул чакта таныша алмадык икән? Насыйп итмәгән, күрәсең... Энем, син ышанма, бу — башкорт халкы түгел... Син боларны гафу итә күр... — һәм мосафир, ышанасызмы, үксеп елап җибәрә. — Җылыйм әле, туган... Бу бит шатлык яшьләре... Безнең авылда да укытуны көчләп башкортчага күчергәннәр иде. Әмма, ходайга рәхмәт, синең «Дружба народов» журналындагы мәкаләңнән соң, райкомга бардык. Аңладылар. Хәзер балалар, быелдан башлап, татарча укый башлады, ышанасыңмы?! Казаннан әсбаплар алып кайттык. Без бит, ни дисәң дә, башкортның үзәге — Баймактагы бердәнбер татар авылы, энекәем...

— Баймак ягы — искиткеч матур як... Халкы да ифрат яхшы... Киң күңелле...

Мин термостан су эчәм һәм көне буе тәмәке тартмаганыма куанам.

— Мин Руставели урамындагы кызымда туктадым, — ди абзый. — Сиңа чишмә суы китеримме? Ул тирәдә бик чиста чишмә бар...

Баймак, Баймак!
Күңелең — айлы тугай!
Болытларга житкән кыялар,
Әйтерсең лә, морадына житеп,
Жиргә төшеп яткан хыяллар, —

дип, мин аңа 1967 елда Баймакта язган шул исемдәге шигырьне укыйм. Аны Хәсән абый Туфан ярата иде. Бу шигырьне ул 1969 елда чыккан «Шигырь бәйрәме» исемле җыентыкка да керткән иде.

Танышым күз яшьләрен сөртә, минем вакытымны алудан уңайсызланып, гафу үтенә һәм көрәшебездә уңышлар теләп, куыштан чыга...

Мәйдан һаман шаулый.

— Айдар, кызың керсенме? — ди Кадерле, чатыр япмасын ача биреп.
— Керсен, әлбәттә! — дим куанып.

Бая аның кызы һәм улы килеп китте. Гаилә визитлары башланды. Бу әйбәт фал иде.

Без Зөлфия белән кочаклашабыз. Ул укыган сәнгать училищесы бездән бераз гына түбәндәрәк. Иртәсен-кичен ул безнең мәйдан аша үтәчәк.

— Әниең нихәлдә?

— Әйбәт. Сәлам әйтергә кушты. Йөрәгем бераз тынычлангач, килермен, диде. Бер таныш түгел ханым, аның әшенә кереп, «Ваш балбес провоцирует межнациональные столкновения!» — дип җикеренеп чыгып киткән...

Башкорт әдәбиятында һәм иҗтимагый фикерендә татарны кимсетү, аңа каршы көрәшү, дошман күрү үз татарыбыз Шәехзадә Бабичтан башланмадымы? Бу — бик зур тема. Мин бу хакта кайта-кайта уйланачакмын. Бабич — татар-башкорт тәнендә кансырап торган яра. 1917—19 елларда ул кичергән рухи трансформация, көрәсең, беркайчан да ачылмас. Татар зыялылары арасында татар-башкорт мәсьәләсендә икегә аерылу, раскол Зәки Вәлиди һәм Шәехзадә Бабичтан килә. Аларның икесендә дә идея-иман артында меркантиль интереслар ята иде. Вәлидидә — беренче башкорт ханы булу. Бабичта — беренче башкорт ханлыгының беренче сарай шагыйре, ягъни Пушкины булу. Бу кадәр фаҗигане башкача аңлатып булмый. Башкорттагы кадрлар кытлыгы белән файдаланып, ниндидер шәхсән файда эзләү һәм шундый файда өчен дәүләти шартлар тудыру тора-бара Башкортстан татарының, Үзәкнең һәм Башкортстан җитәкчелегенең рәсми идеологиясенә әйләнде. Икенче милләт өчен булса да классик булу, бәлки, шарты килсә, «Гафури кебек» берьюлы ике милләткә классик булу соңгы дистә елларда Башкортстанда аеруча көчәйде. Мостай Кәрим, мәсәлән, сиксәненче еллар башында татарның һәм башкортның егерменче гасыр азагында урыслашып бетәчәгенә ышана иде. Хәтердә, 1981 елның ямьле июнь айлары. Без минем туган якларга — Миякә районына кайтып барабыз. Раевкада машинасын райкомныкына алыштырып утырганнан соң, Шафран тирәсендәге тауларга күз сирпеп, Мостай Кәрим болай диде:

— Башкорт әдәбиятында өч тау бар. Дүртенчесе булмаячак.

— Ул нинди таулар, Мостай агай?

— Акмулла, Бабич...

— Ә өченчесе?

Ул серле елмайды. Өченче, соңгы тау — ул үзе иде. Бу исемлектә Гафурига урын бөтенләй юк иде. Мин аның белән килешмәдем. Балаларча беркатлылык белән, танып-белү процессының чиксез икәнлегенә ышанасы килә, дидем. Без шунда ук уку-укыту телләре турында да сөйләштек. Милләтләрне урысча укыту — прогрессив. Татарларны башкортча укыта башлау — шулай ук прогрессив икән. Мостай Кәрим белән минем арадагы эчке аерымлыкларның башы менә шул көннәрдә башланды...

Ашыйсы килми. Тамак кына кибә. Су эчәм. Чатыр эче тәмам караңгылана. Мәйданда шау-шу бер кими, бер арта. Мин урынга ятам һәм безне уратып алган тарафлар турында уйланам. Нинди биналар һәм оешмалар камаган безне — көнчыгыш, көнбатыш, көньяк, төньяктан? Көнбатыш тараф хакында сүз булды. Миннән уң кулда, ягъни төньякта, нәрсә һәм кемнәр? Башкорт опера һәм балет театры. Утызынчы еллар азагында, тулаем алганда, татарлар һәм урыслар оештырган аны. Беренче бөек биючесе татар Фәйзи Гаскәров. Икенче бөек биючесе — татар Рудольф Нуриев та шушында башлаган дөнья классикасына салган юлын. Беренче бөек җырчысы — татар Габдрахман Хәбибуллин. Бүген дә анда ике башкорт, ун татар башкортча җырлый. Директоры — татар Радик Гәрәев. Сәхнә буш, зал буш. Халык йөрми. Ә татарның «Нур» театры — урамда. Урам аша — Уфа сәнгать институты. Озак еллар аның ректоры булып башкортның бөек таланты — композитор Заһир Исмәгыйлев эшләде. Татар Нәҗип Җиһанов белән башкорт Заһир Исмәгыйлев дуслар иде. Хәтта үзенең кызын Ләйләне Исмәгыйлев Казан консерваториесендә укытты. Әмма бу дуслык Уфадагы хәлләрне юньләп белмәгән һәм белергә дә теләмәгән Казан татары өчен алдавыч битлек кенә иде. Заһир агаебыз соңгы дистә елларда башкорт милләтчелегенең бастионы булды. Әлбәттә, татарга юл бирмәгән юнәлештә. Югыйсә без башкортның акыллы дәрәҗәдәге милләтчелегенә һич тә каршы түгел. «Әйт әле, кустым, башкортса беләһеңме? — дип бирер иде беренче соравын талантлы татар баласына Исмәгыйлев. — Курайза уйнай беләһеңме? Белмәйһеңме ни? Бар, кусты, өйрәнеп кил». Мәшһүр җырчы Мәгафүр Хисмәтуллин белән бергә, карт булсалар да, «Дружба народов»та чыккан

мәкаләмә каршы кампаниядә катнашып та пычрандылар алар. Хәзер анда ректор — профессор Зиннур Нургалин. Социалистик реализм буенча докторлык яклаган мөлаем, бик мөлаем кеше.

Мин мәйданга чыгам. Сәгать кичке сигез. Анда халык шактый әле. Көне буе арымас-талмас Кадерлене бераз кыздырып алам һәм урынга алып кереп яткырам. Йөрәген сакларга кушам. Безгә ияреп, егетләр дә керә. Алар караңгы чатырны ничек итеп яктырту турында хыяллана башлыйлар. Җылытасылары да килә. Он комбинаты заводы эшчесе Замир Якупов, иртәгә барысы да булыр, ди. Кызык, нәрсә эшли алыр икән ул?

Мин уйлануларымны дәвам итәм. Моннан ике ел чамасы элек татар әдәбиятына бөтенләй катнашы булмаган Зиннур Нургалин «Кызыл Таң» газетасында татар әдәбияты, иҗтимагый фикер тарихына оятсыз һөҗүмнәр ясады. XIX гасыр азагы, XX гасыр башы әдәбияты гыйлемендә наданнардан надан Нургалин, КГБ биргән материалларга нигезләнеп һәм КГБ оештыруы буенча, мәрхүм Гаяз Исхакыйны тетеп чыкты. Аның белән әңгәмәгә газетада бер бит диярлек урын бирелгән иде. Сәбәпләрен аңлау авыр түгел: Казанда Ибраһим Нуруллин житәкчелегендә бер төркем зыялылар һәм җәмәгатьчелек Гаяз Исхакыйның исемен кире кайтару буенча батырларча көрәш башлады. Без дә калышмадык. Ибраһим Нуруллинны чакырып, матур игъланнар бастырып, бик зурлап, Уфада Гаяз Исхакый кичәсен үткәрдек. Бу КГБны бик борчыды. Казанда «Советская Татария» Исхакыйга каршы пычрак, ялган документлар игълан итте. Уфада Зиннур Нургалин (татар газетасында!) калкып чыкты. 1988 елның август уртасында Башкортстан язучылар берлегенең «Дружба народов»та чыккан мәкаләмне тикшерүгә багышланган жиде сәгатьлек ачык партия җыелышында мин турыдан-туры «татар буржуаз милләтчелеге, гаязисхакизмда»да гаепләндем. КГБ моны болай гына калдыра алмый иде. Мәкаләнең исеме генә дә ни тора: «Халыкка хыянәт итүне аклап булмый». Зиннур Нургалин үзенең Казандагы фикердәше — Казан дәүләт университеты профессоры Камил Фасеевның 1987 елда «Советская Татария» газетасында чыккан «Гаяз Исхаки, он же Штольц» дигән мәкаләсеннән «Гаяз Исхакыйны гафу итү һәм реабилетацияләү — партия принципиальлеген югалтуны, пролетар һәм социалистик интернационализмнан чигенүне, иң яхшы революцион-демократик традицияләргә хыянәт итүне, безнең дошманнарга хезмәт күрсәтүне аңлатачак»,— дигән сүзләрен классик күрсәтмә итеп алып, аны арытаба үстерә: «Пантюркист... Англия агенты... Контрреволюцион ак эмигрант... Г. Исхакый үзенең бөтен гомерен Совет властена, ленинчыл милли политикага каршы көрәшкә, пантюркизм, панисламизм идеяләренә хезмәт итүгә багышлый. Бу аның аңлы рәвештә сайлаган позициясе...» («Кызыл таң», 13 сентябрь, 1988 ел). Казаннан сигез күренекле татар язучысы — Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники, Нурихан Фәттах, Мөхәммәт Мәһдиев, Ибраһим Нуруллин һәм башкалар «Кызыл таң» газетасына Зиннур Нургалин әңгәмәсенә каршы «Ачык хат» яздылар. Газета басыла башлар алдыннан баш мөхәррир урынбасары Расих Ханнанов, мәкаләгә ничек кенә булса да юлны бикләргә тырышып, Башкортстан язучылар берлегенең ул чактагы җаваплы секретаре, татар дигәндә чәчләре үрә торучы искиткеч кызганыч бәндә Асылгужа Баһуманов аша Өлкә комитетына шалтыраттырды, материал яшен тизлеге белән полосадан алынды. Баш мөхәррир Муса Мөлеков өлкә комитеты секретаре Әхнәф Дилмөхәммәтов тарафыннан келәмгә бастырылып, бер сәгать сүгелгәннән соң инде ничәнче тапкыр йөрәге тотып, хастаханәгә ятты. Күп тә үтмәс, күренекле журналист, филология фәннәре кандидаты, Мирхәйдәр Фәйзи иҗаты буенча берданбер белгечебез Муса әфәнде Мөлеков эшеннән алып ыргытылыр һәм «Кызыл таң»га баш мөхәррир итеп Расих Ханнанов тәгаенләнер...

Кемдер жиннән тарта. Күрәм, күптәнге танышым полковник Таюпов.

— Безнең чатыр өстеннән бүген төнлә йөк машинасы җибәрәчәкләр, дигән хәбәр бар,— дим мин.— Чара күрсәгез иде, иптәш полковник...

— Юк, Айдар әфәнде, борчылмагыз,— ди ул, Уфа шартларында «әфәнде» сүзен кертә башлаган кешедән нечкәлек белән көлгәндәй.— Милиция наряды төнгә каршы Киров районында бермә-бер арттырыла.— Аннан ул уң кулын минем иңемә дустанә сала һәм хәйләкәр елмаеп: — Беләсезме, Айдар әфәнде... Сезне халык бик ихтирам итә... Кайда гына булсам да, кем белән генә сөйләшсәм дә, сезне яраталар... Әйе, Өлкә комитетында да, Министрлар Советында да... ди. Бу мәдхия нәрсә белән бетәчәк? Көтәм.— Шундый зур абруй белән файдаланып,— дип дәвам итә полковник,— сез үзегезгә үзегез аяк чалмыйсызмы? Үз итеп, изге теләктән әйтәм: таегыз моннан, ә?

Күзләрем шар була.

— Чынлап әйтәм, таегыз. Шәһәрдә криминаль обстановка, сезнең хәвефсезлек өчен җавап бирү дә авырая...

— Юк, таймыйм, иптәш полковник.
— Ә кайчанга кадәр торачаксыз?
— Югары Совет татар телен дәүләт теле итеп кабул иткәч тә, сәяси ачлыкны туктатачакмын...

Полковник әллә киная белән, әллә чын күңелдән: «Уңышлар телим!» — дигән фраза ычкындыра һәм, кырт борылып, китеп бара. Ялгышмасам, бу Кушнарен татарын мин бүтән беркайчан да күрмәдем.

Без Кадерле белән куышка үтәбез. Анда гүр караңгысы. Совет мәйданында башня сәгате сукмый башлады — аның кыңгыравын туктаттылар. Көне буе кизү булып торган егетләрне алыштырырга килгән Рәфис Мөхәммәтов һәм Вил Латыйповлар шәм кабызалар. Әмма шәмнән чыккан сөрем бер минут эчендә чатырдан газ-камера хасыйл итә, без аны сүндерәбез.

**Көндәлекләрдән.** *«02.11.89. Бүген татар хәрәкәте активистлары Югары Совет бинасында башланачак сессия алдыннан ике сәгатьлек пикет оештырды. Яшевлар нишләптер күренми. Депутатларга «Мөрәҗәгать» тараттык. Күрәм, баскычлардан «мәңгелек» депутат Мидхәт Шакиров менеп килә. Мин: «Егетләр, Шакиров!» Егетләр аны уратып ала, китаплар, листовкалар, «Мөрәҗәгать»не тыгалар...*

*— Нәрсә таратасыз? — ди Шакиров саф татарча.*

*— «Башкортлаштыруга каршы Мөрәҗәгать», — ди кемдер.*

*— Кирәкми. Бушка да кирәкми! — Шакиров кулын селтәп, кереп китә. Артыннан тавышлар:*

*— Сатлык җан! Хурлык!..*

— Айдар абый, ышанасыңмы, Шакиров үзе килеп китте безнең чатыр янына! — Мотоцикл кебек кызган Зөфәр миңа яңалык хәбәр итә. Мин хәбәргә һич тә аптырамаган төс бирергә тырышам.— Безнең таләпләр белән танышып чыкты!..

— Төнгә әзерләнегез, Зөфәр... Сиңа бүген көндез дә, төнлә дә йокы булмаячак. Безгә дә жылырак киенергә кирәкми микән? Сизәсеңме, салкынайта?

— Айдар абый, киемнәр әзер! Кайчан киенәсез, хәзер үкме, әллә бераз соңракмы? Алар әзер!..

Мизгел дә үтми, безнең куышка калушлы киез итек, тышлы тун, мамык шәлләр күтәргән Сәҗидә һәм Земфираларыбыз килеп керә. Мин кирза итекне жылы пималарга алыштырам. Билгә Земфираның мамык шәлен урыйм. Көне буе октябрь салкынында суынган сөякләр жылынып китә. Уфаның «Чегән аланы» бистәсендә яшәгән һәм милләт өчен жанын фида кылырга әзер булган Галия Батыршина чит кешеләр алып килгән термослардагы шикле суларны түгәргә тәкъдим итә. Егетләр чатыр артында термосларны шомбырдатып бушаталар. Мотор эшләүчеләр заводында сменасын тәмамлап, янадан килеп житкән Ирек Әхиярetдинов — минем таң күбәләгем! — Галияне утыртып «Чегән бистәсе»нә юл ала. Озакламый Галия белән Ирек кайнатылган чишмә суы тутырылган термосларны куышка кертәләр. Төнгелеккә тирә-юньне караштыру өчен тышка чыгам.

Мәйданда халык ике-өч йөзләп булыр. Нигә таралмыйлар алар? Сәгать ун бит инде. Очсыз вино эчкән әйбәт кешеләрне исәпләмәгәндә, мәйданда — татарлар. Һәркем туктата, изге теләген әйтә, кочаклый, тагын да жылый, кемнәрдер кесәгә нәрсәдер тыга — иртән карасам, алар төрле чирләрдән дарулар булып чыкты: бер апаны һичкенәләр дә онытасым юк. Ул ашъяулыкка төреп, яна гына пешкән вак бәлешләр алып килгән.

— Айдар туганай! Ач торма! Нигә ашамыйсың? Менә бит — мичтән генә!

Мәйданда жыр-бию башлана. Татар мәдәният мәркәзеннән үзешчән артистлар килгән икән. Кемдер баянда сыздыра, кемдер бии — Совет мәйданы, гарасат мәйданы, тамаша залына әйләнгән.

— А-а-йдар а-а-бый, тт-такое з-зрелище еще где н-найдешь? — ди шатлыгын кая куярга белмәгән Ирек Әхиярetдинов.

Кара да гыналай урман, караңгы төн...

Кем бу? Нинди тавыш бу? Без сагынган ирләр тавышы! Минем чыгып йөгерәсем, бу адәми затны кысып кочаклыйсым килә. Әмма тәренеп ятканмын. Мин күренсәм, халыкның шаукымы тагын да күтәрелә. Юк, ярамый. Соңыннан әйтүләренчә, ул Уфа сәнгать институты студенты булган икән. Имеш, Борай районыннан. Жырын жырлаган да, чыгарылыш курсы студенты буларак, исемен

әйтмичә качкан. Юк, оныта алмам мин яңгырлы-карлы Совет мәйданында, төнге уникенче яртыда яңгыраган «Кара урман»ны! Булган хәлме бу?

Яхшы атлар кирәк үтәргә...
И-и-и,
Аерылмыйк без, дускаем...

Җырны бөтен мәйдан күтәреп ала. Күзгә яшь бәреп чыга. Шушы җыр яңгырый алсын өчен генә дә мәйданга чыгасы булган, шайтан алгыры!.. Төнге унике дә житкән икән. Җыр ераклашкан сыман. Куышыбызның япмасы ачыла. Галия Батыршина:

— Айдар абый, чатырыгызны тыныбыз белән җылытып китәбез! Күңелсезләнмәгез... Тыныч йокы сезгә. Иртәгә тагын да киләчәкбез...

— Рәхмәт, туганкайларым. Ташламагыз инде...

Зөфәр, милиция УАЗының сакта булуын, үз егетләребезнең периметр буенча кизүгә куелуын хәбәр итеп, чатырдан чыга.

— Ашыйсың киләме, Кадерле?

— Юк, искә дә төшмәде, малай...

Аның шулай дию булa, күз алдына хәләл җефетем пешерә торган токмач ашы пәйда була. Мин аңа мул итеп катык катам. Гаиләм миннән көлә: «Катыкка аш кушып ашый». Шулкадәр ашыйсы килеп китә ки, аңкау селәгәй белән тула. Ун көн эчендә мин бүтән беркайчан да мондый ачлык тойгысы кичермәячәкмен...

Чатыр брезентына яңгыр сибәли башлый. Яратам мин яңгыр тавышын. Кадерле исә тыйнак кына гырылдый да башлый. Ул бит көне буе аякта булды. Арыгандыр. Яңгыр шыбырдавы астында йокы тәмле була шул. Ә мине йокы ала алмый. Төнге Уфа. Бер миллион йөз мең халык. Орден тактырылып, трибуна артында телсез калдырылган бер миллион йөз мең бәхетсез адәм баласы. Аңа инде хокук та кирәкми. Аңа фенолсыз су, нитратсыз туфрак, метансыз һава кирәк. Ул исәңгерәгән. Әлеге төндә ул икеләтә йоклый. Матди һәм рухи йокы. Һәр ике кеше мәйданда. Ошбу миллион йөз мең адәм баласы үзен шәхес итеп тойсын өчен кар-яңгыр астында как асфальтта яталар. Аларның берсе гүя мин түгел, ә үзен-үзе алдый алмаган тиле. Патша воеводалары Нагойлар тау башына — җен өермәсенә халыкны яклау һәм халыкны саклау өчен түгел, ә басып алынган халыктан куреп качу өчен крепость итеп салынганы өчен бәхетсез мәллә бу Уфабыз? Ничек айнытырга, ничек уятырга, ничек чистартырга сине, газиз шәһәрем Уфа? Фәнирә Ибраһимова-Исмәгыйлева бу хакта юкка гына язмаган икән:

*Кемнәр сине каргадылар?*
*Кемнең генә төште каһәре?*
*Сине күреп бүген шаклар каттым,*
*Яшьлегемнең яшел шәһәре.*
*Син дә кебек, син түгел дә кебек,*
*Сүз дәшәлмим, телем бәйләнгән.*
*Мине әсир иткән гүзәл кала*
*Җен йортына, ахры, әйләнгән...*
*Сәрхүшләрдәй, йөзең, һай, таушалган.*
*Тузган бакчаларның яме юк.*
*Тыныч кына халкың йөреп ята.*
*Берни дә, ахры, гаме юк...*
*Куеньнда миллион йөрәк тибә.*
*Буладыр бит шуны кузгатып?*
*Уян әле, Уфам, яшәмәче,*
*Авылларның йөзен кызартып...*

Без, Уфа татары өчен, тетрәткеч шигырь бу. Гади авыл хатыны язган. Мин аны күреп тә белмим. Әсәр үзеннән үзе ятлана. Нинди тугры Тукай премияләре ди, шигырь китабы да юк бу үгисетелгән татар хатынының.

## Икенче көн

Нидидер лыбырдауга уянып китсәм,— үзебезнең егетләр һәм радио:

— ... Һәм эшче Кадерле Имаметдинов Уфаның Үзәк Совет мәйданында, татар телен башкорт, урыс теле белән беррәттән дәүләт теле итеп игълан иттерү ниятеннән, сәяси ачлык башладылар. Башкортстан Югары Советының 11 октябрьдә ачылачак сессиясе алдыннан эшләнгән бу адым җөм-

һуриятнең сәяси тормышында житди акция булып тора. Киләсе чыгарылышларыбызда без бу хакта даими хәбәр итәчәкбез...

— «Азатлык» сөйли! — ди чиксез дулкынланган Кадерле.— Безнең хакта — Мюнхеннан!

Фәрит Иделле тавышы. Ул мина житмешенче еллардан, «Азатлык»ны төнлә чикмән бөркәнеп тыңлаган заманнардан ук таныш. Без аның белән бары тик ике елдан, Бөтендөнья татарлары Конгрессында гына, таныша алырбыз. Эфирда икенче темага күчкән Фәридә ханым Хәмит тавышы да ифрат ягымлы. Хәбәрне Казанга, ижтимагый үзәккә, шалтыратып алганнар, күрәсең. Рәхмәт сезгә, кардәшләр.

Егетләр белән бергә, Кадерленең өеннән алып килгән «Спидола»сы да горурлана кебек. Адәм баласына күп кирәкмени: безне күрәләр, без исән! Чит дөнья белән бәйләүче бердәнбер жан булачак ул бу көннәрдә. «Азатлык» жир шарының башка хәбәрдарлек чараларына да юл ачты. Ун көн эчендә безнең сәяси ачлык турында Би-Би-Си, «Немецкая волна», «Голос Америки» радиостанцияләре хәбәр итте, Санкт-Петербургның (ул чакта әле Ленинград) «120 минут» программасы сюжет тапшырды. Аларның «коткысы илә» ижтимагый фикернең иң караңгы карбазы — Башкортстан радио-телевидениесе дә безне телгә алырга мәжбүр булды. Югыйсә, төкереп тә бирмәсләр иде.

— Егетләр, төн тыныч үттеме?

— Тыныч, Айдар абый. Октябрь революциясе урамы ягыннан ике тапкыр ниндидер революцион автомобильләр килеп туктаган иде, без бара башлагач качтылар... Матрослары куркак булып чыкты...

Без көлешәбез. Шулчак куышыбызга алмашка килгән кизү төркеме керде. Зөфәрләр хәзер ялга китәчәк. Икенче тәүлеккә кизүгә басачак Дамир Шәйбәков, Равил Шәмсиев, Вәкил Хәкимов, Нурфаяз Шәрәфиевләр безне беренче тәүлекне тәмамлавыбыз белән жылы котлый...

Кадерле радиодулкынны Казанга бора. Казан сөйләвен сөйли, әмма Мюнхен кебек ачык ишетелми. Яңалыклары болай кызыклы гына булмакчы: бәрәңге чыгару, сөт саву барышы...

Без тиз генә тешләрне чистартып, битләребезне юып килдек тә, урыннарыбызга ятып, матбугат белән таныша башладык. «Совет Башкортстаны». Аны актара башлау белән мине салкын тир баса. Истәлекләр биләп ала. Житмешенче еллар башында 5—6 ел бу басмада эшләп, мин, һич арттырмыйча әйтәм, урындагы матбугатка чын публицистик рух өреп тора алдым. Кырык кеше арасында журналистик белеме булган бердәнбер белгеч буларак, мин ошбу газетаның йоклаган битләрендә шактый гына четерекле темаларны күтәрә, нечкә милли интересларны үткәрә алдым. Шигырь белән әйткәндә:

Мин күмгән теге миналар
Әле дә шартлый сыман...

«Совет Башкортстаны»ндагы хезмәт чорында мине, әгәр читтән карасалар, ялкынланган факелны хәтерләткәнмендер. Андагы кебек, тагын да кайда яндым икән мин?! Туган жирне сагынып кайту, аның кешеләре, табигате турында яза алу хокукы мине аңлатып бирә алмаслык дәрт һәм илһам белән туендырып торды. Дөресен әйткәндә, кызык та, кызганыч та чор булды ул. Мин анда турыдан-туры милли изелүнең нәрсә икәнлеген үз жилкәмдә татыдым. Баш мөхәрриребез Абдулла Исмәгыйлев, Зиянчура башкорты, Башкортстан Югары Советы президиумы рәисе Фәйзулла Солтановның якташы, аның уң канаты иде. Таң калырлык дәрәжәдә үзенчәлекле кеше: күзенә яшь бәреп чыкканчы көлә, юктан гына мактый, юкка гына эттән эткә салып сүгә, кычкыра, төкерә, бүлмәсеннән куып чыгара һәм биш минуттан кире чакырып, шаркылдап көлә ала торган, ифрат та эзлексез, дорфа, тупас, әмма нәрсәсе беләндер үзенә тартып, яраттыра торган бер демоник кеше. «Казан» дигәндә кашлары сикереп китә торган Исмәгыйлев миңа, Казан дәүләт университетын тәмамлаган татарга карата бик тә үзенчәлекле сәясәт үткәрә: әгәр мин «бүләк» дигән сүзне кулланcам, башкортча түгел дип «награда»га үзгәртә, «награда» дип язсам, башкортча түгел дип «бүләк»кә үзгәртә. Мин «һугышсы» дисәм ул «воин»гә, мин «воин» дисәм, ул «һугышсы»га, мин «Самар» дисәм, ул «һамар»га, мин «һамар» дисәм, ул «Самар»га төзәтә. Көннәр буе шулай тычкан белән песиле уйныйбыз. Мин мәкаләмә «Б. Хәлимов» дип имза куйсам, ул «А. Хәлим»гә, мин «А. Хәлим» дисәм, ул «Б. Хәлимов» дип кабаттан яза. Һәм һәрвакыттагыча «Был — татарса!» дип өстәп куя. Бу кеше хакында елмаймый сөйләү мөмкин түгел. Ул минем материаллар дөнья күргән көнне

көндәлек планерканы үткәрми: язманы мактарга кирәк булачак, моңа күнел тарлыгы бирми, хурларга исә көч житми — монда да белем кирәк. Ул көнне газетага иртәнге кузәтү вакытында да республика радиосыннан минем — номердагы иң зур материал авторының — исем-фамилиям яңгырамый, аны «фәләнфәлән битләрдә фәлән хакында очерк укырһыгыз» дип кенә китәләр. Хәер, мин, ятим үскән, түземле авыл малае, мондый гаделсезлекләргә бер кыргыйлык итеп кенә карарга тиз өйрәнеп киттем.

Алты ел буе газетаның төп публицистик йөген тартып килеп, мин анда бер генә дә жылы сүз ишетмәдем. Редакциянең шактый өлешен милли горурлыкның нәрсә икәнен оныткан принципсыз татарлар тәшкил итә иде. Бер-берсен ике тиен дә хак алмый саталар. Әмма бер-береңне уңышлы мәкалә, шигырь белән котлау дигән нәрсәне ишетмәссең. Шулай да изге күңелле, бик тә сәләтле бер татар бар иде. Мөхәррир урынбасары Гали Галиевич Шәрипов. Минем беренче зур мәкаләм «Кәркәлетамак» дөнья күргәч, аның бүлмәмә кереп, «Туганым, шулай дәвам ит. Бездә мондый әйберләр сирәк чыга»,— дип бик жылы котлаган иде. Житмеш икенче елның язында, газетада ул заман күзлегеннән бер тупас сәяси хата киткәннән соң, өлкә комитет бюросында Исмәгыйлев жаваплылыкны Шәрипов өстенә аудара һәм бу хыянәтне күтәрә алмаган Гали абзый, йөрәге тотып, кинәттән вафат булды.

Менә бит ул, мавыгып китеп, мин ничек кайтып урнашуымны да сөйләргә оныткамын. Түбән Камада сәяси басым көчәйгәч, интригалар аеруча куера төшкәч, мин күземдәге яшьне сыпырып ташлап, яшьлек шәһәрем — Түбән Кама белән хушлашырга ният иттем. Казанга китү турында хыялда да юк иде. Такташ ләгънәтләгән «фәхешләр башкаласы» Казанның рухи пычрак, сатлык, икейөзлелек атмосферасы тәмам ачуны китергән иде. 1971 елның 1 мартында иртәнге сәгать тугызда — шулай уйланылган иде — мин ике сумка китап белән Казан аша Уфага юл алдым. Казанда кичерелгән авыр көннәрдә минем туган йортым татар академия театры иде. Андагы дусларым — артистлар Хәлим Жәләй, Равил Шәрәфи, Ринат Тажетдинов, Ирек Баһман, Айдар Хафиз һәм башкалар минем ижатымны үз күрә, газета-журналларда басылудан тыелып торган чорда да теләктәшлек күрсәткән мәрхәмәтле радиожурналистлар — әдәби тапшырулар редакциясе хезмәткәрләре Рим Кәримов (инде вафат, урыны жәннәттә булсын!), Рим Шириязданов лар артист дусларым башкаруында минем берәр сәгатькә сузылган «Беренчеләр», «Биктырыш» исемле поэмаларымны яздырып, милләткә житкерәләр иде... Шагыйрь һәм язучы фикердәшләрем Рәшит Әхмәтжанов, Атилла абзый Расих бар иде — алар белән очрашып, Кекин ашханәсендә әле генә тәмамлаган «Печән чапканда» исемле поэмамны укыдым. Без эчкән кызыл шәрап мине һич кенә дә алмый иде...

Поэманың татарча әле булса чыкканы юк. Икенче көнне иртән Тукай һәм Мәржанине зиярәт кылганнан соң, мин самолетта Уфага очтым. Иртәгесен иң якын кешем, алла урынына күргән шагыйрем Мостай Кәримгә шалтыратырга жөрьәт иттем. «Уфада яшь язучылар киңәшмәсе ачылды, Айдар, ул шунда»,— диде мәрхәмәтле Рауза апа. Актерлар йортында киңәшмә башланган иде. Йә, хода, Уфа мине ничек кабул итәр, минем бит монда булганым да юк, беркемне белмим дип әйтергә була... Залга керү белән президиумда утырган Мостай агай миңа жилкәндәй ак башын какты. Күңелгә жылы керде. Мине белүче бар. Тәнәфес вакытында аның янына килеп, барысын аңлаттым. Ул башта югалыбрак калгандай тоелды. Йөзеннән ниндидер серле дулкыннар йөгереп үтте. Мин кичәсе сират күпере хакында уйлаган булгандыр ул, күрәсең.

— Ныклап уйладыңмы?

— Ныклап, Мостай агай. Чигенү юк.

— Тагын бер сәгать уйла. Киләсе тәнәфескә кадәр...

Киләсе тәнәфестә дә шушы ук әңгәмә кабатланды. Ул тиз генә бер язу сызгалап бирде. Кызганыч, язуны калдырмаганмын. Ялгышмасам, анда болайрак язылган иде: «Гальперину Д. С. Уважаемый Давид Самойлович! Прошу устроить моего питомца в редакцию какой-нибудь газеты. Мустай Карим. 03.03.71 г.»

Давид Гальперин Башкортстан журналистлар берлегенең жаваплы сәркатибе икән. Мин Уфа буйлап пар канатта оча идем. Сәркатип чирле булып чыкты. Өенә киттем. Ул озак-озак сораштырды. Казаннан һәм милләтем татар булгач, һичшиксез, «Кызыл таң»га урнаштырырга тырышып, кем беләндер сөйләште. Әмма минем «Кызыл таң»га түгел, ниндидер сәер сизенү белән, тәмугының үзенә — «Совет Башкортстаны», ягъни үзәк башкорт органына урнашасым килә иде. Әмма «Башкортстан»ның баш мөхәррире Мәскәүдә укуда икән. Миңа аны егерме көн буе көтәргә туры килде.

Ниһаять, мин Исмәгыйлев кабинетында. Тирән күн кәнәфидә аксыл йөзле, чәчләрен шома итеп тараган кеше. Теләр-теләмәс кенә исәнләшә һәм:

— Кайзан килгән Казан байы! — дип куя.

Мин аңламый торам. Ул минем өстемдәге бик тә очсызлы костюмга ишарә икән. Исмәгыйлевның иң яратмаганы — костюмның эчендәге тройкасы икән.

— Һин бит летун! — дип ырылдый ул хезмәт кенәгәмне карап.

Анда мин, ятимнең, студент елларымда акчасыз интеккәч, «Спартак» комбинатының 3 нче балалар бакчасында өч ел буе төнге каравылчы һәм ишек алдын себерүче, аннан Түбән Камада балта остасы булып эшләгәннәрем язылган шул. Аңлатам. Аңларга теләми.

— Берәй нимә язганың бармы?

— Ба-а-ар,— дим мин куанып. Сорасалар-нитсәләр дип, бер портфель тутырып, «Татарстан яшьләре», «Социалистик Татарстан», «Ялкын», «Казан утлары»нда булган публикацияләремне алып килгән идем. Өстәлгә чыгарып салам.— Рәхим итегез...

Чыгарып та салам, аларны Исмәгыйлев жине белән сыдырып идәнгә дә аткарып төшерә. Соңыннан аңлашылуынча, «Казан» ярамады.

— Былар минә указ түгел!..

Мин газета-журналларны жыям, гарьләнүдән сугып жибәрә күрмим, дип үземне тыям.

— Информация язганың бармы? Журналист информациянан башлана,— ди бу Мәскәүдә алган белемен күрсәтеп.

— Бар,— дим.

— Юк, тиген!.. Иртәгә гәзиткә информация алып кил!..

Мин Уфа урамнарына чыгам һәм афишаларны караштырам. «Француз пианисты Жан-Ришар Помье концерты...» Әйдә, булгач булсын. Мин концерттан соң тәржемәче аша Жан-Ришар Помье белән микроинтервью эшлим. Ниһаять, ул басылып чыга һәм мин «Совет Башкортстаны»на штатка алынам...

Мәйданда ун көн буе бер үк мәхәббәт, бер үк ләгънәтне тыңлаудан да авыр жанр юк икән язучы өчен. Гомумиләштерүләргә килгәндә, шул: асфальтта пыяла сыман юка гына боз элпәсе. Күлләвек булган төшләрдә бу пыяла ак салган башмак күзен хәтерләтә. Салкынча. Егетләребез мәйданда йөренеп тора. Күп тә үтми, шул ук «Икарус»лар килеп туктый башлый. Безнең мохит жанлана.

— Все еще не убрались...

— Исәнмесез, егетләр!..

— В торговле все татары, а он театр требует! Татарин сам театр!..

— Нефть не башкирская, а российская!..

— Татар мәктәбе белән кая барасың, әбрәкәй артынамы?

— А что он дрыхнет? Пусть людям покажется!..

Мин чыгам. Кешеләрнең күзләренә укталып, рәт буйлап үтәм. Аларда берберенне аңларга тырышу юк дәрәжәсендә диярлек. Бер-берең турында кайгыртучанлыкны бүгенге күзләрдән эзләп табу өчен космик микроскоп кирәк. Нишлисең, шундый шартларда яшәдек. Шундый шартларга куелганбыз. Бу карашлар «дошман» эзли. «Дошман»ын тапса, куана. Үзләренең хакимияткә никадәр ышанычлы икәнен белдереп, кул чаба һәм бала-чага кебек урында сикерәнә. Коллык психологиясеннән чыккан жирәнгеч сыйфат бу. «И-и жаныкайларым,— дим мин үз-үземә.— Сез түгелме Христосны да имән тәрегә кадаклаган гаепсез бәндәләр?»

— Хор-рошие мои...— Башка бер сүз әйтә алмыйм.— Хор-рошие мои...

Жыелып өлгергән халык тулаем урыс-татар булса да, сөйләшү, билгеле, урыс телендә генә бара.

— Сезгә нәрсә житми соң?

Бу мөлаем тавыш, әйтерсең лә, ожмахтан чыккан. Безнең тормышта нәрсә житмәве турында гүяки ул уйлап та карамаган. Ул барысыннан канәгать.

— Мәктәп житми,— дим мин, артык уйлап тормыйча.— Сабыйны туган теленнән аерып тәрбияләү — жинаять...

— Бәй, өегездә укытыгыз,— ди бу Ижтимагый Аккош.— Монда безнең ни катнашыбыз бар?

— Нигә сез башкалар хәленә керә белмисез? — дим мин кайнарлана төшеп.— Нигә үзегез белән генә исердегез? Нигә сез башка милләтләр дә үз телендә белем алырга тиеш дип исәпләмисез? Нигә әле саны ягыннан урыс белән тигез татар халкы, республиканың яртысы дип әйтерлек милли байлыгын житештереп, үз телендә укырга һәм татар театрын карарга тиеш түгел? Монда жыелган адәми затларның да яртысы татар бит, нигә авызыгызга су каптыгыз?

— Дөрес! — ди арттан сыек кына тавыш.
— Ә моны ач торып хәл итеп буламы? Бәлки башка юллар бардыр?
— Башка юллары калмаганга, мәйданга чыктык та инде. Башка юлларны эзләргә сез дә ярдәм итмәссез микән дип чыктык...
Бәләк сыман танаулы әфәнде сүзне икенчегә бору өчен хәлиткеч тырышлык сала:
— Сезне саклаган өчен милиционерларга түлиләрме? Ә мине менә... нигә сакламыйлар?
Өер көлә. Өер авыр уйлардан арына. Өер шат.
— Правильно, Юрий Петрович! — ди кемдер.
Бәләк танаулы чәчкә ата. Аны куәтлиләр.
— Әйдә, безнең белән ят, сине дә саклырлар,— дим. Аннан карынына футбол тубы йоткан бу бәндәне куздән кичереп, өстим.— Бераз ябыгырсың да.
Шул ук өер хәзер мине куәтләп көлә.
— Ябыгыр өчен ел да бер мәртәбә больницага ята ул...
— Дөньяның мәдәниятле илләре кеше сау-сәламәт булсын өчен шартлар тудыра,— дип әләктереп алам мин.— Шартлар тудыра да, яңа больницалар төзүдә хаҗәт тә калмый. Ә безнең бу режим кешене тизрәк сафтан чыгару өчен тырышлыгын сала да, больницалар җитми дип кычкыра, аннан «былтыр бер больница төзесәк, быел икене сафка бастырдык»,— дип бөтен җир шарына мактана... Былтыр бер кешене үтерсәк, быел икене үтердек була инде бу безнеңчә, шулаймы, җәмәгать?
Әңгәмәдәшләремә кызык булып китә, чөнки аларны бу масштаб белән уйларга өйрәтмәгәннәр. Мина хастаханәгә ятучылар, аңа ихтыяҗлылар никадәр аз булса, аларга исә хастаханәләр никадәр күп, анда «дәваланучылар» никадәр саллы булса, шулкадәр яхшырак. Форсаттан файдаланып, әле кәч барда, мин аларга бер гарәп хикәяте сөйлим. Шулай итеп, мәйдан «Белем» җәмгыятенә әйләнә. (Дөрес, безгә лекцияләр өчен акча түләмиләр.)
— Бер гарәп хәлифе танылган табибны ерак мәмләкәттән хезмәткә чакыртып китерә. Табиб берничә ел дәваланучыларны көтә, әмма, күпме генә көтмәсен, аңа беркем дә килми. Аптыраган табиб хәлифкә килеп болай ди: «Хәлифем, күпме еллар сездә хезмәттә торсам да, мина бер адәми затның да дәваланырга килгәне булмады. Әйтегезче, бу нидән шулай?» «Мондагы халыкның гадәте шундый,— дип җавап бирә хәлиф.— Тәмам ачыкмый, көн дә ураза тотмый торып, тәгам ашамас, ачыгуы тәмам басылмый торып авызына аш алмас, ягъни беркайчан да туйганчы ашамас». «Бәй, сәламәтлекнең нигезе шушы нәрсә ләбаса!» — дип табиб җирне үбә дә, гомерлек сабак биргән хәлифкә рәхмәт әйтеп, иленә кайтып китә... Бу иптәшкә дә чама белән ашау зыян итмәс иде...
Бая гына ярылган йолдыздан Гулливер булып килеп чыккан бәләк танаулы хәзер чәнти бармактай Гномга әйләнеп, кара кабыкка кереп сенә. Ул хәзер юк инде. Аны күрер өчен тагын да галәми микроскоп кирәк.
Көтмәгәндә генә рухи бушанып, замандашларым «социалистик ярыш»ны дәвам итәргә ашыга. Мин аларны көн саен каршы алачакмын һәм озатып калачакмын. Күрәм, чишмә суында юылган ак орлык сыман бер әбекәй мине куышыбызга тарта. Култык астында ниндидер төргәге дә бар.
— Балакаем,— ди ул тыны бетеп.— Синең өчен генә вак бәлеш пешердем. Ашап кына ал әле, беркем дә күрмәс...
— Сез нәрсә?! — дим мин инде икенче тапкыр тәмам аптырап.— Мин бит монда бәлеш ашар өчен утырмыйм, әбекәй!..
Куышыбызга туктаусыз кешеләр керә. Бүздәк районыннан делегация. Шаран районы укытучылары. Чакмагыш элеваторы хезмәткәрләре. Ә мәйданда шул ук күренеш. Шул ук тема, шул ук сүзләр. Шунысы кызганыч, монда сөйләнгән сүзләрне магнитофонга язып баручы кеше юк. Мәйдан буйлап йөреп, көне-төне яздырсаң, Башкортстандагы «милләтара мөнәсәбәтләр»нең культурасы турында үлемсез документ тудырып булыр иде. Әмма кайдан аласың ул магнитофонлы кешене? Татарда автомобиль бихисап, әмма милләт өчен дигәндә, ул — юк. Татарда магнитофон, фотоаппарат һ. б. бихисап, әмма милләт өчен дигәндә, алар — юк. Аннан бит әле баш миен уйлатырга, уятырга кирәк. Дөрес, бүген «Кызыл таң»ның фотохәбәрчеләре Игорь Крылов һәм Наил Акмиев килеп киттеләр. Кызганычка каршы, Кадерленең һәр мизгелен сурәткә төшерергә, магнит лентага язып бару белән «куркыткан» улы да аллә ни куандырмый һәм куандырмас та кебек. Минә куышка дусларым — шагыйрьләр Фәрит Гәбдерәхим һәм Рим Идиятуллин килеп керә. Яктырып китәбез. Караңгы куыш эчендә йолдызлар кабына. Зөлфәт Шаһбазов һәм ошбу ике фикердәшемнән башка

Уфада «рәсми» татар шагыйрьләре юктыр, шөт. Төбәгебездәге татар мохитының корымас карамалары алар. Бөтен доньясы сатылган заманда сатылмый яшәү өчен алар күпме түләде икән? Дусларым мине кочаклый, әмма яшьле күзләре туры карый алмый. Бу манзара елый-елый шешенгән керсез сабыйларны хәтерләткәндер, мөгаен. Фәрит менә утыз елдан артыктыр инде, «Кызыл таң»да мәдәният бүлеге мөдире. Уфада татар язучылары секциясен оештыру турында Өлкә комитетка хат язганы өчен Расих Ханнановлар аны нык кына кыздырып, редколлегия составыннан алып очырдылар. Рим исә, «Кызыл таң»дагы кысымга һәм торгынлыкка түзә алмыйча, «Сәнәк»кә күчте. Әмма торгынлыкның сөрсегән сазлыгына барып эләкте. Култыклап, мин аларны Октябрь революциясе урамы чатына кадәр озата барам. Безне күрмиләр микән дип, чаттагы йортның тәрәзәләренә карыйбыз. Монда Фәридә Кудашева һәм Бәхти Гайсин яши. Бәхти абзый — татарның ачыла алмый калган Шопены. Аның аккордеоны — Уфа татар дәүләт симфоник оркестры буларак тарихка керде... Шушы чатта без хушлашабыз. Тагын да тамчылый башлаган суык яңгыр күздәге яшь һәм моң белән аралаша. «Онытма, без синең белән». Рәхмәт, көрәштәшләр.

**Архивтан.** *«Милләтебезнең соекле улларыннан берсе — талантлы композитор, сокландыргыч баянчы, аккордеончы, импровизацияләр остасы БӘХТИ ГАЙСИН вафат булды... Шик юктыр, мәрхүм иҗат иткән гүзәлдән-гүзәл җырлар һәм көйләрне татар халкы еракларга алып китәчәк. Әмма шунысы кызганыч, кешелексез система корбаны булган Бәхти Гайсин вакытыннан алда бу якты дөньяны ташлап китте. Ул әле күптән түгел генә үзенең алтмыш яшен билгеләгән иде. Тагын да шунысы аяныч, шушы ук система, шушы ук корылыш, милли изелү һәм кысылганлык аркасында табигатьтән татарның Моцарты, Шопены булырга туган бу шәхеснең искиткеч таланты барлык яклары белән дә ачылып өлгермәде. Халкыбыз аны яратып, «Безнең Бәхти» дип торган иде. Без дә аңа шулай дибез. Безнең Бәхти. Хуш, безнең Бәхти...*

*«Аргамак» журналы, 1, 1992 ел».*

Чатырыбызга таба килгәндә таныш тавыш ишетәм:

— Исәнме, түбәтәй!

Мансур Мөлеков. Башкорт академия театрының директор урынбасары. Без аның белән жылы кочаклашабыз. Үзе башкорттан булса да, тар башкортлыктан ерак тора ул Мансур. Якты күңелле, әңгәмәдәше татар булса, татарча сөйләшә торган мөлаем кеше.

— Китер минем түбәтәйне! — дим мин аңа шаяртып.

Моннан ун елга якын элек, мин Мәскәүдә Югары әдәби курсларда укыганда без аның белән Башкорт академия театрының Мәскәүдәге булачак гастрольләрен бергә әзерләгән идек. Измаил паркында татарлар жыенында шигырьләр укып, мин Мәскәүдәге милләттәшләремне туганлаш театрга теләктәшлек күрсәтергә чакырган идем. Аннан, башкорт хөкүмәтенең Башкортстан татарларына карата алып барган сәясәтенә ачуы чыккан Мәскәү мишәрләренең башкорт театрына бойкот игълан итәргә, аны тамашачысыз калдырырга җыенуын белгәнгә күрә, мин татар даирәсе җитәкчеләре белән очрашып, бердәмлеккә чакырып, чыгыш та ясаган идем. Ә-ә, түбәтәй хакында онытып торам икән. «Түбәтәй кисәң, татарлар үз итеп кабул итә, малай, миңа биреп тор әле», — дип, Мансур түбәтәемне алып торган иде. Шуннан соң яраткан чем-кара түбәтәемне бүтән күрергә насыйп булмады.

— Өйдә, ул, Айдар, бер үтешләй кертеп чыгармын, — ди елмаеп Мансур. — Аннан, тирән сулап, өсти. — Нинди көннәргә килеп җиттек, малай...

Ул мине гаепләми. Киресенчә, сыкрап һәм сыктанып, үзен гаепле тоя сыман. «Тоткан юлың дөрес, — ди ул чатыр каршында аерылышканда. — Нык тор, бирешмә, малай».

Вакыт төшлеккә житеп килә. Куанычымның чиге юк: мин бит икенче тәүлек инде тәмәке тартмыйм. Ташлый гына алсам иде! Кулыма кемдер телеграмма тыкты. «Җидессендә кич белән килабез Рәис». Чаллыдан Рәис Зарипов. Илеш егете. Китабымның Вильнюста басылырга әзерләнгәнен ул гына белә. Аны нәшер итү өчен бу ярдәмчел егет миңа алты мең сум акча биреп торды. Уфада да, Казанда да бастырып булмагач, нәрсә эшлисең? Күңел күтәрелеп китте. Куышыбызга әле генә оешып маташкан Уфа яшь тамашачылар театры баш режиссеры Олег Ханов та килеп кергәч, ул тагын да күтәрелде. Олег белән безнең арада әлләни якынлык юк. Әгәр үз теләге белән килгән булса, рәхмәт инде. Аның әтисе Закир абзый Ханов — Башкортстанның халык артисты.

Сибай башкорт театрында уйнады. Татар. Әнисе — башкорт. Олег урыс мәктәбен тәмамлап, саф башкортча укыган башкортка да башкорт теле буенча дәресләр бирә алырлык актер ул. Партия номенклатурасыннан бөтен өстенлекләрне сыгып алган актер. Башкортстанның халык, Рәсәйнең атказанган артисты. Салават Юлаев премиясе лауреаты. Хәзер менә баш режиссер. Заманы килгәч, партиядән дә чыга белде. Моннан өч ел элек Уфада башкорт, татар, урыс телләрендә эшләүче яшь тамашачылар театры кирәк дип махсус мөрәҗәгать язып, ун күренекле сәнгать әһеленнән кул куйдырып, аны «Советская Башкирия»дә бастырган идем. Менә театр ачылды да. Башкорт студиясе бар, урыс студиясе бар, миллион ярым татар өчен татар студиясе генә юк. Кичерә, барысын да күтәрә татар.

Олег китү белән куышыбыз авызына карасам — Нәҗар абый! Күземә яшь бәреп чыкты. Әмма ул һәрвакыттагыча ашыга. Номенклатурадан кемдер күреп калыр дип, ахрысы, ул чатыр эченә керергә ашыкмый. Барыбер рәхмәт, чиксез рәхмәт аңа. Ни дисәң дә, Нәҗар Нәҗми — чын шагыйрь. Атаклы «Татар теле» һәм «Иблис» поэмасының авторы. Шул поэмасын язган хәлдә генә дә ул әдәбият тарихында кала алыр иде...

— Авыр көрәшкә чыктың,— ди ул күзләрен челт-челт йомып.— Озаккамы?

— Максатка җиткәнче, Нәҗар абый...

— Тазалыгыңны сакларга иде...

— Рәхмәт.

Ул чатырга кермичә генә хушлаша. Уфаның һәр зур шагыйре кебек, Нәҗар Нәҗми дә шактый сәер сыйфат-комплексларга ия. Уфада бая телгә алган аберрация төшенчәсе адәм баласы белән бергә ярала. Үзең татар — әмма башкорт шагыйресең. Моннан да сәер аберрациянең булуы мөмкинме? Беренчедән, мин Миякә «башкорты» булган кебек, Нәҗар абый да Дүртөйле «башкорты». Уфада башкорт, Казанда татар булып гаҗәеп бер гармония белән күренә белә. Һәм моны иҗаты белән раслый. Мондый гармониягә бездә беркем дә ирешә алмады әле. Хәтта Сәйфи Кудаш белән Мостай Кәрим дә. Уфаның яшь буын шагыйрьләре аңа никадәр якынаерга омтылган саен, Нәҗар Нәҗми алардан шулкадәр ераклаша, Казанның яшь шагыйрьләре белән уйнаклый белде. Дөрес, мин аның иҗатындагы бер даими сыйфатны һич тә кабул итмим. Ул да булса һәр шигырендә кем бакчасынадыр таш ыргыту, кемнәндер гаеп эзләү, ниндидер «дошман» образын әвәләп, ваклану, үзен кечерәйткән булып, бөеклегенә ымлау. Гомумән алганда, мин аның шигъриятен яратам. Нәҗар Нәҗми — гадәттән тыш сак кеше. Аның мондый саклыгы, бәлки, мәңге сак булырга кушылган хезмәтеннән киләдер — сугыш чорында Нәҗар абый армия контрразведкасы — «Смерш»та офицер булып хезмәт итә һәм бүгенге көндә «Смерш» пенсиясе ала...

**Көндәлекләрдән.** *02.02.93 ел. Заманнар үзгәрде. Күрәсең, бу юлы «добро» сорап тормаганнардыр. Башкортстаннан шактый соңга калып килгән газеталар Равил Бикбаев һәм Нәҗар Нәҗмигә «Башкортстанның халык шагыйре» исеме бирелүен хәбәр итте. Равил, билгеле, асаба башкорт, Нәҗар абый «Дүртөйле башкорты» булып үткән. Котлыйм, Нәҗар абый! Иҗатыгыз ике милләткә дә рухи яңару, бердәмлек тойгысын көчәйтсен! Сезгә «Татарстанның һәм Чувашстан, Мордваның халык шагыйре» булырга да насыйп итсен!*

Менә өйлә дә җитте. Кадерле кайдадыр «типкендә» йөри. Куышта утырырга яратмаганы, гел мәйданда булып, бәхәсләшергә ратканы өчен шулай дим. Көчләрен киләчәк «кара көннәргә» сакларга кушам. Тыңламый, кәһәрен. Су эчәм. Су туклыклы икән. Дистиллирләнгән су булса, ул, бәлки, болай туклыклы да булмас иде. Тормыш бактерияләрендә туклыклы матдәләр күптер, дигән фикергә киләм мин. Тәүлегенә өч-дүрт литр су эчеләдер. Мәйданга чыгам. Янадан килеп җиткән Сәид абый Еникеев белән карт укытучы Барый абый Хәбибуллин татар халкының бүгенге рухияте турында нотык тоталар. Халык һәр сүзләрен җөпләп тора.

— Миллион ярым татар эшләп тапкан бюджет акчасы кая китә? Мәктәп юк, радио-телевидение юк, балаларыбыз өчен гәзит-журналлар юк!

— Дус булырга кирәк!

— Безгә колбиләүче белән кол арасындагы «дуслык» кирәкми, тигезлек кирәк! Мин сине яратам, дип кенә милләтне мәгърифәтле итеп булмый!

— Дөрес!

— Уфада йөз кырык мәктәп — барысы да урыс мәктәбе! Балаларыбызны урысча укытып, чукындыралар да, аннан марҗага өйләндерәләр, урыска кияүгә бирәләр!

— Дөрес! Рәхимовка барырга кирәк...

— Уфада татар кешесенә бирелгән бер урам, татар кешесенә куелган бер һәйкәл юк!

— Татар гомер буе баш күтәргән, алар башкорт бунты булып тарихка кергән! Соңгы сугыштагы башкорт дивизиясендә житмеш процент татар! Генерал Шәйморатов татар! Нигә моны язмыйлар?

— Уфада татар филармониясе оешсын! Башкорт филармониясендә сиксән процент татар, татарча жырлатмыйлар! Әйдәгез, министрга керәбез!

— Кабул итмәс бит ул...

Мине сырып алалар. Чыгыш ясавымны үтенәләр. Миңа күп сөйләргә ярамый. Шигырь укыйм...

Урыныма кереп авам. Күп тә үтми, халык жыенында эт чинаган тавышлар чыгарып, Хәйбулла сөйләшендә зәһәр аһәң яңгырый башлый:

— Халыктарзы дошманлаштырзы! Быга кәзер дус йәшәй инек! Уны гыуырга гәрәг! Саузала кем эштәй? Татарзар! Совминда кем эштәй? Татарзар! Орден һәм нагҙадаларзы кем ала? Татарзар! Заводтарза директорзар кем? Татарзар!

Моңа ничек түзеп торырга? Кадерленен миңа ишетелгән карлыккан тавышы гына моны баса алмый. Әле генә һәр сүзгә «Дөрес!» дип тау жимерергә әзер тоелган милләттәшләр — юк, аларның тугандаш башкорт халкына мәхәббәте көчле, алар бары тик татарга каршы куптарылган «башкортчылык»ны, шуннан, ике милләтне бәрелештерүдән файдаланган империя структураларын гына гаепли! — авызларына су капкан: житәкчелек үткәргән бу сәясәтне, башка атамасын таба алмый, «башкорт шовинизмы» дип атаса, башкортчылык вәкилләре аны шундук барлык башкорт милләтенә күчерә һәм милли кимсет- итеп кабул итә, әйе, нәкъ менә шул башкортчылыкның гадәти бер вәкиләсе — теленә ни килде, шуны лыгырдаган тиле хатын кыланышларына нәкъ татарча түзем белән хәзер дә сыртын куя, милли мәсьәләдән ерак торган халыкны яна аберрация күренешенә алып керергә мөмкинлек бирә; аптырыйсың, шушы хатын белән эшлекле әңгәмәгә керерлек татар юкмы бу мәйданда, йә хода?

Ә хатын кызганнан-кыза барды:

— Башкорт районнарының бюджет аксаһын татар районнары Дүртөйле, Сакмагош, Илештәргә бирәләр — шуга күрә улар якшы йәшәй! Урман ишелеп торһа ла, башкорт землянкала көн күрә, сөнки акса бирмәйзәр! Татарзар бында килгән халык... Ибн Фазлан үзенен сәйәхәтнәмәһендә татар тигән халыкты телгә лә алмаган, сөнки ундай халык булмаган! Болгарзар — без ул!

Бу — провокатор иде. Һәм провокация хатын-кызга тапшырылган иде.

Мин чыгу белән егетләр уратып алды:

— Айдар абый, якын барма, артында кичәге боевиклары тора!..

— Ана үзе сыкты, һорокорт!

— Совминга кереп тыгына ла, палаткаһынан сыгып беззе ашай!..

Театр хөжрәләреннән грим ягып чыккандай чибәр, кара тутлы, нәзек кашлы гүзәлләр минем йөземә котмәгәндә генә учлап-учлап бакыр акча сибә:

— Бына һиңә театр! Бына һинә мәктәп!

— Бына һинә филармония! Бына һинә институт!

Аяк асты минем битемә сибелгән бакыр акчалар белән саргайды. Күк йөзе айкалды. Йөрәктә нәрсәдер өзелде. Бу инде «үз татарларымыз» Зыя Нуриев, Мидхәт Шакиров житәкчелегендә Рәшит Шәкүрләр, Марат Колшәриповлар, Булат Рафиковлар, Мортаза Рәхимовларның еллар буе тәрбияләп килгән «эмбриональ фашизмы» иде. Бер хәерченең икенче хәерчене талау фашизмы. Иң куркыныч фашизм. Кайда икән безнең автократ минералларыбыз Мостай Кәрим, Нажар Нәжми, Әнгам Атнабаев, Нәжип Асанбаевларыбыз? Менә монда кирәк иде алар. Кемнеке бу бакыр өч һәм биш тиеннекләр? Чыгырдан чыккан биш-алты гүзәл йөзгә төкерә, сөртеп өлгермим...

Инәкәйгенәм! Кемнәрне күрәм! Башкорт мәктәпләреннән беренче-икенче сыйныф балаларын алып килгәннәр! Артта, төркемне миңа өстереп, теге, кичәге кара бәндә тора. Гаепсез толпа ятлап алган сүзләрен туктаусыз тәкърарлый:

— Без барыбер татар булмаясакбыз! Без башкорт буласакбыз!

**Көндәлекләрдән.** *«30.04.90. Язучыларның Ленинград янындагы Комарово иҗат йортында ятам. Монда, урман эчендә, Анна апабыз Ахматова җирләнгән. Каберендә зур тимер тәре. «Мне от бабушки — татарки были редкостью подарки, ах, зачем я крещена, горько гневалась она...»*

*Эстониянең Нарва каласында булып, андагы татар-башкортлар белән очраштым. Минем белән бергә Ленинград татарлары мәдәни оешмасының җитәкчесе*

*Халисә ханым Зарипова да булды. Нарвада ике йөзләп татар гаиләсе бар икән. Эстоннар монда нибары җиде процент. Урыслар — туксан. Эстон телендә сөйләшкәннәрен ишетмәдем... 90 процент тәшкил иткән урыс халкы хәтта шушы шартларда да Нарва эстоннарын милләтчелектә гаепли. Нинди милләт бу — урыс? Нигә ул шулкадәр империячел? Нигә ул башкалар хәленә керә алмый? Күрәсең, бу — империянең бердәнбер яшәү формасы. Кыйнаучы, мине кыйныйлар, дип сөрән сала. Андыйларны БМО яклый...*

*Очрашуга алтмышлап татар гаиләсе килгән иде. Шуларның икесе башкорт булып чыкты. Куанычымның чиге булмады. Балалар үз телләрен белми. Аңлаучылары да сирәк. Иң тетрәндергәне шул булды: аларның нинди зур, илаһи теләк белән шигырь тыңлауларын күрсәгез!.. Күзләрендә моң һәм сагыш. Гүя алар үз трагедияләрен аңлаган. Бездә, Уфада һәм Казанда, мондый аңлау юк әле. Чөнки милләтләрнең сәяси аңы ифрат дәрәҗәдә түбән. Ә монда милли горурлык рәүзә булып чәчкә аткан эстон җире. Мин сабыйларның әдәплелегенә шаклар каттым. Аларда татар-башкорт һәм эстон тыйнаклыгы бергә кушылган иде. Империячел милләт балаларында мондый әдәплелек була алмый. Мин сабыйларга өч телдә — татарча, башкортча, урысча шигырьләр укып күрсәттем. Аңлап җитмәсәләр дә, котырып кул чабалар, җаныйкайларым!.. «Биктырыш»ны ифрат та яраттылар.*

*Соңыннан балалар мине уратып алды. Аларның берсе «Туган тел»не яттан белә иде. Мин аны сәхнәгә күтәреп, яңадан укыттым. Очрашу яңадан башланды. Барыбызның да күзләребездә яшь иде... Сабыйлар куанып сөйләделәр: алар Нарва татар якшәмбе мәктәбенә укырга йөриләр икән. Әгәр хәлемнән килсә, мин татар балаларын бары тик татарча, ике башкорт баласын да бары тик башкортча укыткан булыр идем...»*

— Сабыйларым,— дим мин халык арасында нәрсә эшләргә белмичә.— И-и сабыйларым! Кайдан, кайсы мәктәп, интернатлардан китерделәр сезне укуыгыздан аерып?! Онытмагыз, сабыйлар, татар милләте — башкорт милләтенә канкардәш милләт! Сезне алдыйлар! Онытмагыз һәм коткыга бирелмәгез — башкорт милләте бары тик татар милләте белән бергә булганда гына бу авырлыклардан чыга ала!..

Мин аларны яратырга, сөяргә итәм. Алар читкә тартылалар. Йә, хода? Кайсы ил бу? Нинди җир бу? Нинди җыр бу?

Әмма тегеләре җавапсыз кала бит әле. Безнең егетләр дә шаулаша, минем фикерләрне куәтли башлагач, сан ягыннан зур булмаган «хунта» бераз тына төште. Мин аларга 1988 елның кара көзендә, тәмәке исе белән тынчыган буровой будкасында язылган «Башкорт милләтчеләренә» дигән шигыремне укыйм. «Дружба народов»та чыккан мәкаләмнән соң дошманнарым барлык яшәү тамырларымны өзгәч, миңа буровойга кара эшче булып китәргә һәм радио-телевидение, матбугат алып барган көндәлек коткыдан беразга гына булса да тынып торырга туры килгән иде...

> Шаяру җитте, шашмагыз. Инде болай шаштыру —
> Тилелек, ягъни татарны уптым башкортлаштыру.
> Киңәш шул: яктыртып эчтән милләтен тирәнләгән,
> Ныгытырга иде сезгә халыклар бердәмләгән...

— Татар һәм башкорт халкын якты юлга алып чыгу өчен барлык демократик көчләрне бергә тупларга кирәк, туганнар! дип дәвам итәм.— Безнең аерымлыктан өченче көч файдалана. Без бит башкорт мәдәнияте һәм теленә дәгъва итмибез, без бары тик татар милләтенең дә үз телендә белем ала алуын таләп итәбез. Күзләрегезне ачсагыз иде... Сөйләнеп таралудан узарга, конкрет эшкә күчәргә вакыт. Кара көчләр мине ничек кенә дошман күрсәтсәләр дә, бу мәсьәләләрне барыбер хәл итәргә туры киләчәк. Бу фикерне сезгә бүген мин әйтмәсәм, иртәгә кем әйтер, туганнарым?!

— Дөрес! Дөрес!

— Бүген татарга: «Казанга кит!» — диючә ахмаклар да табыла. Юк, без беркая да китмибез. «Башкорт» нефте һәм «башкорт» игененең татар районнарында икәнен онытмыйк. Бу безнең тарихи җиребез. Әгәр миллион ярым татар чынлап та каядыр китеп барса, калган ике миллион ярымны кем туйдырыр? Шәһәрнең бер миллион урысын кем азык белән тәэмин итәр? Кем сыер савар? Нефть чыгарыр? Йортлар төзер? Вузларда укытыр? Милләтнең мең еллык мәгърифәт тәҗрибәсе тугандаш башкорт милләтенә кирәкми мени?

— Дөрес! Дөрес!

Авызга күбек чабыртып чыга. Күп сөйләргә, көчәнергә ярамый.

Мин чатырга таба юнәләм. Казан милиционерлары кыйнап үтергән шагыйрь Фаил Шәфигуллин каны турында беләме алар?!

— Здравствуйте, Айдар абый!

Гөлназ икән. Якташым, Миякә былбылы Нурия Ирсаеваның кызы. Аны бер егет култыклаган. Кияүгә чыккан икән. Урыс егете. «Матур яшәгез, балаларыгыз татар һәм урыс, булдыра алсагыз, башкорт телен дә белсен»,— дигән теләкләр телим.

— Если два языка полностью совпадают и люди могут объясниться без переводчика,— дип сорый Гөлназ,— то какой из них язык, а какой — подъязык? То есть, какой из них оригинальный, а какой производный?

Чынлап та, кызык сорау бит бу. Татар һәм башкорт телләренең кайсы оригинал тел? Кайсы аларның тамырлырак, кайсы аларның халыклар өчен уртак тел булып тора? Минем Гөлназга замандашым Зөлфәт шигырен укып ишеттерәсем килә. Татарча ипи-тозлык белсә дә, әдәби телне аңламый ул. Шулай да укыйм:

Бөек очыш өчен жәйгән идек
Горурланып ап-ак канатны —
Кем сүндерде безнең учакларны?
Кисәүләрен кемнәр таратты?

Яшь гаилә халык арасына кереп югала. Мин, Нурия турында уйлап, куышка юнәләм. Минем әти сугышка кадәр Нуриянең туган авылы Канбәктә укыткан. Әгәр әти Нуриянең өлкән туганнарын укыткан булса, Нуриянең апасы Кәшифә апа мине укытты. Безнең әти-әниләр дә дус булган. Мин еш кына Канбәккә ялга кайтам. Ул ике тапкыр чукындырылып, ике тапкыр мөселманлыкка кайткан авыл. Әтинең эзләре буйлап йөрим. Илле ел үтүгә карамастан, аны Канбәк кенә түгел, бөтен район онытмаган. Өлкәннәр «Нәҗметдин учительнең улы» дип эндәшәләр миңа. Заманында Нурия белән уртак иҗади кичәләр үткәрсәк тә, милли мәсьәләдә безнең юллар аерылды. Бу хакта миңа сөйләве ифрат та авыр. Нурия ике халыкның да көчен суырып, аннан аның берсе белән тәп, автоном халык уены уйнап, бер кол милләтне икенче кол милләткә хезмәт иттерү җинаятенең корбаны булды. Ә мин шул җинаятьне эзәрлекләп килүче шагыйрь. Әгәр синең бертуган сеңлең урынына күргән кешең сәхнә артында татарча сөйләшеп, сәхнәгә чыккач, татар белән туган телендә түгел, «сәхнә телендә һөйләшә» башласа, сез ничегрәк карар идегез? Казан татарына боларны аңлавы авыр, әлбәттә. Нурия, драматик актриса булуы белән бергә, сирәк очрый торган талантлы җырчы, әгәр шулай итмәгән булса, номенклатур партократиянең айт дигәненә тайт дип тормаса, Рәсәйнең һәм Башкортстанның халык артисткасы, Салават Юлаев премиясе лауреаты исеменә ирешә алган булыр идеме? Кызганыч, шундый җырчының, илле яшьтән узуына карамастан, Башкорт радиосы һәм телевидениесе фондына калган язмалары юк. Нинди тавыш югала, юк, югалды инде! Әйе, анда «татар Нурия» ул. Баш миемдә нәрсәдер яктыра һәм яктырткыч ядрәләр булып фикер сызылып үтә: «Бу татар һәм башкортны үзеннән-үзе җирәнерлек дәрәҗәдә ничек итеп оялтырга? Ничек итеп аларны үзләренә читтән карарга һәм болай яшәргә ярамаганлыгын аңлатып, уятырга?» Фикер, ук булып, Калининградтан Владивостокка кадәр сикерә. Мин кичергән халәтләр, мин күргән кешеләр, минем һәм башкалар башыннан үткән түбәнлекләр... Нәрсә хакына? Юк, нигә әле мин кеше булып туганыма горурланып түгел, үкенеп яшәргә тиеш? Миңа сәләтне кем биргән? Милләт биргән. Табигать биргән. Нигә мин ул сәләтем өчен түбәнлекләргә тарырга тиеш?

Барый абзый белән Сәид абзый мине чатырга кадәр озатып куялар. Сибәләп торган вак күзле яңгыр туктый. Көн яктырып китә. Урыныма ятып уйларымны дәвам итәм. Әйе, аптырамыйм: татарның сатыласы сатылып беткән; сатылу — андыйларның нормаль халәте; әмма үзләрен алар юньле, нормаль кеше дип исәпли, бу юлдан бармаганнарны беркатлы ахмаклар дип ышана; шуңа күрә милли, рәсми җитәкчелеккә дә күбрәк милләтен сатканнар күтәрелә; бу инде борынгы татар каны, борынгы татар нәселе түгел, бу бөтенләй икенче генетик нигез; антинигез; милли хәрәкәттә исә күп өлеше сатылмыйча яшәп хәлсезләнгән, зиһене таркалган, буыны сыекланган, кайчандыр кем тарафыннандыр кыерсытылып, алардан үч алырга теләгән наив олыдөресләр, рухани контуженнар, намусын югалтмаган чатаннар, сукырлар, үз теленең кирәклеген аңлый башлаган сабыйлар һәм житмеш-сиксән яшьлек әби-бабайлар... Бәрәңге һәм корсак турында уйлаган татар милли хәрәкәттән җеннән качкан кебек кача, чөнки ул —

«нормаль кеше», имеш... Әйе, алар ике мәртәбә чукындырылып, ике мәртәбә кабердән күчерелеп, ике мәртәбә мөселманга кайткан Канбәк авылы нәселеннән түгелләр...

Теләр-теләмәстән Шәехзадә Бабичның «Уфа кызыклары» дигән фельетоны хәтергә төшә: «Кызык дигәч, син кызык эзләмә! Уфада чуртым кызык булсынмы? Кызык дип аптыраганнан гына әйтәсең... Уфа сүнгән дек сүнгән инде... Чынлап уйлаганда бит, әфәндем... вафасыз бу Уфа, хафасыз бу Уфа, менәмен дигән кешеләрне ваклатып, җәфалап бетерә бу Уфа... Ит юк, май юк, сөт юк, кымыз юк, аш юк, шулпа юк, тоз юк, ярма юк, он юк, икмәк юк... Кызлар, хатыннан күп, иркәкләр юк. Кызлардан да әвәлге сайраучы нечкә билләр юк, сайраучы былбыллар юк. Язучы юк, мөхәррир юк. Мөхәррир булса, әдип юк. Әдип булса, әдәп юк. Әхлак юк, әхлаклыларда аң юк, фикер юк, башларында ми юк...»

Бабич бу юлларны, ялгышмасам, уналтынчы елда язган. Әгәр Шәехзадә әфәнде Уфага бүген кайтып әйләнсә, нәрсә дияр иде икән? Бер сүз белән — тиленләр, алмашынганнар йорты! Ихтыяр көченең нинди витамин икәнлеген оныткан, беркүзле адәмзатлар кыямәте!

Мәҗлесләрдә, вак мөнәсәбәтләрдә һич тә начар кеше түгел алар. Хәтта, әйтер идем, молаем кешеләр. Иҗтимагый, сәяси, милли мөнәсәбәтләргә кергәндә шәхси яктан әйбәт кешеләр дә танымаслык булып үзгәрә. Монда инде, укытучым профессор Алексей Малышев әйтмешли, кешеләр дөньясы икегә аерыла: гуманитарийлар һәм милитаристлар. Үз гомеремдә яхшы кешеләрне күп очраттым мин. Алар ярдәме белән генә аңлы булдым. Менә әле мәйданда сиксән ике яшьлек Барый абзый Хәбибуллин йөреп ята. Чын гуманитар, канлы фронтларны үткән, менә дигән балалар үстергән, гомере буе Дәүләкән районында яшәп, балалар үстергән, инде сөекле җәмәгатен югалтып, Дмитриевка исемле урыс авылында үз йортында ялгыз гомер кичергән Барый абзый... Гүзәлләрдән гүзәл зат. Шагыйрь. Менә дигән декламатор. Тукай, Бабичларны яттан сөйли. Кирәк икән, Югары Совет каршысына пикетка килә, кирәк икән, мәдәният мәркәзенең афишаларын да ябыштыра. Яшьләр көнләшерлек хиссияткә ия ул. Бу якты күңелле кеше — бабайлардан килеп җиткән соңгы могикан. Әмма мин аның соңгы булуын теләмим, шуңа күрә татар-башкорт милләте бәхете өчен җан аткан булам. Уфада минем башкорт дустым Гәфәр Вәлиуллин бар. Сигез бала атасы. Кешене түгел, чебенне дә рәнҗетмәс бер изге бәндә. Ул татарга каршы булу түгел, башкорт кебек хокуксыз татарны яклый. Бәйрәм җитсә, ул газеталарга шигырь алып килә иде. Шигырьләре, кем әйтмешли, «тәк сибә», әмма бәйрәмне бәйрәм итү теләге бөек. Бу бит үзе шигърият — сигез бала атасы шигырь яза! Бер мәлне мин аңа атап үзем дә шигырь кораштырган идем:

Слушай мине, Гәфәр!
Язма шигырь, яз хәбәр!
Шигырь кирәкмәс заманда
Ул шигырьгә бәрабәр!

Гәфәр дус укыды да, үзенчә ягымлы елмаеп:

— Чыгарасыңмы? — диде. — Синекен гәзитләр шундук чыгара ул!..

Мин аны үпкәләмәс микән дип борчылган идем. Бу минутта мин өлкән буын башкорт каләмдәшләрем — фронтовиклар Хәким Гыйләҗев, Газыйм Аллаяров, Якуп Колмый, Шәриф Биккол, татар Нәҗибәк Хафизов, Тимер Арыслан, Йосыф Гәрәй, Рәис Габдрахманов, Гариф Гомәр, Динис Исламов, якташым башкорт Хәкимҗан Зарипов, урыс Геннадий Молодцов, яһүди Михаил Воловик — тагын әллә кемнәрне, әллә кемнәрне сагынам. Минем бит гаебем юк — минем бары үз телем, үз динем белән генә яшисем килә. Дусларым, нигә читтә торасыз, нигә ярдәм итмисез? Тел һәм иман сезгә дә кадерле түгел мени?

Бер караганда, Башкортстан мәгариф министры Рифкать Гарданов та менә дигән кеше. Гомер буе партия органнарында җитәкче эшләрдә эшләде. Шакиров кушкач, эһ тә итмичә үзе беренче секретарь булган татар районы Благоварны башкортлаштырып бетерә язды. Райондашлары Үзәк комитетка язып, комиссияләр чакырткач кына бераз тынды. Син аның белән сөйләшеп кара, ясалма, сәхнәви халыклар дуслыгының сагында торучы ватанпәрвәр ул. Әмма бу дуслык — номенклатур дуслык. Яңа беренче секретаребез Хәбибуллин кушкач, бу дуслыкның да эзе калмый...

**Көндәлектән.** *«Зачем вам это?» Нурия Ирсаеваның кызы, ягъни минем сөекле Канбәгемдә туып үскән татар кызының кызы, миңа шундый сорау бирде. Гүя безнең таләпләрне ул аңламый иде. Гүя икенче галактикадан килгән. Кияве,*

*ялгышмасам, соры күзле урыс егете, шалканга менгән кәбестә кубәләге сыман, бу мәсьәләләрнең күтәрелә алуын башына да сыйдыра алмый. «Как вы смеете? Аның ерак бабасы, атасы һәм үзе дәүләт исеменнән, ике башлы сәмруг кош томшыгы астында мине басып алып, җинаять эшләгәннәр һәм эшләүләрен дәвам итәләр. Элек «үзләре теләп урыс канаты күләгәсенә кергән милләтләрнең бүленмәс Россиясе» булса, хәзер инде милләтләрдән «территория һәм субъектлар»га әйләнгән, милләтләре турында уйлаудан да мәхрүм ителгән «халыклар дуслыгы»... Мин аңа әйтәм: «Син минем йортымны басып алдың. Суымны, һавамны, ашар ашымны нәҗесләдең. Мин синең белән үз йортымда өйдәш булып яшәүдән арыдым. Хәерчелектә булсам да, чабатада калсам да, минем синнән аерым яшәп карыйсым килә. Әйдә, үз кенебезне үзебез күрик. Аерылып чыгу, гаилә кануны гына түгел, дәүләт кануны — Конституциядә дә язылган». Ә ул миңа әйтә: «Юк, син миннән башка яши алмыйсың. Давай вместе». Мин аңа әйтәм: «Ачка үлсәм дә, сиңа үпкәләмәячәкмен. Әйдә, аерым яшәп карыйк». Ул һаман: «Давай вместе. Давай дружбу крепить». Синең «дружба»ңнан арыдым, гарык булдым», дип баш күтәрсәм, ул һаман «давай вместе», дип «миротворческий» гаскәрләр кертә. Казах ашатмаса, украин ашатмаса, татар ашатмаса — урысны кем ашата? Мәскәү сазлыкларында якутның «урыс алмазы» да, казахның һәм украинның «урыс икмәге» дә, үзбәкнең «урыс мамыгы» да, грузинның «урыс чәе» дә, әрмәннең «урыс персигы» да, татарның «урыс нефте» дә юк бит... Менә ни өчен урыс җир шарында «дуслык һәм туганлык режиссеры» булырга ярата... басып алган милләт гаскәренең «миротворческий» булырга хакы бармы?»*

Кинәттән күңел уйный башлый. Укшыта. Тын кысыла. Күзләремне ачарга итәм — ачам, әмма алар күрмиләр. Кинәттән тома сукыраюны мин үз гомеремдә беренче тапкыр 1990 елның алтынчы октябрендә кичердем. Аваз салып, кеше чакырырга базнат итмим. Кайчандыр Татарстан язучылар берлегендәге бер кинәшмәдә, үзеннән күпкә яшь «энекәш»нең һөҗүменнән соң шундый хәлгә калган Хәсән ага Туфан Маяковский урамындагы «спартан» фатирында миңа бу халәтнең, гадәттә, кинәттән генә кан басымы күтәрелүе белән бәйле икәнен сөйләгән иде... Күңел уйнаудан туктый, әмма күзләр һаман да күрми. Күпме вакыт ятканмындыр, бер мәлне йомшак кына тавыш ишетәм:

— Әтисе... Әтисе... Мин килдем...

Ниндидер йомшак, шаукымлы куллар минем битемнән сыйпый. Тавышыннан абайлап алам — хатын. Хәләл җефетем. Советларча әйтсәк, «иптәшем». И-и җаныкаем! Ышансагыз ышаныгыз, ышанмасагыз — юк, куркып кына күзләремне ачам — һәм күрәм!..

— Әйбәт әле, — дим мин балачактан күңелгә сеңгән сорауларны шаянлык белән автоматтан сиптереп. — Үзегез сон ни хәлдә? Бала-чагалар исән-саулармы? Сыерыгыз бозауламадымы? Кәҗә-сарыкларыгыз бәрәнләмәдеме? Ничәсе саулык, ничәсе тәкә?..

Һәм без, берни булмагандай, көлешәбез.

Без бер-беребезне уналты яшьтән үк беләбез. Башта минем күзем аның апасы Мәүсиләгә төшеп йөреде. Мәүсилә, үзенең йөзе, матур борыны белән борынгы юнан хатын-кызларын хәтерләткән Мәүсилә, миңа «Сине яратам да бит, әмма мин чирлим шул», — дигән иде. Йөрәк чире аны чынлап та кабергә алып китте. Әниләре безнең авылдан булган, хәзер зур тимер юл станцасы Раевкада яшәгән бу гаилә безнең авылга еш килә, ә балалары җәй буе бездә яталар иде. Үз гомеремдә Венераны яраткан кебек мин башка беркемне дә яратмадым. Әйе, аның исеме утызынчы елларда көчләп диярлек тагылган Венера, минекe — Борис иде. Соңыннан без «Ярый әле Станция белән Генератор кушмаганнар», — дип шаярта идек. Шуңа өстәп, мин аңа: «Мин бит сиңа өйләнмәдем, бары фамилияңә бер аркылы сызык кына өстәдем», — дип тә куя идем, чөнки сөйгәнемнең йөреткән аты Галимова, минеке Хәлимов иде. Әмма өйләнешкәнгә кадәр без бик катлаулы юллар үттек. Алар яшьлеккә хас тилелек, хаталарга бәйле. Әмма йөрәктәге серләрне актарганчы, мин беренче мәхәббәт турында берничә сүз әйтергә тиешмен. Их, беренче тойгы, беренче кичерешләр! Беренче мәхәббәт никадәр көчле, никадәр чиста булса, шәхес тә шулай көчле һәм чиста булып формалаша. Беренче мәхәббәт — тормышны, галәмне акка-карага аера, шуңа күрә аның күпчелеге фаҗига белән тәмамлана. Беренче мәхәббәт кабергә кадәр онытылмый. Аның сурәтенә сеңгән көмеш мәңгелек була. Гомумән, җирдәге бөтен барлык һәм байлык мәхәббәт көче белән һәм аның хакына иҗат ителә. Уйлый китсәң, безнең тәнебезне агулаган һәм тормышны юк иткән атом электр станциясе, атом-төш коралы да шул ук тормышка мәхәббәт исеменнән бар ителә

бит. Минем аңлавымча, менә ни өчен безнең татардагы иң ачы сүгенү — ул «и-и мәхәббәтсез!» дигән сүз. Калган сүгенү безгә урыстан кергән. Тәрҗемә ителгән.

Әйе, мин Венераны Мәҗнүн гыйшкы белән яраттым. 1966 елның ноябрендә ул минем янымa — Казанга кунакка килде. Мин ул чакта университетның журналистлар бүлегендә укый идем. Без яна елда өйләнешергә сүз куештык. Имтиханнарны алдан тапшырып, тулы әзерлек белән Уфага кайтсам, минем сөйгәнемне гүяки кирегә өйләндереп куйганнар иде. Мин бер нәрсә дә аңламадым, әмма кеше коткысы, көнчелекнең нинди юллар белән йөрегәнен мәңгелеккә сеңдердем. Ничек кенә тырышсам да, мин аны күңелдән алмадым. Утыз градуслы салкында туй көткән туган авылым Кәркәле — бертуган абыем Ингелгә кайтып, мин бер атна буе баш күтәрмичә эчтем. Безнең якта халык ифрат кунакчыл. Мин авылны, авылым исә мине бер мәҗнүни сөю белән сөйгән бу очракта бөтен халыкның туйга әзерләнгән булуы һич тә сәер тоелмастыр. Кәркәле — ике текә тау арасында урнашкан авыл. «Борисның туен эчәбез!» — дип, Фәиз кардәшемнең уң таудан сул тауга, икенче Зөбәер кардәшемнең «Борисның туен эчәбез!» — дип сул таудан уң тауга бал мичкәсе тәгәрәткәнен хәтерлим. Әмма мин исерә алмадым. Һәм әле булса шәрап эчеп исерә алган адәмнәрдән көнләшәм. Бу вакыйганы мин 1970 елның кышында Түбән Камада язылган поэмамда сурәтләдем.

Бетте, бетте!..
Каеннарым чүкте!..
Дуслар әйтте: «Булма түземле!
Җимертеп бер эч тә... Беткән мени?
Юкка кимсеттермә үзеңне!..»
Хәтеремдә шәрап кәсәсына
Беренче кат иренем тигәне...
Караңгыда, каеннарны кочып:
«Аңла мине, Ватан!» — дигәнем...
Нигә «Ватан»? Монда «Ул» гына бит?!
Юк, гражданин булып Ватанны
Тәүге тою миндә бер вакытта
Тәүге сөю булып яралды...

Мин сөю алып килә торган ошбу сирәк гармониянең бәхетсез бер корбаны идем. Әмма бу гармония алтыннан да сирәк очрый торган байлык икән. Шушы гармония никадәр камил булса, кешедә шәхес тә шулкадәр көчле була. Бу көч исә кешенең биографиясен иҗат итә. Бер карасаң, биография һәркемдә дә бар, әмма шәхес кенә һәркемдә дә юк. Менә шул шәхес дигәне тагын да килеп сөю иҗат итә шул...

Хыянәт итеп кабул ителгән бу гармония миннән тагын да корбан таләп итә иде. Һәм мин аңа бармыйча кала да алмый идем. Шагыйрьләрчә тилелек белән мин Казан урамына чыгып, беренче булып очраган кызга, хатынга өйләнергә карар иттем. Мин өйләндем дә. Ул миннән дүрт яшькә өлкәнрәк булып чыкты. Беренче кызым Илсөяр — шушы никах җимеше. Әмма... «Җаны теләгән — жылан ите ашаган», — дигән борынгылар. Мин Венераны оныта алмадым. Сирәк-сарак сәламнәр дә алгалый идем аңардан. Дүрт елдан соң беренче хатынымнан аерылып Венерага өйләндем. Монда килеп йөрүче Зөлфия безнең кызыбыз була инде... Бу вакыйгалар турында, гомерем бирсә, бер әсәр язарга ниятлим.

Венера ифрат та тыйнак хатын. Ул кеше күзенә чалынырга һич кенә дә яратмый.

— Әйдә, өйгә кайт, дип әйтә күрмә...

— Хәзер әйтмим инде, — ди ул саран гына елмаеп. — Бүген җиңелрәк инде, кичә бик авыр булган иде...

Менә бит ул ничек: миңа кичә җиңелрәк иде, бүген исә авыррак. Куыш караңгысында ул минем урын өстен рәтләгән була. Тагын нәрсә эшләсен? Ашатырга кирәкми. Кер юарга кирәкми. Суы бар. Киеме өстендә. Түш кесәмә ручка тыга ул. Тегесен югалтсаң, кирәк булыр, ди. Һәм тыныч кына хушлашып, гүя беркемгә күренмичә, куыштан чыга...

Миңа яңа көч иңгәндәй була. Кадерленең койкасы өстендә иртәдән бирле укылмый яткан хатны алам.

*«...Исәнлегегезне, вакытыгызны кызганмыйча, безнең мөселман халкы өчен көчегезне, сәламәтлегегезне сарыф итәсез. Без сезнең изге уйларыгызны хуплыйбыз һәм ризалыгыбызны белдерәбез... Башкортстанга суверенитет бирүгә без һич тә каршы түгелбез, ләкин тигезлек белән булса иде. Әлегә тигезлек гамәлдә күренми.*

*Башкорт һәм урысларның алтышар театры бар, ә безгә, миллион ярым татарга, җыелып сөйләшер өчен бер бүлмә дә юк. Татарларның азатлыгы өчен көрәшегез. Балалар татарча укысын иде. Үзебез дә, балаларыбыз да татар моңнарын бик сагындык. Безнең моторлар төзү заводының илле мең кешелек коллективының яртысы татар. Алар эшләгән акча кая китә икән? Без, утыз дүрт татар хезмәт ветераны, шушы завод мәдәният сарае каршында «Йолдыз» исемле татар вокаль ансамблен оештырдык. Халыклар дуслыгына хилафлык кылмыйбыз, бары тик тигезлек кенә даулыйбыз. Сезнең изге көрәшегездә безнең теләкләребез кабул булсын. Амин. Наилә Лотфый кызы Камалова, 69 яшь. Гаидә Гатият кызы Кәримова, 62 яшь. Сәлимә Мөҗәһит кызы Мокасыймова, 62 яшь. Мәрхәбә Абдулла кызы Богданова, 87 яшь, җитәкчебез. Хәтимә Абдулла кызы Богданова, 81 яшь. Хәкимә Вәлиева, 70 яшь, Нәсимә Кәлимуллина, 60 яшь. Тимерҗан Кәлимуллин, 62 яшь. Барлыгы утыз ике имза».*

Бу киләчәк буыннарга калырга тиешле йөрәк документы түгелме?

Бераз ял иткәннән соң янадан килеп житкән Зөфәр, чатырга кояштай елмаеп, беренче телеграммаларны кертә. Үзе яланбаш. Сумаладай кара чәчләре һәм кашларында янгыр бөртекләре. Безнең турыда чынлап та беләләр микәнни? «Поддерживаем ваши требования. Преклоняемся перед вашим мужеством. Семья Ларионовых. Уфа». Кызык бу. «Молодец. Так держать. Все мы писатели и работники искусства Татарстана с вами. Ахмет Адиль. Казань». Шагыйрь Әхмәт Гадел. Кайчандыр аны гаиләсе белән Түбән Камага чакырып китергән идем мин. Бер ай чамасы бездә яшәгәннәр иде. Рәхмәт сина, Гадел дускай.

Көн кичкә авыша. Мәйдан һаман да шул элеккечә бер гөрләп ала, бер тынып кала. Анда бәхәсләшергә кеше һәрвакыт табыла, әмма тамаксыз кала күрмә. Асфальтта шыксыз булса да, мин вакытны күбрәк чатырда үткәрергә тырышам. Тыныч. Уйланырга мөмкинлек бар. Йөрәккә дә жиңелрәк. Кадерле мәйданнан кермәгәч, әнә, валидол да эчә башлады. Бу кадәр тынгысыз жан булыр икән.

Куышка Кадерле, төнге сакка килгән яңа алмаш — Рәфис Мөхәммәтов, Раил Шакиров һәм Замир Якупов килеп керде. Замир чатырыбызны жылыту өчен көнә буе махсус тимер мич ясаган икән.

— Монда төнгелеккә суык бит, Айдар абый,— ди ул елмаеп.— Әйдәгез әле, жылытып карыйк...

Ягар өчен ул каен шакмаклары да алып килгән. Мичнең торбасын куыш тәрәзәчегә аша тышка чыгардык. Күңеллерәк булып китте. Әмма бу шатлык озакка бармады — чатыр эче төтен белән тулды. Без ысланып беттек.

Татар мәдәният мәркәзе тырышлыгы белән яңа гына оештырып жибәрелгән татар ижтимагый үзәге житәкчелеге һич аңлап булмас ысуллар белән милли хәрәкәттә раскол китереп чыгаргач, ТИҮ бик сәер рәвештә мәдәният мәркәзе кадрларын үзенә суыра һәм безгә каршы куя башлады. Без бер яңа көрәшче табабыз икән, ТИҮ аны шундук үз идарәсенә кертә. Алар Замир Якупов белән дә шулай кыланганнар иде...

Сиксән тугызынчы елның жәе Уфа татар хәрәкәте өчен аеруча кайнар булды. Без ТИҮдә оештыргач, рәсми органнар, әллә нинди уйдырмаларга нигезләнеп, милли мәсьәләләрне аек акыл белән хәл итү урынына турыдан-туры һөжүмгә күчтеләр. Уфада татар театры ачу гамәли яктан чишелү алдында тора иде кебек. Казан зыялыларының теләктәшлек күрсәтүен үтенеп, мин танылган унбүрт язучыбызга хат белән мөрәжәгать иттем. Бары тик Нурихан Фәттахтан гына жавап алдым. Аның тырышлыгы белән хат Татарстан язучылар берлеге жыелышында шагыйрь Ркаил Зәйдуллин тарафыннан укылды да. Мин Нурихан абыйга һәм Ркаил энекәшкә еллар аша бу батырлыклары өчен рәхмәт әйтәм. Әмма Туфан Миңнуллин, жыелышның рәисе буларак, бу акциянең тәэсирен кимәтү өчен тырышлык куя... Әмма бөтен кешеләр дә бертөсле уйламый. Менә — хат. Мин аны алгач һушсыз калдым. Булган хәлме? КПССның Татарстан өлкә комитетында әллә татарча хат язарлык кеше бармы? Татарча машинка да булдырганнармы?

**Архивтан.** *«Хөрмәтле иптәш Айдар Хәлим! Милләтара мөнәсәбәтләрнең бик әһәмиятле мәсьәләләрен чагылдырып язган хатыгыз өчен бик зур рәхмәт. Бүгенге көндә безнең республиканың партия һәм совет органнары, министрлыклар һәм ведомстволар, җәмәгать оешмалары, үзләренең булган мөмкинлекләреннән чыгып, илебезнең төрле төбәкләрендә яшәүче татар халкының (шул хисаптан Башкортстан АССРда яшәгән татарлар өчен дә) милли-мәдәни ихтыяҗларын тулырак канәгатьләндерү йөзеннән байтак эш алып баралар... Шул ук вакытта Сез күйган*

*күп кенә сораулар безнең вәкаләтләргә туры килми, аларны урыннардагы рәсми органнар хәл итәргә тиеш. Ул органнарның эшчәнлеген тикшереп тору исә шулай ук, конституция нигезендә, һәр республиканың үз вазифасына керә. Милли республикаларда аерым милләт вәкилләренең үзара мөнәсәбәтләрен, бәйләнешләрен көйләү-җайлау эшен җирле һәм югары дәүләт һәм идарә оешмалары башкара. Шулардан чыгып, Сезнең Татар иҗтимагый үзәгенең оештыру съездында ясарга әзерләнгән чыгышыгызның текстын тәрҗемә итеп, без КПСС Үзәк Комитетының дәүләт-хокук бүлегенә кергән милләтара мөнәсәбәтләр бүлекчәсе инструкторы А. Ф. Солодовниковка тапшырдык.*

*Сезгә чын күңелдән,*

*КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре Р. Идиятуллин (имза).*

Мәсьәләләрнең хәл ителү-ителмәвенә карамастан, бу хат безгә — Уфа татарларына — билгеле бер импульс бирде. Соңыннан билгеле булуынча, хатны Өлкә комитетының ул чактагы инструкторы Харис Әшрәфҗанов әзерләгән булып чыкты.

Шул ук сиксән тугызынчы елның апрель аенда мин Мәскәүдә булып, Башкортстан татарларының милли-мәдәни тормышын яктырткан 76 битлек хат-анализымны КПСС Үзәк Комитеты секретаре В. Медведев һәм Үзәк Комитетның административ-бүлек мөдире Павлов исеменә тапшырып кайткан идем. Озакламый Башкортстан Өлкә комитетының пленумында татар мәктәпләре ачу һәм Уфада татар театры булдыру турында мәсьәләләр күтәрелде. Без тагын да куандык. Әмма Өлкә комитетының идеология буенча ул чактагы секретаре Әхнәф Дилмөхәммәтов әле ачылмаган театрны Уфада түгел, ә Башкортстан-Татарстан чигендәге Туймазы шәһәренә күчерү турында астыртын эшләр башлады. Республика газеталарына, Дилмөхәммәтов кушуы буенча, Туймазы шәһәр комитетының идеология буенча секретаре Сәгыйдуллин оештырган хатлар агыла башлады — имеш, татар театры өчен 350 мең татар яшәгән, кадрлар һәм яшәү шартлары булган Уфа түгел, утыз биш мең татары булган Туймазы шәһәре кулай икән... Театр ачуга дип билгеләнгән 180 мең акчаны да тиз генә Туймазыга күчерттеләр. Шулай итеп, властьлар яңа конфронтация учагы кабызып җибәрде. Уфада эшли башлаячак яшь тамашачылар театрында да татар студиясе булмаячагы ачыклангач, Өлкә комитетының беренче секретаре Р. Хәбибуллинга мин татар, башкорт, урыс, яһүд зыялыларының «Ачык хат»ын оештырырга карар иттем. Ул чакта мин Совмин хастаханәсендә ята идем.

Хастаханәдән качып чыгып, өемә кайтам һәм бер тын эчендә «Ачык хат» текстын язам. Аңа скульптор Тамара Нечаева, рәссам Сахно, биюче Хәзинә Магазова, медицина фәннәре кандидаты Мөхәммәт Галләмов, СССР халык рәссамы Борис Домашников, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе Л. Левитиннан кул куйдырып, «үз татарларымыз» янына — шифаханәгә кайтам. Рафаэль Сафин: «Мин культура министры Әминев менән кәңәштем. Был нәмәнең булуы мөмкин түгел икән», диде. Мирзаһитовны кул куелган текст белән таныштырдым. Әсгать абый — авыр туфрагы җиңел булсын мәрхүмкәйнең, тумыштан изге күңелле, татар җанлы, әмма бу шартларда шактый таркалган кеше иде! — болай диде: «Моннан ике ел элек Мостай Кәрим белән без бу теманы югарыда күтәреп караган идек, булырдай түгел». Нәҗип Асанбаев текст белән танышудан баш тартты. Әнгам Атнабаевка киттем. Минем белән доктор Мөхәммәт Галләмов та бар иде. Әйе, бу хатка милләте татар булган «башкорт интеллигенцияһы вәкилдәре» бик тә кирәк иде, туганнар!

— Иҗатчы иҗат итәргә тиеш. Аның эше политика белән шөгыльләнү түгел,— диде Атнабаев сөйләшүне йомгаклап.— Мин сиңа шундый киңәш бирер идем...

Без чыгабыз. Кәеф трамвай юлына аркылы ятарлык. Күңелдә торналар кычкыра. Мин Уфа иҗатчылары тәрәзәләреннән шәхес чаткылары эзлим.

Ниһаять, хатны Өлкә комитетына илтеп тапшырдык. Татар милләтле ике-өч язучы гына аңа кул куйды.

...Җир йөзе тәмам караңгыланды. Ертылган болыт сыман кисәк-кисәк тупланган халык мәйданда кичәге сәнгать бәйрәмен дәвам итә башлый. Кем җырлый, кем шигырь сөйли. Безнең мегафон сыйфатсыз булып чыкты. Зөфәр каяндыр икенче мегафон табып китерде. Аны беренче булып Барый абзый Хәбибуллин сынап карады. Тукайның «Су анасы» шактый матур яңгырады. Ничек куанмыйсың, кайдадыр ерак Дмитриевка авылында үз йортында ялгыз гомер кичергән сиксән яшьлек Барый карт яшьләренңе уздырып тамаша кылып йөри бит. Их, безнең яшьләребездә дә шундый аң булса! «Су анасы»н тыңлаганда мин

Тукай турында уйландым. Әгәренки Тукаебыз безнен мәйданга килеп чыкса, мөгаен, берәр татар кызы үзенә караткан, я берәр татар хатыны үзенә өйләндергән һәм Тукаебызны нәселле иткән булыр иде. Әнә бит, алар тагын йөгерешеп килеп житкәннәр:

— Айдар абый, чишенегез, без сезне янадан жылы итеп киендерәбез! Менә сезгә жылы тун! Тагын да кәттәрәк пима! Бәйләгән свитер!..

— Рәхмәт, кызлар, мин болай да жылы киенгәнмен,— дип көләм.— Боларын да кисәм, мин бит йөри алмаячакмын!..

Галия һәм Зaремалар мине барыбер янадан киендерәләр. Мондый кызларыбыз барда милләт үлә диме?! Тукай заманы һәм безнең заман бөтенләй аерыла шул. Категорияләр икенче. Жир белән күк бергә буталды. Рәсми идеология безнен аңыбызга Тукайны «Россиянен үги баласы» итеп сеңдерде. Татар милләте вәкиле буларак, ул чынлап та шулай иде. Әмма... ул чактагы милли ан? Милләттәге ватанпәрвәрлек? Милли икътисад? Милләт турында кайгыртучанлык? Күз алдыгызга китерегез: һәр мәхәллә, һәр авылда мәдрәсә. Урысча сөйләшә белгән татар сирәк. Шул ук рәсми статистика 1910 елда 179 татар нәшрияты һәм типографиясе булуын, елына 2,5 миллион данә татар китабы, шуның 60—70 процентының дөньяви әдәбият булуын раслый. Тукайны татар миллионерлары Троицкига, Уфага, Петербургка дәваланырга чакыра, ә ул, «горур шагыйрь», бармый, барса да, алардан күләп кабул итмичә, тупсасыннан кире жибәрә... Гомере буе «Болгар» номерларында яши, моның өчен ел саен чыккан биш-алты китабының каләм хакы һәм хезмәт хакы, иншалла житеп тора... Безнең заман шагыйрьләре Тукайга караганда йөз мәртәбә үгирәк булып чыкты түгелме? Тукай безгә караганда бәхетлерәк иде түгелме? Их, бер генә тапкыр Тукай сыман, «көйсез кияү» булып карарга!

Мәйданда — татарлар. Әдәби-музыкаль кичә кызганнан-кыза бара. Зарема, балалар бакчасында эшләүче хатынкай, әнә, бик матур итеп жырлый. Күренүенчә, бик унган. Ялгыз. Кызы бар шикелле. Янында гына Ирек Ганиев басып тора. Шулай ук ялгыз. Безнең мәркәз ярдәме белән ул «Татар китабы» дигән кибет тә ачып жибәрде. Сәеррәк егет. Шулай да кавышсыннар иде. Алар өчен көн жылыныбрак китәр иде сыман.

Мәйданда Тукайның «Туган тел»е яңгырый. Ләззәт тә, газап та! Мин киткәнне күреп, күңелсезләнмәсен дип, халык күзенә ташланмыйча гына куышка үтәм. Егетләр мине йокы капчыгына «киендереп», сәдәфләрне элэктерәләр һәм хәерле төн теләп, чыгалар. Кадерле исә һаман «вахтада». Аны мәйданнан алып керү — үзе бер мәшәкать.

**Көндәлекләрдән.** *14—22.11.89. Бакуда һәм Минеральные Воды шәһәрендә булып, ерак Словакия җирендә һәлак булган әтиемне җирләүдә катнашкан Бөек Ватан сугышы ветераны Тимофей Черкасов белән очраштым. Истәлекләрен язып алдым. 1984 елда «Правда» газетасында чыккан мәкаләмнән соң, ул миңа «Мин синең әтиегезне җирләгән кеше»,— дип хат язган иде. Бу хакта үзе бер китап була алыр иде...*

*Бакуда төрки халыкларының «Берлек» җәмгыятен оештыру буенча киңәшмә эшендә катнаштым. Әзәрбайҗан туганнар бу киңәшмәгә бары тик татарларны гына чакырганнар иде. Хәер, бер үзбәк туганыбыз да катнашты. Казан, Саратов, Уфа, Төмән, Чаллы, Ташкент, Мәскәү һәм Баку татар иҗтимагый үзәкләре вәкилләре белән якыннан таныштым. Татар-башкорт мөнәсәбәтләрендә Үзәкнең җимергеч сәясәте турында доклад белән чыктым. Казаннан Фәүзия Бәйрәмова һәм Габделбәр Фәйзрахманов бар иде. Аларга булган чиксез ихтирамны күреп, мин әле базларыбызда дарыбыз тәмам чыланып бетмәгәнлегенә ышандым.*

*Әзәрбайҗан-әрмән мөнәсәбәтләре буенча пленар утырышта академик Айдын Мамедов һәм шагыйрь Рза Хәлил чыгыш ясады. Хәлил кардәш — Муса Җәлил шигырьләрен әзәрбайҗанчага тәрҗемә иткән кеше. Ул Җәлилнең берничә шигырен яттан укыды.*

*Без «Апшерон» кунакханәсендә яшәдек. Киңәшмә делегатлары Бакуда миллион кеше катнашлыгындагы митингта булды. Миллион кеше... әйтүе генә җиңел. Моны күрү — үзе бер манзара. Халык диңгезенең чигенә чыгып булмый. Ары — Каспий диңгезе. Соңыннан бу митингтан фотосурәт «Огонек» журналында басылып чыкты. Мин әзәрбайҗан милли хәрәкәтенең массовый рәвештә оешканлыгына хәйран калдым. Митинг кичке сәгать алтыда башланды. Сәгать бишләрдән айлы яшел байраклар астында тыгыз рәтләр белән халык ташкыны агыла торды. Алар завод һәм оешмалардан шулай бердәм җыела икән. Алтынчы яртыда инде йөзләгән гектарны билә гән мәйданда энә төшәрлек тә урын юк иде. Менә трибунага милли*

*хәрәкәт җитәкчелегенең түбәндәге өченче эшелоны, унбиш минуттан икенче эшелоны белән без — кунаклар да күтәреләбез. Биш минуттан Милли мәҗлес рәисе Илчибәй күтәрелә. Ул безнең һәммәбез белән күрешеп чыга. Мәйдан кул чаба, мәйдан айкала-чайкала... Татарстан һәм татар халкы исеме чыгу белән ул диңгездәй актарыла һәм байраклар дулкыны чынлап та диңгезгә барып тоташа... Монда Фәүзияне яхшы беләләр һәм ихтирам итәләр. Аны бары тик татарча гына сөйләттеләр. Бу чынлап та тетрәткеч чыгыш булды. Аны тыңлаганда татар милләте үстерә алган шундый лидерыбыз — аеруча хатын-кыздан! — булуына горурланмый мөмкин түгел иде. Фәүзия бер-ике сүз әйтү белән миллионлы мәйдан «Азатлык! Азатлык!» «Татарстан! Азатлык!» дип сөрән сала... Караңгы төште. Әлегә Вәзиров утырган Әзәрбайҗан ҮКның гранит бинасыннан прожекторлар мәйданны айкый башлады. Саратовтан килгән Бибарсов хәзрәтнең чыгышы нәкъ менә шул ак-кара буталган мәлгә туры килде. Аның һәр сүзе империягә каршы ядрә иде. Шундый сәяси белемгә ия булган яшь муллаларыбыз күбрәк тәрбияләнсә иде!..»*

Капчык эчендә җылы икән шул. Тән изри, әмма йокы килми. Тагын да «Туган тел» яңгырый. Мегафонга җырлаучының тавышы күмәк җырны боза. Нишлисең, Башкортстан хор капелласы килсә яхшырак булган булыр иде дә бит. Килми. Филармония артистлары килсә дә, яхшы булган булыр иде. Килмиләр. Алар — ике милләтлеләр. Үзем язганча:

Андагының кубесендә ике паспорт:
Өйдә — татар, ыслужбада — асаба башкорт...

Мин башкорт җыр-музыка сәнгате һәм аны тудыручылар турында уйланам. Бармы ул башкорт җыр-музыка сәнгате? Йә хода, нишләп булмасын ди сәнгать — халык, милләт үзе булгач?! Бөек җырчылар Мәгәфүр Хисмәтуллин? Сөләймән Абдуллин? Рамазан Йәнбәков? Тагын кемнәр? Эзли күңел, эзли. Композиторлар Заһир Исмәгыйлев, Хөсәен Әхмәтов. Саф башкортлар. Тагын кемнәр? Телисеңме, теләмисеңме, милләте татар булып, социализм шартларында, татардан ясалган Башкортстан шартларында, бер милләт икенчесенә хезмәт итәргә мәҗбүрләнгән кысаларда телгә татар фамилияләре сикерә һәм бу феноменаль күренеш бер гүзәл җинаять булып күзаллана. Башкорт опера һәм эстрада сәнгатенә нигез салучыларның берсе — мәшһүр Габдрахман Хәбибуллин. Томский татары. Сандугачларыбыз Әсмә Шәйморатова. Бану Вәлиева — атаклы Фәхри Насретдиновның сеңлесе. Мәгъфирә Сәлигаскәрова. Сәлих Хөснияров — Актаныш татары. Хөсәен Мәҗитов — Ишембай татары. Зәки Мәхмүтов — Гафури татары. Камил Вәлиев — Зианчура татары. Башкорт опера сәнгатендә бердәнбер колоратур сопрано Зөлфирә Фәрхетдинова. Галия Солтанова — Салават районыннан татар кызы. Тәлгать Сәгыйтов. Радик Гәрәев — Яңавылдан. Җырчы һәм композитор Нәзир Әбдиев — Кырмыскалыдан. Легендар Даһи Бакиров — Дәүләкәннән. Рудольф Нуриевне телгә алмый буламы?! Тагын да дистәләгән, хәтта йөзләгән татар егетләре һәм кызлары... Әгәр сез ирекле шартларда үз туган сәнгатегезгә хезмәт итә алган булсагыз, сез ничек кенә үсмәс идегез дә, сәнгатебез ничек кенә үсмәс иде?!

Башкорт профессиональ җыр музыкасына нигез салучы Солтан Габәши. Борай районының Чалкак авылында сөргендә үлә. Ул шунда җирләнгән. Каберен зиярәт кылдым. Солтан Габәшинең шәкерте композитор Камил Рәхимов. Салкын февраль төнендә хастаханәдә минем кулымда үлде. Теге хәтәр заманнарда Бөрҗән якларында сөргендә була. Вафатыннан соң мин аңа багышлап шигырь дә язган идем...

Мөлаемнәрдән мөлаем, нечкәләрдән нечкә композитор Рәүф Мортазин. Сагынычлы җырлар авторы һәм кабатланмас баянчы Таһир Кәримов. Мәшһүр Бәхти Гайсин. Берничә ел эчендә бөтен төрки дөньясын иңләп алган һәм, кысымнарга түзә алмыйча, Г. Сәлам премиясе таныклыгын һәм «Башкортстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дипломын Югары совет өстәленә томырган Рим Хәсәнов... Күпме алар тугандаш башкорт милләтенә сәнгать бүләк иткән, әмма гел кыерсытылып көн күргән татар талантлары?! Кемгә кирәк бу «оптимистик трагедия»?

Инде башкорт эстрадасына килсәк? Төрки дөньясының сирәк таланты Фәридә Кудашева. Мостай Кәримнең, Сәйфи Кудашның авылдашы. Соңгысының ике туган сеңлесе. Кабатланмас аһәңле Илфак Смаков — Чакмагыш татары. «Их, егетләр, кайчан килер икән авыз тутырып татарча җырлар чаклар?» — дип, авыр

чиргә сабышып, илле яшендә тормыштан китеп барган Флүс Гәрәев — Краснокамадан. Башкорт эстрада сәнгатендәге тоталитаризмга каршы фетнә күтәреп, филармонияне ташлап чыккан һәм аерым татар бригадасы оештырганы өчен яңа эзәрлекләүләргә дучар ителгән Фән Вәлиәхмәтов — Шараннан. Фәннең көрәштәше — баянчы һәм жырчы Салават Әхмәтов. Илфакның хатыны жырчы Асия Смакова. Тавышы искиткеч үзенчәлекле аның. Бүгенге башкорт эстрадасының күренекле вәкиле жырчы Шамил Хәмәдинуров — Мишкәдән. Рейхстагка беренче булып байрак кадаган Гази Заһитовның якташы.

Ридель Фәтхиев — Балтачтан. Әлфия Хәсвәлиева — Учалыдан. Фәйрүзә Нуриева. Айсылу Солтанова — Уфадан. Лена Гәрәева. Фәдис Гәниев — Борайдан. Лилия Букеева — Нефтекамадан. Әлмирә Солтанова — Чакмагыштан. Рәис Вәгыйзов — Минзәләдән. Барлык филармония татарлардан тора түгелме? Әле мин яшьләрнең күбесен белмим. Танылган алып баручыларны онытканмын. Римма Дашкина. Фәрит Шәйхетдинов — Туймазыдан бугай. Гөлзәмия Ситдыйкова — Тәтешледән...

Нишлик соң, Тукай? Син Уфага кымызга дип кенә килеп киткәнсең дә бит... Безгә монда яшәргә, балалар үстерергә кирәк. «Сабах» китапханәсендә әрҗәләр өстендә черем итүең хакка чыкты. Без, күсе сыман, әрҗәләр астында көн итәбез, маржалар кулы астында ми черетәбез. Ә менә «Сабах» китапханәсе урнашкан бинага Башкортстан хөкүмәте истәлекле таштакта куярга рөхсәт бирми. Украин Микола Бажан, Максим Рыльскийга бирә, чех Ярослав Гашекка, ниндидер немец Вольфка бирә, ә менә кулына «Әлифба», күңеленә шигырь биргән Тукайга рөхсәт итми дә куя — и вчү тут!.. Тагын да Сибгат Хәким хәтергә төшә:

> Тынгысыз чат, тынгы бирмәс җанга,
> Үзем тынгач, шушы чат тынар,
> Тукай тавышы, кычкыра күк Тукай,
> Бер генә сүз яңгырый: саттылар...

Күңелдә тагын күпме исемнәр-фамилияләр!..

Башкортстан хор капелласының яртысын урыс-маржалар, яртысын татар егет һәм кызлары тәшкил итә. Ә җыр исә «башкортча» яңгырый... Вата-җимерә җырлыйлар. Аһ, алданган башкорт сәнгате! Кайда синең үз көчләрең? Кайда алар, чәчкә атарга хокуклары булмыйча, гарипләнеп, сәнгатьтән киткән, эчкечелеккә, чиргә сабышкан, кайбер очракларда үзләренә үзләре кул салырга мәҗбүр булган милләт талантлары? Кем җавап бирер?

**Көндәлекләрдән.** *«06.06.93. Уфадан хәбәр килеп җитте: Илфак Смаков вафат булган... Хәлем бетеп китеп, таш диварга утырдым. Чаллы урамыннан, минем яннымнан бер егет үтеп бара. Коеп куйган татар.*

*— Илфак Смаков үлгән, туганым,— дим кайгымны уртаклашырга тырышып.*

*— Кем ул? — ди замандашым.*

*Социалистик татар-башкорт дуслыгы җимеше Илфак Смаковның кем икәнен белми. Соңыннан аңлашылуынча, аны күп кенә «язучы» исемен йөреткән бәндәләр дә белми булып чыкты.*

*Илфак Смаков... Кабатланмас тавыш иясе. Башкорт җырында яңа бер чорны алып килгән горур шәхес. Ул сәхнәдән татарча җырларга бик тырышты, хәтта җырлады да — әмма аны сындырдылар... Беренче хатыныннан уңмады. Аерылды. Баласы калды. Эчүгә сабышты. Асиягә өйләнгәч, аларның тормышы рәтләнеп китте. Үзем фатирсыз булсам да, кеше өчен сүзем үтәрлек заманда, Өлкә комитетына хат язып, җитмешенче еллар уртасында мин аларга фатир алып бирергә ярдәм иттем. Ярата идем мин Илфакны. Характерларыбыз да бер чама иде кебек... Әмма аны сындырдылар. Минем олы кызым Илсөярне, әле тугач та, Илһам Шакиров, икенчесен, Зөлфияне, дүрт айлык чагында булса кирәк, Илфак Смаков күтәреп яратканнар иде. Ике сөекле җырчым...*

*Уфадан «Кызыл таң» да килеп җитте. Рәсми некролог биргәннәр хәтта. Үлгәч яратырга бездә осталар инде. Ярый әле, «бер төркем иптәшләре» түгел. Бөтен җитәкчелек кул куйган: Рәхимов, Әюпов, Әминев... «...Башкортстанның халык артисты Илфак Смаков 53 яшендә кинәт вафат булды...» Хуш, дускай. Вакытсыз киткән корбаннарның чиге син генә түгел...»*

*Башкорт тудырмаган-үстермәгән генә түгел, башкорт мохитен җанына сеңдермәгән, телендә тәрбияләнмәгән, иң мөһиме, башкорт милли аңын һәм психологиясендә иманга китмәгән һәм аның өчен гаепләп булмаган «башкорт» язучылары белән эш ничегрәк тора? 1977 елда башкорт һәм рус телләрендә чыккан «Совет Башкортстан язучылары» дигән җыентыкта вафат һәм исән булган 160*

*язучы теркәлгән. Аларның сиксәне татар. Мин үзем татар дип белгән, әллә кайчан вафат йә һәлак булып, милләтләре ягыннан ачык түгелләрне мин анда кертмим. Шулай ук анасы, атасы татар булган метисларны да кертмим. Мәсәлән, күренекле драматург Азат Абдуллин. Әнисе — татар. Үзе гамәлдә урысча яза. Мәскәүдә яши. Газыйм Шафиков. Кыргызстанда туган. Урысча укыган. Урысча яза. Башкорт массаларында татарны куралмаучылык тәрбияләүче идеологларның берсе. Мин аны башкорт язучылары исәбенә кертәм. Исемлектә 16 урыс язучысы. Саф башкортлар 40—50 дән артмый. Зур иseме булган әдипләр алар арасында, кызганыч ки, юк сирәк.*

*Татарча китаплар чыгару тыелганга күрә, «башкорт» язучысы булып киткән әдипләр. Әхвәл коллары. Үзләренчә бер гаепсезләр. Соңгы елларда язучылар берлеге шактый яшәрде. Талантлы башкорт яшьләреннән яңа буын каләмкярлар килде. Бу куанычлы күренеш. Әмма язучылар берлегенә алганда һаман да милли дискриминация чолтәре аша үтәсең: бер алганда, гадәттә өч башкорт, ике (йә бер) урыс, бер татар алына. Әмма ул паспорты буенча, гадәттә, «башкорт» була...*

Колаклар тынып калды. Мәйдан бушады бугай. Менә Кадерле дус та килеп керә һәм, валидол кабып, су белән йотып җибәрә.

— Сәгать ничә, Кадерле?

— Уникенче ярты...

— Ятарга иде сиңа... Саклар тәртиптәме?

— Хәзер ятам. Бүген төнгә сакта Җәвәд Мәһдиев төркеме...

Кадерле үзенең «хөлләләренә» төренеп ята. Ул башта авыр тын ала һәм, ниһаять, тын алышы тигезләнеп, йокыга тала. Без бер-беребезне аз, бик аз белә идек. Ике көн эчендә мин аны яратып өлгердем. Дөрес, кайчакта ачык мәсьәләләрне яңадан ачыкларга тырышып вакытны сарыф иткәне өчен кыздырып та алгалыйм. Ул минем «карахтерны» белә, шуңа күрә һич кенә дә ачуланмый. Мин көн нәтиҗәләрен барлыйм. Икенче көн дә үтте. Авыр көн. Кызыклы көн. «Кешеләргә үпкәләмә,— дип тәкърарлыйм мин.— Алар да синең кебек каһәрләнгән система коллары. Җитмеш ел ватканны төзәтү өчен ике йөз ун ел кирәк булачак. Әйе, татар милләтенең революциядән соң югалткан иң сөйкемле сыйфатларын кире кайтару өчен кимендә ике йөз ун ел кирәк булачак. «Минем «өч таган» теориясе буенча, төзү — җимерүгә караганда уртача алганда өч тапкыр авыррак...

Иң мөһиме — без хатын-кызны боздык. Шәхсән таркаттык. Эмансипация уены уйнап чыгырдан чыккан хатын-кыз хәзер үзе дә нишләргә белми. Ир-ат бозылса, ир-ат гаиләдән китсә, әле гаилә таркалмый да, бозылмый да. Ә хатын-кыз бозылса, йә гаиләдән китсә, бик сирәк гаилә генә үзен саклап кала ала. Гаилә таркалса — дәүләт таркала. Безнең дәүләтнең аякка басуы бик шикле. Чөнки без хатын-кызны яңадан учак хуҗабикәсе итү турында уйламыйбыз да. Безнең дәүләтнең аякка басуы бик шикле. Чөнки башка милләтләр өчен урыс укыту системасы — дөньяда иң милитаристик, иң утилитар, иң артта калган система. Гүяки ул идиотлар тәрбияләү өчен уйлап чыгарылган. Ир-ат укытучы мәктәптән китте. Мәктәпкә ир-атның каты кулы һәм акылы кирәк. Болай да таркалган хатын-кызларыбыз гаиләдә ир балаларны ихтыярлы спартаннар итеп тәрбияли алмый, киресенчә, ир баладан хатынша әвәли... Йокларга иде. Ничек итеп бу мине эшләүдән туктатып торырга? Бер... ике... өч... Мин йөзгә кадәр саныйм. Әмма йоклап булмый. Кайчандыр мин Жан Жак Руссоның «Фәннәр һәм сәнгать турында фикерләр» дигән трактатын укыган идем. Аның шундый сүзләре хәтергә сеңеп калган: «Мин хатын-кызның йогынтысында үзеннән-үзе килгән явызлык бар, дигән фикердән ерак торам. Мин аңа кешелек бәхете хакына табигатьтән бирелгән бер бүләк итеп карыйм, чөнки максатка яраклы итеп юнәлтелсә, бу йогынты явызлык микъдарына тигез итеп изгелек тә иҗат итә алган булыр иде. Адәмнәр әле кешелекнең яртысы өстеннән хакимлек итә ала торган бу икенче яртысын яхшырак тәрбияләгән хәлдә, моның җәмгыятькә никадәр файда китерәсен аңлап бетерми. Хатын-кызлар да ир-атны ничек итеп күрәсе килсә һәм ничек итеп тәрбияләсә, алар шундый булып калачак. Әгәр сез алардан җан бөеклеге һәм изгелек дәгъва итәсез икән, хатын-кызны иң әлек шул изгелек һәм җан бөеклеге төшенчәләрен аңларга өйрәтегез...»

**Хаттан өзек:** *«...Сезнең «Азатлык» радиосыннан «Милләт һәм сәер мәгърифәт» дигән чыгышыгыздан соң, шул минутта ук, күңелдә утка-суга керерлек дәрт туды. Мин инде карт кеше — 68 яшьтәмен. Яшьләрне, сабыйларны ничек саклап калырга?!*

*Барысы да хатын-кыздан башлана. Ир-егетләрне дә ул тәрбияли бит. Айдар энем. Ахыргы елларда безнең Сенбергә Татарстан районнарыннан бик күп халык килеп урнашты. Иң әлек нәрсә күзгә бәрелә? «Акны күрдем — акайдым» дигәндәй, авылдан килгән егетләр һәм кызлар, бәрелеп, дөньясын онытып, урысча гына сөйләшергә тырыша. Ата-аналар балаларын бары тик урысча гына укыта. Әгәр: «Балаларыгызга тәре такмый торып, мәктәпкә алмыйбыз», — дисәләр, иртәгәдән тәре тактырып килячәкләр. Яңа гына килеп урнашкан яшь егетләр, кызларның психологиясе: шартларга җайлашу, урвать от жизни все любой ценой. Милләт турында уйлаганнары да бары тик корсак һәм ашказаны тирәсеннән чыгып кына уйланалар — ә ул, милләт, миңа нәрсә бирә?*

*Шулай бер мунчага бардым. Анда яшь кенә татар хатын-кызлары юына. «Кызлар, сез кайсы районнан?» — дигәч, сезгә безнең нинди районнан булуыбыз нигә кирәк, дип, баңкаларын авызларына күтәреп, сыра эчә башладылар. Сыра эчәләр дә, тагын чабынырга кереп китәләр... Сөйләшергә дә кеше юк. Автобус тукталышларында еш кына исерек, әдәпсез татар хатын-кызларын очратырга туры килә. Бездә, мишәр арасында, бу хәлләр юк иде әле... «Руслан» мәдәният сараенда, бер спектакль тәнәфесендә, иске мәчетне кайтарып алу буенча имзалар җыям. Сез кул куймассызмы, дигәч, әби: «Атла моннан, без — коммунистлар», — диеп куып җибәрде, икенчесе: «Мин җитәкче кеше, миңа ярамый», — дип тупас рәвештә кире какты... Татарстан читтәге үз татарлары өчен җаваплы булырга тиеш...*

*Суфия Тимербулатова, Ульян каласы.*
*18.06.93».*

Мин йокыга талам шикелле. Бер мәлне дөнья яктырып киткәндәй була — өнемме, төшемме? — мин күземне ачам — әйе, алдымда гүзәл хатын-кыз сыны.

— Мин синең туган йортыңның иясе булам, — ди сылу хатын. — Минем исемем Сөекле. Хәленне белергә килдем. Исәнлегең ничек?

— Әйбәт, — дим мин. — Килүең өчен рәхмәт. Мин сине көтә идем. Өйдәгеләр исән-саумы? Мал-туар тазамы?

— Исән-саулар. Мине нигә котәргә, мин бит һәрчак синең белән бергә. Сине беркайчан да ташлаганым юк. Хәтереңдәме, синең ашыңа ничә тапкыр агу салдылар? Мин аны синнән ашатмадым. Хәтереңдәме, сиңа өч яшь чакта, әниең Минсорур бәрәңге утаучы хатыннарга Кәркәле елгасы буенда аш пешергәндә, чыбыкка абынып егылып, пычакка кадалган идең?

— Хәтеремдә, ничек хәтердә булмасын? Яра эзе ияк астымда әле дә бар!

— Сине коткарып калучы мин бит ул. Хәтереңдәме, 1945 елның зәмһәрир суыгында яланаяк тышка бәләкәй хаҗәт артыннан чыгып, кергәндә ишек ача алмыйча ике аягыңны да туңдырган идең?

— Хәтердә, ничек хәтердә булмасын! Ишекне ача алмагач, өйдә паралич белән урын өстендә яткан картәтәйдән башка беркем дә юк — мин кире карлы ишек алдына чыгып, ат чанасының канатына кунакладым. Күпме торганымны хәтерләмим. Шунысын хәтерлим — бар дөнья миңа зәңгәр булып күренә башлады...

— Синең күзләрең шунардан зәңгәр...

— Мәктәптән кайтып килүче күршебез Ниязир абый күтәреп алып кергән мине... Аңа гел рәхмәтләр укыйм...

— Аны синең янга мин җибәргән идем. Миңа бит күренергә ярамый...

— Рәхмәт инде сиңа, Сөекле!.. Минем аякларым өрелеп шеште. Тезләремдә генә шуыша идем. Миңа, еламасын дип, танклар, пушкалар төшкән елтыр сугыш лотерейларын бирәләр иде... Шул хакта миңа шаһәдәтнамә язып бир дип, Ниязир абыйга ничә тапкырлар инәлдем, Сөекле. Сүз бирә дә, үтәми. Ул хәзер Уфада яши. Бездән ерак түгел...

— Әйе, «Хрусталь» кибете артында...

— Ул ифрат изге җанлы, алла бәндәсе кеше. Соңгы вакытта бик тә эчә башлады. Хатыны марҗа булса да, бик әйбәт үзе. Әмма балалары татарча белми...

— Әгәр дә мин аның йорт иясе булсам, мин аны коткарган булыр идем. Бездә, йорт ияләрендә, мафия дигән нәрсә юк. Сиңа килгәндә, мин сине гомереңбуе коткара килдем. Дошманнарыңны беләсең, дусларыңны белеп бетермисең. Дусларың арасында дошманнарың күбрәк. Сак бул дусларыңнан. Сабыйсың. Беркатлысың.

— Шагыйрьнең сабыйлык — беркатлылык түгел.

— Аңлыйм. Синең дошманнарың сабыйлыгыңны беркатлылык дип аңлап, еш кына яналар. Шулай да, ашыңны карап аша, суыңны карап эч, ярыймы? Ходай Тәгаләбез сакланганны саклармын, дигән... Син, фил булсаң да, энә күзеннән үткәреләсең. Йорт-жирең, почмакларың, ясаган адымың күзәтелә...

Тавыш ерагая... Гүзәл сын томанда эри... Мин упкынга очам...

Һәм ниндидер шыгшуга уянып китәм. Сәгать ничә икән? Командир сәгатенең укларын караңгыда күрмим. Кадерләне уятасым килми. Кайдадыр Октябрь революциясе урамы тарафында эт җылый... Йөрәкләргә төшеп кенәләр эт җылый!..

Бервакыт, әни минем тәмәке көйрәтүемне сизеп алып, болай дигән иде:

— Атаң фронтка: «Үзем тарттым, әмма улларым тәмәке тартмасын!» — дип васыять әйтеп китте, ә син, мәхәббәтсез, шушы яшеңнән көйрәтә башладыңмы?!»

«Мәхәббәтсез» безнең авылда, халыкта иң әшәке сүгенү сүзе иде. Мин бик гарьләндем, инәй алдында гафу үтендем, әмма унбиш яшемнән, качып-посып, куначадан урланган йомырка исәбенә пыскытуны ташлый алмадым. 1988 елның августында Сергей Баруздин һәм СССР Оборона министрлыгының Генераль штабы ярдәме белән мин һәм гаиләм унбиш көн Чехословакиядә булып, Зволен шәһәрендә җирләнгән әтиемнең каберен зиярәт кылдык. Мин аның алдында васыятен үти алмаганым өчен гафу үтендем...

Менә бүген дә, кешеләрдән оялып, калтыранган кулларым белән мин тәмәке кабын ачтым... Хуш исле сигарет чыгардым... Их, бер-ике генә суырырга... Ач ашказанына — тәмәке? Бер генә суырсам? Яртылаш кына суырсам? Юк, суырмыйм да, кабызам гына, ә? Әйдә, кабызып кына карыйм, ә? Шайтан котырта бит... Мин үземне аклар сәбәп тә таптым. «Юньсез кеше белән очрашу да юньсез юлга тарта». Һәм бу дөрес тә иде. Кем салган минем кесәгә «Мальборо» тәмәкесен?! Бу нинди сихер тагын? Очраклы абзыйдан шырпы сорап сигаретны кабызам һәм тирән итеп суырам... Көлеп җибәрәм. Рәхәт булып китә... Ходайдан ярлыкавын үтенәм һәм, ничек кенә зарарлы булмасын, күңел тынычлыгы өчен, үземә сирәкләп кенә, берничә тапкыр суырып кына, тартырга рөхсәт итәм...

Мин урынга кереп авам. Кадерле дә ял итә. Куыштан чыгып, егетләргә беркемне дә үткәрмәскә кушам.

— Йөрәк авыртып тора, малай, — ди Кадерле. — Дару каптым әле...

— Син күп бәхәсләшәсең, Кадерле. Кирәкмәс иде...

— Үземне шартлатасы килә, малай...

Без тынып калабыз.

...Чатырыбызга Әхтәм абзый Вәлиуллин килеп керде. Ул минем авылдаш. Кәркәләләр теле белән әйткәндә, «акбәкәт Әхтәм». Илленче еллар башында аның исеме безнең авылда гөрләп торды. Кырыгынчы еллар азагында, биш баласы белән бәләкәй арбага җигелеп, Урта Азиягә чыгып киткән иде әниләре Өммегөлсем түтәй. Әхтәм абзый авылда беренчеләрдән булып югары уку йорты — Дүшәмбе университетының юридик факультетын тәмамлады һәм эшкә Уфага кайтты. Ул авылдашыбыз Фатыйма түтәйгә — безнең чыбык очы Миннәхмәт мөәзин кызына өйләнгән иде. Миннәхмәт мөәзин, заманның бик тә алдынгы, укымышлы кешесе, утызынчы елларда гаиләсен алып, шулай ук Урта Азия якларына чыгып гая... Әхтәм абзыйга Ходай Тәгалә зур сынаулар алып килде: абруй булгач, игътибар, ашау-эчү, мал-акча муллан йөрде. Юристларның рухын җимергән төп чир — клиентлардан вакытында чумырып калу аның җанына да үтмәде түгел, үтте. Кайчандыр татарлык, тукайлык рухында, укымышлылардан укымышлы Өммегөлсем абыстай һәм хәлле Ибраһим мәхдүм гаиләсендә тәрбияләнгән Әхтәм абзый да тора-бара советчылыкның җимергеч көченә каршы тора алмады: эчкечелеккә сабышты, балалары күз-колактан еракта, иркендә тәрбияләнде. Алар урыс телендә генә сөйләште. Фатыйма түтәйнең шикаяте аркасында Башкортстан адвокатлар коллегиясенең җаваплы секретаре Әхтәм Вәлиуллин эшеннән алынды. Алар аерылыштылар. Хәзерге көндә абзыебыз икенче җиңги белән яшәп ята. Әммә аны балалары бик ярата. Гомумән алганда, искиткеч кызыклы, белемле, башлы һәм ярдәмчел кеше ул...

— Мәйданга чыктың инде?

— Әйе, Әхтәм абзый. Килүеңә рәхмәт, — дим. Үзем уйлыйм: гаделлек өчен көрәшче булырга тиешле юрист нәрсә әйтер? Татар мәктәбендә белем алып, кеше булган авылдашым нәрсә әйтер? Тукай алдында тәүбәгә килү тойгысы чагылмасмы? Балаларының һәм оныкларының киләчәге алдында үзен гаепле сизмиме?

— Нигә кирәк булды инде бу? — ди якташым. — Без бит — башкортлар.

— Башкорт булгач, нигә минем белән татарча сөйләшәсең?

— Без башкортлашканбыз.

— Ул чакта Бүздәк районындагы бердәнбер башкорт авылы Каныы-Төркәй нигә гасырлар буе татарлашмый? Җитмәсә, башкорт әдәбиятына классиклар бирә... Йөзләгән татар авылы арасында бер башкорт авылы.

Әхтәм абзый — номенклатур тойгы кешесе. Ул алдана һәм алдашканлыгын белә. Күрәм, җавап таба алмый, җәфалана.

— Безгә башкорт булып йөрү выгоднырак...

Менә шундый хәлләр. Икейөзлелек алдан планлаштырып куелган. Инде нәрсә сөйләшергә? Без салкын гына хушлашабыз. Мин урынга ятып жылыйм. Без Әхтәм абзый белән якын туганнар да. Аларның фамилиясе дә Хәлимов булырга тиешле, әмма әтиләре Ибраһим абзый утызынчы еллар башында, билгеле сәбәпләр аркасында, фамилиясен үзгәртә. Үзе, мәрхүм, сугышта һәлак булып кала. Төбе-тамыры белән кубарылып, авылдан чыгып киткәч, аларның карагайдан төзелгән сарай кебек йорты озак еллар буш торды. Тирә-ягыбызның Ак әбисе Өммегөлсем абыстай кызларының балаларында — Урта Азиядә кышлап, җәйләрен туган якта үткәрә торган булды. Ниһаять, Уфага алдан кайтып төшкән Әхтәм абзый үзенең дүрт ир туганын Башкортстанга тартты. Әмма аларның берсе дә туган авылга кайтмады, дип әйтер идем, башта Әхнәф, аннан Хәниф абый авылда яшәп матапты да, озакламый Уфага чыгып тайды... И бу тормыш... Нәрсә таптылар? Фатирлары бармы, ичмасам? Йөрәкләре кайда? Нәрсәне югалттылар? Илләрен, телләрен югалткан, урыс белән никахлашкан балалар... Өммегөлсем абыстай житмешенче еллар азагында Уфада шәһәр мунчасында таеп егылып үлде. Мәетне моргтан алып чыгуда мин дә катнаштым. Авылга алып кайтып җирләделәр. Туганнар ел да җәйләрен авылга кайтып, аның рухына Коръән укыталар... Менә бит нишләде безнең белән большевизм: туган җирне, туган милләтне, телне, динне кирәкмәс итте. Шулай итеп, без аксөяктән — тирес кортына, укымышлы, зыялыдан — надан карасөяккә, шомпеига әверелдек. Нигә бу хакта язам? Кемгә кирәк? Үземә урын таба алмаганга язам.

**Көндәлекләрдән.** *17.11.69. Ленинград һәм Казан татарларына юлны көнбатыштан беренче булып Финляндия татарлары ачты. Илһам Шакиров җитәкчелегендәге концерт бригадасы анда барып кайткач, бу бәйләнешләр тагын да көчәя төште. Югыйсә, без бит милләттәшләребезнең кайдадыр чит мәмләкәтләрдә дөнья көтеп ятуларын күз алдына китерә алудан да мәхрүм идек. Инде бу бәйләнешләр өзелә генә күрмәсен иде, Ходаем... Миңа алда хат ята. Аның авторы — Финляндиянең Тампере каласында яшәгән татар Гайсә Хәкимҗан. Кайчандыр гасыр башында гаиләләре белән эмиграциягә киткән «малай» еллар аша менә ничек сагына... Тетрәткеч хат бу. Шигъри хат. «Тукай һәйкәленә карап» дип атала бу мәктүп. Кириллицада язылган.*

Кызыл гөлләр үссен матур булып,
Яңгыр дымы белән ярсылып.
Йитешсеннәр алар, чәчәк атсын.
Синең һәйкәлеңә сарылып.
Йир шарының төрле почмагында
Тукай шигырьләре яңгырасын.
Таш өстенә койган ташка басып,
Һәрбер таңда кошлар сайрасын.
Җырларыңны җырлыйм диәр идем,
Кара туфрагыңны үбәр идем,
Синең һәйкәлеңне коча-коча.
Шунда күз яшемне түгәр идем...
Гайсә Хәкимҗан.»

**Истәлекләрдән.** *Июнь, 1974. Уфага Америка Кушма Штатларыннан «Туризм һәм ял» исемле күргәзмә килде. Журналист сыйфатында күргәзмәгә мин дә бардым. Күрәм, бер төркем татар апа-әбиләре экскурсовод кызны уратып алганнар. Ә ул татарча гына белә, урысча бөтенләй белми икән. Без танышабыз. Нью-Йорктан татар кызы. Гүзәл Сәлахова, америкача — Сала. Кич белән алар урнашкан «Россия» кунакханәсендә кыска вакытка очрашу турында сөйләшеп аерылышабыз. (Шунысы кызык, американ күргәзмә турында безнең газеталарда яздырмадылар.)*

*Артыннан шымчылар күзәтүен һәм безнең сөйләшүнең Гүзәл ханым нумерында тыңланып барачагын белсәм дә — киттем. Ул мине бик тә җылы каршылады. Булган сөйләшүне төкми-чәчми укучыларыма җиткерәм:*

*— Гүзәл ханым, әни-әтиләрегез кайда эшли?*

*— Әнием өйдә генә тора, әтием Нью-Йоркта йортлар идарәсе мөдире.*

*— Безнеңчә управляющий була инде?*

*— Белмим. Мин урысча белмим. Мөдир инде...*

*— Сез ничек шулкадәр чиста итеп татарча сөйләшергә өйрәндегез?*

*— Әти-әниләр балачак чактан ук өйрәттеләр. Әгәр без энем Ринат белән үзара инглизчә сөйләшсәк, йә булмаса алардан берәр нәрсәне инглиз телендә сорасак, алар безгә җавап та бирми һәм сөйләшмиләр иде...*

— *Нәкъ безнең илдәге кебек икән...— Мин елмаям.— Ринат эшлиме, укыймы?*

— *Укый. Нью-Йорк университетының сурәтчелек бүлегендә өченче сыйныфта. Укыган җирләре Нью-Йорктан читтәрәк бер калачыкта...*

— *Нью-Йоркта татарлар күпме?*

— *Күп түгел. Бер өч йөзләп гаилә бардыр.*

— *Моны ничек аңларга?*

— *Һәр татар фатирында бары тик җомга көнне генә ачыла һәм Коръән укыла торган бүлмә бар. Без шуны мәчет дип атыйбыз.*

— *Әгәр авырга алмасагыз, мин Сезгә истәлеккә «Казан утлары» журналының үземнең шигырьләрем басылган күптәнге санын тапшырыр идем. Башка бернәрсәм дә юк, Гүзәл ханым...*

*Ул журналны игътибар белән актара.*

...Әхтәм абзый белән очрашу, Америкадагы берничә мең татар белән бары тик Башкортстандагы миллион ярым татарның үз алларындагы рухани җаваплылыкларын чагыштырып карау мине менә нинди истәлекләргә этәрде. Авыл... Бәләкәй Кәркәле... Диндардан диндар, эчкерсездән эчкерсез, шаяннан шаян, эшлекледән эшлекле Бәләкәй Кәркәле... Әле илленче еллар азагында авылда исерек, ачыктаначык тәмәке тарткан кеше әдәпсезгә санала иде. Кайвакыт төннәрен мин авыл башыннан үзем чыгып киткәннән соң вакытсыз китеп барган яшьтәшләрем, ир уртасы кешеләрне саный башлыйм. Авыл соңгы сугышта алтмыш кеше югалтса, соңгы егерме ел эчендә аракыдан һәм йөгәнсезлектән кешеләр күбрәк һәлак булган.

**Укылган китаплардан өстәмә фикерләр.** Унынчы гасыр башларыннан Киев Русенә үтә башлаган яһүд элементының гасырлар буе ничек итеп сәүдә һәм аракы житештерү индустриясен үз кулына төшерүе һәм славяннарны, алар аша башка күрше милләтләрне эчкелеккә батыруы турында яһүд тарихчысы Юлий Гессен менә нәрсә яза: «В численном отношении евреи по деревням и селам не занимали видного места, составляя напр., по Полоцкой губернии менее 2 процентов. Но по роду своей деятельности, окруженные несвободным крестьянством, они играли важную экономическую роль — в их руках сосредоточивалась торговля, они брали в аренду различные статьи помещичьих доходов, продажу водки в шинках (эчкеханәләрдә — А. Х.). Завися от помещика, евреи были вынуждены эксплуатировать в пользу дворян-землевладельцев — труд крестьянина, а также пускать в продажу среди крестьян назначенное помещиком количество водки, чем способствовали распространению пьянства. Когда местная администрация предписала (1783 г.) помещикам не отдавать винокурения ни на откуп, ни в аренду лицам, не имеющим на то права, «особливо жидам», помещики этому воспротивились... Помещики продолжали отдавать евреям на откуп винные промыслы. Это было их право». (Юлий Гессен. «История еврейского народа в России». Москва. 1925—26. 72 бит.)

Мин милләт кадәр милләткә каршы эшләнгән җинаятьне эзәрлекләп барам.

**Көндәлекләрдән. 4—10 июнь 1991.** Вакыйгалар тыгыз. Уфа—Чаллы—Түбән Кама—Мәскәү—Минск—Вильнюс—Каунас—Мәскәү—Казан—Чаллы—Уфа маршруты буйлап «Книга печали» китабын туган илгә алып кайтып житкердек. Каунас типографиясендә конвейердан машина әрҗәсенә агылган китап бәйләмнәрен күреп җыладым. Типографиядә очраган һәр кешегә китап таратып чыктым. Шундук Вильнюска кайттык. Анда татар җәмәгатьчелеге кечкенә презентация тантанасы һәм Вильнюс татар җәмгыяте житәкчесе Адам Асанавичюс квартирасында аш-су мәҗлесе үткәрде. Адамның хатыны Ульян татары Фәридә ханым бик тәмле итеп бәлешләр пешергән иде.

Вильнюс әле һаман фронтовой хәлдә. Телебашня һәм телестудия биналары әле һаман совет гаскәрләре сагы астында. Танклар, танклар, танклар. Телебашняга һөҗүм вакытында һәлак булган көрәшчеләр каберен зиярәт кылдым. Алар арасында, Адам Асанавичюсның якын туганы, татар кызы да бар. Литва Югары Советы бинасы чәнечкеле тимер чыбык, ком тутырылган капчыклар белән уратылган. Аны милли гвардия саклый. Телестудия бинасын совет гаскәрләреннән азат итү өчен Литва патриотлары сәяси ачлык игълан иткән. Ярты көнемне алар белән үткәрдем. Телләктәшлек күрсәтеп, радиодан татарча һәм урысча чыгыш ясадым. Моны Литва татарлары житәкчесе Менсәид Байрашевский оештырды. Китапны чыгарган «Мокслас» нәшрияты житәкчелеге үтенече буенча безне — мине һәм редакция мөдире Антанас Балашайтисны — Литва Югары Советының мәдәният буенча комиссиясе рәисе Геримантис әфәнде кабул итте. Без Литва хөкүмәтенә бөтен татар милләте исеменнән зур рәхмәтләр әйтеп, «Книга печали или Записки аборигена» басмасының әле буяу исе дә китеп өлгермәгән нөсхәсен тапшырдык. Шундый ук рәхмәтләр белән Югары Совет

Рәисе Витаутас Ландсбергис әфәндегә автограф белән бергә бүләк итеп тагын да егерме китапны кабул итүен үтендек. Ул бу үтенечләрне зур теләк белән үтәячәген әйтте...

Вильнюс татар җәмгыятенә бүләк итеп — биш йөз, Мәскәүгә — бер мең, Казанга — ике мең, Чаллыга биш мең китап калдырып, без унында төн карасында Уфага кайтып кердек...

11.06.91. Шофер Нияз белән ял да итеп тормыйча, без кире Чаллыга юл тоттык. Татар җәмәгатьчелеге мине яңа журналга баш мөхәррир итеп сайлатып куяу өчен ут капкандай ашыга. Нәрсәгә? Серен һич аңлый алмыйм. Миңа кадәр дә штатлары була торып, журналны ике ел буе чыгара алмаганнар икән, нигә бер атна тын алырга да ирек бирмиләр? Һаман да шул сәер татарлыкмы? Барам, әмма милләт хакына гына. Гомер буе кыйналып, инде тынычлап язып ятам дигәндә, миңа нәрсә җитми?

Кичен Чаллы язучылар оешмасы җыелышы булды. Шәһәр хакимияте вәкиле Фәйрүзә ханым Мостафина да катнашты. Алар мине, мин аларны белмим. Әмма өч кешедән — Казаннан Рахмай китерткән Газинур Вәлиев, Чаллыдан Рәфис Сәлимҗанов — берне — мине сайлап куйдылар. Күптәнге танышым, Чаллы Язучылар оешмасын җитәкләгән Рахмай Хисмәтуллинның кызарынган йөзенә карыйм. Аңа бу юлы да көч килгән, әлбәттә. Нәкъ егерме ел элек мин, аның аркасында, Татарстанны калдырып киткән идем. Кем уйлаган?! Нәрсә бу, өнме, төшме? Бер генә тавыш белән өстен чыктым бит. Рахмай каршы булды. Чынында исә һич кенә дә өстен чыгуымны теләмәгән идем.

12.06.91. Иртән сәгать сигезгә безне шәһәр советы рәисе Рәфкать Алтынбаевка баш мөхәррир итеп раслану йоласына чакырганнар иде. Безгә бер сәгать чамасы көтеп торырга туры килде. Күп тә үтми, кабул итү бүлмәсеннән тирләп-пешеп, Рахмай Хисмәтуллин һәм Газиз Кашапов килеп чыга — Газиз мәрхүмнең авыр туфрагы җиңел булсын! (Алдан әйтеп куям: үзенең илле яшен каршыларга, мин Чаллыга күченергә йөргән көннәрдә Газизнең китеп баруы мине бөтенләй ушсыз һәм ятим итте. Минем белүемчә, егермегә якын «рәсми» язучы исәпләнгән Чаллыда ул — каләмдәшем шагыйрь Кадыйр Сибгатны да кушып — берничә бөртек чын иҗатчының берсе иде... Үләреннән берничә көн элек ул мине бакчасына алып барды, дусларының мунчасында юындырды. Машинада барганда һәм кайтканда, аннан бигрәк дачада, миңа нәрсәдер әйтәсе, бик җитди әйберләр житкерәсе килде, әмма ул сүзләр әйтелмәде, күрәсең, минем тарафтан кызыксыну житешмәгәндер). Әйе, татар хәрәкәте җитәкчеләрен һәм мине иртән иртүк шәһәр советында күреп, Рахмай югалып кала. Әмма ул андыйлардан түгел:

— Сиңа кул бирмим! — ди, ягъни Вахит Имамовка сайлауда минем кандидатураны яклап тавыш биргәнә өчен кул сузмый, имеш.

— Ә менә сиңа бирәм! — ди, монысы миңа, ягъни булачак баш мөхәррир Айдар Хәлимгә, имеш.

Бер тиен тормаган сарай интригалары. Монда кайгы журнал чыгаруда түгел икән. Монда кайгы — вазифада. Хакимлектә. Бу инде милләтне үстерү өчен көрәш түгел, милләт артына ышыкланып, милләттәшне батыру өчен көрәш икән. Соңыннан билгеле булуынча, алар, мине раслаттырмас өчен, Алтынбаевка керә, аннан үзенең якташы булган Татарстан Президентына телефоннан чыга... Була бу сөйләшү. Әмма безнең Президентның үз башы бар шул.

Ул гына да түгел, миңа каршы басылган төрле мәкаләләр Алтынбаев өстәленә кертеп салына. Ә минем күңелдә һаман борчылу: «Нәрсә, тагын кыйнатырга алып киләләрме?»

Менә без Алтынбаевта. Коңгырт йөзле, туры гәүдәле, бик тә мөлаем кеше. Кыяфәтендә авыл егетләренә хас ягымлылык. Әмма ул — сәяси җитәкче. Журнал алдында торган бурычлар турында сөйли. Мәдәни мәсьәләләр буенча урынбасары Фәйрүзә ханым Мостафина кичәге сайлауларның нәтиҗәсен житкерә. Монда Рахмай нишләптер юк. Ул бит монда беренче булып утырырга тиеш. Соңыннан, әлбәттә, барысы да аңлашылыр. Миңа сүз бирәләр. Мин кыска гына сүземдә күрсәтелгән ышанычны аклау өчен бөтен көчемне бирергә ышандырам.

— Егетләр, сәгать ничә? — ди Алтынбаев.

— Биш минуттан тугыз, — диләр татар хәрәкәте җитәкчеләре.

— Хәерле сәгатьтә!

Һәм Алтынбаев алдында яткан кәгазьгә кул куя...

*1993—95. Чаллы*



# ЛЕНА ШАГЫЙРЬҖАНГА 50 ЯШЬ

Лена Галимҗан кызы Шагыйрьҗан (Шакирҗанова) — әдәбиятыбызда нык-лы урынын тапкан, заманча көчле-кыю һәм нәфис-нечкә фикри куәте, матур сурәтләре белән кызыклы үз шигъри дөньясын тудырган, чын мәгънәсендә профессиональ шагыйрәләребезнең берсе, үзенчәлекле лирик дип шикләнмичә әйтә алабыз.

Шагыйрә Актаныш районы Пучы авылында туа, Сибгат ага Хәким туган Күлле-Кимедә (Әтнә районы) үсә, шунда урта мәктәп һәм Казан педагогия институтын тәмамлагач, укытучы, Татар Дәүләт җыр һәм бию ансамблендә җырчы-артистка, Татарстан радиокомитетында тәрҗемәче булып эшли. Яшьтән үк — җыр-моң юлында булу, шигърият белән югары белем, эрудицияне куша алу һәм тормыш сәхифәләре — болар барсы да аның иҗатында да чагыла.

Әле мәктәптә укыганда ук «Яшь» журналында шигырьләрен бастырган яшь шагыйрәнең исеме 1960—70 елларда көндәлек матбугатта еш күренә, 1977 елда «Кызлар җыры» исемле күмәк китапта зур шәлкем шигырьләре дөньяга чыга. Ә инде сиксәненче елларда аның «Мөлдерәмә күңел», «Ышанам йөрәгемә» исемле шигырь китаплары басылып чыгып, әдәби җәмәгатьчелектә танылу тапты. 1993 елда исә «Иман әлифбасы» исемле китабы дөнья күрде. Бу китап та шигъриятебездә вакыйга буларак каршыланды. Быел, юбилей мөнәсәбәте белән дә аның сайланма характердагы китабы чыгачак дип беләбез.

Шагыйрәне — журналыбызның күптәнге авторын — юбилее белән котлап, бу санда укучыларыбызга аның төрле елларда иҗат иткән шигырьләреннән бер бәйләм тәкъдим итәбез.

# Лена Шагыйрьҗан

## ТӨРЛЕ ЕЛЛАРДАН

### Шагыйрь кызлар

Шагыйрь кызлар, дисез, нинди була,
Шагыйрь кызлар алар төрле була.
Карашлары тирән, серле була —
Җидесендә җитмеш төрле уй...

Кошлар телен белеп сөйләшәләр,
Җилләр белән калып серләшәләр,
Йолдызларга җырлар өләшәләр —
Җидесендә җитмеш төрле көй...

Салават күперләрен кичәләр, ди,
Әкият иленә дә күчәләр, ди,
Сусаганда... шигырь эчәләр, ди —
Җидесендә җитмеш төрле сер...

Эч серләрен җырга салалар да,
Эчкерсез саф булып калалар, ди —
Ал таңнардан илһам алалар, ди —
Җидесендә җитмеш төрле җыр...

*1978*

### Үземә кайтып төштем

Тагын кайтып төштем үземә,
Мин үземне үзем сагынып.
Ничәнче кат инде адашып,
Ничә тапкыр инде абынып.

Ялыктырды чит-ят гадәтләр,
Гарык итте ашы-табыны.
Бушка узган күпме сәгатьләр,
Ятлар почмагына табынып.

Кайтып төштем тагын үземә,
Арып-талып, әмма бушанып.
Соңгы кабат, бүтән китмәскә,
Үз-үземә тәмам ышанып.

Ахры кайтып төштем үземә,
Сусап, сырхаулардан арынып.
Ятсынасыз, беләм, үзем дә
Мин үземне көчкә таныдым...

*1973*

## Бер кыз бар...

Көлә-көлә акты ак ташулар,
Елый-елый карлар эреде.
Бии-бии кайтып керде язлар,
Җир яңадан яшьнәп терелде.

Йолдызлардан сирень исе аңкый,
Сиреньнәрдә көлә йолдызлар...
...Китәлмичә шушы яз иленнән
Җырлар эзләп йөргән бер кыз бар...

Ул киткән дә булыр иде инде,
Суыныр иде күптән эзләре.
Итәгеннән тартып яз җилләре
Җибәрмичә тора үзләре...

Йөрсен әле, йөрсен урамнарда,
Туймагыз сез аннан, кумагыз.
Тәрәзәгез аша бакса үрелеп,
Пәрдәгезне тартып куймагыз.

Балкып йөрсен шунда язгы төндә,
Ай нурына манчып чәчләрен.
Чык тамчысы булып яфракларга
Кунып калыр таңда яшьләре.

Адашсын ул кереп яз иленә,
Сүз әйтмәгез моңлы ул кызга...
...Йолдызлардан сирень исе килә,
Сиреньнәрдә — көлә йолдызлар...

*1984*

## Зар

Йә, ходаем, күрергәме
Бирдең миңа бу күзләрне —
Ал бүрекле бүреләрне,
Битлек кигән куш йөзләрне?..

Йә, алла, бу нинди бәла,
Бирдең миңа гүзәллекне:
Мәкер дигән шомлы шәүлә
Гел артымнан эзәрлекли...

*1970*

## Ялгыш кына

Ялгышып, бер күзләреңә күзем салдым —
Төнсез калдык шуннан бирле, көнсез калдык...
Иңнәреңә ялгыш кына башым салдым —
Ниләр эшлик, башсыз калдык, ашсыз калдык...

Ялгыш кына колагыңа бер сүз салдым —
Икебез дә телсез калдык, өнсез калдык...

*1973*

* * *

Пешеп өлгергән чагым —
Кайчак ялгыш адым ясап,
Кеше көлдергән чагым...

Яшен уйнаткан чагым —
Артык туры әйтеп ташлап,
Нәфрәт уяткан чагым...

Инде еракта чагым —
Һәр җырымда мине сагынып,
Һәр юлымнан мине танып,
Дусны елаткан чагым...

*1976*

## Күзге җәй

Их, күзләрнең — кышка түгел,
Җәйгә ялганган чагы...
Күлмәклек ефәкләр алдым,
Сабан туй көтеп тагын...

Нинди ут — озакка түгел,
Ә яна ялкынлырак.
Нинди моң — колакка түгел,
Ә җанга якынрак...

Тыңлап кал инде, бер генә,
Тыңлап кал, тагын кил дә!
Әллә яфрак, әллә йөрәк
Талпына сары җилдә...

Бу — күзләрнең — кышка түгел,
Җәйгә ялганган чагы...
Күңелнең, шуңа ышанып,
Юри алданган чагы...

*1981*

## Үзе чакырып алыр

Дускай, нишлик, әллә дим
Монда калабызмы?
Әллә инде яшьлеккә
Кире кайтабызмы —
Дәшеп торган чагында
Кайнар кайтавазы...

Әйт, синеңчә кайда без
Кирәгерәк икән?..
Кайда безнең кебекләр
Сирәгерәк икән?..
Әллә йөгереп үтикме
Калган чакрымнарны —
Бик теләсә яшь гомер
Үзе чакырып алыр...
Әйдә, очыйк еракка
Икәү канатланып,
Сагынсак та үткәнне,
Бүтән кабатламыйк.
Сүндермәсәк йөрәктә
Дәртле чаткыларын,
Яшьлек безне, кирәктә,
Үзе чакырып алыр...
*1980*

## Кем бәхетле дөньяда?

Кем бәхетле дөньяда:
Игенче иген иксә,
Олаучы атын җиксә,
Юлаучы барган җиреннән
Исән-сау кайтып җитсә —
Шул бәхетле дөньяда.
Балыкчы балык тотса,
Балтасын тотса оста,
Мәңгелек сүз әйтсә шагыйрь,
Булса да җыры кыска...
Кем бәхетле дөньяда? —
Җырчы җырлап туймаса,
Рәссам төсен җуймаса,
Көзе җитмәс борын агач
Яфракларын коймаса...
Шул бәхетле дөньяда —
Кем кешегә елмая,
Кайгы килсә, җиргә түгел,
Айга карап моңая...
Шул бәхетле дөньяда —
Кемгә газиз Ил-Ана,
Кем тормышның кадерен белә
Һәм үзенә инана!..
*1979*

## Нәкъ минем кук...

Нәкъ минем кук, беркөн
арырсың да,
Туктап калырсың да юлыңнан,
Мәгънә тапмый сукыр бер тиенлек
Бар булганың белән югыңнан,
Шаккатырсың...
Бераз читкә чыгып,
Куып җиткәннәрен күтәрсең...

Куып житеп, узып китсәләр дә,
Китмәс исең... Инде бүтән син...
...Аңа хәтле әле шактый ерак...
Янарсың да әле, көярсең...
Ә бер көнне, искә төшереп мине,
Әйткән иде аны, диярсең...
Нәкъ минем күк, селтәп кулың гына
Бар булганың белән югыңа,
Акрын гына югалырсың кереп,
Язган шигырьләрең юлына...
Нәкъ минем күк,
җырларыңнан бигрәк,
Ул көн житкәч, Җирне сөярсең...
Үз-үзеңне тыңлап, мине уйлап,
Әйткән иде аны... диярсең...
Нәкъ минем күк, инде яңага да,
Искегә дә исең китмичә,
Шул ук фани дөнья җырын җырлап,
Китәрсең син — барып житмичә...
*1993*

### Чәчәк җыры

Үләм, бетәм, дигәндә дә
Тылсым табып, терелəм мин.
Ничәнче кат инде, янә
Мәхәббәткә бөредә мин...

Ә болытлар җилләр белән
Сүз берләшеп куйган мыни —
Килә ява, килә ява —
Чиләкләрдән коя мыни.

Ачылырга һич юк ирек,
Төшми якты, салкын җиле.
Бөреләрем туңар инде,
Ышыкламый кем дә килеп.

Әрәм иттең. Ишетмичә
Калдың тагын чәчәк җырын...
Ярый әле тамырымда
Ага иде кояш нуры...
*1982*

### Һай, бер гомер генә житәмени...

Һай, бер гомер генә житәме соң
Йөрәктәге сөю хисенә?!
Терелермен кебек үлгәч тә мин,
Мәхәббәтем төшеп исемә...

Һай, бер генә гомер житәме соң
Күңелдәге безнең моңнарга?!

Калсаң икән мәңге бу дөньяда
Былбыл сайрауларын тыңларга...

Һай, бер гомер генә җитәме соң
Һәммәсен дә әйтеп бирергә?!
Ниләр генә эшләп китим икән,
Килер өчен кабат бу җиргә?..

*1989*

## Газап

*(Г. Мистральгә ияреп)*

Ничә еллар инде, күкрәгемә
үткен хәнҗәр булып кадалган
канлы шигырь, бирми тын алырга...
Ярдәм сорыйм кемнән, кайлардан?..

Давыл вакытында үрә баскан
диңгез дулкыннары шикелле,
алар минем күңел ярларына
ярсу атлар булып сикерде...

Мин буйсындым аңа. Сүзнең әмма
бөеклеге алды йокымны.
Иреннәрем каный, чәйнәгәндә
иҗекләрнең каты токымын...

Гади сүзләр белән өреп кенә
дөрләтермен димә ялкынны!..
Алтын юучылар белә аны —
арындырган комнан алтынны...

Ул канымны имә яшь бала кук.
Үзе газап, үзе сихәтле.
Бер бала да җирдә хатын-кызның
суырмыйдыр җелеген бу хәтле!

Коточкыч хәл! Язмыш биргән бүләк —
көннәр, төннәр эчкән газабым.
Тәңрем! Үзең башлап юл күрсәттен,
хәерле кыл инде азагын!..

*1993*



**Шамил Маннап**

# МОҢСУ ХАТИРӘЛӘР

## Билгесез кыз елмаюы

Һиндидер бер акыл иясе: «Адәм баласының күңелендә хосусый милекчелек хисен дөрләтим дисәң, аңа ашъяулык кадәр генә булса да җир бирергә кирәк»,— дигән, имеш. Әйе, бик дөрес әйткән. Мисалга әллә кая барасы юк, үземнән беләм. Васильево белән Атлашкино арасындагы сыек кына урман буеннан дача өчен җир алганнан бирле күңел әллә нишләде. Аунап яткан такта-токта күрсәм, әләктерә кайтам. Чүплеккә иске урындыктыр, арурак тактадыр, фанердыр, әрҗәдер ташлаган булсалар — алам. Дачада ярап куяр. Элек мондый искемоскыны үзем чыгарып ташлый торган идем, югыйсә, ә хәзер ташлау кая, һәммәсен җыям. Инде шундый «байлыктан» фатирымның аран кадәрле лоджиенда борылыр урын да калмады. Бу хәлгә хатыным Асылбикә баштарак ризасызлыгын белдереп караса да, соңыннан үзе дә мине уздырып, тегене-моны ташый башлады.

Әле менә бүген җир казып арыгач, бераз бил яздырып кайтыйк дип, дачабыз янындагы урманга чыктык. Монда да кул кушырып, бер-беребезгә карашып йөрергә вакыт юк. Күзебез, теге-бу очрамасмы дигәндәй, тирә-юньне күзли. Әнә нечкә генә каен кәүсәсе аунап ята. Кайсыдыр юньсезе, себеркегә дип, ботакларын аннан-моннан гына ботарлаган да ташлап калдырган. Урынын билгеләп китәбез. «Кайтышлый алырбыз, теплица ясаганда кирәк булыр бу! — ди хатын.— Калган нечкә ботаклары помидорларны бәйләп куярга ярар». Әнә тагын... берничә кызыл кирпеч тәгәрәп ята. Иске учак урыны. Болары — сарай нигезенә менә дигән!

Чү, мондый затлы мәрмәр плитәне кайсы бае китереп ташлаган тагы? Иһи, шактый авыр икән үзе. Әмма арба алып килсәк, хатын белән икәү ничек тә өстерәрбез әле. Плитәне җирдән кубарып, икенче ягына әйләндереп салган идем, имәнеп киттем. Ташның кыеклатып киселгән почмагыннан миңа яулыклы бер кыз елмаеп карап тора иде. Бу хәлгә аптырап, хатынга карыйм. Аның, киресенчә, күзләрендәге елмаюы сүнгән, йөзенә моңсу күләгә яткан.

Мин яшел үлән сабакларын йолкып, шулар белән плитәне сөрткәләгәч, елмаеп торган кыз сурәтенең астына ташны уеп язылган сүзләрне

аермачык күрдем. «Сабирова Мәгъмүрә Әхмәр кызы. 1934—1955 санә» һәм шунда ук ике юллык шигырь:

Үлгәннәрнең каберен бел,
Исәннәрнең кадерен бел!

Үлгәннәрнең каберен бел... Ә бу каберне онытканнар, күрәсең... Шуңа да карамастан, якты дөньяда нибары егерме бер ел яшәп, җир куенына кергән бу матур кыз һаман елмаеп тора... Үлгәннәр үпкәли белмидер, күрәсең. Мәрхүмә шушы тирәдәге берәр авылдан булгандыр инде. Авыллары йә таралып беткән яки, «перспективасыз авыл» дип, башка урынга күчергәннәрдер. Ә менә зират күченмәгән. Ул калган. Чардуганнар ауган, җир белән тигезләнгән, кабер өсләренә утыртылган агачлар гөрләп үсеп киткән дә кечерәк әрәмәгә әйләнгән... Каберләр онытылган... Ә бәлки онытылмаганнардыр, бу кызның якын туганнары үз сеңелләрен яисә сөекле апаларын һаман да хәтерлиләрдер, тик дөнья куып, бирегә килергә, ауган чардуганны торгызып, туганнарының моңсу елмаюлы йөзен сөртеп китәргә вакыт тапмый торганнардыр. Бәлки, башка сәбәпләре бардыр...

Менә үземнең дә Кама аръягындагы ерак бер авылдагы газиз әти, әни, сөекле Кечкенә апам каберләрен кайтып күрергә, зиярәт кылырга күптән инде вакыт таба алганым юк түгелме соң?! Минем апамны бит чәчәк кебек вакытында сугыш еллары кыравы суккан иде. Ул барлы-юклы киеме белән, ач-ялангач килеш дүрт-биш чакрымлы күрше авыл мәктәбенә укырга йөрде. Абыйга булышырга дип, бәләкәй чана тартып, урманга утынга да бара иде. Шуннан кайткач: «Тирләгән килеш утырып ял иткән идем, йокымсырап киткәнмен. Утын кисү белән мавыккан Кечкенә әзи дә мине онытып җибәргән. Уянып китсәм, агач кебек катканмын, шундый туңганмын, әни!» — дип, әрнеп әйткән сүзләре әле дә хәтеремдә. Шуннан соң ул шактый авырып ятты. Аннары терелгәндәй булып, укуын дәвам итте. Үзенең кулы, вакыт-вакыт нинди дер җайсызлык сизгәндәй, иңбашы аша аркасына сузылып, шунда тукталып кала торган иде. Җылы вакытта да, аркам туңа, дип, кәҗә мамыгыннан үзе бәйләгән шәлен ябынып утырыр иде. Ул укуда да бик тырыш, эшкә дә бик уңган, чирак кыз иде. Сәламәтлеге шәптән булмаса да, яшьтәшләреннән калышырга теләми, җәйге каникул вакытларында, бигрәк тә урак житкәч, колхозга төрле эшләрдә булышып йөри, йә ындыр табагында ашлык җилгәрешә, йә басудагы чабылган борчакны әйләндереп-әйләндереп киптерешә.

Фаҗига буласы көнне дә Кечкенә апа, иптәш-дус кызлары белән тырма күтәреп, борчак басуына киткән иде.

Алар көне буе баш түбәсендә янып торган кояш кызуын сулап, борчак теземнәрен әйләндереп йөриләр. Үлеп эчәселәре килә, телләре беләүләнеп, аңкауларына ябыша. Күзләрен мөлдерәтеп, авыл ягына карап-карап алалар, мәгәр кайтып китәргә ярамый. Әнә, Имәнсәр буенда кара айгырына атланган колхоз рәисе Әслах абыйлары күзәтеп тора.

Айгырның да нинди әле: кеше талый торганы! Ат караучы Хәмәтьяр абзыйны бернича тапкыр җилкәсеннән умырып, башы аша ташлаганы бар. Ат караучыларны да куркытып, дер калтыратып торган бу юньсез Иблис пырагы-аты, ни гаҗәп, рәиснең үзеннән генә курка иде... Аның камчысы бик зәһәр иде шул.

Әнә ул кызларга да: «Тизрәк кыймылдагыз!» — дип, кулындагы шушы зәһәр камчысын һавада болгап куя. Шулай да, төштән соң, түземнәре төкәнә кызларның. Алар, көтүчене тыңламаган кырыкмыш тайлар кебек, күтәрелеп, авылга йөгерәләр. Кызлар чаба, алар артыннан атка атланган рәис чаба. Кызлар, арган-талган булуларына карамастан, җан-фәрманга элдертәләр. Әмма рәиснең яллы бүре сыман айгырын узып буламыни? Әнә генә Әслахның арттарак калган кызыйларны чаж-чож иттереп камчы белән пешергәне ишетелә!

Ниһаять, кызлар, югары очтагы Габделлатыйф абзыйлар бакчасына житеп, шунда агачлар арасына чумалар. Рәис чыбыркысыннан котылу дигән сүз инде бу, чөнки Габделлатыйф абзыйның бакчасы үзе кечтеки бер урман шикелле ул. Урман булгач, чишмәсе дә бар инде аның. Кызлар шул чишмәдән туйганчы сап-салкын су эчәләр, тирләп-пешкән битләрен, муеннарын юалар. Рәис Әслах бакча киртәсе буенда сүгенгәләп йөри-йөри дә, кулын селтәп, китеп бара. Үзе күрмәсә дә, кызлар аңа тел күрсәтеп, үртәп-көлеп калалар. Тынычлап, тагын учлары белән көмеш суга үреләләр. «Әй, яратам да соң шул, Габделлатыйф абзыйлар чишмәсенең суын! Мин бит чәйгә дә суны гел шуннан китерәм...» — дип, мактый-мактый, рәхәтләнеп эчә апам. Ләкин бу рәхәтлекнең үзенә әҗәл угы булып кадаласын белми шул ул...

Кечкенә апамның, каты салкын тиеп, тәннәре ут кебек кызышкан хәлдә авырып ятуы, көтмәгәндә шаулатып кан косуы, ике атна чамасы үлем белән тартышуы һәм, керосины беткән лампа шикелле, таң алдыннан тетрәп сүнүе гомергә онытылмаслык әрнү булып, бәгыремә уелып калган... Мин беренче мәртәбә үлемнең ни икәнен шул вакытта аңладым, газиз кешеңне югалту хәсрәтен, ятимлек ачысын беренче мәртәбә шунда кичердем. Кечкенә апам — мине җырлый-җырлый бишектә тирбәтеп үстергән туганым, урамда ата казлардан, усал малайлардан яклаучым иде бит. Кечкенә апа дисәм дә, ул минем өчен зур иде. Район сабан туйларында да, башка яшьтәшләре белән күңел ачыйм әле, дип, мине олау янында калдырып китмәс, кулымнан җитәкләп, төрле кызыклар күрсәтеп йөрер, ашыйсым килгәндә соңгы кисәген миңа бирер иде. Аның: «И энем, нигә син кыз булып кына тумадың икән?..» — дип, миңа яулык бәйләтеп караулары, шомырт кара чәчләрен туздырып, Тукайның Су анасы булып кыланулары, минем куркып калуымнан кәефе килеп, башын артка ташлап, шаркылдап көлүләре — барысы да бүгенгедәй күз алдымда...

Мин янә кабер ташыннан моңсу гына елмаеп карап торучы кыз сурәтенә текәләм. Күземә чыккан яшь элпәсе аша ул җанлы булып, иреннәре хәрәкәтләнгән кебек күренә. «Әйе, апаң сине ничек яраткан, ә син аның мәңгелек йортын зиярәт кылганың бармы соң?» — дип сорый шикелле ул миннән. Ни әйтим, еллар узган саен туган төбәккә кайтулар сирәгәйде шул. Бигрәк тә әти-әни вафат булганнан соң. Соңгы кайтуымда апам каберенең агач рәшәткәсе инде туза башлаганын күрсәм дә, яңартып торырга вакыт табалмадым. Казна эше белән берничә көнгә генә кайткан идем шул... Инде минем Кечкенә апамның каберендәге чардуган да шулай авып-түнеп, тузып-таралып ятмый микән? Әх! Ә мин менә дача җирен рәшткәләү өчен такта-токталар җыеп йөрим...

Бу дөньяның фанилыгы, алдаучанлыгы турында күп укыганым да, еш ишеткәнем дә бар, югыйсә. Билгесез мәрхүмә алдында миңа бик уңайсыз булып китте. Карашымны янә хатыныма күчердем. Ул да исәнкә-уйга калгандай тын гына басып тора.

— Әйдә, кайтырга вакыт...— диде ул, кемнедер уятудан курыккандай әкрен тавыш белән.

— Әйе шул, кайтырга кирәк... Кайтырга...

Без кайтыр юлга борылдык. Дачабызга ала кайтырбыз дип карый килгән «төзелеш материаллары» онытылды. Билгесез кыз кабере яныннан болай да күп нәрсә алып китеп бара идек без... Шуның өчен дә адымнарыбыз салмак-басынкы, башларыбыз аз гына иелгән иде...

## Скрипка ни әйтә?

Аның исем-шәрифен дә, кайсы авылныкы булуын да хәтерләмим инде. Аны без Скрипкачы бабай дип кенә атый идек. «Скрипкачы бабай килгән!» — дигән хәбәр ишетелүгә, Түбән очка — кибет яны-

на йөгерә идек. Чөнки ул, кеше күп йөри торган урын дипме икән, кибет янына туктала, кибет белән колхоз идарәсе арасындагы мәйданчыкта яшел чирәм өстенә утыра да, скрипкасын сыздырып җибәрә. Тагын шунысы: аның борыны юк, борын урынында алсуланып ике тишек кенә күренеп тора иде. Беренче дөнья сугышында әсирлеккә эләккән дә, нимесләр кисеп алганннар, ди борынын. Кайсыбер кеше, төче ашаган, имеш, дип тә әйтә. Ләкин борыны булмау, ничектер, аны кимчелекле итеп күрсәтми, бик табигый кабул ителә, хәтта ки, скрипкачылар нәкъ менә шундый, борынсыз булырга тиешледер кебек тоела иде безгә. Хикмәти хода, скрипкасына кушылып җырлаганда әнә шушы ике алсу тишектән чыга торган авазлар, ничектер, аның уенына аерым бер төсмер бирә, ярдәм итә кебек иде. Хәтта скрипка моңы да аның әнә шушы борын урыныннан чыгадыр сыман.

Скрипкачы бабай еш килми. Күрәсең, ул башка авылларга да баргалыйдыр. Аны соңгы күрү, соңгы кат тыңлау аеруча хәтердә калган. Сугыш вакыты иде бу. Язгы ташудан соң, юллар ачылгач та, килеп чыкты. «Скрипкачы бабай килгән!» — дигән сөрәнне ишетүгә, мин дә абыйга ияреп, кәнсирт карарга киттем. Без кибет янына килеп җиткәндә, скрипкачы бабай үзен урап алган халык уртасына баскан килеш (утырырга әле җир юеш иде), үзе уйнап, үзе җырлый иде инде:

Германнар туп аталар,
Крипесне ваталар.
Кайсы аяксыз, кайсы кулсыз,
Кычкырышып яталар.

Халык тын калып тыңлый. Ак альяпкычлы җиңгиләрнең йомшарган борыннарын лышык-лышык тартып куюлары гына ишетелә. Шунда кемдер: «Их, бичаракайларым!..» — дип өзгәләнеп куя. Арадан кайсыдыр: «Вәт маладис, бабай! Шәп әйттең, афәрин!» — дип дәртләндерә.

Скрипкачы бабай моңланган, хәсрәтләнгән вә нәфрәтләнгән гавәмне бераз ял иттерим, кәефен ачып алмыйм дип микән, күңеллерәк җырларын әйттерә башлый:

Скрипкам тарый-тарый,
Тарый булса да ярый.
Кая безгә матур кызлар,
Хатын булса да ярый.

Сыер сука сукалый,
Бозау тырма тырмалый.
Яз җиткәнен шуннан беләм:
Кызлар артын боргалый.

Халык күтәрелеп көлә. Яшь кызлар да чырык-чырык көлешеп: «И-и, оятсыз!» — дигән булалар. Бабай шундыйларның берсенә күз кысып ала да, җырын дәвам иттерә:

Скрипкамның кыллары
Борыла-сырыла башлады.
Кая барсаң да тол хатын,—
Күңел аза башлады.

Аннары бабай авыз эченнән генә хикмәтле бер җыру әйтеп куя:

Калхуз каз ала микән,
Сәвит тары ала микән?
Казы да юк, тарысы да,—
Кайдан табарга икән?

Каз ала — кадала, тары ала — тарала булып ишетелгәнгә, бу җырдан да тыенкы гына көлешеп алалар. Скрипкачы бабай кәнсиртенең ахырына якынлашты бугай, болай дип җырлады:

Скрипка ни әйтә? —
Ун тин акча, дип әйтә.
Ун тин акча бирмәсәләр,
Кайтып китик, дип әйтә.

Чыннан да, бабаң бушка гына җырлап тормас бит инде. (Югары очның Галимҗан абый гына ул һәр кичне клубтан урам ярып, бушлай җырлап кайта.) Кешеләрнең күзе шунда гына аның алдына куелган буш эшләпәсенә төшә. Эшләпәгә өч тиенлек, биш тиенлек бакыр акчалар төшкәли. Бабаң үз бәясен яхшы белә. Шаярган булып, тешләшеп тә ала:

Биш тиен дә биш тиен,
Биш тиенгә нишлием?
Үзең карсак, дөмбер корсак, —
Синең белән нишлием? —

Нишлисең, халык үзе дә ярлы шул. Кем әйтмешли, авызын ачса, үпкәсе күренә. Скрипкачы бабай вак акчаларны алып, учында чылтыраткан булды да, бишмәт кесәсенә салып куйды. Ә скрипкасын ашъяулыкка кадерләп төреп, куенына яшерде һәм тамашачылары белән саубуллашып, күрше авылга таба кузгалды.

— Яңадан кил, безне онытма, Скрипкачы бабай! — дип озатып калдылар аны.

Ләкин ул безнең авылда бүтән күренмәде. Аның югалуын төрлечә гоманладылар. Кайсы, язгы ташу вакытында Чирмешәнгә батып үлгән икән, дип, кайсы берсе, авылларда совиткә каршы коткы тараткангa Себер җибәргәннәр икән үзен, дип сөйләделәр. Ни генә булмасын, Скрипкачы бабай суга төшкәндәй югалды. Әмма аның җырларын авыл онытмады, җае чыккан саен җырлыйлар иде. Адәм гомере чикле булса да, җыр үлемсез икән ләбаса. Җыр суда да батмый, утта да янмый. Җырны Себергә сөреп тә, күңелләрдән җуеп та булмый икән... Бәлки, скрипка безгә әнә шуны әйтергә теләгәндер...

## Сукыр рәнҗү

Адәм баласының рәнҗүе җирдә ятып калмый, үзен кыерсытучыга төшә, дигән сүз бар. Моның хаклыгына шикләнмим шикләнүен, әмма синең рәнҗүең үзеңне турыдан-туры кыерсытмаган кешегә дә төшәргә мөмкин икән. Мин менә шул турыда үзем белән булган гыйбрәтле хәлне сөйләп бирмәкче булам.

Ул вакытта мин яшьләр гәзите редакциясендә эшләп йөри идем. Өч кешелек гаиләм белән башта кеше почмагында, аннары уртак коридорлы бүлмәдә шактый интеккәннән соң, ниһаять, фатир алу чираты миңа да килеп житте. Нәкъ шул елда, яңа бер йорт төзелеп беткән икән, шуннан безнең редакциягә дә ике бүлмәле фатир тиячәк, имеш, дигән хәбәр таралды. Фатирның да ниндие әле: «обком йорты» дип аталганыннан! Һәм шушы «оҗмах почмагы» чират буенча миңа тиеш, имеш. Ышансаң — ышан, ышанмасаң — ихтыярың. Редакциядәге миңа карата хәерхаһ кешеләр, бу хәлдә битараф булмаска, авыз ачып калмас өчен фатир артыннан йөри башларга киңәш итәләр. Дөресен әйтим, әрсезлекне, үземә ни дә булса йолкып алу өчен эш йөртә белү сәләтен Ходай миңа җәлләгән. Шулай да берничә көн кыюлыгымны туплап, җай котеп йөргәннән соң, ниһаять, тәвәккәлләргә булдым. Мөхәрриребез белән сөйләшеп карарга. Мөхәрриребез тырышып эшләгәннәрнең кадерен белүче,

кеше гозеренә илтифатлы, иплe кеше. Шушы хәл миңа кыюсызлыгымны җиңеп, аның ишеген шакып керергә көч бирде булса кирәк. Ул салкын бүлмәдә өстенә пәлтәсен ябынып, башына бүреген кигән хәлдә, газитәгә җибәрәсе материалларны укып утыра иде. Күтәрелеп миңа карады. Күзлеген салып, бармак битләре белән арган күз кабакларын уыштырып алды. Бүлмәсе суык булса да, хуҗаның күз карашы җылы иде.

— Йә, ни әйтмәкче буласың редактор — ырылдап тор абыеңа? — диде ул, гадәтенчә, җиңелчә генә шаяртып.

— Абый, ни... безнең редакциягә бер фатир бирмәкчеләр икән дип ишеттем дә, шуны белешмәкче идем...— дидем.

Мөхәррирнең йөзе җитдиләнде.

— Шулай... Син ишеткәнсең генә. Ә менә кемнәрдер ул фатирны дәгъвалый да башладылар инде... Хәтта обкомга барып җиткәннәр.

— Соң, исемлектә минем чират лабаса...

— Анысы шулай. Белмиләр түгел, беләләр.— Ул өстәл тартмасын ачып, бер кәгазь тартып чыгарды да миңа сузды.— Менә укып кара әле.

Стандарт кәгазьгә йомры-йомры хәрефләр белән язылган. Таныш кул шикеле. Әйе, шул икән. Әфтах абый. Чү әле, нишләп ул? Әле бит ул узган ел гына ике бүлмәле фатир алган иде ләбаса. Элек үзе яшәгән бер бүлмәне редакциядәге башка иптәшкә бирделәр. Шул зарланып торган иде, Әфтах абый бүлмәсенә ремонт ясатмый китте, алай гына да түгел, түшәмдәге иске люстрасы, ишегенә куйган йозакларына кадәр акча түләтте, дип... Чү әле, бу гозернамәне язарга аны тагын нәрсә мәҗбүр итте икән? Әһә, аңа панель йортта яшәү ошамый икән. «Бетон диварлардан һава керми, үзем дә, гаиләм дә авырыйбыз, яңа төзелеп беткән һәм безнең редакциягә тәгаенләнгән фатирны миңа бирүегезне сорыйм...» — дигән.

Әйе, җитди көндәш бу минем өчен. Әфтах абый — тәҗрибәле журналист, редакциядә күптәннән эшли, биредә күпләрнең остазы ул. Дөресен әйтергә кирәк, эшли башлавымның беренче вакытларында комсомол яшьләрнең булган-булмаган сәяси укуларын килештереп язарга үземне дә ул өйрәтте ләбаса... Димәк ки, өлкә комитетында башлап аның сүзе үтәр шул инде...

Ләкин «югарыда» чишелешнең башка юлын тапканнар булып чыкты.

— Дәгъвалы фатирны бездән алып, башка иптәшкә бирәчәкләр,— диде мөхәррир.— Тик син борчылма. Тагын бер йорт өлгереп килә, хрущевка... Шуннан сиңа ике бүлмә, һичшиксез, булачак. Кайгырма, өч-дүрт ай да узмас, яңа фатирга күченерсең...

Мөхәррирнең ышанычлы вәгъдәсе беркадәр тынычландырса да, борын салынды минем. Салынмыйча. Шундый шәп фатирга ия булам дигәндә генә кулыңа коры вәгъдә тотып кал әле! Әй, үзем дә беркатлы авыл гыйбаты инде! «Обком йорты»ннан оҗмах почмагы бирәләр, имеш. Бирерләр, тот капчыгыңны! Андый җәннәткә түрәләр генә керә алганны белмиммени мин?! Әфтах абый белән минем ишеләр «өстәгеләр» мәнфәгатен яклаучы фирканең төпсез капчыгына взнос дип аталган налог түләүчеләр дә, «партия дисциплинасы» камытын киеп, йөкнең авырын тартучылар гына бит...

Мин, эчемнән генә кемнәргәдер рәнҗи-рәнҗи, әнә шулай уйландым. Әмма беркемгә дә кара коелмадым, эчем тулы ялкын булса да, төтенен күрсәтмәскә тырыштым. Чөнки болай эшләүнең эшемдәге үзара мөнәсәбәтләрне чуалтудан башка нәрсә бирмәячәген чамалый идем. Хәер, мин башлап үпкәмне белдерер кешенең, ягъни Әфтах абыйның да ул көннәрдә йөзен кара болыт каплаган һәм ул болыттан кемнәргәдер рәнҗүкаргыш яңгыры яварга әзер иде сыман...

Ләкин Әфтах абыйның холкы минекенә капма-каршы. Ул бер төрле халәттә озак торалмый. Шундук ачулана — шунда ук кайтып та төшә, әле генә җитди була, бер минут та узмый — йөзе кояштай яктырган, шаяртакөлә. Тик шунысы: ул үзенә төрттереп шаяртканны бер дә яратмый,

үпкәли һәм шундук... үпкәсен дә оныта. Фатир вакыйгасыннан соң да, бер-ике көн күзгә-башка күренми йөрде дә, бүлмәбезгә үзе килеп керде. Һәм ни ишетим:

— Теге... фатирны алган Сабирны ток сугып үтергән бит, ишеттегезме?— диде Әфтах абый төшенке тавыш белән.

— Китсәнә! Кайсы Сабирны?— дидек без, бүлмәдәшем Зоммер белән беравыздан диярлек.

— Кайсы булсын, шул — «Татарстан коммунисты»нда эшләүче егетне. Гардиннар өчен стенага кадак какканда үткәргеч чыбыкка эләккән...— дип аңлатып бирде Әфтах абый.

Тыныч кына әйтелсә дә, әлеге сүзләр миңа ток суккандай тәэсир итте. Әй, бичаракай! Мин бит ул дәгъвалы фатирны кемгә бирүләре белән дә кызыксынмаган идем. Миңа булмагач, кемгә булса да барыбер түгелмени? Баксаң, анда якташым күченгән булган икән. Сабирны мин университетта укып йөргән вакытыннан ук беләм. «Р» авазын авызында чия төше әвәләгәндәй йомрылатыбрак әйтеп сөйләшә торган бик ягымлы, әйбәт егет иде. Актив һәм булдыклы икәнен күрептер, укуын тәмамлагач та, аны комсомол комитетына лекторлар группасы җитәкчесе итеп алдылар. Аннары ул «Татарстан коммунисты» журналына баш мөхәррир урынбасары булып күчкән иде. Дуслар ук булмасак та, үзара мөнәсәбәтебез җылы гына иде. Бер очрашуыбызда ул: «Икенче кызым туу белән котлый аласың, якташ. Шагыйрь әйтмешли, хатын кыз таба да, кыз таба. Бервакыт кияүләрдә кунак булып йөриселәр бар әле...» — дип, шатлыгын уртаклашкан иде. Әй, язмыш-язмыш! Үлемне ике каш арасында гына йөри дип, юкка гына әйтмәгәннәр шул...

Әфтах абыйның үз уе икән.

— Адәм булдым дигәндә генә әрәм булган, бичара,— диде һәм миңа карап өстәде:— Тәк шту, ул фатирга эләкмәвеңә шөкерана кыл...

Мин ни әйтергә аптырап торганда, сүзгә «туры мишәр» Зоммер кушылды:

— Йок инде, парин, син үзең шөкерана кыл! Сабир урынында син булырга тиеш идең бит.

Әфтах абыйның куе кара кашлары күзлек кысаларыннан өскә, маңгаена сикереп менде.

— Нәрсә әйтмәкче буласың? Нишләп мин? Кешене ток сукканга мин гаеплемени, әкият?!

Зоммер тыныч кына дәвам итте:

— Гаепле шул, парин, гаепле. Бу эшкә синең кирәкмәгәнгә кысылуың аркасында ул фатирга кеше рәнҗүе барып урнашкан иде. Ул рәнҗү сине көткән иде, тик анда бәхетсезлегенә күрә, бер гөнаһсыз башка берәү барып эләкте. Шуны белеп тор, парин...

Әфтах абый чебен кугандай кулларын буташтырды.

— Кит, әкәмәт! Яман авыздан яхшы сүз чыгамы соң!— һәм ул, ашыгып, ишеккә юнәлде.

Зоммерның мине яклагандай әйткән сүзләре күңелемә җиңеллек китермәде, киресенчә, яңа хәсрәт уты салды. Болай булгач, якташымның фаҗигале үлемендә минем дә дәһшәтле булып чыга түгелме соң? Тик Сабирга рәнҗү минем башыма да кереп карамаган иде ләбаса. Һәм кирә дә алмый иде. Ә шулай да... Кеше рәнҗүенең кулы озын, күзе сукыр буладыр, ахры. Күрәсең, шулайдыр...

## Дуслык

Шәһәр тирәсендәге санаторийларда булган кешеләр игътибар иткәннәрдер: әлеге сихәт алу урыннарында койрыклы ял итүчеләр — песиләр һәм маэмайлар шактый очрый. Хәер, ял итүче-

ләр дип әйтү дөрес үк булмастыр,— алар, бередә даими теркәлгәндәй, яшиләр, бала үстерәләр, картаялар. Шуңадыр, күрәсең, үзләрен табиблар, шәфкать туташлары һәм башка хезмәткәрләр кебек үк табигый тоталар, кунак булып түгел, хуҗа булып йөриләр. Тик, кайбер хезмәт күрсәтүчеләрдән аермалы буларак, алар ял итүчеләргә карата бик тә ягымлы, бик тә итәгатьле мөнәсәбәттә. Шулай булмый хәле дә юк, бередә сихәт алучылар койрыклы хуҗаларга дәгъва-мазар белдерми, теге яки бу дәваны таләп итми, юк даруларны сорап аптыратмый, киресенчә, үзләре аларның күңелләрен күрү җаен карый. Ашханәдә тамак ялгап чыгучылардан мыраубикә вә алабайларга калган кәтлит кисәгедер, сөяк-санак яисә балык койрыгы ише тәм-томнар эләгә тора.

Койрыклы хуҗалар сихәтханәдәге гомуми тәртипләрне дә яхшы беләләр. Бигрәк тә ашау һәм йокы вакытын. Шул мәл җиттеме, ашханә тирәсендә урала башлый болар.

— Беләсеңме, канәт, мәчеләр алар — хатын-кыз нәүгыннан, этләр исә — ир-ат сыман, талымсыз...— дип, аңлатма бирде миңа «Крутушка» санаториенда бергә ял итүче танышым Габделбарый абый.

Абый дим, чөнки заманында сугыш мәхшәрен узып, инде җиденче дистәне ваклап килүче булса да, җиңел сөякле какча гәүдәсеме, ачык күңеллелегеме, аны шактый күркәм, яшь күрсәтә иде. Менә шул абый ял итә башлавының тәүге көннәрендә үк бер кәкре койрык белән дуслашты. Башкалары арасыннан ул нишләптер арт аягына аксаклап йөри торган юаш кына маэмайны сайлап алды. Бу этнең төсе үз мыегы кебек сары булуы җәлеп иттеме, әллә инде аның башка ишләре сыман ашханә ишек төбенә үк килеп әрсезләнмичә, моңсу гына күзләрен мөлдерәтеп, бер читтә утыруы ошадымы, аксавы кызгану хисе уяттымы, белмим. Янына килеп чүгәләде дә:

— Нихәл, Сарбай? — дип, этнең башыннан сыйпады.

Теге алабае да, күптәнге хуҗасын очраткандай, йөнтәс койрыгын болгаштырып, дуслык билгесен күрсәтте. Аның электәге исеме ничек булгандыр, кем белсен, әмма ул үзенең яңа атына да тиз күнекте. «Мине хет чүлмәк дип атагыз, тик кызган мичкә генә утыртмагыз»,— диләрме әле? Шуның шикелле, Габделбарый абыйның ашханәдән кайтышлый: «Сарбай! Сарбай!» — дип дәшүенә, культик-культик аксап, шундук килеп җитә торган булды. Бу абыйның ягымлы тавышы да, кәгазьгә төреп китергән күчтәнәчләре дә, «Аша, аша тартынма»,— дип, башыннан сыйпаштырып куюлары да күңеленә бик хуш килә Сарбайның. Ул, койрыгын рәхмәтле болгый-болгый, алдындагы ризыкны бик тиз ялмап бетерә дә: «Ай-һай, тәмле булды бу, тагын юкмы соң?» — дигәндәй, яшькелт күзләрен мөлдерәтеп, Габделбарый абыйсына карый.

— Йә-йә, нибарына канәгать бул, күп ашасаң, йөгергәндә авырга килер үзеңә,— ди мәрхәмәтле абый, чал керә башлаган җиз мыегын боргалап.

Йөгерү димәктән, Габделбарый абый, һава хәленең нинди булуына карамастан, һәр иртәдә урман юлыннан сигез-тугыз чакрымны урап кайта, шунда Сарбайны да үзе белән ала. Бергәләшеп йөгерә алар.

Санаторийда булу мөддәте тәгәлләнер алдыннан Габделбарый абыйның дүрт аяклы дустына булган илтифаты-кайгыртуы тагын да арта төште. Ул еш кына:

— Мин киткәч, бу мәхлук нишләр инде? — дип, уфтангалый башлады.

— Яңа килүчеләр арасында синең кебек мәрхәмәтле адәмнәр булмый калмас әле, иншалла,— дип, юатырга тырышам мин аны.

Габделбарый абыйның какча йөзен янә елмаю нурлады:

— Беләсеңме, канәт, хайваннар белән дус булуның саулыкка да файдасы бар бит. Хәтта ки, аларны сыйпау да кешене тынычландыра. Әнәтерә, дәвалаучы песиләр турында гәзитләрдә дә яза башладылар.— Ул, нидер исенә төшкәндәй, иңбашыма кагылып алды.— Карале, канәт, соңгы вакытта Сарбайга игътибар иткәнең бармы синең, ә?

— Нигә? — минәйтәм.— Берәр хәл булдымы әллә?
— Булды шул. Әйдә, күрсәтәм...
Ул мине үзебез торган өченче бинаның кояшлы ягына алып чыкты.
— Сарбай, тихий час тәмам! — дип эндәште ул.
Бина эргәсендә сары йомгак булып бөгәрләнеп яткан маэмай елтыр кара танавын күтәреп, йөнтәс кашлары астыннан елт кына карап алды да янибызга йөгереп килде, дустының аякларына сырпалана, иркәләнә башлады. Хәтта ул, ап-ак казык тешләрен күрсәтеп, елмая да шикелле иде.
— Күрдеңме, канәт? Күрдеңме, нинди егет булды безнең дустыбыз?
Күрмимме соң? Сарбайның элеккеге йолкыш туны шомарган-матурайган, гәүдәсе елгырланган-җитезләнгән, ә иң гаҗәбе: ул инде хәзер аксамый диярлек.
Габделбарый абый, мыек астыннан елмая-елмая, сүзен дәвам итте:
— Минем карчыкка да күрсәтәсе иде Сарбайны. Юкса, картаймыш көнеңдә бала-чага кебек йөгереп йөрүдән нинди хикмәт табасыңдыр, дип битәрли ул мине. Менә Сарбайның йөгерә-йөгерә төзәлгән ялары аягын күрсә, хикмәтнең нидәлеген үзе дә аңлар иде. Шулаймы, Сарбай дус?
Сарбай, сүзнең ни турында икәнлеген аңлаган шикелле, йөнтәс койрыгын болгый-болгый:
— Һау-һау! — дип, өреп куйды. Гүяки ул: «Шулай, шулай!» — дип әйтергә тели иде.

## «Мин болай гына да...»

Элекке заманда ярлы-ябагайлар совет властеның ышанычлы терәге иде бит. Гәрчә бу терәкне ныгыту турында кайгыртмасалар да. Әллә инде югыйсә шундый, авызын ачса, үпкәсе күренерлек адәмнәрне арттырып, совет җөмһүрияте үзен яклаучылар да күбәер дип исәпләде микән? Мондый фәкыйрьләр сугыштан соңгы елларда авыл җирендә аеруча күбәйде. Безнең авылның Нургали абзый шундыйларның берсе иде. Ул кышын чабата үреп, Алпар базарында сата, шуның акчасына тереклек итә, малайларын укыта, җәен буш хезмәт көненә, ягъни «трудәтнә»гә колхозның яшелчә бакчасын каравыллый. Яшелчә бакчасы яныннан узсаң, һәрвакыт печән белән коршып ясалган куышы янында башына иске эшләпә, өстенә ямаулы фуфайка, аягына исә шыгырдап торган яңа чабата кигән, кулындагы шома таягына таянган Нургали абзаң басып торганны күрәсең. Каргаларны куркытырга куелган карачкы дип белерсең үзен.
— Нургали абзый, кыяр бир әле? — дисәң, «Калхуз малы эчеңне тишеп чыгар...» — дигән мыгырдау тавышын гына ишетәсең.
Ул шундый инде: хәттин ашкан намуслы, ачка үлсә үләр, әмма дә ләкин колхоз хәзинәсенә кагылмас. Башкалардан да кагылдырмас. Әйтәм бит, үләм дип сорасаң да, аңардан сынар кәкре кыяр да алалмыйсың. Безнең якта мондый кешеләр турында: «Раштуада кар да алалмассың аңардан...» — диләр.
Менә шул Нургали абзый бер көнне колхозның кыр каравылчысына зарланып тора:
— Ну, урлыйлар, Ибрай энем, калхуз икмәген, ну урлыйлар. Мин болай гына да, ну алай булса да, урлыйлар...
Колхоз рәисен очратканда да шул ук сүзләр:
— Ну, урлыйлар, Исхак энем, калхуз ашлыгын, ну урлыйлар. Мин болай гына да, ну алай булса да, урлыйлар...
Авыл җитәкчеләре картны игътибар белән тыңлыйлар да, тугрылыгы өчен аркасыннан кагып, мактап китәләр. Күмәк хуҗалык малына шулай һәмишә күз-колак булып торырга кушалар. Ләкин алар шуннан башкасын эшләмиләр, чара күрмиләр, чөнки беләләр: урламасаң, кәкрәеп

ачтан үләргә генә кала. Болай да инде халык алабута, кычыткан, балтырган кебек табигать нигъмәтләре белән генә җан саклый. Шул үләннәр арасына ни дә булса кушып җибәрергә кирәк бит инде. Кесәгә салып, яки хатын-кызның яулык белән эченә бәйләп алып кайткан бер-ике уч бөртекне урлашу дип әйтерең бармы? Шулай да ул заманда йөз грамм ашлык урлаган өчен бишәр-алтышар елга хөкем итүләрен исәпкә алганда, өеңә бер уч бөртек алып кайтуның никадәр хәтәр эш икәнен дә аңлау кыен түгел.

Бу хәлләрне Нургали абзый үзе дә яхшы аңлай. «Урлыйлар»,— дигәннән соң: «Мин болай гына да...» — дигән тирән мәгънәле сүзләре әнә шуны күрсәтә булса кирәк. Бу гыйбарәнең асылында: «Урлыйлар урлавын да, әмма бичарадан ничара урлыйлар. Мин исә үз хезмәтемне намус белән үтәвемне генә белдермәкче булам...» — дигәнрәк мәгънә яшерелгән. Нургали абзаң урлашучылар хәлен аңлаган кебек, житәкчеләр дә картның тел төбен яхшы төшенәләр, шуңа күрә яратып, аның аркасыннан кагып китәләр...

Бүген әтисе турында болай язганым өчен балачакта бергә уйнап үскән Исламгали дус миңа үпкәләмәс дип уйлыйм. Мин болай гына, яратып кына яздым ла. Ну алай булса да, бар иде бит Нургали абзыйның шундый кызык гадәте...

*1993—1994 еллар.*

## Алдан хәбәр итәбез!

# Локман Закир

## «ИНША»

КАРА ХИКӘЯТ

**Хөрмәтле укучыларыбыз! Журналның 7 нче санында сезнең игътибарга әнә шундый әсәрне тәкъдим итәчәкбез. Авторның кульязмасын укып өйрәнгәннән соң бездә киңәшү, сөйләшү, икеләнүләр байтак булды: басаргамы-юкмы бу әсәрне? Чөнки бик тә көтелмәгән, күнекмәгән, безнең татар халык күңеленә ят нәрсәләр күп монда. Кыскасы, элекке еллардагыча уйласак, тыелган «тема» бу. Мондый хәлләр бездә хас түгел дип, әсәрне читкә тибәрсәң, тормыш-яшәешнең күпләрдән яшерелгән «караңгы» почмаклары, ачы чынбарлык бер читтә кыелып калачак... Тормышның кояшлы ягы күбрәк дип ышаныйк. Ләкин аның кырыс-ямьсез яклары да байтак ич — бүгенге тормыш калейдоскобы моны ачык раслый.**

**Менә шуңа да бу язманы укучылар хөкеменә тапшырырга булдык.**

## Дамир Гарифуллин[1]

### Минем уйлар сездә, робагыйлар...

* * *

Дөнья гамен йөрәк белән ташып мин,
Наз өләшәм кешеләргә — шашып мин.
Бу гамәлдән туктарга юк исәбем,
Тукталалмыйм — бу дөньяга гашыйк мин.

* * *

Җаным җырлый тормышның һәр мәлендә,
Тоям яшәүнең бар ямен-тәмен дә:
Былбыл барыбер былбыл булып кала ич,
Тотсалар да кайчак... чыпчык хәлендә.

* * *

Күпме сытты җанны, изде бу тормыш,
Үземчә һич яшәтмәде бу тормыш.
Судан алып, утка салам үземне,—
Шушы яшькә җитеп, димен, ни кырмыш?!

* * *

Җитмәдеме үҗәтлек йә кыюлык,—
Очар мәлдә кала килдем тыелып...
Күренсәм дә тыштан аяз көн булып,
Күңелемдә агыла болыт куерып.

---

[1] Дамир ГАРИФУЛЛИН (1939) — *шагыйрь, балалар өчен китаплар, әдәби шәхесләр, әсәрләр турында мәкаләләр авторы. Шигырьләре журналыбызда беренче тапкыр басыла.*

* * *

Бер уйласам, әллә нинди кеше мин,
Җанымда — ут, үзем никтер өшимен.
Мәхшәр көнен хәтерләткән заманда
Юанамын, бу бары бер төш димен...

* * *

Син төшенсәң шигърияттнең серенә,
Җәбраил вәхи китерер үзеңә.
Нигә керми йокы шагыйрь күзенә? —
Аның уе — мәңгелекнең түрендә.

* * *

Килә иде йолдызларга җитәсе,
Җиребезгә нурлар алып төшәсе.
Хыял булып калыр ахры теләкләр, —
Гомер кыска икән — нихәл итәсе.

* * *

Өмет йөртә адәмне җиһан буйлап,
Яши кеше нужа куып, туй туйлап.
Вәләкин күп өметләр кысыр була,
Аңлыйбыз шул моны без бары соңлап.

* * *

Күч-күч яши кырмыска вә бал корты,
Ялгызлыкта һәлак була ил-йорты.
Гыйбрәт ала белмибезме? Таралдык,
Шуңа татар яшидер ярым-йорты.

* * *

Арка белән борылгач дөнья хәтта,
Тик бер кеше синең өчен җан атса,
Бәхетле син бу дөньяда, — ышанма,
Бәхетсез дип кемдер гайбәт таратса.

* * *

Юк-бар уйлап, җаным, җаның көйдермә,
Күңелемдә сакламыйм сиңа кинә:
Ничек саклыйм аны? Тормыш-дәрьяда
Мәхәббәтең — мине коткарган көймә.

* * *

Теге дөнья дип сөйләргә ашыкма,
Барын күрдем бу дөньяда вакытта:
Кемдер яши «оҗмахта хурлар кочып,»
Ә кемнәрдер — яна һаман «тәмуг»та.

* * *

«Без кабызган утлар» әллә сүндеме;
Без төзегән йортлар җимерелдеме?
...Яңартып төзелгәне дә, кем белә,
Кирәксезгә чыгып куяр бер көнне.

* * *

Бер ятьмә ул — тормыш диеп йөргәнең,
Сизмисең дә анда барып кергәнең.
Бәргәләнә-сугыла анда бәндә, тик
Ятьмәдән чыкканын бармы күргәнең?

* * *

Туздырасың атаң малын, көлеп, син,
Ни майтардың бу дөньяга килеп син?
Тузан кадәр эшең Җирдә калмаса,
Җиһан өчен — тумас борын үлек син.

* * *

Карыйлыкка калдырма бер эшең дә,
Эшләп кал син булган чакта көчеңдә.
Җимешләме язың? Кара борылып:
Бакчада берни үсми кыш көнендә.

* * *

Илтифатсыз гөлләрнең ис-төсенә,
Матурлыкка китми аның исе дә.
Яхшы белән яманны аералмый
Яшидер ул — әнә шуның өчен дә.

* * *

Таңгы бер нур була алсам күгеңдә,
Юкка, димәк, тумаганмын бу Җирдә.
Сагыш дәрьяларын кичкән чагымда
Куанычым — маягым син күңелемдә.

* * *

Үткән гомерне кызганып — ни файда?
Картлык көндә җиң сызганып — ни файда?
Сират күпере кичәр вакыт җиткәндә
Үкенүдән җан сызланып — ни файда?

* * *

Төкерсәләр бакча тулы гөлемә? —
Козгын тулган сандугачлар иленә:
Чукый алар кан саркыган йөрәкне...
Тәгәрәтеп бабамнарның көленә.

* * *

Ике дөнья барын белү ярыйдыр,
Адәм бер көн шуны уйлап карыйдыр.
Уттан алып, суга салып торса да,
Тегесеннән бусы әйбәт барыбер.

* * *

Гомер бакый җәфаландым, нидән бу? —
Гомер бакый хафаландым, нидән бу? —
Әйтер сүзем һаман ярып әйталмыйм,
Асылымамы кайта алмыйм? Нидән бу?

* * *

Айрылганны аю ашар, ди халык,
Зирәклегенә аның таң калырлык.
Бәхетебезне ничә гасыр буена
Аю ашагандыр — безне аерып...

* * *

Әле уйнап-көлик — исән чагында,
Тормыш кадерен белик — исән чагында.
Айрылырбыз мәңгелеккә бер заман,
Күрешүләр телик — исән чагында.

* * *

Дөнья буйлап татарларым күмелгән,
Үлгәннәрнең каберләрен кем белгән?

Җавап биреп кара, Тарих, нилектән
Бу халык соң җирдә шулай сибелгән?

* * *

Һай, дөньяның безне кызык итүе,
Буш вәгъдәләр белән алдап йөртүе.
Кая китте Ак бүреләр, әйтегез,
Ник күбәйде мәхлук сарык көтүе?

* * *

Татардан күп асыл затлар — җиһанда,
Горурланам тарих битен ачканда.
Дөрес икән: ничек кенә бутама —
Алтынлыгын җуймый алтын кайчан да.

* * *

Дәгъваламыйм алтын-көмеш үземә,
Бер нур булсам җитә — дөнья күзендә.
Минем өчен олы бәхет — әйткәнем
Дәвам булса бабамнарның сүзенә.

* * *

Адәм үлсә, дөнья бетми, дусларым,
Кояш сүнми, чишмә кипми, дусларым.
Теге дөнья ничеклеген, киткәннәр
Кайтып хәбәр итә алмый, дусларым.

* * *

Язмышыннан берәү дә качалмаган,
Яшәү серен Хәйям да ачалмаган.
Аерым-аерым яшәгәч, илгә килгән
Афәт утын берәү дә басалмаган.

* * *

Син халыкка таяна күр эшеңдә,
Ышанычың артыр, артыр көчең дә.
Беләсеңдер инде моны үзең дә:
Алтын да бит була ком-таш эчендә.

* * *

Сәфәр чыктым, туган якны урадым,
Юлларымны хәерлегә юрадым.

Бабайлардан калган изге әманәт,—
Шуны эзләп табу иде морадым.

* * *

Чыга тора, бетә тора законнар,
Ярый әле язылмаган закон бар.
Шуның белән яши кеше дөньяда,
Ул законда — яшәтүче ялкын бар.

* * *

Күзләреңнән нурлар булып наз ташый,
Ташый-ташый күңелемдә яз ясый.
Мең елларга җитәр иде шушы яз,—
Ни аяныч, адәм Җирдә аз яши.

* * *

Якты көнем дип дәшәм сөйгән ярга,
Ул булганда урын юк моңга-зарга.
Күрмисең, диләр, күп гүзәл ярларны,—
Күренми шул йолдызлар Кояш барда.

* * *

Таңда үземне бәхетле хис итәм,
Шифа тулы җилләрен дә үз итәм.
Шул җилләрнең тавышында: «Сөям!..» — дип,
Иреннәрең пышылдавын ишетәм.

# ПУБЛИЦИСТИКА

Рашат Низамиев

# БЕЗ КАЯ БАРАБЫЗ?

Мишә елгасы Саба, Теләче һәм аннары Питрәч районнары аша уза. Туган авылым Олы Мишә шушы елга тирәсенәрәк урнашкан. Балачактан ук Мишә елгасына еш төшә идек. Илленче еллар азагы... Ул чакта әле су тегермәннәренең худта чагы. Кечкенә генә Җәнәй авылын бизәп торган тегермән буасы мөлдерәмә тулы. Безнең ише малайлар өчен — диңгез инде бу! Хәтерлим: без, җиде-сигез яшьлек малайлар, бервакыт болынга төштек. Мишә ярына басып, ирләрнең ике дилбегә буйлы озын җылым белән балык сөзгәнен тамаша кылабыз. Шаккатуыбыздан күзләргә яшь бәреп чыкты: җәтмәдә ат камыты зурлыгындагы тере балык бәргәләнә иде! Канат очлары кызыл, энҗе-энҗе тәңкәләре кояшта ялтырый...

Еллар үтте. Балачак һәм яшьлек эзләрен сагынып, туган ягыма, Мишә буйларына еш кайтам. Инде Мишәбезне танырлык түгел: күп урында суы, ачуым килмәгәе, саескан тезеннән генә. Дөньяда кояш барлыгы төшенә дә кермәгән эреле-ваклы ташлар көн яктысына калкып чыккан. Таллыклы урыннарда суы, шөкер, тирән әле. Божра ясап, балыклар уйнап ала. Икенче бер килүемдә мин фаҗигале күренешкә тап булдым: болганчык сулы елга өстен күче-күче белән үле балыклар каплап алган. Йөз сиксән градуска әйләнеп ятканнар, корсаклары гына агарып күренә...

Ун-унбиш еллар чамасы элек «Икшермә» совхозының Кибәче авылында дуңгызчылык комплексы төзегәннәр иде. (Татар авылын дуңгыз үстерүгә мәҗбүр итү — милләтебезне күрәләтә мыскыллау, әлбәттә, әмма монысы аерым тема...) Менә шуннан озын колаклы чучкаларның бөтен пычрагын-нәҗесен ай саен диярлек Мишә елгасына ерып кына җибәрәләр икән! Әйләнә-тирәне, тереклекне, чисталыкны саклау турында уйлаучы да юк, әйтерсең, шулай булырга тиеш.

Хәлбуки, терлекчелек комплекслары эшендә тирес, сыекча һ. б. тәр калдыкларны зыянсыз рәвештә юкка чыгару, чистарткыч җайланмалар булдыру, санитар-саклык биләмәләрен күздә тоту каралган. Юкса калдыкларның парга әйләнүе, күкертле водород һәм аммиакның чамадан тыш күбәеп китүе тирә-юньгә һәм халыкның сәламәтлегенә зыян салачак. Гомумән, терлекчелектә генә түгел, промышленностьта да төрле-төрле калдыклардан санитар төстә арыну хакында кагыйдә-нормативлар җыелмасы бар. Хөкүмәт, фән һәм законнар дәрәҗәсендә. Кызганычка күрә, төрле сәбәпләр аркасында, боларның күбесе үтәлми.

Менә шуңа да мин әлеге проблемаларны яхшы белгән шәхескә, белгечкә мөрәҗәгать итәргә булдым. Әңгәмәдәшем — Казан врачлар белемен камилләштерү институтының (ГИДУВ) медицина-профилактика факультеты деканы, гомуми гигиена кафедрасы мөдире, медицина фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасының әйләнә-тирәне һәм табигый ресурсларны саклау Министрлыгы каршындагы фәнни-техник совет әгъзасы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе **Фидаил Фәсхи улы ДАУТОВ**. Аның хакында кыскача мәгълүмат: Татарстанның Кукмара районында туган, 54 яшьтә, өйләнгән, кызы һәм улы бар.

**— Фидаил Фәсхиевич! Әйдәгез, безнең барыбызны да борчыган кайбер мәсьәләләр хакында ачыктан-ачык сөйләшик әле... Су. Җир. Һава. Бүгенге көндә**

**экология менә шушы «өч кит» өстендә тора. Мин сүземне юкка гына елгалардан башлап китмәдем. Миңа калса, табигатьтә иң нык рәнҗетелгәне — сулыклар...**

Әйе, чишмә, кое, елга-күлләрнең пычрануы, кибә баруы бик хәвефле хәл. Завод-фабрикалар ташландык суларын турыдан-туры елгаларга агызалар. Ә алар үз чиратында шәһәрләрне чиста су белән тәэмин итү корылмаларына барып эләгәләр. Фильтр иләкләре ничек кенә яхшы булмасын, калдыкларның байтагы барыбер «ирекә» чыгып китә. Фәндә, гамәлдә моның нормативлары бар, билгеле. Ләкин эш кайда, ничек куелган бит. Әйтик, АКШта эчәргә яраклы суның составын, сыйфатын тикшергәндә 100 төрле күрсәткеч алына. Бездә исә бу сан 25—30 тирәсендә генә тирбәлә.



**— Суны чистартканда, бездә моңарчы хлор кулланыла килде. Бу хәзер дә шулаймы?**

— Суны хлор белән чистарту иң камил ысуллардан димәс идем. Америка галимнәре исбатлаганча, хлорның башка органик матдәләр белән кушылуы нәтиҗәсендә суда концероген матдәләр барлыкка килә. Менә шуңа да алдынгы капиталистик илләрнең күбесендә суны инде күптән озонлаштыру ысулы белән чистарталар. Сүз уңаеннан, мондый ысул безнең илдә бары Мәскәү Кремлендә генә кулланыла. Бу яңа методның технологиясен тәфсилләп сөйләп тормыйм. Шунысын гына әйтәм, 1 кубометр суны озонлаштыру өчен 4,6 киловат электр энергиясе кирәк.

**— Татарстанның кайбер авылларында хәтта ашка-чәйгә дигән суны да мичкәләп, цистерналап читтән ташыйлар икән, дип ишеткәнем бар...**

— Лениногорск, Әлмәт, Азнакай һәм башка кайбер төбәкләрне күздә тотсак, хаклык бар бу сүзләрдә. Җир маен суырту нәтиҗәсендә бу якларның туфрагы, басу-кырлары нык бозылды. План, план дия-дия табигатьнең бәгырен җәрәхәтләп бетерделәр, җирнең күкрәгенә тишеп-тишеп керделәр. Җирнең исә барлык катламнарында су чыганаклары прессланып ята һәм алар бер-берсенә тоташкан савытлар рәвешендә яши, сулый, хәрәкәтләнә, күчеп йөри. Бер-бер җирен тишеп уздыңмы, әлеге гигант «савыт»ның башка почмакларында да үзгәрешләр килеп чыгуы ихтимал.

**— Башкалабыз Казан уртасындагы Кабан күленең гөрләп торган чагы булган, диләр. Анда хәтта кечкенә пароходлар да йөреп торган... Хәзер ул саекты һәм пычранды. Вахитов комбинатының селте-сабын калдыклары, Казан-Оренбур трассасыннан җәен-көзен агып төшкән майлы-мазутлы ерганаклар үз эшен эшли торалар. Әгәр болай дәвам итсә, Кабан күле сакланып калыр микән?**

— Кабан күленең киләчәге күп нәрсәләрдән тора. Аның төбендә 10—15 метр калынлыгындагы ләм катламы посып ята. Күл төбенә Менделеев таблицасындагы нинди генә элементлар төшеп батмагандыр! Аның үле күлгә әверелү куркынычы саклана. Шушы ләм катламнарыннан чистарткан яисә чистартмаган очракта да аны чиста су белән яңартып, сафландырып алырга һәм ташландыклар агызмаска кирәк.

**— Инде һава темасына күчсәк тә ярыйдыр. Авыл җирендә һаваның чагыштырмача сафрак, чистарак булуы һәркемгә мәгълүм. Шәһәрдә исә янәдән дә шул ук завод-фабрика, ТЭЦ морҗалары төтен чәчә, автомашиналар ташкыны һаваны пычрата. Транспорт туктралышларында хәтта кайчакны противогаз киясе килә башлый. Радиация фоны турында әйтеп тә тормыйм инде...**

— Фән болай аңлата: адәм баласы саулыгының 50 проценты безнең нинди тормыш алып баруыбызга бәйле. Ягъни йокы, ял, мәхәббәт, ашау-эчү һ. б. Саулык-тазалыкның 5—10 проценты сәламәтлек саклау структуралары эшчәнлегенә, 40—50 процент чамасы исә әйләнә-тирәнең торышына бәйле. Кеше тәүлеккә уртача 15—23 кубометр һаваны үпкәсе аша үткәрә. Гадиләштереп әйтсәк, бу — 15—23 килограммга тиң. Чагыштыру өчен: кеше, сыеклыкны да кертеп, бер тәүлектә 3 килограммга кадәр ризык ашый. Димәк, һаваны без алты-җиде мәртәбә күбрәк «кулланабыз», аның чисталыгы организм өчен аеруча мөһим. Тагын кайбер гыйбрәтле саннар. Һава чисталыгының 50—70 процентын автотранспорт боза, калган өлешне промышленность предприятиеләре кертә. Фактлар үҗәт нәрсә. Ачыкланганча, автомашина 100 км араны узганда бер кеше ел буена сулыйсы һаваны, дөресрәге, кислородны ашый. Реактив самолет тоташтан 8 сәгать очканда 25 гектар урман эшкәрткән кислородны йотып бетерә...

Ярый әле, су шикелле үк, һаваның да үз-үзен чистарта алу сәләте бар. Һава катламының югарыгы өлешендә иллегә якын зарарлы матдә туплана. 25—30 км биеклеккә күтәрелгәч, алар азот, кислород, су парларына әвереләләр һәм җиргә әйләнеп кайталар. Безнең бәхеткә күрә, галәмдә әнә шундый гаҗәеп «карантин» капкалары эшләнгән.

**— Гигант төзелешләр иле буларак, без һәр төзелешне җирне актарып салудан башладык. Дөрес, чираттагы ахмаклыкны эшләргә — Себер елгаларын кирегә борырга гына өлгермәдек. Җир — барыннан да элек икмәк үстерү, игенчелек мәйданы. Электән ишеткәнем-укыганым бар: капиталистик илнең байлары гектарына 8—10 центнер уңыш чыккан табигый ипине генә ашыйлар икән. Без исә һәрвакыт саннар артыннан кудык, җирне ашламалар белән тугладык, көчләдек.**

— Халыкта, ояты үзеңә булсын, дигән сүзләр бар. Моның ояты элекке СССРга, хәзерге Русиягә, ил җитәкчеләренең ялгышларына күләгә булып төшә. Җирне промышленность калдыкларына батыру гына җитмәгән, без инде пестицидларны, ягъни агулы химикатларны туфракка үз кулларыбыз белән чәчәбез. Элеккерәк елларны ДДТ — халыкта аны «дуст» дип йөрттеләр — бик популяр иде. Баксаң, аның зарары туфракта унбиш елдан соң да саклана икән! Иң яманы — ул нәсел аша тәэсир итә, зәгыйфь балалар тууга сәбәпче була. Заманында, шушы кәсафәтне истә тотып, академик Мальцев: «Без үз халкыбызга каршы химик сугыш алып барабыз», — дип юкка гына язмагандыр. Пестицидларның йөзләп төре бар. Аларда булган азот кушылмаларын туфрак эшкәртеп бетерә алмый, нәтиҗәдә, кеше организмы өчен зарарлы булган нитратлар барлыкка килә. Татарстан басуларында пестицидларның алтмышлап төре кулланыла иде. Хәзер кемедә алар. Чөнки зарарын аңлау да көчәйде, аннары хәзер колхозларның акчасы да әлләни юк.

АКШ, Германия, Франция, Италия һәм башка күп кенә алдынгы илләр пестицид җитештерүдән инде әллә кайчан баш тарттылар. Алар сайлаган юл — зарарлы бөҗәкләргә каршы биологик ысуллар белән көрәшү.

**— Бер дә күңелле булмаган картина килеп баса бит әле алга. Уенын-чынын бергә кушып әйткәндә, кешене — гомосапиенсны да «Кызыл китап»ка теркәп куяр чак җитмәде микән?**

— Уйланырга нигез бар. Соңгы ике елда Русиядә, шул исәптән Татарстан буенча да демографик күрсәткечләр куанычлы түгел: халык саны күзгә күренеп

кими. Үлүчеләр күп, туучылар аз. Ләкин кешенең акылына, зирәклегенә ышанып, ул үз-үзен юкка чыгаруга юл куймас.

**— Чернобыль фаҗигасеннән соң тузганак һәм башка төр үләннәр котырып үсеп киткән, дип ишеткәнем бар. Агу ашаган кайбер күселәр дә гәүдәгә зураеп киткән, имеш... Бәлки, адәм баласы да төрледән-төрле тышкы йогынтыларны күтәрергә, ияләшергә сәләтледер?**

— Кеше дә төрле зарарлы нәрсәләргә күпмедер дәрәҗәдә ияләшә, билгеле. Ләкин бу — вакытлы күренеш. Тәндәге зарарлы матдәләрне нейтральләштерү процессында организмның кайбер системалары, бигрәк тә сулыш юллары һәм бөерләр нык зарар күрә. Акрынлап иммуналь системаның какшавы мөмкин. Соңгы елларда әйтик, «Тасма», авиация һәм мотор төзү заводлары тирәсендә яшәүче балаларның 35 процентында аллергик чир күзәтелә.

**— Нишләргә соң, нишли алабыз?**

— Кешелек җәмгыяте өчен өлгереп җиткән зур сорау бу.

Чит илләр тәҗрибәсенә күз салыйк. Франциядә 100 чакрым ара узганда 5 литрдан артыграк бензинны исраф итүче автомобильләр житештерү тыела. Әйе, тыела — бетте-китте! Японияның заманча машиналары 1 литр бензин белән 52 чакрым ара уза. Шул ук японнар промышленность әйберләрен калдыксыз эшләүнең йомык циклын уйлап таптылар. Гади генә итеп аңлатсак, болай: бер цехның калдыклары шундагы икенче цех өчен чимал булып хезмәт итә. Соңгы циклларның берсендә калдыкларның да калдыгы пресслана һәм, яндырылып, анда да әле җылылык энергиясе алуга тотыла. Ә без бөтен нәрсәне тизрәк чүплеккә озатабыз, аларны тәүлекләр-айлар буе яндырып, үзебез сулыйсы һаваны пычратабыз.

**— Бездә берни дә эшләнми икән, дигән фикер калмасын укучыда. Экологик тәҗрибә күзлегеннән башкалабыз Казандагы иң күркәм бер-ике мисалны әйтеп китсәгез икән...**

— Уңай мисаллар бар. «Оргсинтез» заводы ун ел элек зарарлы матдәләрне тирә-юньгә бик зур радиуста тараткан булса, хәзерге вакытта бу нәрсә нормаль хәлгә китерелде. Шәһәрне әйләнеп уза торган юл салу да экологик чисталыкка хезмәт итә. Соңгы ике-өч елда, шәһәр мэрының кайгыртучанлыгы белән, Казанда юлларны төзекләндерүгә нык игътибар бирелде һәм зур чыгымнар тотылды.

**— Бездә бит кылган хаталарың өчен җавап тоту дигән нәрсә юк. Арал тикле Арал елгасы кипте — җавап бирүче юк. Елга-басуларга нефть ага — гаепле кеше табылмый. Чернобыль фаҗигасе уңаеннан, ялгышмасам, берәүгә дә җәза эләкмәде шикелле. Ә бит һәр җинаять үзенең җәзасын алырга тиеш. Табигатьне зарарлаган өчен бездә завод-фабрика хуҗалары штраф белән бик ансат котыла, чөнки бу — саклык корылмаларын төзүгә караганда күпкә ансатрак юл. Предприятие хуҗаларыннан, гадәттә, экологик күрсәткечләрне сорамыйлар ич. Шулай булгач, бу хакта нигә башы авыртсын ди аның...**

— Бездә план «чире» көчле булды. Хәтта сырхауханәгә дигән даруларны да үлчәп, дозалап кына бүлеп бирәләр иде. Әйтерсең, халык планлы төстә чирләргә һәм дәваланырга тиеш. Абсурд бу. Болар һәммәсе һаман да мескенлектән, акчасызлыктан килә. Завод-фабрика директорларының исә штрафка әллә ни исе китми иде, чөнки акчаны үз кесәсеннән чыгарып салмый ич ул. Халыкка каршы экологик зыян эшли дә, шуны халык хисабыннан каплата. Законнан курка белмиләр, чөнки аларның күбесе кәгазьдә бар, гамәлдә юк. Экологик зыяны нормативларны узып китә икән, алдынгы чит илләрдә андый предприятиеләрне закон нигезендә бик тиз ябалар. Бездә андый тәҗрибә юк. Ябар-туктатыр иден, әлеге дә баягы, — акча кирәк, эшсез калучыларны социаль яклау механизмы эшләнмәгән, план өзелә һ. б. Технологияне камилләштерми торып, бу проблемаларның берсен дә яхшы якка таба үзгәртеп булмаячак.

**— Тагын бер гаеп, миңа калса, империячел сәясәттә. Башкалар җилкәсендә яшәү — гигант илдәге иксез-чиксез биләмәләрне талау, кысу, сыгу хисабына барды. Камчаткадан Брестка кадәрге киңлекләрдә экологик тәртип һәм чисталык**

**берничек тә була алмый иде. Һәрхәлдә, кечкенә илләрдә тәртип, цивилизация җимешләре бары соклану тудыра. Унбиш бала асрауга караганда ике-өч бала тәрбияләп үстерү күпкә җиңелрәк, дип әйтмәкче булам һәм бу схема җәмгыять кануннарына да тулысынча туры килә.**

— Килешәм. Бу фикердә хаклык зур. СССРдагы экологик хәлне тәртиптә тотар өчен акча-финанс юмартлыгы ифрат түбән иде. АКШта исә бу юнәлеш өчен милли доходның 30—40 проценты тотыла килде.

**— Безнең Татарстанда экология мәсьәләләре белән хөкүмәт дәрәҗәсендә шөгыльләнүче көчләр бармы, күпме алар?**

— Эшчәнлекләрен тәфсилләп тормыйча, санап кына китик: Татарстан Республикасының әйләнә-тирәне һәм табигый ресурсларны саклау Министрлыгы, Югары Совет каршындагы әйләнә-тирәне саклау комиссиясе, Татарстан Фәннәр академиясе, санэпидстанция, дәүләт санэпиднадзор комитеты, яңарак оешкан экология институты, Казан университетының экология факультеты. Болар инде зур көч.

**— Рәсәйдә ни өчен Тур Хейердаллар юк, «Гринпис» командалары да күзгә чалынмый? Әллә Русияне «иртәгесе өчен ишәк кайгырган» фәлсәфәсе тәмам чорнап алганмы?**

— Бөтенесе бергә кушылган. Иң кыены шул: экологик тазалыкны тиешенчә саклау өчен тиешле акча табылмый, ул каядыр бүтән тармакларга «агып» китә, күрми дә каласың. Фәнни эзләнү һәм ачышлар өчен акча һаман кысыла икән, бу илнең киләчәге мактанырлык түгел, әлбәттә.

**— Нигә әле бездә мәктәпләрдә экология фәне укытмаска? Бу — тамыр һәм яфрак төзелешенә караганда күпкә әһәмиятлерәк ич...**

— Әйе, халыкның игътибарын экология мәсьәләләренә юнәлтү ихтыяҗы үзен көннән-көн ныграк сиздерә. Моны балалар бакчасыннан, мәктәпләрдән үк башларга кирәк. Кечкенәдән белеп, аңлап үссеннәр. Бер-бер чәчәк яисә агачны рәнҗетү дә гаеп саналсын.

Казанның Каравай белән Оргсинтез арасында буш яткан җирләр бар. Шәһәр читенә, махсус урынга ташланасы күпме чүп өеме биредә «прописка»га кергән. Автомәктәп тәмамлап, шофер таныклыгы алырга җыенган егетләргә моның экологик, матди һәм мораль зыянын аңлату начар булмас иде югыйсә. Кызганыч, әмма уку программасында мондый «вак-төяк»ләргә вакыт каралмаган. Производствода, югары уку йортларында да экология дәресләре керсә, бер дә начар булмас иде. Экологик белемнәрне пропагандалау, әйләнә-тирәне саклауда һәркемдә шәхси җаваплылык хисе тәрбияләү — көн тәртибенә баскан, күптән өлгереп җиткән мәсьәлә.

**— Сез чит илләр буенча шактый мисаллар китереп сөйләдегез. Кайсы илләргә сәфәр кылганыгыз бар?**

— Япония, Һиндстан, Төркия, Югославия, Румыниядә булырга туры килде. Һәр илнең үз дөньясы, үзенчә яшәеше. Әмма алардан өйрәнерлек нәрсәләр күп.

**— Галимнәр кешелеккә өч төрле үлем — атом сугышы, әхлак җимерелү һәм экологик фаҗига куркынычы яный, диләр. Боларның алдагы икесе фәндә нык өйрәнелгән. Ә менә экологик куркыныч күпләрнең аңына барып җитми булса кирәк. Уйлавымча, иң нык борчылырлык хәл — яңа туган сабыйлар язмышы, киләчәк буын мәсьәләсе. Кешелеккә алмашка кемнәр, нинди потенциаль көчләр килә? Беркөн шулай Казан телевидениесеннән чукрак балалар төркемен күрсәттеләр — имәнеп киттем... Без кая барабыз? Акыл ягыннан зәгыйфь балалар туа тора. Инде, заманына күрә, «дебиллар мәктәбе» дигән термин барлыкка килде. Сәбәпләре дә мәгълүм: радиация, экологиянең тулаем торышы-сыйфаты, шикле эчемлек һәм ашамлыклар куллану һ. б. Үзебез әле кайчан гына сүккән капиталистлар, ил капкасын каерып ачып җибәргәч, безнең кибет һәм урамнарны азыктөлек белән тутырып куйдылар. Русия хәзер тегеләр каршында ялтыравык кәгазьгә алданган сабый бала хәлендәрәк калды шикелле. Тышкы сәүдә әһелләренә баеп**

**калу кирәк. Ришвәт тартучеләр булса, алар сертификатка яшел урам ачарга бер дә тартынып тормыйлар, шулай итеп, барлык милләтләрнең тормышын, генофондын, менталитетын куркыныч астына куялар. Бу хакта Сез ни уйлыйсыз?**

— Чынлап та, атом сугышы куркынычы нык кимеде. Теләк булганда, җәмгыятьнең әхлагын да яңартып була. Ә менә экологик киеренкелек бүгенге көндә барысыннан да көчлерәк булып чыкты. Гавәм моны әллә ни сизми шикелле, чөнки бу процесслар бик акрын һәм талгын бара. Кискен бер хәл килеп чыкса, чаң кагабыз да онытабыз — тормышның чираттагы агымнары үзенә бөтереп ала. Чернобыль ярасы ябылды сыман, ләкин төптә аның утлы күмерләре көйри. Зур тема, кереп китәсем килми... Ә менә Череповецтагы хәлләрне искә төшерсәк, монысы безнең темага турыдан-туры кагылышлы. Хәтерлик: 40 бала берьюлы диярлек кинәттән пеләш калды! Әлеге уңайдан илдә абруйлы комиссияләр эшләде, һәм алар уртак бер нәтиҗәгә килделәр: бу — балалар организмына эләккән зарарлы мәтдәләрнең йогынтысыннан барлыкка килгән чир.

Бу уңайдан шуны әйтергә була: безнең фән кайсыдыр өлкәләрдә көчле, кайсыдыр өлкәләрдә сыек. Тирә-юнебезне, без сулаган һаваны, ашаган ризыкларыбызның сыйфатын өйрәнү көчле димәс идем. Төрле ризык ашаганнан соң кеше организмына эләккән зарарлы матдәләр нишли, организмда нинди үзгәрешләр бара — фәндә әле болар ныклап өйрәнелмәгән. Профилактика чаралары күрер идең, моның өчен исә төгәл мәгълүматлар, фәнни белем белән ныклап коралланү зарур. Бер танк төзү өчен киткән чыгымнарны медицина өлкәсенә бүлеп бирсәң, бездә хәлләр тамырдан үзгәрер иде, бәлки.

**— Теләсәң-теләмәсәң дә, цивилизациянең гасырлар буе куәт алган тәгәрмәче күпмедер дәрәҗәдә табигатьнең, кешелекнең үзенә каршы эшли башлады. Хәзерге заманда аерым дәүләтләр, республикалар экология дигән әлеге масштаблы мәсьәләне үзләре, үз көчләре белән генә хәл итә алмастыр, мөгаен. Менә шуңа күрә дә, экология проблемаларының кискенлеген истә тотып, Берләшкән Милләтләр Оешмасы каршында халыкара берәр оешма төзү ихтыяҗы өлгермәде микән? Белгәнебезчә, Җир шарындагы халыкларның мәдәни-эстетик мирасын саклау йөзеннән, ЮНЕСКО төзелгән иде һәм ул халыкара мәйданда уңышлы гына эшләп килә.**

— Сөйләшә торгач, бик зур сорауга килеп чыктык без. Ә җавабы шактый гади, бөтенебезгә дә шактый аңлаешлы төсле: табигатьне зарарлау яисә әйләнә-тирәне саклау мәсьәләләре бернинди дәүләт чикләрен, милли аерымлыкларны һәм географик меридианнарны да белми. Үзендә нинди «йөк» йөрткәнне сизми дә торган болытлар, сары яңгырлар теләсә кайсы авыл, шәһәр, мәмләкәт һәм дәүләтләр аша тоткарлыксыз узарга мөмкин. Биредә, чынлап та, халыкара килешү, аңлашу, хезмәттәшлек мөнәсәбәтләре мөһим. Хәзергә исә экология буенча төрле кыйтгаларның башкаласында халыкара конгресслар, симпозиумнар үткәрелә тора. Минемчә, болар барысы нәкъ менә Сез әйткән идеягә хезмәт итәләр.

**— Ниһаять, соңгы сорау. Экология өлкәсендә эшләүче белгечләрнең берсе буларак, әйтегез әле: Сез оптимистмы, пессимистмы?**

— Экология өлкәсендәге бүгенге кимчелекләр акрынлап, һичшиксез, бетерелер дип уйлыйм. Кеше үзе яшәп яткан әйләнә-тирәлекне, андагы табигый хәзинәләрне күз карасыдай сакларга, дөрес яшәргә өйрәнер, егерме беренче гасырга оптимист булып аяк басар, дип ышанасы килә.

* * *

*Йомгак. Кем син, Кеше: табигатьне җимерүчеме, әллә аны сакларга җан аткан фидакарьме? Бүген күп нәрсә үзебездән тора. Тәҗрибәләр остасы Мичуринның: «Без табигатьтән рәхимлекләр көтә алмыйбыз, аны аннан алу безнең бурыч», — дигән сүзләре инде күптән искерде. Без гомер-гомергә рәхәтлекләрен күп татыган табигать бүген үзе безнең яклауга, мәрхәмәткә мохтаҗ. Мәрхәмәт эшләргә исә беркайчан да соң түгел...*



# ДУСТЫБЫЗ МӘХМӘТ ЧАВУШ

Дөньяда гаделсезлекләр күп. Шуларның берсе — төрки халыкларының байтак җирдә, хәтта тарихи ватаннарында да, азчылык хәлендә калып, башка милләтләрнең җәберенә дучар булуы. Бүгенге көндә алар милли тигезлек, хөррият өчен киеренке көрәш алып бара. Бу көрәшнең үзәгендә минем карашка, үзбәк Байморза Хаит, Әхәт Әндиҗан, уйгыр Мәхмәт Риза Бәкин, Иса Йосыф Алыптәкин, Кибрис (Кипр) төрекләре Дәрвиш Манизадә, Нәвзат Карагил, татар Гали Акыш, Надыйр Дәүләт, төрекмән Зыят Күпрүле, Балкан төрекләре Әхмәт Дуган, Мәхмәт Чавуш һәм бүтән олы шәхесләр кайнавын ишетеп беләбез. Әмма татар җәмәгатьчелеге аларның күпчелеге белән таныш түгел, чөнки озак еллар дәвамында рухи казыйларыбыз тарафыннан безнең аңыбызга җиде ят каһарманнар — әллә нинди «шәп» Фидель Кастро, Нельсон Манделалар дыңгычлап тутырылды, аларның татар язмышына һичбер катнашы булмаса да, без шуларны телдән төшермәдек. Болай яшәү, әлбәттә, табигый бер хәл түгел иде. Алар урынын уйлары һәм гамәлләре якын кан кардәшләр биләве кирәк. Бу эш беренче нәүбәттә татар эшлекләләрен таныштудан башланды, хәзер инде алар янәшәсенә кайбер кардәш-туганнарыбызны да барлар вакыт җитте.

Мәхмәт Чавуш Болгарстанның Туриаовасы авылында 1933 елда туа. Искезагра һәм Разграт төрек педагогия училищеләрендә белем ала, София университетының тарих-фәлсәфә һәм төркология бүлекләрен тәмамлый. София радиосында тапшырулар бүлегендә, Болгарстанның төрек телендәге гәзит-журнал редакцияләрендә эшли һәм төрле уку йортларында төрек теле һәм әдәбияты укыта. Болгарстан җитәкчелегенең шовинистик сәясәтенә карышкан өчен берничә мәртәбә эшеннән куып чыгарыла, сөргенгә илтеп ташлана, 1982 елда исә ватаныннан сөрелә.

М. Чавуш унөч яшендә чакта матбугатта беренче шигырен бастыра. Болгарстанда аның «Еллар серенадасы» (1964), «Юл бирегез!» (1969) шигъри җыентыклары нәшер ителә. Әмма аның беренче романы «Сөюнең башлангычы», шигъри җыентыгы «Сөюдә тәүге туктальш» һәм байтак бүтән әсәрләре, сәяси киртәгә очрап, басылмый кала.

Төркиягә күчеп килгәч, монда аның «Болгарстанда милләтсезләштерү» (1984), «Болгарстаннан авазлар» (1985), «Болгарстан төрекләре элек һәм хәзер» (1986) китаплары дөнья күрә, гәзит-журналларда күп кенә шигырьләре, мәкаләләре, новеллалары, дастаннары басылып чыга.

М. Чавуш, ватанында вәхшиләрчә җәберләүләргә дучар ителгән милләттәшләре хокукын яклап, Төркиядә «Балкан төрекләре теләктәшлек һәм мәдәният җәмгыяте»н кора һәм 1990 елда «Балкан төрекләре сәсе» (сәс — аваз) исемле әдәбият, сәнгать, тарих, сәясәт журналына нигез сала. Төркиягә күчеп килергә мәҗбүр булган мөһаҗирләрне үз тирәсенә туплап, Балкан җирендә — туган төбәкләрендә яшәп яткан төркиләрнең, мөселманнарның милли-дини тигезлеге, хөррияте өчен көрәшне дәвам итә. Шуның белән бергә, Балкан төркиләренең әдәбиятын, сәнгатен, тари-

**хын өйрәнүгә көч түгә, каләмдәшләренең иҗатын укучыларга җиткерүгә зур игътибар бирә. Ул төзегән «XX йөз Болгарстан төрекләре шигыре» (антология) Истанбулда инде икенче мәртәбә дөнья күргән.**

**Мәхмәт Чавуш — сүрелмәс рухлы сәяси көрәшче, җитди галим, киң карашлы нәшир, ихлас күңелле, кызыклы шагыйрь. Без аның белән 1993 елның ноябрендә Истанбулда очраштык. Төркиядән тыштa яшәүче төрки кавемнәрнең уртак кайгылары, уртак казанышлары, аларны үзара якынайту чаралары хакында фикер алыштык һәм әдәби багланышларны ныгытуның аеруча әһәмиятле булуын таныдык. «Балкан төрекләре сәсе» журналы белән татар басмалары арасында дуслык урнаштыруның һәр якка файда китерәчәгенә ышаныч белдердек.**

**Әйбәт теләкнең сүздән гамәлгә күчүе яхшы. Танышлыгыбыз киңәйсен, туганлыгыбыз ныгысын, бу юлда Мәхмәт Чавуш шигырьләре Балканнан Идел буена җибәрелгән кайнар кардәшлек сәламе булып яңгырасын! Мин аларның берничәсен төрекчәдән тәрҗемә итеп, укучыларыбызга тәкъдим итәм.**

**Тәүфикъ ӘЙДИ**

# Мәхмәт Чавуш

## Ялгыш аңламагыз безне

Ялгыш аңламагыз безне —
Шундый ук су ич без башка касәләрдә,
Ботакларда — шундый ук гөл,
Шундый шытым — башка басуларда.

Ялгыш аңламагыз безне —
Булсак та чит һава, нигезләрдә,
Агачларда — шул ук җимеш лә без җирдә! —
Шундый җилкән — башка диңгезләрдә.

Ялгыш аңламагыз безне —
Безнең яктылык — шул ук бер Кояштан,
Яшәсәк тә башка биналарда,
Шул ук бәндә — шундый ук туфракта...

Ялгыш аңламагыз безне —
Бер үк йөрәк тибә — салкында да;
Башка туйракта да шул орлык,
Шундый чаткы — башка ялкыннарда.

Ялгыш аңламагыз безне —
Шул ук балалар — тик азчылыкта,
Башка кәүсәләрдә шул ук токым,
Шул ук дөнья — башка яссылыкта.

Ялгыш аңламагыз безне —
Шул ук планета без башка галәмнәрдә,

Башка рәхәтлектә шул ук җырлар,
Шундый ук җан — башка гамәлләрдә.

*Турнаовасы, 1970*

## Газәл

Кышка кердек, юлларыма юрган җәяр калмады,
Җәйгә чыктык, колагымда җанлы гөрләү калмады.

Ашкынуым кочагында җәйдән бер ямь эзләсәм,
Мең өметләр кабынса да, миңа дөрләү калмады.

Карлыгачлар канатында алып китте йөрәкне,
Яраланган йөрәгемә имче берәү калмады.

Биек таулар сурәтченең рәсемендә яшәрер,
Бу тауларда дәртләремә сулыш өргән калмады.

Кил, сөеклем, касә кулда, узачактыр бу кичә,
Синнән башка Чавушыңа күңел биргән калмады.

*Искеҗома, 1972*

## Пычрак урам

Ятка әйләнде дөнья — ул бормалы кичү;
Тормыш юлчысы — гүя, көзге урманнарда...
Кайдан килдек? Кая юл тотабыз? Ни өчен?
Ни эзләдек, ни таптык без бу урамнарда?

Сорау куеп озайгандай урамнар, баксалар...
Дымы кипшенгән яфраклардан гарык без.
Дәрья-елгаларның сулары бик мул акса да,
Тегермәннәребезнең һәммәсе чарыксыз.

Маңгай сыры һәм күз чокырларында — тоз туе,
Төкәнмидер өч заманның боздай салкыны.
Сырларны — язмышыбыз, чокырны кошлар уйды,
Пычрак урамнарда тәмамладык йокыны.

Сорамагыз киемебез пычрану хәлләрен —
Эчтә газиз җиргә кайнар мәхәббәт тулган.
Без — исемсез кешеләредер бу мәхәлләнең,
Әйтче, шулай түгелме, и пычранган урам?

Зарлы килдек дөньяга, китәрбез шулай фәкать,
Үзгәрәдер замана, тик безнең өчен түгел.
«Күлмәк ертык, кесәм буш», дип көткән чакта шәфкать,
Үлем сулышын тоя да нәгъри ора күңел.

*Искеҗома, 1970*

## Азчылыклар кабере

Җылысын җуйган хатыннар шикелле,
Ак кан төседәй Румәледә көннәр.
Агу тамызган, гүя, чаян теле:
Богаулар, дар агачлары, сөргеннәр...

Кан коса бүген дә тыелган җырлар,
Үлем китерә канәфердәй һәр яра.
Золымга каршы күтәрелгән хурлар
Чәчләрен җилдә байрак итеп бара.

Әйтерсең, төн әсирлегендә көннәр,
Йөрәк һәм җан парә-парә теленгән.
Шәфкатькә мохтаҗ сызланулы меңнәр,—
Күзләре яшьле, буйлары бөгелгән.

Үлем түшәгендә ята Герлова,
Инри Родоп, Добруҗа, Дилеурман.
Кайда ул дәва, юаныч, ярлыкау?—
Замана утлы гауга белән тулган.

Тел дә, дин дә, гадәтләр дә тыелган...
Ил тулы сыкрау һәм ил тулы хаста.
Чиргә дару юк, күзләрне кан баскан,
Азчылыкка бер кабер — Болгарстан!

*Искеҗөма, 1982.*



# ШАГЫЙРЬ ГАБДЕССӘЛАМ

XVIII гасыр татар әдәбияты күп кенә кызыклы әдип һәм шагыйрьләр иҗаты нигезендә үскән. Бу гасырдан калган әдәби мирас белән җәмәгатьчелекне таныштыру зарур, чөнки безнең заманда әдәби-тарихи мирасыбыз белән кызыксынучыларның саны арта бара.

Татар укучысы әдәбиятыбызның алты томлык тарихы һәм аз гына санда басылган «Татар поэзиясе антологиясе» (Казан, 1992) аша шагыйрь Габдессәлам, аның әсәрләре үрнәкләреннән хәбәрдар инде. Ләкин бу әсәрләр белән генә шагыйрьнең зур иҗатын тулы итеп күз алдына китереп булмый. Шуңлыктан Габдессәлам шигырьләре белән киңрәк һәм күбрәк укучыларны таныштырырга булдык. Бер рәттән аның тәрҗемәи хәленә дә бераз тукталып үтү артык булмас...

Габдессәлам бине Уразмөхәммәт (Урай) бине Колмөхәммәт бине Колчура Татарстан җөмһүриятенең хәзерге Әтнә төбәгенә караган Олы Мәңгәр авылында туган. Укып белем алгач, туган жиреннән ерак булмаган Ташкичү авылында (хәзерге Арча төбәге) укыта һәм анда имам була. Ташкичү мәдрәсәсенә белем алырга, заманында, 1755 елдагы татар милли азатлык хәрәкәтенең булачак юлбашчысы Батырша Алиев та килеп укый. Габдессәлам белән Батыршаның дуслыгы шул дәвердә үк башлана.

Габдессәлам 1746 елда Ташкичүдән Оренбург янындагы Сәгыйть бистәсенә күчеп китә һәм анда ахун булып хезмәт итә башлый. Борынгы әдәбиятыбыз белгече, мәрһүмә Зәйнәп Максудова, Габдессәламнең кульязма «Коръән»ен һәм шигырьләрен Петербург фәнни китапханәләренең берсендә күргән була. Яңа урында Габдессәлам үзенең тирән белеме, гаделлеге, тыйнаклыгы белән мөселманнар арасында зур абруй казана. Сәгыйть бистәсенә күчеп килгәч тә шигырь язуын туктатмый. Монда аның иҗатына Оренбург ягының үзенчәлекләре тәэсир итә: әсәрләрендә Төркестанның сәүдә юлы, күчмә казакъларның җәйләү алыштырулары, татарларның пыяла тәрәзәле йортлары һ. б. чагылып китә. Барыннан да бигрәк Габессәлам — лирик, мәхәббәт шагыйре. Аны бу яктан фәкать XIX йөздәге атаклы шагыйребез Габделҗаббар Кандалый белән генә чагыштырырга мөмкин. Ләкин Габдессәламнең үз үзенчәлеге бар: ул Алтын Урда чорындагы татар шагыйрьләре Мәүлә Казый Мөхсин, Мәүләнә Исхак, Сәйф Сараи стилендә иҗат итә (XIX гасыр татар поэзиясе стилендә үскән татар шигъре традициясе исә XVII—XVIII гасырларда яшәгән Мәүлә Колый, Габди, Исмәгыйль, Максуд һ. б. шагыйрьләр иҗатында үстерелә.

Габдессәламнең шигырьләре үз вакытында татар халкы яшәгән Идел-Җаек буйларында кульязмалар рәвешендә киң таралганнар. Әлегә аның иҗаты аз өйрәнелгән, шуның белән бергә күп кенә шигырьләрендә авторның исеме дә күрсәтелмәгән. Шулай да кайбер басылып чыккан китапларда билгесез авторларга нисбәтләнгән шигырьләрнең стиль, тематика, тел материаллары нигезендә Габдессәламгә нисбәтләргә мөмкин. Әсәрнең авторы күрсәтелмәгән очракларда, аны билгеләгәндә, хронологик, географик факторларны һәм социаль мотивларны да исәпкә алу хажәт.

Габдессәлам 1746 елларга кадәр дини, милли колониаль изүнең үзәге булган Казан тирәсендә иҗатын башлый. Бу иҗатка иң зур этәргеч — борынгы әдәби мирас хәзинәләре нык сакланган Олы Мәңгәр авылында яшәү, уку дәвере булган. Олы Мәңгәр авылының тарихи үзенчәлеге — аның Казан ханлыгын җимергән елларда да чагыштырмача ким зыян күрүендә; шуңлыктан анда мәдәни әдәби традицияләр һичбер вакыт өзелмәгән. Соңгы елларда бу авылда эзләнүләр (хәзер ул Татарстан җөмһүриятенең Әтнә төбәгенә керә) искиткеч күп әдәби мирас хатирәләре сакланган булуын күрсәтте. Андагы

археографик эзләнүләр нәтиҗәсендә 200 берәмлектән артык борынгы кульязма китаплар, 50 дән артык XVIII—XX гасырга караган язма документлар табылды. Бу кульязма китаплар XIV—XIX гасырларда күчерелгәннәр. Алар арасында «Кыйссаи Йосыф» дастанының XVIII гасырдан өч кульязмасы, Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасының XVIII гасыр күчермәсе, Алтын Урда татар әдәбияты ядкарьләре булган «Җөмҗөмә солтан», «Кыйссаи Ибраһим», «Кыйссаи Сәкам», «Түләк белән Сусылу», «Кәлилә вә Димнә», «Кисекбаш» әсәрләре кульязмалары, урта гасыр татар әдәбиятының иң популяр шагыйрьләре Әхмәт Ясәви, Сөләйман Бакыргани әсәрләренең XVII—XVIII йөз кульязмалары, XVIII дән калган кульязма календарьлар. XVII гасырдан калган фарсы-гарәп телендәге, иллюстрацияле «Кешенең әгъзалары һәм гигиенасы» исемле медицина китабы, XIV гасырдан калган гарәп телендәге шәрех китабы һ. б. бар...

Габдессәламнең поэтик таланты нәселдән килә, күрәсең, аның онысы Әбелмәних Әбелфәез улы Габдессәламов-Каргалый да (1782—1826) атаклы татар шагыйре булган.

Сәгыйть (Каргалы) бистәсенә нигезне 1745 елда хәзерге Татарстанның Кукмара, Саба районнарына караган авыллардан хәлле сәүдәгәр татарлар сала. Олы сәүдә юлына утырган татар бистәсе таза тормыш белән яши башлый. Габдессәламнең Сәгыйдкә килгәч язган «Илаһи бәет»ләреннән инде хөр яшәү рухы сизелә, аларда карындык тәрәзәләр урынына пыяла тәрәзәләр, йорт (киез тирмә түгел), утрак тормыш, сәүдә, сәүдәгәр психологиясен күреп торабыз. Моның традициясе ерактан килә: Урта Азиягә сәүдә юлын татарлар Оренбург, Сәгыйть бәстәсе корылганчы ук күптән таптаганнар. Олы Мәңгәр һәм аның янындагы авылларның сәүдәгәрләре дә XVII—XVIII гасырлардан бирле Урта Азия белән тыгыз элемтәләрдә торганнар. Алар аеруча Өргәнечкә йөреп, Олы Мәңгәрдә юл күрсәтүче карван башлары яшәгән. Шушы сәүдә юлы Габдессәлам бәетенә дә килеп керә:

Төркестанның юлына төште томан,
Арт ягын бер баскан юрга кунан.

Габдессәлам шәхес буларак милли, дини изүнең Русия империясендәге бөтен авырлыгын күреп, ул — беренче чиратта дин әшлеклесе түгел, ә, бәлки, милли азатлык хәрәкәтенең рухын саклаучы булган. Юкка гына урыс хакимияте аның Батырша белән бәйләнешенә шик тотмаган. Бер шигырендә ул:

Карчыга канат кагар тауны күрсә,—
Ир егет кылыч алыр яуны күрсә,—

дип, ир-егетнең ватанын, халкын саклаучы булырга тиешлеген әйтә.

Без Габдессәламнең ике кульязма җыентыгын таптык. Алар Татарстанның Байлар Сабасы һәм Сарлы авылларында археографик экспедицияләребез дәверендә табылды. Шулай ук аның әсәрләре академик М. Госманов, әдәбият белгече Зәйнәп Максудова, әдәбиятчы Әхнәф Харисов хезмәтләренә дә килеп кергәннәр, димәк, алар кулында да шагыйрьнең кульязма күчермәләре саклана.

Габдессәлам дәверендә, татар халкында милли бер фольклор жанры булып, XIX—XX гасырларда формалашачак бәетләр жанрының әле шигырь-мөнәҗәтләрдән аерылып җитмәгәнлеге күренә. Моны аеруча Меллагол хакындагы «Илаһи бәет» тә сиземләргә мөмкин. Чыннан да, татар бәетләре аеруча XIX гасырның икенче яртысында киң булып үсеп китәләр. XIX гасырның беренче яртысында бәетләр күп булса, аларның кульязма күчермәләре дә күп сакланыр иде, ә бу дәвердән бары әле җыр дип тә аталган «Француз сугышы», «Җиде кыз», «Зөлхәбирә», «Аккан Ору», «Лашманчылар» кебек аз санлы бәеткә хисапланган әсәрләр генә мәгълүм...

Шигырьләрендә ул исемен — Габдессәлам, Габдеш, Габди рәвешләрендә — шигырь ритмикасына, иҗекләр санына ярашырлык рәвештә куллана. Бер шигырендә аның язылу вакытын да — 1757 ел — билгеләп була. Исем, географик пространство, хронологик дәвер, иҗтимагый тоткан урыны, татарча язуы, белем амплуасы — Габдессәламнең күренекле һәм замандашларына тәэсирле татар шагыйре икәнлеген раслыйлар. Аның иҗаты, борынгы традицияләргә таянып иҗат иткәнлектән, халыклашкан. Шунлыктан, күчерүләр «Кыйссаи Йосыф»ка иҗади өлешләрен керткән кебек, Габдессәлам шигырьләренә дә үзләренчә өстәмәләр, үзгәртүләр керткәннәр. Бу дәверләр өчен үзгәртүләрнең шагыйрь өчен дә, укучылар өчен дә принципиаль әһәмияте булмаган. Бу — үзенә күрә бер иҗат методы. Ул төзәтүләр аерым сүзләр, юлларга гына карамыйча, әсәрнең аерым өлешләрен кыскартып, төшереп калдыруга хәтле мөмкин.

Габдессәлам — үзенең мәхәббәт лирикасы, осталыгы ягыннан чын шагыйрь. Анда кешенең эчке кичерешләре, борчулары, шатлыклары өстенлек ала:

ул үгет-нәсыйхәт, фәлсәфә шагыйре түгел.

Шагыйрьнең кайсы елны вафат булуы әлегә мәгълүм түгел, тик аның 1762 елда әле исән булганлыгын сөйләүче документ табылган.

...Бүгенге заманда, экономик кыенлыклар сәбәпле, шагыйрь Габдессәламнең алтмышка якын шигырен тәшкил иткән мирасын аерым китап итеп, вариантлары белән бастырырга мөмкинлек юк. Бу басмада шигырьләре безнең тарафтан шагыйрьнең ике кульязма җыентыгыннан алып, тексталогик яктан әзерләнеп бирелде...

Марсель ӘХМӘТҖАНОВ
1994 ел, 15 октябрь

# Габдессәлам

## ИЛАҺИ БӘЕТЛӘР

* * *

Һәр эшнең хәйередер —
Бисмилладыр — исме Аллаһ.
Ахрида салават әймак [1]
Мөхәммәд рәсүлуллаһ.
Бәгъдә [2] галәм, карендәшләр,
Сәхавәтлек [3] әйләңез!
Һәрвакытта дога кылмай,
Онытубән калмаңыз!
Әткәй-әнкәй, карендәшләр,
Бәндин бәхил улыңыз!
Гариблектә [4] җан бирүбән,
Изге дога кылыңыз!
Әткәм-әнкәм, без гарибне
Инде канда [5] күрәсез!?
Яумел-гаиде [6] җомгада
Хәйер-дога кыласыз!
Әткәм-әнкәм бән гарибә,
Нәүхә-зарый [7] кылмаңыз.
Рәсүлуллаһ хәдисене [8]
Аңламайын калмаңыз.
Вафат улган йирем бәнем —
Таифәи урыс [9] арасы,
Бу дөньяда үлмәйүбән,
Кемнәр бакый[10] каласы!
Хак тәгалә тәкъдир кылды
Исме Пүлшә[11] йиридә.

[1] Салават әймак — мактаулы догалар әйтмәк.
[2] Бәгъдә — аннан.
[3] Сәхавәтлек — юмартлык.
[4] Гариблектә — туган иленнән читтә.
[5] Канда — кайда.
[6] Яумел-гаиде — гает көнне.
[7] Нәүхә-зарый — кычкырып елау зары.
[8] Рәсүлуллаһ хәдисене — пәйгамбәр сүзләрен.
[9] Таифәи урыс — рус халкы.
[10] Бакый — мәңге.
[11] Пүлшә — Польша.

Газраил жанымны алды
Карендәшләрем кулында.
Газраил жанымны алды,
Гамәлсез ни кылгаймыз.
Хак тәгалә гафу кылса,
Оҗмах эчрә калгаймыз.
Меллагол дип әйдиләр —
Бу бәйетнең ийәсен.
Хак тәгалә үйлә кылды [1]
Без фәкыйрьгә, күрәсен.
Бу бәйетнең мөбәййене [2] —
Исмедер Габдессәлам,
Иманымны йулдаш әйлә
Фазлың [3] илә, зөлкәрам [4].
Улдым сәфәр, кылдым җиһад [5]
Бу урыс Пүлшә йиридә.
Тарих мең дә йите йөз дә
Илле йитенче йылыда.

* * *

Ибтида [6] киләм, сүвекле җефтем [7],
Сезә сәлам әйләрем,
Гөл йөзеңне йад әйләмәйүб,
Дәрт илә аһ әйләрем.
Әй, нигярем [8], кичә-көндез
Васфыңны [9] йад әйләрем.
Сәндин фирак[10] улгандин соң,
Канду даду[11] әйләрем?
Мисле[12] айдыр кашларың,
Сыйфатә инжү дешләрең,
Кылды бәни шуридә[13],
Зөлеф[14] кылган сачләрең[15].
Әй, нигярем, сәнең йөзең,
Багудагы[16] гөлмедер.
Васыф кыла белмәсмен,—
Оҗмах ичрә хуридыр.
Васыф кылам буйларың,
Бал-шикәр тик сүзләрең.
Кылды бәгърем бер йәнә,
Нәркәс кара күзләрең.
Васыф кыла белмәсмен.
Имди сәне нәрсәгә.
Дәстүр виргел[17] нигярем,
Күкрәңдәге бәстәгә[18]!
Әй, нигярем, сәнең васфа

---

[1] Үйлә кылды — ишарә итте.
[2] Мөбәййене — бәян итүчесе.
[3] Фазлың илә — өстенлегең белән.
[4] Зөлкәрам — юмарт (алла).
[5] Җиһад — изге сугыш.
[6] Ибтида — башлап.
[7] Сүвекле җефтем — сөекле хатыным.
[8] Нигярем — сурәтем (матурлыкка карата әйтелгән), сылуым.
[9] Васфыңны — сыйфатыңны.
[10] Фирак — аерылу.
[11] Канду даду — нинди зар.
[12] Мисле — мисал.
[13] Шуридә — гашыйк (итте).
[14] Зөлеф — йөзнең ике ягына аерылган.
[15] Сачләрең — чәчләрең.
[16] Багудагы — бакчадагы.
[17] Дәстүр виргел — рөхсәт ит.
[18] Бәстәгә — сергә.

Йад әйләрем кичә-көн,
Исмең сәнең белмәк илә
Һәркем сорса да әл-нун[1],
Инде сезләр сорасан
Тәсанныйфың[2] исмене,
Изгелексез, батыйль[3] эшле,
Габдессәлам мескенне.
Дәрйаның уң йанында
Хөсне[4] агач, йарым, һай,
Башында әлхәмде укыр
Бер кара күз, йарым, һай.
Йул берлә барыр ирдем,
Һәстә-һәстә, йарым, һай.
Айакларым кабарадыр,
Күңлем самыт[5], йарым, һай.
Мән шәһәр барыр ирдем
Бер гөл өчен, йарым, һай,
Ике дохтәр[6] оршышадыр
Йегет өчен, йарым, һай.
Әй, дохтәрләр, ни оршасыз?
Йегет өчен, йарым, һай.
Йегетләр мал ийәседер,—
Шуның өчен, йарым, һай.
Агу алма, багу алма,
Балдин татлы, йарым, һай.
Гүзәл йарлар кулга төшсә
Андин татлы, йарым, һай.
Кулымда карамыз бар,
Күл күтәрмәс, йарым, һай.
Дөнйада бер йарым бар—
Сүз күтәрмәс, йарым, һай.
Кулымда бер йаулыгым бар
Бидер-бидер, йарым, һай.
Йанымда бер залим бар—
Әллә нидер, йарым, һай.
Йан йаулыгым пәрдә-пәрдә,
Урам гиздем, йарым, һай.
Аны күргән йегетләр
Ничек түзсен, йарым, һай?
Дәрйаның уртасында
Сал барадыр, йарым, һай.
Сал өстендә тутыйгош—
Йалбарадыр, йарым, һай.
Тутыйгошны багламага,
Йепәк кирәк, йарым, һай,
Гүзәлләрне алдамага
Хәйлә кирәк, йарым, һай.
Агу алма, багу алма,
Бер көнлектер, йарым, һай.
Гүзәл йарлар кулга төшсә—
Гомерлектер, йарым, һай.
Күперне уза торгач
Күрдем сәне, йарым, һай.
Бер Аллаһның хөкме берлә
Сүвдем сәне, йарым, һай.
Йарымның чыбылдыгы,
Йалт-йалт итәр, йарым, һай.
Аны теккән бармаклары

---

[1] Әл-нун — нун(н) хәрефе.
[2] Тәсанныйфың — әсәрләр язучының.
[3] Батыйль — файдасыз.
[4] Хөсне — матур.
[5] Самыт — дәшми.
[6] Дохтәр — кыз.

Ак көмеш тик, йарым, һай.
Агачның башын киссәң —
Төбе калыр, йарым, һай.
Атадин ике дуга —
Бере калыр, йарым, һай.
Йалгызның йыглып үлсә,
Нисе калыр, йарым, һай?
Алыгың сүвекле булса,
Йыглай калыр, йарым, һай.

* * *

Гажәп сәнең налишың[1],
Буйыңа кул салышын.
Хәрир[2] зибага охшар,
Һәрбер айак басышың.
Йөрер йулым төзәдер,
Кичә бәңа көндездер
Рөхсәт биргел, китәлем!
Йарым анда йалгыздыр.
Баг эче, бадам[3] эче,
Барчадин буйым кече.
Ни бакарсың буйыма,
Куйным гөлбостан эче.
Мулламәтлек үзеңә,
Гашыйкмын бер сүзеңә.
Җаным фида кыйлырам,
Коңгыр кара күзеңә.
Бу гөли хыйнамыдыр[4] (?)
Йарым багыйдамыдыр?
Йарым багыйда булса,
Мәне сагынамыдыр?
Әфтаб[5] вә әлза...ле (?)
Ай йордының тәхете.
Кашың әнә фатиха
Сурәсе, хак айәте.
Сув акар гөлдер-гөлдер,
Сүвгәнем кызыл гөлдер.
Сәндин үзгәне дуст тотсам,
Пычак ал, бәне үлдер!
Барырым йулым, имеш,
Йавлыгым тулы йимеш,
Йарымдин хәбәр килмеш,
Тормасын, йитсен, димеш.
Барырыңны белмәдем,
Барып йулда тормадым.
Тотлыгты мәнем телем,
Хуш калыңыз димәдем.

* * *

Аһ җаным, йарым, җәмалым[6],
Хушчә кальбем мивәсе[7]!

---

[1] Налишын — үксүең.
[2] Хәрир — зибага — ефәккә.
[3] Бадам — миндаль.
[4] Хыйнамыдыр — кына гөлемедер.
[5] Әфтаб — кояш.
[6] Җәмалым — матурым.
[7] Кальбем мивәсе — йөрәгем җимеше.

Ни гаҗәп хуш мәүҗүд [1] улмыш,
Сән нигярнең [2] әгъзасе.
Маһи бәдер [3] нуры һәм
Мисле тавис [4] рикъктәсе [5].
Авазы хуш гандәлиб [6] тик,
Тутый кеби кяфтәсе [7].
Шөгълә [8] кылыр золмәт [9] эчрә,
Сән нигярнең ханәсе[10]
Кашлары һилал[11] кебидер,
Һәм йаңакы лаләсе
Ничә дик мәдех[12] кыдсам,
Васыфа килмәс[13] кәсе[14].
Бәгъреме парә кыладыр,
Ул висалең[15] кичәсе.
Рузи кылсын[16] ул нигяри[17],
Бәңа гареш[18] идәсен.
Хәмед Аллаһ[19], кавыштырсын
Әкълим Казан[20] шивәсен[21].
Мәсьүл улса[22], агыз эч(и)дер
Ул нигярнең исмәсе
Габди бани тасныйф кылып[23]
Әл-фасыйлә вәзәсе[24].
Ихраҗ итте[25] бу шигырьне,
Исме фәлән кәндүсе[26].
Вилайәте[27] Болгар ирер,
Мәгълүм улсын бәндәсе.

* * *

Сүзем сәңә җан-тән илә,
Тәкатем так[28] өйләде.
Сәне бер гиз күрмәс ирсәм,
Бәгърем кәбаб әйләде.
Пүсә[29] кылган ләбләреңез[30],
Бал-шикәрдин татлы, ди.

---

[1] Мәүҗүд улмыш — бар булган.
[2] Нигярнең — сөеклене.
[3] Маһи бәдер — тулган ай.
[4] Мисле тавис — тавис кошы кебек.
[5] Рикъктәсе — йомшаклыгы.
[6] Гандәлиб — сандугач.
[7] Кяфтәсе — тулысынча.
[8] Шөгълә кылыр — ялкын итәр.
[9] Зөлмәт эчрә — караңгылыкта.
[10] Ханәсе — йорты.
[11] Һилал — яңа туган ай.
[12] Мәдех кылсам — мактасам.
[13] Васыфа килмәс — сыйфатланмас.
[14] Кәсе — шәхсе.
[15] Висалең — кавышуың.
[16] Рузи кылсын — язмыш итсен.
[17] Нигяри — сөеклене.
[18] Гареш — тәхет.
[19] Хәмед Аллаһ — Аллага мактау.
[20] Әкълим Казан — Казан җире.
[21] Шивәсен — телен, сөйләшен.
[22] Мәсьүл улса — соралган булса.
[23] Тасныйф кылып — язып.
[24] Әл-фасыйлә вәзәсе — фасыллары үлчәве.
[25] Ихраҗ — чыгару.
[26] Кәндүсе — шәһәре.
[27] Вилайәте — иле, өлкәсе.
[28] Так — ялгыз.
[29] Пүсә кылган — үпкән.
[30] Ләбләреңез — иреннәрегез.

Заты галим, фигьле галим,
Үзе фәлән атлы ди.
Казан кулы иленез һай,
Сәйран икән йиренез.
Мәдрәсәдә урнымыз һай,
Тәрәзәдә күземез.
Бакый [1] сезгә җаным фида,
Сәнме килдең йарым һай.
Бер багыйдин [2] гаклым алдың
Касдмидәрсең [3] йарым һай.
Таулар башы томандыр һай,
Сәнең сүзең гөмандыр [4].
Ничә җәһәт идәр ирсәң,
Бән бу йирдә тормамдыр.
Ходавәндә [5] ошбу нәкыш [6],
Җиһанга куш улсайде.
Хак тәгаля ләтыйф белән [7]
Озын гомер вирсәйде!
Иншалла өмидем вар.
Кавышмакга сезләрә.
Кавышубән бер үпсәм, һай,
Әфзаль ирер [8] сезләре.

* * *

Гашыйк булдым бер нигярә [9],
Йөзедер шәмсекамәр[10].
Агзы шикәр, теле бал, һай,
Ләбләре[11] балдин битәр.
Һәмчү сөнбел[12] сачләре,
Кавырсын тик[13] кашлары,
Йанды йөрәгем нарә[14], һай,
Сафи җенҗү[15] дешләре.
Әй, нигярем, күр бәне,
Гыйшкың бәне нәйләде:
Талчыбык тик буйларың, һай,
Сабырым гарабәт[16] әйләде.
Сәд һәзаран[17] җан илә
Гашыйк улдым бән сәңа.
Инша халең[18], нә гаян, һай[19],
Уламассың сән бәңа.
Ачылыр йазы-йапан[20],
Сайрайур былбыллары.
Шадилә вә хуш тойыр, һай,

---

[1] Бакый — мәңге.
[2] Багыйдин — караудан.
[3] Касдмидәрсең — телләрсеңме.
[4] Гөмандыр — шик-шөбһәлесдер.
[5] Ходавәндә — хода.
[6] Нәкыш — бизәк.
[7] Ләтыйф белән — йомшаклык белән.
[8] Әфзаль ирер — кадерлерәк булыр.
[9] Нигярә — сурәткә (гүзәлгә).
[10] Шәмсекамәр — кояш белән ай.
[11] Ләбләре — иреннәре.
[12] Һәмчү сөнбел — гиацинт чәчәгедәй.
[13] Кавырсын тик — кош канатыдай.
[14] Нарә — утка.
[15] Җенҗү — энҗе.
[16] Гарабәт әйләде — бетерде.
[17] Сәд һәзаран — йөз мең.
[18] Инша халең — яз хәлең.
[19] Нә гаян һай — күренеп торучы була алмассың, һай.
[20] Йазы-йапан — дала.

Әйләйүр голголлары [1].
Шул дәгъвәга фәрех илә [2]
Парә [3] улып инде жиһан.
Уйнайур әнсе пәри [4], һай,
Мисле багъ әнвар жинан [5].
Иллә бәндәнен уйы
Бәне хәсрәт нәйләде.
Бәхре гыйшкының [6] дабы [7], һай,
Бәне дотык [8] әйләде.
Сагыдин сырхау [9] әйләде:
Бу гыйшкының халеме,
Халика[10] заһир әйләде[11], һай.
Сер мани[12] исә кеми,
Дусты Габдулла өчен
Диде Искәндәр нәби[13].
Назмы көлли[14] мәгъшукына, һай,
Васыйл итсен[15] хак нәби.

* * *

Дөшем эчрә күрдем сәне,
Буйларың буйдин зифа.
Уйганубән[16] гашыйк улдым,—
Аң, жаным кылдым фида.
Үтәр идем карьяңездин[17]
Бер вакытта көндезем.
Ал шәһребан[18] сурәтеңне
Күрде шул дәм[19] бу күзем.
Ай кеби йакты йөзең, һай,
Бал кеби татлы сүзең.
Гыйшык дәрдгә салды бәне
Шул ике кара күзең.
Мисле Мәҗнүн кылды бәне
Һай, бу гыйшык халләре.
Саргайыптыр бән фәкыйрьнең,
Гөл тик кызыл йөзләре.
Бакчадагы гөл чыбыкның
Талына былбыл кунар.
Сәнең кеби зифа йарлар
Күзләренә бай сынар.

[1] Голголлары — кош сайраулары.
[2] Фәрех илә — шатлык белән.
[3] Парә — кисәк.
[4] Әнсе пәри — төрле-төрле гүзәл затлар.
[5] Әнвәр жинан — нурлы җәннәт.
[6] Бәхре гыйшкының — мәхәббәт диңгезеннән.
[7] Дабы — бөеклеге.
[8] Дотык — тоткын.
[9] Сагыдин сырхав — саудан чирле.
[10] Халика — Аллага.
[11] Заһир әйләде — күрсәтте.
[12] Мани — моны.
[13] Нәби — пәйгамбәр.
[14] Көлли — һәммә.
[15] Васыйл итсен — ирештерсен.
[16] Уйгану бән — уяну белән.
[17] Карьяңездин — авылыгыздан.
[18] Шәһребан — ай кебек.
[19] Дәм — бер мизгелдә.

* * *

Мәхбүбеми [1] күрдем ирсә,
Дел хас кылып йөзенә,
Йөзен аның тәшбиһ иттем [2],
Җәннәт эчрә хур кызыйнә.
Әгәр сүзе улса тагълар,
Әлван-әлван [3] гөл багълар,
Биле нечкә, зифа, гөлзар [4],
Агъзы шикәр, деле бал.
Әй нигярем, Алла сәндин
Кылыр ирсә әлфирак [5],
Рәжа [6] хасил улмаса,
Бәңа үлем йахшырак!
Йаным шәбдә йадма килсә,
Һәргиз йокым килмәйдер.
Сәндин гайре вар җиһанда
Иллә күңлем сәндәдер.
Күз йәшем акызды сияһ [7],
Барнакым [8] улды каләм.
Бу бәйетне тасныйф иттем [9],
Сән мәхбүб йарә сәлам.

* * *

Әй, нигярем, пәстә[10] агъзың,
Ләбләреңез[11] бадәтар[12],
Дешләрең әнҗүйә нисбәтдер,
Йөзләрең шәмсекамәр[13].

Кашларын һилалә[14] тиңдәшдер,
Буйларың сәрви шәҗәр[15].
Улмагай һәргиз[16] җиһанда
Сән сыйфатлау гөлгыйзар[17].

Сәни дирләр һуп сурәтле,
Мәүҗүд[18] улмышдин хәбәр.
Кани[19] сәндин гайре дилбәр,
Кани сәндин үзгә йар?

Сән дилбәрне арзу әйләп[20],
Һәр кичә дотам сәхәр[21].

---

[1] Мәхбүбеми — мәхәббәтемне.
[2] Тәшбиһ иттем — охшаттым.
[3] Әлван — төрле.
[4] Гөлзар — чәчәклек.
[5] Әлфирак — аерылу.
[6] Рәжа — өмет итү.
[7] Сияһ — язу карасы.
[8] Барнакым — бармагым.
[9] Тасныйф иттем — яздым.
[10] Пәстә — фисташка.
[11] Ләбләреңез — иреннәрегез.
[12] Бадәтар — шәрап сыйфатына ия.
[13] Шәмсекамәр — кояш белән ай.
[14] Һилалә — яңа туган айга.
[15] Сәрви шәҗәр — пальма агачы.
[16] Һәргиз — һичкайчан.
[17] Гөлгыйзар — гөл яңаклы.
[18] Мәүҗүд — бар булган.
[19] Кани — кайда.
[20] Арзу әйләп — теләп.
[21] Сәхәр — таң.

Гашыйк көнендә гидай [1] тик
Гизәрем бән дәр-бәдәр [2].

Загълы [3] йирдә тутый былбыл
Һәргизән [4] кылмас карар...
Ләкин улмаз тәкъдир үзрә
Тәбдил улмак [5] ихтыйар.

Терек дөнйа кылгыл, әй дуст,
Кимә атлас илә зар!
Бивафадыр [6] ушбу дөнйа
Улмайа улдасы йар.

Йан улуы сән гүзәлнең
Гыйшкы берлә бу кадәр,
Чарасын кыл, һәр нә кылсаң,
Дөмбәдем [7] артыр зарар.

Бу мөбин [8] исем даим
Йай [9] илә кылды карар:
Бакыйлык[10] йук һәр кемсәгә,
Улса-ләйләтел — бәдер[11].

Бусә кылсам[12] ганҗә агъзың[13],
Ләбләрең ширин бер тат.
Кәббәрүгез[14] бәшьйа кылса[15],
Кылмагыл сән хуп торрәһәт[16].

* * *

Хилафдин[17] чыгубән йөрдем иртә,
Кем билеңдин кочтым төн уртасында?
Шул күренгән сары болыттаймыдыр,
Арамызда безем илләр сагъмыдыр?
Йитә-йитмәс намыңа[18], сереӊ алырыма,
Һавадагы былбылга загъ[19] кундырма.
Сөләйман пәйгамбәр кош телен укыр,
Анларның сүзләре йалганмы улыр!
Гашыйк улып, мескен йөреп таң аттыр,
Сүзләгән сүзендин галимнәр куркыр.
Шайтан улып адәм әһлин аздырыр,
Мөэминләрнең кәгъбәсене боздырыр.
Катыг йәйә мәгәрдин укмы атмайын,

---

[1] Гидай — ярлы.
[2] Дәр-бәдәр — дәрвиштәй.
[3] Загълы — каргалы, козгынлы.
[4] Һәргизән — һичвакытта.
[5] Тәбдил улмак — үзгәртүгә.
[6] Бивафадыр — тотнаксыздыр.
[7] Дәмбәдем — өзлексез.
[8] Мөбин — хакыйкатьне аеручы.
[9] Йай — җай.
[10] Бакыйлык — мәңгелек.
[11] Ләйләтел-бәдер — тулган айлы төн.
[12] Бусә кылсам — үпсәм.
[13] Ганҗә агъзың — гөлбакчасы булган авызыгыз.
[14] Кәббәрүгезе — горурлыгыгыз.
[15] Бәшьйа кылса — елмайса.
[16] Торрәһәт — юк-бар, чүп-чар.
[17] Хилафдин — ярамаган урыннан.
[18] Намыңа — исемеңә.
[19] Загъ — карга, козгын.

Гәүһәр алып базаркянә [1] сатмайын.
Атадан-бабадан бәклек итмәйен,
Солтан улып илең корытмайын.
Сәнең өчен сигез җәннәт мивәсе,
Куйны тулы мивә [2] илдин (нур) киләсе.
Әлемне [3] вирдем мәрданә [4] әлинә,
Сәчрап мендем бән, һай, дөлдел [5] биленә.
Йар кадрен белмәскә йәшем йәш дәгел,
Әгъламый нәйләйем [6], халем хуш дәгел.

* * *

Аһ, бәнем шу ким талигым [7] чөн дугманың, әй ширин йар [8],
Күрмәк өчен гөл йөзеңне газиз уйым бикарар [9].

Йөрер ирдем бер вакытта каййәнездә көндезем,
Әй ширин, сурәтеңне күрде шул дәм бу күзем.

Сәрүви камәтеңне[10] күрмәсәче күзләрем,
Күрдекемдә зәгъфран дик сарыйг улды йөзләрем.

Зарым әйтмәк сәндин үзгә кемсәләргә нә сөзә,
Ләбләреңнең[11] абыдин виргел[12] ул бәңа айлык азык.

Ай кеби йакты йөзең һәм бал кеби татлы сүзең,
Салды бәне гыйшык утыйга шул ике кара күзең.

* * *

Әй мәнем җаным, ай тик йөзеңне күрмәгәйдем, кяшки[13],
Ширбәт ширин лебеңдин[14] татмагайдым, кяшки.

Чук кара зөлфең[15] айагымы грифтар[16] әйләде,
Мән сәнең берлән мөсахиб[17] булмагайдым, кяшки.

Мән сәне җаным дидем, җаным кеби сүвдем сәне,
Гәр бәне йаратмаз ирсән, мәүләйә[18] салдым сәне.

* * *

Кичә-көндез йөкердем күрмәк өчен сәндиш нишан[19],

---

[1] Базаркянә — сәүдәгәргә.
[2] Мивәсе — җимеше.
[3] Әлемне — кулымны.
[4] Мәрданә — ирләрчә.
[5] Дөлдел — чаптар мифик ат.
[6] Әгъламай нәйләйем — кайгырмый нишлим.
[7] Ким талигым — ким бәхетем.
[8] Ширин йар — асыл йар.
[9] Бикарар — чарасыз.
[10] Сәрүви камәтеңне — кипаристай буйларыңны.
[11] Ләбләреннең абылин — иреннәрең суыннан.
[12] Виргел — бир.
[13] Кяшки — эх, әгәр дә.
[14] Ширин лебендин — татлы иреннәреңнән.
[15] Зөлфен — толымнарың.
[16] Грифтар әйләде — тоткын итте.
[17] Мөсахиб — сердәш.
[18] Мәүләйә салдым — алла иркенә куйдым.
[19] Нишан — билге.

Канда [1] сән, гөлгыйзарым [2], гөл йөзең күргәз гайан [3].

Кичләрдә даим бәнем уйку килмез күземә,
Йимәк-эчмәк арзу кылмаз [4] — ни улды бәнем үземә?

Аh идәрем, йандырыр тәбәссемлә [5] галәми,
Сабры варым кичә белмәз ушбу хәстә [6] хәлеми.

## Бәйет

*(1758 ел)*

Керпекнең укдыр, күзең утдыр, үзең — күңлем рәгъбәте [7];
Йарны сүвмәк, гыйшык дотмак — әнбийәләр сөннәте [8].

Дешләрең әнҗи кебидер, агызын уймак кеби,
Көн би көн артыр бу гыйшкым суга су коймак кеби.

Йук мәҗалем [9], кил, гүзәлем, туйганчы бер бакмага,
Камәтең[10] таййар[11] сәнең бәне утка йакмага.

Кайсылар кем делдә йөрде һәйьәтең рәсмең сәнең,
Кайсы мәктүбтә укылды кыйсса-и хәснең сәнең?

Кемсәләрдә гыйшык тормас, кальбе гәр[12] пакъ улмаса,
Интиһаи[13] гыйшык улмас, тән череп хак улмаса.

Йуктыр ки җан илә тән сүвмәсмичә күчкән дөнйадин,
Сүвешүдин айрылганчы, тугмасамчы анадин.

•

---

[1] Канда — кайда.
[2] Гөлгыйзарым — гөл яңаклым.
[3] Гайан — ачык.
[4] Арзу кылмаз — теләмәс.
[5] Тәбәссемлә — елмаю белән.
[6] Хәстә — авыру.
[7] Рәгъбәте — теләге.
[8] Әнбийәләр сөннәте — пәйгамбәрләр законы.
[9] Мәҗалем — хәлем.
[10] Камәтең — гоган.
[11] Таййар — хәзер.
[12] Кальбе гәр — әгәр йөрәге.
[13] Интиһаи — чикле.

# ТАТАР РЕКЛАМЫ: КИЧӘ ҺӘМ БҮГЕН

Заманыбыз шаукымыдыр инде, башка күп кенә яна төшенчәләр белән бергә реклам сүзе дә халык сөйләмендә булсын, матбугат, радио, телевидениедә булсын ешрак ишетелә-күренә башлады. Хәер, әдәби телебездә ул инде күптәннән йөри. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу сүз ике мәгънәдә теркәлгән: 1. Файдаланучыларны, кулланучыларны, сатып алучыларны, тамашачыларны һ. б. тарту, аларның игътибарын җәлеп итү максаты белән үткәрелгән чара; 2. Кемнең дә булса дикъкатен юнәлтү өчен берәр кеше яки берәр нәрсә турында хәбәр, мәгълүмат бирә, игълан итә торган белдерү, плакат, афиша, вывеска һ. б. ш.

Шулай да бүгенге буын кешеләре аңында реклам төшенчәсе ул әле әйтелгән чараларның басма рәвештә, башлыча матбугатта һәм радио, телевидениедә бәян ителүе. Татар аңында ул элек-электән нәкъ шул мәгънәдә генә килгән дә — басма сүз белән, газет-журнал белән реклам аерылгысыз. Беренче сәяси сүзлекләрнең берсендә (аны күренекле драматург, публицист һәм тәрҗемәче Галиәсгар Камал төзегән) бу төшенчә болай теркәлгән: алучыларның дикъкатен җәлеп итәр өчен нинди дә булса бер мал хакында басылып таратылган яки гәзитләрдә бастырылган игълан. (К а м а л Г. *(Мөтәрҗим) Русча-татарча сәяси лөгать. Казан, Өмет, 1918, 106 б.)*

Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов һәм башка әдипләр реклам төшенчәсен нәкъ шушы мәгънәдә, нәкъ менә матбугат белән мөнәсәбәттә кулланганнар да. Сүз башлыча туры, уңай мәгънәсендә алынган. Тискәре төсмер салу очраклары да бар. Г. Ибраһимов, мәсәлән, «Китап игъланнары» мәкаләсендә (*«Йолдыз», 1912, 4 март)* «Игълан башка, куык вә реклам башка», ди. Реклам бу урында, куык кебек үк, арттыру, ялганлау мәгънәсендә.

Классикларыбызның кайбер фикерләрен алда да телгә алырбыз әле, ә хәзергә игътибарны бу терминны аларның **реклам** дип язуларына юнәлтеп китик. Утызынчы елларга чаклы фәкать шулай язылган. Дөресе дә шулай: тамыры латинча гесвато — кычкырып эндәшү. Русларга ул французчадан алынган, ә безгә исә руслардан кергән. Хәлбуки, а га беткән алынмаларны кыскартып куллану (р а м, ф а н е р, к у к у р у з, к а н ф е т, г а з е т һ. б.) закончалыгы бу сүзгә дә катгый кагыла. Төрекләрдә дә, мәсәлән реклам.

Реклам төшенчәсенең матбугатка бәйле төсмере ни сәбәпле «Аңлатмалы сүзлек...»кә теркәлмәгән һәм әдәби телдә кулланылуы да 40—50 ел буе сүлпәнләнеп торган? Беренчедән, бу төшенчә дә сәяси идеологиягә капкан, сыйнфый караш астына алынган. Бар иде капиталистик реклам, бар иде — социалистик. Болар капма-каршы төшенчәләр саналганга, капиталистик рекламга хас бөтен нәрсә — уңае да, тискәресе дә — бер чыбыктан сөрелеп, гел яманланды гына. Икенчедән, — ул беренче сәбәптән килеп чыга, — капиталистик реклам массакүләм информация чараларыннан аерылгысыз икән, димәк ки, социалистик рекламга андый бәйләнеш мәҗбүри түгел. Чыннан да, бу эш партия-совет матбугатының төп вазифаларына керми иде, ул дәүләтнең махсус оешмаларына йөкләнгән, реклам бирүчеләр белән рекламны бәян итүчеләр арасында арадашлык шулар кулында; ике тараф да үз белдеге белән берни эшли алмый иде. Татар газет-журналлары да ярты гасыр буе шушы тәртип белән яшәде.

Соңгы елларда хәл үзгәрә башлады: бер яктан, товар җитештерүчеләрнең, көнкүреш хезмәте һәм башка (сәнгати, мәдәни, юридик, медицина һ. б.) хезмәт күрсәтүчеләрнең, сәүдәчеләр һәм кәсепчеләрнең мөстәкыйльлегенә берникадәр юл куелу; икенче яктан, массакүләм информация чараларының да чагыштырмача иркенлек алуы, гомумән дә, демократия, хәбәрдарлыкның борын төртә башлавы

реклам өлкәсенә дә йогынтысыз калмады. Татар рекламы да хәрәкәткә килде дияргә була.

Бүген иң мөһиме, безнеңчә, бу хәрәкәткә бармак аша карамаска, игътибарлы булырга кирәктер. Ни өчен? Иң әүвәле, ул һәркайсыбызга кагыла — житештерүчегә дә, кулланучыга, арадашчы-сәүдәгәргә дә. Димәк ки, реклам ул, фәнчәрәк әйтсәк, иҗтимагый күренеш. Шуңа күрә дә аның массакүләм информация чаралары белән бәйләнеше дә табигый һәм закончалыклы. Аннары, чамалавы кыен түгел: житештерүче һәм аның товарын алучы бар икән, ягъни сәүдә яши икән, татар моңа гамьсез кала алмый, сәүдә аның милли аңында, канында. Риза Фәхретдин әйтмешли: «Кырмыска шикәр тәмен ничек белсә, татар да сәүдә тәмен шулай белә». Ә сәүдәне инде рекламсыз күз алдына китерү мөмкин нәрсә түгел.

Бүген татар рекламын ни көтә, ул нинди булырга тиеш? Чү, тукта! Вакытлы-вакытсыз, белер-белмәс тәкъдим-күрсәтмәләр бирергә кабаланабыз түгелме!? Алыш-биреш ул ике тарафның үз эше, үз мәсьәләләрен үзләре хәл итәр; рекламга да идеологиянең, сәясәтнең тыкшыну-кысылуы гайре табигый саналырга тиештер.

Шулай бу эшчәнлектәге мәҗбүри, котылгысыз хакыйкатьләрне хәтергә төшереп китү дә зыянга булмас. Иң башта, рекламчылык әлбәттә, икътисад, сәүдә канун-кагыйдәләренә таянган хәлдә милли үзенчәлекләрне, гореф-гадәтләрне дә тибәрмәскә, шул ук вакытта халыкара әхлак һәм хокук законнарына, ягъни гомумтанылган тәртипкә дә нигезләнергә тиеш буладыр.

Күрәсез, реклам кәсебен ныклы нигездә тернәкләндереп җибәрер өчен фәнгә дә эш җитәрлек — әле гореф-гадәт, традицияләрне, әхлак, әдәп, кануннар нидән гыйбарәт, ата-баба нинди уңыш-казанышларга ирешкән булган, нинди-нинди сабак, гыйбрәтләр калдырган — һәммәсен фәнни нигездә бөртекләп өйрәнергә, шуларга таянып, шулай ук фәнни нигездә, тәкъдим-рекомендацияләр әзерләргә кирәк. Ә нindиерәк кыйблалар күздә тотыла соң?

Реклам милләтнең үзаңы, гореф-гадәте белән бәйле булганга, аның тәҗрибәсен халыкның үз тарихыннан, беренче чиратта аның язма мирасыннан, аерым алганда, матбугат еллъязмаларыннан эзләү мәслихәттер. Матбугатыбыз тарихы, шул җөмләдән газет-журналларыбыз да шактый тирән өйрәнелгән булса да, кызганыч ки, реклам тарихы, әлеге дә баягы, аңа карата сыйнфый караш хөкем сөргәнгә, бер читтә кала килде.

Тулаем алганда, татар рекламының тарихын да, бүгенгесен дә ике тармакка аерып өйрәнү кулайдыр: беренчесе — газет-журналга бәйләнмәгән реклам (товар ярлыклары, афиша, игъланнар, проспект, каталог, альбомнар h. б.). Аларның үз чиратында язма-басма, тавышлы-әйтмә h. б. төрләре була. Һәр төренең үз тарихы, үз алымы, юнәлешләре — татар эшмәкәрләренең, сәүдәгәрләренең, шулай ук рекламчыларының күп гасырлык бай тәҗрибәсе җентекле өйрәнүне көтә.

Икенчесе — газет-журналга бәйле реклам. Татар матбугатының беренче газет, журналлары ук эшне рекламнан башлаган — аларга бит иң башта үзенә укучы табарга кирәк булган, аны җәлеп итү өчен үзенә-үзе реклам бирергә мәҗбүр булган. Татар матбугаты чәчәк аткан чорларда (1905—1908, 1917—1919 елларда) чыккан кайсы гына газет, журналны алма, һәркайсының беренче битендә иң күренекле урында күзгә бәрелә торган шрифт белән, мөмкинлек биргәндә төрле сурәт, нәкышләр, хәтта төсле буяулар белән бизәлеп, тәэсирле итеп язылган үз игъланнарын күрәсең. Берничә телдә язылган булыр: «Вакыт» газеты, мәсәлән, үзе турындагы рекламны инглиз, рус телендә дә биргән.

Шулай итеп, матбага чаралары, нәшир, журналистлар ул елларда рекламны үтемле итеп язу, аны укучыга җиткерү, ничек тәэсир итүен өйрәнүдә нык остарганнар, тәҗрибә туплаганнар. Шуңа күрә алар реклам бастырырга теләүчеләрне дә яхшы аңлаганнар, үзара файдалы мөнәсәбәт урнаштыра башлаганнар. Уртак омтылыш белән, укучыларның да фикерен искә ала-ала, акрынлап реклам мөнәсәбәтенең тәртип-кагыйдәләре бөртекләп туплана килгән.

Әлбәттә, төрле газет, журналда бу тәҗрибә төрлечә. Ул журналист, мөхәррирләрнең рекламга карашына, реклам бирүчеләрнең кем булуына, байлыгына, реклам хуҗасы белән нәшир арасындагы мөнәсәбәткә, янә дә бүтән шартсәбәпләргә бәйле. Әйтик, безнең анда «рекламчы газет» дип яманаты чыккан газет та бар иде. «Бәянелхак». Шиксез, мондый фикер бездә Г. Тукай әсәрләреннән тамып-тамып җыелгандыр. Бу газетның реклам сәясәтенә карата аның бик тә әче, үтә дә чәнечкеле гыйбарәләре бер генә түгел. Мәсәлән: «Күз алдыбызда һәр «заман» «хакыйкать» булып, «хак»ны кычкырып, «игланелхак» итмәк тиештер — хәтта сыра заводы ачылуы хакында булса да» (Т у к а й Г. *Әсәрләр. 4 томда. 4 т. Казан, 1956. 63 б.*)

Күрәбез ки, шул чордагы матбугатның үзеннән үк рекламчылык хәрәкәтенә җәмәгатьчелекнең, укучыларның һәм дә реклам бирүчеләр белән реклам басучыларның үзләренең мөнәсәбәте дә ачыклана. Әйтик, «Карчыга» журналында басылган менә бу юллар күп нәрсә сөйли кебек: «Байлар, морзалар вә муллалар җырын җырлаучы газетларга байлар һәр җәһәттән ярдәм кылышсалар да, безнең кеби эшче халык файдасына язучыларга алар ярдәм итмиләр, бәлгакыч (*киресенчә* — Н. И.) безгә һәр хосуста аркылы килеп, журналыбызны туктатырга чара эзлиләр» *(Карчыга, 1907, № 9, 2 б.)*.

Сүз дә юк, рекламга, реклам бирүче белән аны басучыга ул дәвердәге төрле караш, төрле фикер гомумән алганда бу тормышчан күренешне йә хурларга гына, йә хупларга гына нигез була алмый. Фактта реклам тулаем кабул ителгән, иҗтимагый кирәкле дип саналган объектив күренешкә әверелгән инде. Г. Тукайның реклам белән үз максатларында артык мавыгучыларны утлы табага басырып язылган фельетоннары басылган газет, журналлар үзләре дә рекламнан бик оста файдаланганнар лабаса.

Димәк ки, шул чор өчен иҗтимагый әһәмиятле күренештән бүген дә эшкә яраклы нәтиҗәләр табылуы бер дә гайре табигый түгелдер. Шул ук «Бәянелхак» газетын алып карыйк. Мәсәлән, ул вакытта матбугатта фотодыр, бүтән сурәттер әле юк дәрәҗәсендә, тоташ битләр — «яп-якты» — хәреф, сызыктан гына тора, бертонлылык хөкем сөрә. Ә менә рекламчылар үз игъланнарын җанландыру, карашны җәлеп итәр өчен төрледән-төрле сурәт-клишеләр тәкъдим итәләр: герб-символлар дисеңме, машина-техника, пароход-паровоз сурәтләре дисеңме, күренекле шәхесләрнең йөз, кыяфәтләреме — болар аерым игъланны гына түгел, бөтен газетны җанландырып җибәрә. Укучыны мавыктырып кына да калмый, ә бәлки аңарга өстәмә мәгълүмат, белем дә бирә.

Гомумән дә, ул еллардагы игъланнарда беренче нәүбәттә укучыны күз алдында тоту омтылышы сизелә. Әйтик, «Бәянелхак» үзенең төп укучысы шәһәр эшмәкәре, сәүдәгәр, байлары дип белә. Ә андыйлар русчасын да «сукаларга» тырыша. Шуңа күрә алар игъланнарны русчалы-татарчалы бирүне хуп күрә.

Шул ук вакытта, уйлый китсәң, Тукайны да аңларга була: татар халкы патша хакимияте, үзенең дә кара көчләре белән күптән тартыша-көрәшә. Ниһаять, 1905 елны инкыйлаб чыккач кына яулап алуга ирешкән газет, журналларын беренче чиратта үзенә, үзенең азатлыгы, тәрәккыяте мәнфәгатенә, үзен белемле итү, агарту ихтыяҗларында файдаланырга тели. Нишләп кайбер газетлар аерым байлар, кәсепче, сәүдәгәрләр мәнфәгатен генә кайгырта? Нишләп әле аларда рус промышленник, фабрикантларының, чит мәмләкәт капиталист, алыпсатарларының игълан, рекламнары көннән-көн күбрәк басыла? Җитмәсә, һәр игълан диярлек русчалы-татарчалы? Тукайга — газет, журнал татарга, татар әдәбиятына, татар теленә хезмәт итәргә, аның үсешенә өлеш кертергә тиеш дип хыялланган, шуңа кыйбла тоткан, җанын-тәнен кызганмаган зыялы затка, газетның һәр юлының, һәр хәрефенең кадерен белгән әдипкә — шул кадерле урынның русчага исраф булуы бик авыр кабул ителгән. Моңа бәгыре ачытканын ул яшереп тә тормаган, җае чыккан саен шуннан ачы көлгән. Бер фельетонында ул, мәсәлән, «Бәянелхак» мөхәррире Сәйдәшевне болаерак «чеметеп» ала: «Мөхәммәтхан Чәйдәшев: «Тулстуй, Тулстуй, әмма аның үлеме аркылы игълан җыярга юл ачыла бит. Атнасына өч чыга торган «чүплегем»дә яңадан бер кат урысча мәкалә дәреҗ итәргә (*кертергә* — Н. И.) мөмкин була бит. Тулстуй үлде, да здравствует сыра заводларының игъланнары!» (Т у к а й Г а б д у л л а. *Әсәрләр. 4 томда. 4 т. Казан, 1956, 66 б.*)

Ялгышмасам, хөрмәтле укучым язманы уку барышында да тарихи фактларны бүгенге белән чагыштыра килә, нәтиҗә дә ясый булса кирәк. Әйе шул, бүген дә кайбер газет, журналлар (мәсәлән, «Татарстан яшьләре», «Кызыл таң», «Татарстан» һ. б. (реклам материалларының теленә талымсызлык күрсәтәләр, вакыт-вакыт «чеп-чи» русча игъланнар чирек, хәтта ярты битне биләп ала, тышлыкларыннан чекрәеп тора. Билгеле инде, бай рекламчыга ярарга тырышыла. Ә газет укучы мәнфәгате ник санга сугылмый? Ул бит газет, журналга иң башта ана телендә укып бару ниятеннән, аннары, һәр юлыннан зиһенгә дә, җанга да яңалык, рухи азык алу өметеннән языла. Ул да акча түли, өстәвенә алдан түләп куя.

Әлбәттә, русчалы-татарчалы текстларның да файдалылары була: транспорт, элемтә расписание-тәртипләре, русча әдәби, сәнгати әсәрләргә, яңалыкларга бәйле игъланнар һ. б. Аларына күпчелек каршы түгел бит. Гомумән дә, халыкның, укучыларның күпчелеге мәнфәгатьләрен истә тотканда, рекламның аны бирүче белән бастырып чыгаручының матди ихтыяҗлары гына түгел, ә бәлки күпчелекнең рухи, әхлакый мәнфәгатьләре дә туры килеп төенләнердәй яклары аз

түгел. Матбугат иң башта шуларын үзәккә куярга тиештер. Монда тел мәсьәләсеннән дә бигрәк эчтәлек алга чыга. Бүгенге укучы рекламның эчтәлек ягын ничек кабул итә? Бу хакта сүзне озакка сузмыйча, бүгенле-кичәле газетларда басылып чыккан ике генә хаттан өзек китереп китәбез: «Телевизорда токымлы мәчеләр турында тапшырулар ешайды. Эт-мәче өчен махсус әзерләнгән ризыклар белән дә тамаша кылалар. Бусы — реклама эше. Шундый авыр заманда, минемчә, болары артык — ачуны китерә торган нәрсә...» (*Татарстан хәбәрләре, 1993, 12 март*); «Кызыл таң»да шушы көннәрдә, «Лигас» фирмасы калай банкаларда консервланган ананас һәм бананнар тәкъдим итә, дигән реклама белдерүе чыкты... Юк инде, господа-әфәнделәр! Безне ананас-банан ашатып алдатмакчы, капиталистлар табынына сөйрәп утыртмакчы буласызмы?.. Бәрәңге — менә безнең ананас! Без аны туйганчы ашарлык үстерәбез. Язга таба гына шыта башлый. Подваллар шәп түгел безнең. Әлегә хәтсезен чыгарып түгәргә туры килә. Менә шул безнең өчен авыр мәлдә тәкъдим итсәгез икән. Бәрәңге тәкъдим итсәгез икән, димен мин» (*Кызыл таң, 1993, 24 февр.*). Шөкер, үзебездә әле туры Тукайның җор рухы сакланган икән, рекламга да без аныңча карый алабыз икән...

Шул хакта, ягъни рекламның тулаем халык өчен, шушы газет, журналны укучы күпчелек өчен, милләтнең тәрәккыяте өчен әһәмияте турында уйланганда янә тарихка мөрәҗәгать итү мәслихәттер. «Еракка китеп кара син, еракка китеп кара...» Уйлый калсаң, бу киңәш бик урынлы да түгел кебек, реклам бит ифрат та минутлык хаҗәт. Нинди товарчы, хезмәт күрсәтүче яисә сәүдәгәр бүгенгене бер читкә куеп, тарих өчен игълан бирер икән!?

Шулай да мин үзем, мәсәлән, гасыр башында басылган күп кенә реклам материалларын бүген дә кызыксынып укыйм. Нинди факт, мәгълүматлар, вакыт каршылыгын җинеп чыгып, бүгенгәчә кызыклыгын, әһәмиятен саклый алган соң? Рекламчылар, сез дә мыегыгызга урый барыгыз әле:

— халык өчен бик кирәкле, күптән көтелгән әйбер, товар житештерә башлау турында өр-яңа мәгълүматлар;

— фән, техника, медицина дөньясындагы прогрессив яңалыклар;

— мәңге искерми торган әдәбият, сәнгать, әхлак темаларына караган хәбәрләр;

— милләтебез өчен, туган ягыбыз өчен горурлык тудырырлык ядкарь булып калган истәлекләр;

— кешеләрдә миһербанлык, олы күңеллелек, ихтирам хисе, башка җан ияләренә карата мәрхәмәтлек кузгата торган мәгълүматлы игъланнар һ. б. ш.

Рекламның эчтәлеге генә түгел, аны бәян итүнең, басып чыгаруның үзенчәлекләре, башкаларны кабатламыйча, калып-штамплардан качып, яңа алымнар табуы да иҗади табыш булып кабул ителә.

Татар матбугатында да еллар узып та шул сыйфатларын җуймаган рекламнар аз түгел. Бер генә мисал китерим. И. Н. Харитонов басмаханәсе рекламын («Вакыт» һәм башка газетлардан) мин кабат-кабат укыдым, кайтып-кайтып күздән кичердем, хәтта үзенә күрә бер анализ-тикшеренү кебек нәрсә дә үткәрдем.

Игълан газетның гадәти бер почмагында әлләни чекрәймичә, басынкы-тыйнак кына урнашкан булыр, шулай да ул эчке бер ягымлык белән, хәтта серле бер тылсым белән димме, үзенә тартып тора. Бирелеп укый башлыйсың. Нәрсәсе белән ул бүген дә үзенә җәлеп итә?

Иң әүвәле, рекламчы үзе мәгълүм кеше — Иван Николаевич Харитонов — заманының алдынгы карашлы, тәрәккыять өчен тырышучы шәхес. Әнә шул сыйфатлары белән ул тарихка да кереп калган. Аның басмаханәсе Казанда татарча китап басуга иң зур өлеш керткән оешма булган. Биредә дөньяви, халыкка, аның белемен үстерүгә хезмәт итә торган әдәбият басыла; татар әдипләренең күпчелеге бу типографияне, аның хуҗасын хөрмәт итә, әсәрен шунда бастырырга тырыша. Басмаханә гарәп шрифтларын үзе ясый, үзе коя, бу юнәлештә ул казанышларга ирешә, иң мөһиме, ул үз китапларын басу ихтыяҗларын канәгатьләндереп кенә калмый, шрифтлар белән башка басмаханәләрне дә тәэмин итәргә омтыла. Реклам менә шушы максатка тәкъдим ителгән дә.

Әлбәттә инде, үтмәс товар кодалаучы гадәти белдерүләрдән ул бер башка өстен: әрсезләнеп яисә ялагайланып өндәми, товарны шапырып мактамый; үзе койган гарәпчә-татарча шрифтларның өстенлеген ышанычлы дәлилләр белән исбатлап бирә, хәрефләрне кою шартларын, тәртибен үтемле итеп төшендерә, хәреф коюдагы яңалыкларны да житкерә (озакламый бакыр хәрефләр эшләнәчәк икән).

Татарның тотып караса гына ышануын «хуҗа» яхшы белгән күрәсең: игълан басмаханә коеп бирә торган хәрефләрнең (кегль) барысын да кертеп җыелган,

ягъни рекламда ук товарның үзе тәкъдим ителә. Димәк, һәр хәреф, һәр тамга үзе — мәгълүмат, информация чыганагы.

Эшмәкәр буларак та, рекламчы буларак та Харитонов эшлекле, «хәйләкәр». Шушы ук рекламда ул «кстати» дигән кебек кенә рус хәрефләрен кою белән шөгыльләнүен дә искәртә. Маңгайга бәреп әйтми, ә җаен таба — Кырымда чыга торган «Тәрҗеман» газеты хуҗасы-мөхәррире Исмәгыйль Гаспралының Харитоновка русча язган хат тексты китерелә. Гаспралы басмаханә коя торган татарча хәрефләрнең чыннан да югары культуралы, яхшы сыйфатлы булуы белән соклануын, аларны сатып алачагын хәбәр итә.

Бу материалда янә басмаханә эшләп чыгара торган бизәкләү чараларын да күрәбез, ул, мәсәлән, милли рухтагы, полиграфия казанышы да саналырлык, сәнгатьчә эшләнгән орнамент сурәте белән дә бизәлгән.

Тарихчылар белә, элекке реклам текстлары, әлеге мисалдан да күренгәнчә, үзенә күрә бер тарихи чыганак та була ала. Мәсәлән, гади генә игъланнардан да мәгълүм шәхесләрнең шөгыль, чыгышлары, күренекле труппаларның, артистларның гастрольләре, теге-бу тарихи оешмаларның, фиркаләрнең барлыкка килүе, эшчәнлеге турында мәгълүмат табып була. Үзем шәхсән Көнчыгыш фронт газетасы «Кызыл яу»ның 1919 елгы саннарын укыганда игъланнардан кайбер фактлар теркәп куйганмын: 27 янв. Камил Якуб Уфаның профсоюзлар җыелышында чыгыш ясый; 5 февр. Уфада «Бәхетсез егет» спектакле куела һ. б.

Өстәвенә, мондый табышларны публицистик алым буларак та файдаланалар. Күптән түгел язучы Мөхәммәт Мәһдиев үзенең «Шәрыкъ» клубы турындагы язмасын нәкъ менә газетага басылган игъланнан башлап җибәргән иде: «Бик күптәннән бирле көтелгән... махсус клуб Декабрь 1 дә кич 7 сәгатьтә... ачылды. Клубка уңайлы фатир хәзергә табылмаганнан, мувәкъкать буларак клуб «Болгар» номерында булып торачак. Клуб һәр көн иртән сәгать уннан өчкәчә, кич алтыдан унбергәчә ачык булачак. Әгъза булыр өчен иске әгъзалардан ике кешенең тәкъдим итүе һәм общий собраниенең кабул итүе кирәктер. Клубның уставы татарча һәм русча басылган. Шәрыкъ клубының хәзергә 666 члены бар» *(Йолдыз, 1907, № 201)*.

Аннары, һәр басманың, һәр газетның рекламчылык эшендә үз йөзе, үз иҗат алымнары бөртекләп җыелган, өйрәнү, сабак-гыйбрәт алу өчен һәркайсы кызыклы лабаса. Әле генә телгә алган «Кызыл яу» газеты, мәсәлән, 1918 елда аерым хәрби фронт, армия органнары булып чыга башлаган татарча газетларның берсе. Бик үзенчәлекле, авыр шартларда чыгуына карамастан ул рекламчылык иҗатын дәвам иткән. Эзләнгәннәр, тапканнар. Әйтик, реклам текстлары рәсми фәрман, боерык рәвешендә дә, бик кыска, телеграф тасмасы кебек «тыгыз» игъланнар булып та, аерым шәхес яисә рәсми оешма исеменнән язылган ачык хат, мөрәҗәгать итеп тә бирелгән.

Кыскасы, рекламчылык эше лабораториясе буларак һәр басма кызыклы, игътибарга лаек. Барла, өйрән генә!

Ә менә совет хакимияте башлангач, матбугат партия-совет органнарына әверелгәч, хәл кинәт үзгәрә. Дөрес, күп кенә газеталар мәсәлән, «Керәш» (Уфа), Исмәгыйль Рәмиев күзәтүенчә «...мөмкин кадәр әзер материал, декрет, карар, хитап, игъланнар белән тулып чыга иде». Әмма бу инде иҗади рекламчылык булмыйча, бәлки өстән төшерелгән директиваларның баса башлавы иде.

Соңгы ярты гасырда партия-совет матбугаты реклам белән махсус шөгыльләнмәде, дигән идек. Шулай да ул чорда да рекламчылык бөтенләй ябылмады. Реклам бюролары эшләде, алар матбугат, радио, телевидение белән бәйләнештә торды, матбугат шулар тәкъдим иткән төрле реклам, игъланнарны баса бирде. Мондый эшчәнлек алымында да игътибар итәрлек яклар булмый калмагандыр, бөтенләй үк кул селтәмик; болай да инде без бер яктан икенче якка ташланырга күнегеп беттек, безгә ак икән, бернинди тапсыз, кара икән, дөм кара булсын. Ә тормышта алай булмый ул.

Димәк, революциягә кадәрге реклам хәрәкәтенә гадел, объектив карарга өндәвебез бу чорга карата да көчендә кала. Чынында бит безнең әлегә нәтиҗә ясарга хакыбыз да юк, чөнки мәсьәләне фәнни нигездә, гомумкешелек кануннарына таянып өйрәнәсебез бар. Хәзергә тик кайбер күзәтү, хатирәләребезне генә уртаклашып китик.

Мисалга, илленче-алтмышынчы елларда без, яшьләр, газетлардан киноанонсларның фотосурәтләрен көтеп ала идек. «Яшь сталинчы» (хәзерге «Татарстан яшьләре») күбрәк аларның үз укучыларының зәвыгына туры килгәннәрен — яшьлек, мәхәббәт, гүзәллек, каһарманлык хисләре кузгата торганнарын бирер иде, бүгенге кебек шәрәлизм, секс-мекс белән мавыкмас иде.

Яшьләр газеты үзе оештырган әдәбият түгәрәгенең киләсе утырышлары турындагы белдерүләрен көтеп алу да истә калган. Ул утырышларда яшь язучыларның әсәрләре тикшереләр иде, киң җәмәгатьчелек катнашыр иде. Көннәрдән бер көнне минем дә «Елга шаулый» дигән хикәямнең тикшереләчәге турында игълан басылды. Хәзер дә шул газет соңыннан басылып чыккан хикәянең үзеннән дә кадерлерәк ядкәрь булып архивымда саклана.

Ул еллардан калган гомумирәк тәэсирләргә килсәк, гомерне матбугатка биргән кеше буларак, барлык журналистларның уртак фикередер дип ышанып әйтә алам: ул дәвердә реклам эше чын журналист эше, иҗади эш дип саналмый иде. Өстән килә торган, чиновниклар үтәргә тиешле «кәҗүнни» бер шөгыль дип канга сеңеп калган. Хөкүмәт һәр предприятиегә, сәүдә оешмасына реклам максатында азмы-күпме акча тоту караган, реклам бирүчеләр шуның үзеннән арткан өлеге бюрога аны республикада чыга торган газетларга алдан планлаштырылган микъдардә бирә бара, ә реклам татарча ничек басыла, укучыга барып җитәме — анысы белән төпле кызыксынучы булдымы икән? Һәрхәлдә мин, рекламны басмадыгыз, дип, соңга калдыгыз, дип яисә, начар сыйфатлы, дип бәйләнгәннәрен, тәнкыйть иткәннәрен хәтерләмим.

Гомер буе газет укыган кеше буларак та әйтә алам: ул елларда укучы да реклам белән даими кызыксындымы икән? Монда сүз аерым очраклар турында бармый, андыйлары күзәтелә иде, мәсәлән, аерым кешеләр газетның дүртенче битендә аерылышу турындагы игъланнарны укып мавыгыр иде. Кино-театр, һава торышы, заем һәм лотерей тиражы таблицаларын күзәтеп торучылар булыр иде, соңрак инде радио, телевидение программалары күпләрне кызыксындыра торган булып китте. Һәрхәлдә болар барысы да мәгълүм бер штамп, калып белән башкарыла, монда чын рекламчылык, иҗади журналистлык юк дәрәҗәсендә иде.

Штамп димәктән, ул еллардагы рекламчылыкның тискәре якларына килгәндә, аның иң зур зарары туган телебезгә астыртын сугуда булды. Иң тун, иң катып калган чиле-пешле тәрҗемә дубляж газетларында да шул реклам материалларында булыр иде. Шулар инде телне, Хәсән Сарьян гыйбарәсе белән әйткәндә, корт кебек әкрен-әкрен генә кимерделәр. Бәланең тамыры да тирәндә. Ялгышмасам, Габдулла Тукай да иң «көлке» тәрҗемә «үрнәкләрен» җыеп язган фельетонына да (тәрҗемәчеләр арасында ул «чыктым аркылы күпер» исеме белән йөри) сүз, әйләнмәләрне үз заманында чыккан газет рекламнарыннан алган. Ул елларда бит әле реклам теле дә чагыштырмача «татарча» булган.

Ә безнең заманда инде «газет теле» дигән бөтен бер тискәре күренеш-атама барлыкка килүгә, минемчә, нәкъ менә партия-совет органнарының газет битләрен дыңгычлап тутырган рәсми документларының, съезд, конференция, сессия беркетмәләренең, өлеге дә баягы, шул реклам-бюро игъланнарының «кәлҗемә» тәрҗемәләре гаепле дә.

Бик тә аяныч, шул тун тәрҗемә штампларыннан матбугат сөйләме әле һаман арынып бетә алмый. Реклам телендә үзгәреш гомумән дә бик сизелми әле. Кутыр-кутыр, шадра-шадра катып калган «үрнәкләр», телебезне зәгыйфьләп, әле дә чекрәеп торалар, теләсә нинди яхшы эчтәлекле, теләсә нинди матур бизәлешле рекламның тәэсир көчен киметәләр, юкка чыгаралар. Татарча булмаган, калька әйләнмәләр дисеңме: «Спортлото» һәм «Спринт» уеннарында катнашып, сез зур әйбер яки акча отарсыз... Бакчаны помидор, кыяр культуралары алып тора (биләп тора кирәк); күп сүзлелек, артыклыклар дисеңме: никахлашу сарае, күп санлы сораулар бирергә мөмкин; чеп-чи русча алынмалар дисеңме: коллектив (күмәк кирәк) карау өчен заявкалар (гариза кирәк) кабул ителә һ. б...

Хәер, болары, ягъни реклам эшчәнлегенең бүгенге хәле, рекламның жанр буларак асылы, аның телен-стилен камилләштерү юллары — болар инде үзенә бер тема.

**Илдар НИЗАМОВ,**
КДУның татар журналистикасы кафедрасы
доценты, филология фәннәре кандидаты.

# СЕМБЕРДӘ АКЧУРИННАР МӘЧЕТЛӘРЕ

Татарда элек-электән бөтен вөҗүде белән үз милләтен сөйгән, аны тәрәккыять юлына бастыру өчен бөтен көчен куйган галим-голәмә генә түгел, сәүдәгәрләр һәм фабрикантлар да булган. Сембернең мәшһүр байлары Акчуриннар да әнә шундыйлардан. Безгә аларның Сембер губернасында үз акчаларына уннарча мәчетләр салдырганнары да мәгълүм. Әлеге мәкаләмдә мин аларның иганәчелек эшчәнлегенең нәкъ менә шушы юнәлеше турында тәфсилләбрәк бәян итәргә булдым.



*Сембер мәчете.*


Сембер каласының Лосевая урамындагы (хәзерге Ульяновск шәһәрендәге Федерация урамы) зур таш гыйбадәтханәне Акчуриннар, тагын да төгәлрәк итеп әйтсәк, сәүдәгәр Курамша Акчурин салдырган. Ә аның Урта Идел буенда постау житештерүдә зур уңышка ирешкән улы Тимербулат Акчурин 1865 елда әтисе төзеткән гыйбадәтханәгә тәмам мәчет рәвеше кертеп, аңа манара куйдыра. Шулай итеп, Сембердә беренче чын мөселман мәчете барлыкка килә. Житмешенче елларда калада татар кешеләренең саны шактый арткач, әлеге бина инде барча мөселманнарны да сыйдыра алмый. Бу юлы да Тимербулат Акчурин ярдәмгә килә. 1874 елда ул мәчетне киңәйтү өчен акча бүлеп бирә. Шул ук елны бинаның ян-яклары өчәр саженьга киңәйтелә. XIX йөз ахырында ул инде 300 кешене сыйдыра алган. Мәчет бинасы әле бүген дә һәркемне сокландырырлык итеп, югары зәвык белән эшләнгән. Дөрес, хәзерге вакытта ул бик нык үзгәртелгән, шуның өстенә ул гыйбадәтханә буларак түгел, ә бөтенләй башка максатларда файдаланыла. Шәһәрнең татар җәмәгатьчелеге аны янадан мөселманнарга кайтарып бирү өчен көрәш алып бара.

Бу Акчуриннар акчасына төзелгән бер генә мәчет түгел. Алар Сембер губернасының Карсун, Сенгилей кебек өязләрендә дә (хәзерге Ульяновск өлкәсенең Барыш районы) мәчетләр салуда матди ярдәм күрсәткәннәр. Мәсәлән, XIX йөз ахырларында Сенгилей өязенең Калны авылында фабрикантлар Йосыф һәм Якуб Акчуриннар ике мәчет төзеткәннәр. Иске татар зираты янындагысының диварлары кызыл кирпечтән, түбәсе калайдан эшләнгән. Бу вакытта инде вафат булган кешеләрне иске зиратка түгел, янасында күмә башлаган булганнар. Мәчет турыдан-туры шушы фабрикантлар житәкчелегендә салынган. Алар бинаның шактый озын гомерле булуын теләгәннәр. Кайбер картларның әйтүенә караганда, хуҗалар осталарга аның кайбер жирләрен берничә тапкыр сүтеп корырга мәҗбүр иткәннәр. Әлеге мәчет авыл мәхәлләләренең берсенә хезмәт күрсәткән. Дөрес, монда әүвәле дә ике агач мәчет торган. Алары да Акчуриннар ярдәме белән салынган, дип сөйлиләр.

Октябрь фетнәсеннән соң бу таш мәчеттә Билал Әблиев атлы кеше мулла булып торган. Егерменче елларда ул вафа булгач, мәхәллә кешеләре күрше Зөябашы авылыннан Габдрахман мулла Мөстәкыймовны чакыртып алганнар. Заманында Каһирәдәге мәшһүр дини университетта укып югары белем алган бу хәзрәт инкыйлабка кадәр Акчуриннар фабрикасы каршындагы мәчеттә муллалык иткән. Әмма аңа Калны авылында озак эшләргә насыйп булмый. Сталин репрессиясе башлангач, иң әүвәле аның йортын тартып алалар, ә соңыннан, кулга алып, атарга хөкем итәләр. Нәтиҗәдә, мәчет ябыла, һәм бинаны келәт сыйфатында файдалана башлыйлар. Алтмышынчы еллар башында, авыл халкының ризасызлык белдерүенә дә карамастан, манараны

¹ Фотолар язма авторының архивыннан алынды.

кисеп төшерәләр һәм авыл клубы бинасы яраксыз хәлгә килгәч, ул «клубка» әверелә.



*Катны авылы мәчете.*


Илдә саф җилләр исеп киткәч, XX гасырның 1991 ел ахырында, авыл халкының тырышлыгы белән мәчет бинасын яңадан гыйбадәтханә иттеләр. Аны сипләү-яңарту өчен өлкән яшьтәге кешеләр пенсия акчаларын да кызганмадылар. Хәзер, Аллага шөкер, «алтын» айлы манара күтәрелгән мәчеткә көн дә түбәтәйле картлар йөри, көн дә дога кыла.

Ә менә безнең гасыр башында Акчуриннар ярдәме белән салынган икенче бер мәчетнең язмышы фаҗигале булды. Утызынчы елларда анда мулла булып торган Шәриф Камалетдинов һәм башка дин әһелләре төрле мыскыллауларга һәм эзәрлекләнүгә дучар булалар. Мәчет ябыла. Соңрак район һәм авыл түрәләре тырышлыгы белән аның манарасы кисеп төшерелә. Кызганычка каршы, бу хурлыклы эштә әлеге авыл кешеләре дә катнашкан. Халык сөйләгән сүзләргә караганда, манараны кисеп төшерүчеләр үзләренең соңгы көннәрен бик күп михнәт-газап кичереп үткәргәннәр.

Аннары мәһабәт мәчет бинасын сүтеп, аны мәктәп итеп коралар. Бу мәктәп берничә бинадан тора иде. Ә әлеге корпусны без «мәчет» дип атап йөрдек. Анда сыйныфлар, китапханә, спортзал, буфет, пионер бүлмәсе урнашты.

Ниһаять, 1975 елда авыл читендә өлкә, район, күмәк хуҗалык җитәкчеләре һәм, иң беренче нәүбәттә, мәктәп директоры Абдулла Ибраһим углы Кадышевның тырышлыгы белән ике катлы таш мәктәп бинасы салынды. Иске корпусларны сүттеләр, ә элекке мәчет бинасына авыл советы һәм элемтә бүлеге кереп урнашты.


Сенгилей өязенең Зөябашы авылында Акчуриннарның берничә постау фабрикасы булган. Анда яшәүче татарларга 1917 елга кадәр Акчуриннар акчасына салынган җиде мәчет хезмәт



*Хәзер дә эшләп килә торган Зөябашы авылы мәчете.*

күрсәткән. Әлеге гыйбадәтханәләрдә Урта Азиядә, Каһирәдә һәм Шәрекъ дөньясының башка шәһәрләрендә укып кайткан дин әһелләре муллалык иткән.

1917 елдан соң авылның (хәзер эшчеләр поселогы) күп мәчетләре ябылды. Аларга элеккеге СССРның күп мәчетләренең язмышы әзерләнгән була. Шуның өстенә, кайберләре җимерелгән булган. Шулай да җирле халык аларның берсен саклап кала алды. Бүгенге көннәргә кадәр монда XIX гасырда төзелгән бер мәчет эшләп килә.



*Зөябашы авылында Акчуриннар һәм Шакулов салдырган мәчет (хәзерге күренеше).*


Акчуриннар һәм аларның кияве Хәсән Шакулов акчасына салынган икенче бер мәһабәт мәчет Зөябашы авылындагы калкулыкка урнашкан. Ул еллә кайлардан күзгә ташланып тора. Совет чорында аның да манарасын кисеп төшерделәр. Башта ул колхоз келәте, аннары урта мәктәп остаханәсе буларак, ә соңгы елларда автомобильчеләр мәктәбе тулай торагы буларак файдаланылды.

Ничәмә-ничә еллар буена сипләнмәгән мәчет акрынлап җимерек хәлгә килеп барган бер вакытта, авыл халкы, аны кире кайтарып бирүләрен үтенеп, Ульяновск өлкәсенең администрация башлыгына мөрәҗәгать итте һәм менә сиңа: мәсьәлә уңай хәл ителде. Хәзер мәчет өстендә янә айлы манара калкып һәм тирә-юньгә ислам, иман нурын иңдереп тора.

Бу изге эшне башлап йөрүчеләрнең берсе — сугыш ветераны Габделхәй Гали улы Урмеев иде.

Дмитровград шәһәре коммерсантлары (бу авылда туган Орловлар гаиләсе) матди ярдәм күрсәтмәгән булса, бу эш шактый озакка сузылган булыр иде. Ходайның биргәненә шөкер, 1994 елның 1 июлендә мәчетне зур тантана белән ачтылар мөселманнар.

XIX гасырда Акчуриннар салдырган Ак мәчет тә чагыштырмача бәхетсез язмышлы булып чыкты. Фабрикадан ерак кына түгел урында урнашкан бу гыйбадәтханә андагы хезмәткәрләргә һәм эшчеләргә хезмәт күрсәткән. Акчуриннар үзләре дә, аларның якыннары да шушы мәчеткә йөргәннәр. Анда Зыятдин Мөстәкыймов




*Зөябашы авылындагы Ак мәчет (элекке күренеше).*

(ул Йосыф Акчураның бабасы Сөләйман Акчурин белән хажга барып кайткан кеше) муллалык иткән. Мәчет каршында мәдрәсә булганлыгы да мәгълүм. Аны Акчуриннар бәдәвам рәвештә уку әсбаплары, җиһазлар белән тәэмин итеп торганнар. Мәдрәсәдә мөдәррис һәм имам-хатиб булып Мөстәкыймов торган.

20—30 елларда бу мәчетнең манарасы кисеп төшерелә.

Килә заман: Исмәгыйль Гаспралы, Йосыф Акчура һәм башка мәшһүр татар сәүдәгәрләре һәм зыялылары гыйбадәт кылган әлеге мәчет кулдан-кулга күчеп йөри башлый. Нинди генә учреждениеләр, оешмалар утырмый аның эчендә: балалар бакчасы, кичке мәктәп, хәтта жирле көнкүреш йорты буларак та файдаланыла бу мәчет. Нәтиҗәдә, хуҗасыз калган ятим бина тәмам яраксыз хәлгә килә. Сиксәненче еллар ахырында бер төркем сугыш һәм хезмәт ветераннары мәчетне мөселманнарга кайтарып бирү мәсьәләсен күтәрәләр. Әмма мәсьәлә әле бүген дә уңай хәл ителмәде. Дөрес, моңа җитди сәбәпләр дә бар. Беренчедән, җирле фабрика, күмәк хуҗалык һәм поселок администрациясе үзләре дә матди яктан бик зур авырлык кичерәләр. Ә тәмам тузып, таушалып беткән бинаны сипләр өчен бик күп акча, төзү материаллары кирәк. Хәзер аптырашта калган мөселманнар Шакулов мәчетен сайларга булдылар.



*Ак мәчетнең хәзерге фаҗигале язмышы.*

Акчуриннарның Гурьевка авылында яшәүче үз эшчеләре һәм хезмәткәрләре өчен дә мәчет салдырганнары мәгълүм. Хәер, бу мәчеттә алар үзләре дә гыйбадәт кылганнар. Мәсәлән, анда Тимербулат Акчурин, аның балалары, туганнары һәм кунаклары да булган. Һәрхәлдә, кайбер картлар шулай дип искә алалар. Инкыйлабтан соң мәчет ябыла һәм җитмешенче елларга кадәр типографиянең ярдәмче бинасы буларак файдаланыла. Аннары ул... яна.

Торгынлык елларында татар халкын милләт буларак саклап калу өчен күп көч куйган күп кенә зыялылар, шул исәптән Акчуриннар турында язарга да, сөйләргә дә ярамады. Аларны каралтып күрсәтергә омтылулар да булмады түгел. Әмма тарихны алдап булмый. Иртәме-соңмы, ул, барыбер, үзенең соңгы һәм хакыйкый сүзен әйтә. Сембер губернасында салынган мәчетләр исә сәүдәгәр һәм фабрикант Акчуриннар токымына һәйкәл булып торалар сыман.

**Наил ТАИРОВ,**
тарих фәннәре кандидаты,
Казан мәдәният һәм сәнгать институты доценты.

■ ■ ■

# «ХӨСӘЕН ӘФӘНДЕ ЯМАШЕВ ХАТИРӘСЕ»

(ТАТАРНЫҢ ОЛЫ ШӘХЕСЕ ҮЛГӘЧ, ӘНӘ ШУЛ ИСЕМДӘ КИТАП БАСЫЛГАН)

Революционер Хөсәен Ямашев үз вакытында ук танылган, кешеләрнең тирән ышанычын казанган күренекле шәхес була. Менә ни өчен татар халкы аның кинәттән үлемен авыр кичерә. Хөсәен Ямашевның зур хезмәтләрен күреп, Казан демократик җәмәгатьчелеге аны олылап, хөрмәтләп күмәргә әзерләнә. Бу хәл Казан полициясен бик нык борчый. Жандарм идарәсе начальнигы губернаторга хәбәр итә: университетның кинәттән үлгән студенты Хөсәен Ямашевны татар яшьләре тантаналы рәвештә күмәргә әзерләнәләр... Әйе, шушы максат белән өч комиссия төзелгән була. Аларга түбәндәгеләр йөкләнә: 1) тантаналы күмү оештырырга, кабер өстенә һәйкәл кую өчен акча җыярга; 2) татар газеталарында Ямашевның биографиясен һәм аның истәлегенә язылган мәкаләләр урнаштырырга; 3) мәетне кабергә төшергәндә речьләр сөйләүне оештырырга һәм аны мөселманнарның алдынгы эшлеклесе итеп күрсәтергә; 4) аның истәлегенә стипендия оештыру өчен кирәкле сумманы җыярга.

Студент Ямашевның вакытсыз үлеменә багышлап, «Йолдыз» газетасы аерым кушымта чыгара. Бу кушымта татар китапханәләрендә сакланмаган. Аның бердәнбер нөсхәсе минем шәхси архивымда саклана. «Хөсәен әфәнде Ямашев хатирәсе» дип аталган бу кушымтада татар демократик яшьләренең алдынгы вәкилләре язган мәкаләләр урнаштырылган.

Хатирә танылган язучы Фатыйх Сәйфи-Казанлы мәкаләсе белән башлана. Ямашевның үлүе бөтен татар халкы өчен зур югалту икәнлеген әйтеп, ул болай дип яза: «Хөсәен әфәнде кеби сирәк очрый торган, рухи үтәли күренгән кешенең, нинди генә халык арасында булсын, югалуы бик зур кайгы булса да, татар халкына андый кадерле әгъзасын югалту чыдамаслык авырдыр». Аннары язучы Ямашевны дөреслек өчен кара көчләр белән аяусыз көрәшче шәхес итеп сурәтли. «Халыкның тормышлары алмашыну вакытында,— ди ул,— дөреслекне әйтүдән курыкмый, тоткан мәсләгеннән аерылмый, фәкать адәмгә яхшылыкларны гына теләгән кешеләрнең никадәр зур әһәмияте булса, Хөсәен әфәнде дә татар халкы өчен шундый бәһале иде, һәмишә шул ук кара көч белән сугышуында дәвам итәчәк иде. Ләкин әлеге ригаясыз үлем... аның бөтен планнарын җимерде».

Балалар язучысы Фәхрелислам Агиев үзенең истәлеген Хөсәен Ямашевны хезмәт иярләренең якын дусты итеп сурәтләгән шигырь белән башлап җибәргән. Бер үк вакытта ул Ямашевны татар яшьләрен алга, мәдәнияткә өндәүче кеше итеп гәүдәләндерә. «Хөсәен әфәнденең бөек теләге,— ди Ф. Агиев,— татар яшьләренең укуы, татар яшьләренең кеше булырга тырышулары, татар яшьләренең киләчәктә эшлекле булулары иде». «Хөсәен Ямашев үзе дә,— дип дәвам итә Агиев,— бөтен көчен сарыф итеп, сигез ел төрле газаплар күреп булса да, теләгән максатына ирешкән, гали мәктәпкә — университетка кергән иде. Ләкин... бәхетсезлегенә каршы, гали мәктәпне бетереп, халык сәгадәте өчен калган көчен сарыф итәргә Хөсәен әфәндегә насыйп булмады».

Талантлы яшь шагыйрь Сәгыйть Рәмиев дусты Ямашевка булган тирән мәхәббәтен түбәндәге юллар белән белдерә:

Әрни-әрни ләгънәт әйтәм тискәре бу дөньяга,
Мин мәхәббәт нуры дим, ул аерылышу шәмен яга.

Шул заманның күренекле журналисты Шиһап Әхмәров Ямашевның зурлыгын, башкалардан аерымлылыгын халык арасында киң таралган җыр белән чагыштыра.

Ак идең син, пакь идең син
Фәрештәдәй саф идең!

Җыен яшьләр арасында
Бер бриллиант каш идең!

Татар интеллигенциясенең танылган вәкиле Ибраһим Биккуловның истәлеге Ямашевны милләтнең иң алдынгы кешесе итеп гәүдәләндерүгә багышланган. «Тарихның һәрбер дәверендә,— дип яза ул,— төрле искелек белән көрәшү, камәләткә юл тоту һәм бертуктамый мәңгелек... хакыйкать эзләнүләр (булып тора). Мондый кешеләр арасыннан халык, милләт дигән массаны хәрәкәткә китерә һәм киләчәкләрен төзи торган генийлар (даһилар) килеп чыгалар. Хөсәен әфәнде Ямашевны һәртөрле искелек белән көрәшүче булганлыктан, шулар арасында бер эшче дип санарга ярый. Әлбәттә, ул алар арасында бер кара эшче генә булып хисапланса да, гади кешеләргә нисбәтән иң алдынгы сафта, һәр заманда, һәр хәрәкәттә һәм һәр эштә алдан бара торган кеше иде. Шунлыктан Хөсәен әфәндене татар милләте дигән почвада яңа тәшкил ителеп килә торган типларның беренчесе иде дип әйтергә ярыйдыр». «Хөсәеннәр,— дип дәвам итә автор,— укудан, тәрбия күрүдән тиз генә килеп чыкмыйлар, алар, күбесенчә, кошларның килеп яз житкәнен белдергәннәре кеби, халыкның аңында үзгәрешләр булыр алдыннан туалар».

Ибраһим Биккулов үзенең истәлеген Ямашевның ижтимагый-фәлсәфи фикере үсүен чагылдыру белән тәмамлый. «Дөньядагы үзгәрешләрне күреп,— ди автор,— Ямашев жәмгыять бәшәрьядә (*тормышында*— Х. Х.) даими булган бер форма һәм бер фикер юк, һәрнәрсә хәрәкәттә, үзгәрүдә һәм көннән-көн камәләт (*өлгергәнлек*— Х. Х.) баскычына күтәрелеп килүдә дигән фикергә килә». Аннары Биккулов болай дип яза: «Ижтимагый эшләрдә, сәүдә һәм нәжат (*авырлыктан чыгу*— Х. Х.) галәмендә мәйданга килгән һәр яңа фикер һәм яңа течение аның дикъкатен жәлеп итә һәм аны шатландыра башлый. Хөсәен әфәнде дөньяда торудан ләззәт— бертуктамыйча яңара баруда һәм камәләткә юл тотуда дигән уйга төшә».



Студент Ямашев төзегән татар яшьләре әдәби түгәрәге членнарыннан бер төркем. Утырганнар *(уңнан сулга)*: **Рәхимбәк Маликов, Әминә Терегулова, Габдрахман Мостафин.** Басканнар: **Хөсәен Ямашев** *(түгәрәк җитәкчесе)*, **Мәдинә Терегулова, Хәдичә Ямашева.**

Казан университеты студенты Габдрахман Мостафин үзенең мәкаләсендә Ямашевның биографиясен тасвир кыла. Биографиядә Ямашевның атасы, аның туган ягы, социаль чыгышы, кәсебе, дөньяга карашы һәм 1870 елда Казанга күчеп килүе турында кыйммәтле мәгълүматлар бар. Аннары Мостафин түбәндәгеләрне искә ала. 1882 елда Минһаж аганың беренче баласы Хөсәен дөньяга килә. 6—7 яшьләренә житкәч, аны акыллы сәүдәгәр итәр өчен мәхәллә мәктәбе «Мәржә-

ния»гә укырга бирәләр. 12—13 яшьләрендә Хөсәенне, прогрессив карашлы Әхмәтҗан хәлфә киңәше буенча, шәһәрнең алдынгы мәдрәсәсе «Мөхәммәдия»гә күчерәләр. Ләкин мәктәп-мәдрәсә белеме яшь Хөсәенне генә түгел, карт атасы Минһаҗ агайны да канәгатьләндерми. Ул Казан байларыннан беренче булып үзенең улын учительская школага бирә. Әмма озак та үтми, искелеккә шактый нык тотынып торучы Минһаҗ агай, тирә-күрше, белеш-таныш Казан татарларының тискәре фикере астында, үзенең улын школага бирүе ялгыш бер адым булган дигән карашка килә. «Ләкин,— дип яза Мостафин,— 17—18 яшьләргә җиткән ачык фикерле, аңлы яшь Хөсәен, үз тезгенен үз кулына алу фикеренә килеп, шул юлында авыр вә зур хезмәтләрендә була вә бара торгач, яшь Хөсәен һәм аның атасы икесе бер-беренә бөтенләй башка, бере икенчесенә каршы вә дошман булган лагерьны алалар. Менә шул вакытлардан безнең Хөсәенебезнең гаилә көрәше башлана, вә ул көрәш озак еллар... Минһаҗ абзыйның үлүенә кадәр сузыладыр». Әмма үз фикерендә нык торучы һәм белемнең тәмен инде татыган Хөсәен юлыннан чигенми, укуын дәвам иттерә. Улының какшамас иркен күргәч, Минһаҗ агай чигенергә мәҗбүр була, Хөсәенне школадан алмый.

Мәкаләдә Хөсәен Ямашевның учительская школада укыган елларда суллашуына зур урын бирелгән. Шактый әзерлекле укытучылары булган һәм дөньяви фәннәргә киң урын бирелгән учительская школа — Хөсәеннең дөньяга карашын әкренләп үзгәртә. Ул йотлыгып рус һәм Европа әдәбиятын укый. Ирекле һәм яхшы тормыш идеясе белән сугарылган бу әсәрләр Ямашевның белемен арттыралар һәм сыйнфый аңын уяталар. Ул җәмгыять тормышы һәм андагы вакыйгалар белән җитди кызынсына башлый. Алмаев һәм Сәйфетдинов кебек революцион рухтагы укучылар белән аралаша, хезмәт халкы арасында аңлату эшләре алып барырга теләгән бүтән яшьләрне үз тирәсенә туплый, аларга җитәкчелек итә. Ямашев тормышындагы шушы үзгәрешләрне күргән Мостафин болай дип искә ала: «Актык сыйныфларда вакытта Хөсәен әфәндедә бергәлек, җәмгыять хисе кузгала башлый. Бу елларда үзе белән бергә школада булган берничә яшьләр арасында якын дуслык вә фикердәшлек мәйданга килеп чыгадыр... Менә бу кечкенә генә өем бергә кушылып, Казан халкының мәдәният тарихында үзенә бер дәвер саналачак, фикердәшлек дәверенең килеп чыгуына зур хезмәт итәчәктер».

1902 елда школаны уңышлы бетергәч, Хөсәен Ямашев үзенең белемен тагын да арттыру максаты белән университетка керергә әзерләнә башлый. Озак та үтми, Россиядә 1905 елгы революция дулкыны күтәрелеп китә. Бу көчле дулкын тиздән Ямашевны да үз эченә тартып ала. Революцион романтика белән рухланып, массаларны капитал изүеннән коткару өчен, ул азатлык һәм тигезлек өчен үз-үзен аямыйча көрәшә.

Революция җиңелгәч, Хөсәен Ямашев тагын зур тырышлык белән университетка керергә әзерләнә. 1909 ел башында ул, үзлегеннән әзерләнеп, беренче гимназия каршында имтихан тота да көзен университетның хокук факультетына керә. Ләкин күп еллар азап чигеп, изге теләгенә ирешкән бер вакытта тәгъдир аның гомерен кыскарта. «1912 елның 12 мартында сигез сәгать ярымда кич,— дип яза Мостафин,— күптән түгел генә язган мәктәпләр хакындагы рисаләләрен (*мәкаләләрен* — Х. Х.) бастыру хакында дип «Гасыр» китапханәсенә сөйләшергә барган җирдә ул кинәттән вафат булды».

Хөсәен Ямашевны тантаналы күмү татар хезмәт ияләренең зур демонстрациясенә әверелә. Халыкның аңа булган көчле мәхәббәтен драматург Галиәсгар Камал үзенең «Йолдыз» газетасында чыккан мәкаләсендә менә ничек сурәтли: «Җеназаны күтәреп чыгалар. Университет ишек алдында бөялеп торган халык дәрьясы хәрәкәткә килде. Җеназа артыннан бу дәрья капкага таба агыла башлады. Дәрелфөнунның (*университетның* — Х. Х.) киң капкаларына халык сыймый, бер-берсен тыгызлап чыгалар иде. Мәйданга барып җиткәнче озатучыларның саны дәхидә артты. Юл буенда туры килгән һәрбер йортның тәрәзәләре һәммәсе җеназаны карап торучы хатын-кыз башлары белән тулган иде. Мәйданда... һичшиксез, ике мең кадәр кеше бар иде... Хөсәен әфәнденең җеназасы өстенә яшьләрдән, иптәш студентларыннан... куелган лентада вакытсыз үлгән мәңге онытылмаслык дустыбызга (дип), юридический кружок идарәсе тарафыннан куелган лентада «Ул үз халкының якты, истикъбале (киләчәге) булганлыгына ышану һәм өмет белән китте»,— дип язылган иде».

**Хөсәен ХӘСӘНОВ,**
тарих фәннәре докторы.

**Китап күзәтү**

# ТАУ ЧИШМӘСЕ КЕБЕК

Яна китап, яна әсәр белән танышу — укучы өчен зур вакыйга. Ул аны тормыш кочагына, хисләр дулкынына алып кереп китә дә истәлекләрне яңарта, үткән тормышны уйлата, яшьлеген искә төшерә. Йә үрнәк, йә гыйбрәт алырга мәҗбүр итә.

Язучы Рашат Низамиевның урта һәм олы яшьтәге мәктәп балалары өчен матур бер бәйләм итеп төзелгән «Кызыл кар яугач» исемле повестьлар һәм хикәяләр җыентыгы әнә шундый китап. Ул, балачакның үзе кебек, саф сулы, уйчан, шаян, йөгерек тау чишмәсен хәтерләтә.

Повесть һәм хикәяләрнең төп геройлары — авыл балалары, аларның әти-әниләре, авыл халкы, күрше-күлән, яшьләр. Язучы аларның холык-фигыльләрен, хис-кичерешләрен җылы, якты төсләрдә тасвирлый, авыр, фаҗигале хәлләрне дә читләтеп узмый. Аларда авыл табигате дә: таныш урман-кырлар, инеш-чишмәләр, салам эскертләре, печән чүмәләләре, миләш, алмагач, көнбагыш һ. б. әсәрдәге геройларның яшәеше, тормыш-көнкүреше, хис-тойгылары белән бик тыгыз үрелә.

Кешенең кем булуы, дөньяга карашы, ак белән караны, яхшы белән яманны аера башлавы, икенең берсенә тартылуы балачактан ук башлана. «Бозлы миләшләр» («Кар кеше») повестендагы тугыз яшьлек Госманны да автор әнә шул ак белән караны аерып торучы сызык өстенә бастыра. «Нәкъ шул минуттан дөнья урталайга — ак һәм карага бүленде. Дөньяны бер сызык, фәкать бер сызык кыл урталай аерып тора. Ул сызык малай басып торган төштән уза. Сызыкның теге ягына борылып карыйсы килми иде, чөнки анда соры, караңгы төсләр. Хәзер иң яхшысы — алга таба кузгалу, ак дөнья белән очрашу һәм үзең дә шуңарга тизрәк кушылып китү».

Әйе, сөлгеләргә, яулыкларга күчкән ак төс — татар халкының күңел сафлыгын, намус пакълеген чагылдыручы символ — Рашат Низамиевның повесть һәм хикәяләрендә киң кулланыла, ул аны тагын да көчәйтеп, ап-ак дип тә еш куллана.

Китап без укып, күнегеп беткән үрнәк пионерлар һәм комсомоллар яисә үрнәк гаиләдә тәрбияләнгән үрнәк балалар турындагы ясалма сюжетлардан тормый. Дөрес, балалар әти-әниләреннән үрнәк алып, өйрәнеп яшиләр, әмма шулай да аларга сабакның зурысын күбрәк табигать үзе, авылдашлары, иптәшләре бирә. Алар эзләнеп, акны карадан аерырга өйрәнеп, дөньяны үзләренчә танырга өйрәнеп үсәләр.

Язучы, оста рәссам кебек, үзенең әсәрләрендә палитрадагы төсләрнең төрлесен һәм җетеләрен дә (ап-ак, ямь-яшел, зәп-зәңгәр, кып-кызыл, чем-кара һ. б.) куллана. Алай гына да түгел, киң кулланылыштагы әзер төсләр җитмәгәндә, ул сүзләр ярдәмендә әсәрләренең эчтәлегенә һәм балаларның бай фантазиясенә туры килердәй бик күп төрле өр-яңа төсләр дә иҗат итә. Мәсәлән: зәңгәрсу-яшькелт, шома-зәңгәр, күгелҗем-яшькелт, карасу-яшел, яшелле-күкле, аксыл-көрән, аксыл-шәмәхә, аклы-кызыллы, кызгылт-алсу, ут-кызыл һ. б.

Әйтик, татар телендә зәңгәрне белдерә торган төсләрдән: зәңгәр, зәп-зәңгәр, зәңгәрле-яшелле, зәңгәрле-кызыллы, зәңгәрсу кебекләре бар. «Кызыл кар яугач»та автор боларга өстәп: зәңгәрсу-яшькелт, шома-зәңгәрләрне таба. Яшелнең телдә — яшел, ямь-яшел, яшел-зәңгәр, яшелле, яшелле-зәңгәрле, яшелле-кызыллы, яшелле-сарылары мәгълүм. Әлеге китапта исә ул төсләргә яшелле-күкле, күгелҗем-яшькелт, карасу-яшел төсләр өстәлә. Ак төсләргә — аксыл-көрән, аксыл-шәмәхә, аклы-кызыллы; кызыл төсләргә — кызгылт-алсу, кызгылт-карасу, ут-кызыл кебек төсләр килеп кушыла.

Автор балаларның төсләрне, төсле рәсемнәрне яратуын, табигатьнең генә түгел, тормышның да төсләргә гаҗәеп

бай булуын бик ачык тоеп иҗат итә. Хәер, бу хакта ул үзе дә бик ачык итеп әйтеп бирә: «Тормыш ул «ике икең дүрт» кебек төгәл кагыйдәләргә генә сыеп бетми. Яшәү формуласы күпкә, бик күпкә катлаулырак. Йөз төрле төсе, тәме, мәгънәсе, шуңа өстәп тагын мең төрле нюанслары бар аның. Боларны көлтә-көлтә бәйләп, берәүнең дә алдына әзер килеш тоттырмыйлар. Болар бөртекләп, тамчылап җыйнала барырга тиешле хәзинә». («Яшьлеккә хат»).

Әйе, тормыш төсләр белән генә түгел, төс-кыяфәте, төс-тәме белән дә катлаулы. Тормыш палитрасының төсләргә бай булуы яхшы, әмма бертөслелек хәтәр: «Бертөслелек урап алган да, әле уңга, әле сулга этеп йөртә адәм баласын. Бертөслелек — хәтәр әйбер, кешене ул йокымсырата, чарланасы уй-хисләрен читлектә тота». (Шунда ук.)

Тугыз яшьлек Госман да, ак белән кара төсләрне аерып торучы сызык өстенә басып, әнә шул бертөсле, соры, караңгы төсләрдән качып, ак дөнья белән очрашу өчен карлы-бозлы чакрымнарны, күз күрмәгән киңлекләрне ерагера әллә ничаклы араны узарга әзер!

Китапның исеме дә төсле булган кебек, аның эчтәлеге дә төсләргә гаять бай, аны төсле китап дияргә дә була. Алар, салават күпередәй, яшь йөрәкләр аша узып, уйлану-эзләнүләр, шатлык-сөенечләр, борчу-хәсрәтләр, сөю-сәгадәтләргә сала.

«Кызыл кар яугач» язучының төрле елларда иҗат иткән дүрт повестен («Бозлы миләшләр», «Кызыл кар яугач», «Урман эчләрендә урман», «Яшьлеккә хат») һәм унике хикәясен («Беренче мунча», «Өчәү», «Билгесез кыз «сурәте», «Көнбагыш», «Матур ялган», «Хат ташучы малай» һ. б.) берләштерә.

Әлбәттә, мәктәп еллары инде күптән артта калган укучы бу китапны укырга ашкынып тормас, балалар өчен бит, дияр. Шулай да, китапны кулга алуга, ул зур кызыксыну уята, укый башлагач, туктап калып булмый. Моның үз хикмәтләре дә бар. Беренчедән, Рашат Низамиев әлегә кадәр журналист һәм шагыйрь буларак танылган иде, чәчмә әсәрләрне ничек яза икән, дигән сорау кызыксындыра. Икенчедән, бүген мәктәп балаларына нинди әсәрләр тәкъдим ителә икән? Дөрестән дә, хәзер мәктәптә элеккеге октябрят, пионер, комсомол оешмалары, быргы-барабан тавышлары, «Без һәрвакыт әзер!» дигән дәртле рапортлар, звено, отряд җырлары, ярышлары, «пионер маршрутлары», комсомол җыелышлары, пионер галстуклары, комсомол значоклары, гомумән әйткәндә, «коммунистик тәрбия», аның атрибутлары юкка чыкты. Кирәге булганмы аларның, шулардан башка укучыны тәрбияләп буламы, хәзер аны нәрсә алмаштыра? Китапта болар берәр төрле чагылыш табамы? Өченчедән, прозаик буларак, Рашат Низамиев балалар өчен нинди телдә яза, аның үз стиле, яңалыгы бармы?

Кулына яңа китап алган укучыны әнә шундый күптөрле сораулар кызыксындыра.

Шунысы игътибарга лаек, һәр әсәрдә авторның эрудициясе, бай тормыш тәҗрибәсе, гаять күзәтүчәнлеге, тәвәккәллеге чагыла, әсәрләренең тәрбияви әһәмияте, үзенчәлекле тел-стиле, аһәңе булуы күренә. Повесть һәм хикәяләрдә билгеле бер эзлеклелек, герой һәм вакыйгаларның үсеш-үзгәреше игътибарны җәлеп итә. Повесть һәм хикәяләрнең исемнәре дә уңышлы сайланган, алар эчтәлек белән бик тыгыз үрелгәннәр. Дөрес, китапка икенче төрле исем биргәндә ничек булыр иде икән, дигән уй да күңелгә килеп китә...

Әсәрләрдәге вакыйгалар, геройлар «балачакның яшел сукмакларыннан» шома гына бармый: ул юллар тормышның үзе кебек катлаулы да, кырыс та, һәрдаим сынап та тора. Син нинди юлдан, кем артыннан, кая барасың, яшь дустым?

Әнә, «Бозлы миләшләр»дә тугыз яшьлек Госман инде үз юлын табарга омтыла. Әйе, бу яшьтә үзеңә юл эзләү — авыр. Һәрхәлдә, укытучы апасы аңа шулай дия сыман, ләкин малайның юлдан кире борыласы килми. Ул классташлары — юньсез Сипкел Хәмит белән Саескан Сәмит кебек түгел: ул үзенә яхшы, ак юл эзли, үз әти-әнисен эзли.

Язучы малайның язмышына битараф түгел, киресенчә, аның кичерешләрен ул үз йөрәге аша уздыра, шул турыда укучыга да ачыктан-ачык белдерә: «Ишетәсеңме, малай, мин сиңа гомер уртасыннан эндәшәм! Тормыш сине, кып-кызыл миләшләр кебек, матурлыгы белән кызыктырды. Ләкин синең язмышка миләшнең ачысы, бозлысы эләкте. Никадәр сәер тоелмасын, бозлары эреп төшкәннән соң андый миләш тәмле була. Миләштәге бозларны эретү өчен сиңа вакыт һәм тормыш-яшәеш тәҗрибәсе кирәк иде.

Беләсеңме икән, синең барлык кичерешләрең, яндырып-яндырып минем йөрәк аша да узды. Синең пакь, керсез йөрәгең күтәрелгән биеклеккә асылда мин дә күтәрелдем. Синең фаҗигаң —

минем дә фаҗигам иде. Ә фаҗига кешеләрне актан караны аерырга, уйлый белергә һәм сафлыкка өйрәтә».

Авторның менә шушы ачыктан-ачык мөнәсәбәте һәм мөрәҗәгате аның бөтен әсәрләренә дә хас, үзенчә бер яңалык булып тора.

Тагын шунысы үзенчәлекле, язучы «Яшьлеккә хат» әсәрендә укучыларны күп кенә күренекле шәхесләрнең хикмәтле һәм гыйбрәтле сүзләре белән дә таныштыра. Һәм алар бер китаптан икенчесенә күчеп йөри торган таушалган әйтемнәр түгел. «Ә бәлки, һәр кешедә Моцарт үтерелгәндер»... (Сент-Экзюпери), «Бер кешенең үлеме — фаҗига, ә миллионнар үлеме — статистика» (Черчилль), «Күрегез әле, яшь вакытта мин нинди ахмак булганмын...» (Грэм Грин), «Һәр кеше — бер-берсенә охшамаган тарих» (Каррель), «Уңышка бер селтәнүдә генә ахыргача ирешү мөмкин түгел. Аңа сәгатьләп, көнләп ирешәсең» (Ромен Роллан), «Кешеләр эзләгәнне бердәнбер роза чәчкәсендә яки бер тамчы суда табарга мөмкин» (Сент-Экзюпери), «Кешедә егерме яшьтә — хисләр, утыз яшьтә — талант, кырык яшьтә гакыл патшалык итә». (Франклин) һ. б. Мондый тәгъбирләр әсәрләрнең эчтәлегенә бик төгәл туры килә, алар укучыны уйланырга, уйларга мәҗбүр итә, кызыксыну тәрбияли.

Әйткән сүзләре генә түгел, бөекләр тормышыннан кызыклы хәлләр дә байтак китерелә бу китапта. Әйтик, унҗиде яшьлек Толстой үзендә булган кимчелекләрне көндәлегенә язып куя һәм шулардан арыну өчен көрәшә. Шул урнәктә автор үзе дә укучыларга мавыктыргыч эш тәкъдим итә: бер баганага кешедәге унай сыйфатларны (ягымлы, юмарт, гадел, тырыш, сабыр, түземле, кешелекле һ. б.), икенче баганага кимчелекле сыйфатларны (тәкәе, сатлык, саран, икейөзле, алдакчы, ялкау, әләкче, битараф, сал, шәфкатьсез һ. б.) яза һәм Толстой үрнәгендә начар сыйфатларга каршы көрәш ачарга чакыра һәм моңа беркайчан да соң түгел, ди. Әйе, автор хаклы, менә монысы беркемгә дә соң түгел: бабигә дә, әбигә дә, малайга да, бабайга да.

Мичуринның тырышлыгы, Юрий Гагаринның гомернең кадерен белергә чакыруы, Бальзакның кеше күңелендәге тирбәлеш-күчешләрне бик дөрес һәм төгәл итеп сизүе, Тукай, Такташ, Сибгат Хәкимнәрнең кешеләр арасындагы яхшы мөнәсәбәтләре, Конфуцийның: «Явызлыкка гаделлек белән җавап бирәләр», Пикассоның: «Мин — эзләмим, табам», Джон Гербертның: «Бер эти кеше йөз укытучыны алыштыра», — дигән сүзләре, Менделеев, Ньютон ачышларының серләре — барысы да китапны зур кызыксыну белән укырлык итә.

Монда күренекле әдипләр, бөекләр тормышыннан гына түгел, кирәкле урында татар халык мәкальләре, геройларның җор сүзләре дә игътибарны тарта: арпа чәчеп солы үсмәс; ачу алдан, акыл арттан йөри; дөнья булгач, юлга чыкканда иптәшең үзеңнән яхшы булсын; талны чыбык чакта бөгәләр; пәри башка, җен башка; дөньяны җил болгата, адәмне сүз болгата; матурлыкка күз кирәк, дәреслеккә сүз кирәк һ. б.

«Кызыл кар яугач» повестенда Шаһинурның балачагы, тапкыр, зирәк булып үсүе, яшьлеге, мәхәббәте, Әфганстандагы һәлакәте берәм-берәм укучы күз алдыннан уза. Аның дөнья белән танышып йөрүләре турында укыганда ирексездән Такташның шигъри юллары искә төшә:

> Әкияттәге ике бала кебек,
> Каен башларына үрмәләп,
> Ике ыштансыз малай дөнья белән
> Танышып йөргән идек бергәләп.

Бу повесть, хикәяләрдә игътибарны җәлеп итәрдәй, әдәбиятта яңалык булырдай алымнар байтак. Әсәрне канатлы сүзләр белән башлау яңалык булмаса да, игътибарны туплау, кызыксындыру көченә ия. Автор бу алымны киң куллана. Кайбер хикәя, повестьларның ахыры зур гомумиләштерүче көчкә ия булган нәтиҗәләр, лирик чигенешләр, эчкерсез киңәшләр белән тәмамлана.

«Бозлы миләшләр»не ул «Ишетәсеңме, малай...» дигән мөрәҗәгать белән, «Кызыл кар яугач»ны «Чынлап та шулай икән: әкиятләрнең генә азагы матур бетә...» дип, «Яшьлеккә хат»ы «Онытма: без тормыш өчен түгел, тормыш безнең өчен» дигән юллар белән тәмамлый.

«Урман эчләрендә урман» повестенда да яшьлекнең уртасыннан тормыш сызыгы үтә. Аның чиста, ак ягында лирик герой, Зөлфирә булса, караңгы ягында Дамир, Өүхәтләр тора.

«Яшьлеккә хат» повесте — авторның аеруча уңышлы әсәрләреннән берсе. Ул яшь замандаш белән әңгәмәләр рәвешендә язылган җиде хаттан тора. Хатка бәйләнешле һәм хат формасында язылган әсәрләр татар әдәбиятында шулай ук бар. Мәсәлән, М. Җәлилнең «Хат ташучы» поэмасы, Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар»ы. Ә бу китаптагы хатларның үзенчәлеге шунда, автор бай тормыш тәҗрибәсеннән, тупланган бик күп материалдан

чыгып, яшьләргә ни рәвешле итеп тормышның саф, ак ягына күчү юлларын күрсәтә. Бу хатлар ашык-пошык кына укыр өчен түгел. «Кайта-кайта язмышлар, ялгышлар кабатлана, онытма: бу хатлар ашыгып укыр өчен түгел!»,— ди автор.

Дөрестән дә, бу хатларны укучыларга гына түгел, ата-аналарга, укытучыларга да ашыкмыйча гына укып чыгарга кирәк. Әнә бит авторның сүзләрендә никадәр хакыйкать ярылып ята. «Әмма ни кызганыч: мәктәп үзенең шәкертләрен берничек һәм беркайчан да яшәү фәненә, аның серләренә өйрәтми. Бүгенге педагогикада андый методика һәм тәҗрибә юк. Унҗиде яшьлек кешене яшәү-тормыш итү фәненә, соңга калып булса да, тормыш үзе өйрәтә башлый. Аяныч, унҗиде яшьлек кеше яшәү фәнен үзләштерү дигәндә нәкъ менә унҗиде елга соңарган була инде! Аны, беренче чиратта, кулына өлгергәнлек аттестаты биреп алдыйлар. Тормышкамы — нәрсәгә өлгергәнлек? Ну, бу чиновникларны: яшь кешене үсендерү, юату, канатландыру өчен нинди купшы, бизәкле, ялган термин уйлап тапканнар! Ә инде мең төсмер белән кайнап торган олы тормыш кайдадыр читтә, укыган китаплар һәм караган кинолар, әти-әни һәм укытучылар биргән үгет-нәсихәтләр артында күмелеп кала».

Һәр хат тирән эчтәлекле һәм гыйбрәтле. Андагы әһәмиятле фикерләрнең кайберләре белән генә танышып үтик:

«Бер алманың үсеп өлгерүе өчен генә дә дөньяның нихәтле көчләрен хәрәкәткә китерергә кирәк. Кеше белән исә хәлләр тагын да катлаулырак. Чөнки ул, табигать баласы, өстәвенә, җәмгыять баласы да әле».

«Бездә мәктәп тормыштан шулкадәр нык аерылган — алар, Сак белән Сок сыман, кушыла алмыйча, икесе ике якта яшәп яталар шикелле».

«Мәхәббәт — шулай ук эш, хезмәт, илһам, иҗтиһат. Кешедә шушы сыйфатлар бар икән, димәк, мәхәббәт бар һәм булачак».

Әсәрләрдәге яшь геройлар тормышны, хакыйкатьне әти-әниләреннән, китаплардан укып кына түгел, күбрәк үз күнелләре аша уздырып, табигатьнең үзеннән өйрәнәләр. Андыйлар яхшы күңелле, кешелекле булып үсәләр.

Хикәяләр дә истә калырлык, мавыктыргыч итеп язылган. «Беренче мунча»дагы Фәнис белән Роза, Сабиралар; «Өчәү»дә сугыштан аяксыз кайткан Госман, Нәзифә; «Билгесез кыз сурәте»ндә рәссам Фатих белән Миңлегөл; «Көнбагыш»та Кәрим; «Матур ялган»дагы Фәния; «Хат ташучы малай»дагы Назыйм, «Хуш исле үн чүмәлә»дәге Мирсәет һәм аның улы; «Беренче урындык»та Гадел һәм аның әтисе; «Кайту»да урман каравылчысы; «Ташлы тауда елмаю»да Артур һәм башкалар тормыш сынауларына бирешмичә, алга ак, якты юлдан атлыйлар.

Автор вакыйгаларны, геройларны кичерешләрен зур осталык белән, үзенә хас тел-стиль чаралары белән тасвирлый. Повесть һәм хикәяләр җиңел аңлаешлы, мавыктыргыч, йөгерек тел белән язылган. Анда төрле эндәш, аеруча парлы сүзләр күп. Аларның саны берничә йөзгә җитә. Шуның белән ул башка әсәрләрдән шактый аерылып тора һәм авторның стиль үзенчәлеген билгеләүдә шактый зур роль уйный. Парлы сүзләр уй-фикерне белдерүдә зур көчкә ия: алар аны әле ачыклап тулыландыра, әле тәэсир итү көчен арттыра, әле вакыйгаларны серлерәк, тылсымлырак итеп сурәтли.

Монда телдәге әзер парлы сүзләр белән бергә, автор кулланган бик күп яңа парлы сүзләр дә бар: тулы-таза, елап-мышкылдап, сыгылмалы-салмак, тормыш-яшәеш, сәер-бичара, тән-гәүдә, саргылт-йомры, эш-мәшәкать, һ. б. Мәсәлән: «Шаһинур сыгылмалы-салмак хәрәкәтләр белән «Таң атканда» көен сызып җибәрде». Авылдашлары бу хәлгә шаккаттылар һәм белделәр: тальянның уң ягын сул кулга, сул ягын уң кулга көйләп-үзгәртеп куйган икән Кирам».

Повесть һәм хикәяләрне игътибар белән укып чыккач, укучы күңелендә, сораулар белән бергә, киңәш-табыш, теләк-тәкъдим сүзләренә, ягъни тәнкыйди карашка урын калуы да сизелә.

Әдәби әсәрнең, нәфис сүз сәнгате әсәре буларак, үз кануннары, үз үзенчәлекләре бар. Шуларның аеруча әһәмиятлесе: әдәби әсәрнең композициясе һәм сюжеты, ягъни андагы образларның бер-берсенә бәйләнеше, вакыйгаларның максатка ярашлы итеп урнаштырылуы; эчтәлекнең нигезе, әсәрдәге вакыйгаларның билгеле бер эзлеклелектә агышы.

«Кызыл кар яугач» әсәрендә авторның композицион уңышы белән бергә, аерым әсәрләрендә сюжет чылбырының тигезсезлеге һәм йомшаграк булуы чагыла. Дөрес, автор тасвирлауда сюжетны үзмаксатка әйләндерми, ягъни вакыйгаларның тышкы ягын эффектлы итеп сурәтләү белән мавыкмый. Аларда эчке каршылыкларга, хис-тойгыны сәнгатьчә тасвирлауга корылган талгынрак сюжетлар өстенлек ала. Шулай да әдәби әсәрләрдәге образлар һәм

вакыйгаларда конфликт йомшак булса, ул аның тормышчанлыгын, тәэсирен сүрәнләндерә.

Шул ук вакытта повесть һәм хикәяләрдә авыл темасы белән генә чикләнү дә күренә. Анда бүгенге авыл тормышы, аның шәһәр белән бәйләнеше, ул бәйләнешнең йогынтысы аз чагыла. Билгеле, автор рухи сафлыкны, әхлак тәрбиясен үзәккә куеп бик дөрес эшли, чөнки ул мәңгелек тема. Шулай да әдәби әсәрдә үз заманының сулышы, аның кискен проблемалары да чагылырга тиеш.

Әлбәттә, тулаем алганда, бу искәрмәләр китапның әһәмиятен, аның кыйммәтен киметми.

Гомумән, «Кызыл кар яугач» — Рашат Низамиевның бай тормыш тәҗрибәсе туплаган, өлгергән, сәләтле прозаик булуын күрсәтә. Аның «Яшьлеккә хат» повесте татар әдәбиятына яңалык булып керерлек. Аны укып чыккач: «Их, безнең мәктәп елларында мондый әсәрләр юк иде шул», — дип әйтүчеләр дә күп булыр. Ә менә яшьләр өчен ул бик вакытлы мәйданга килгән әсәр. Аны яратып укучылар күп булыр дип ышанасы килә.

«Кызыл кар яугач» китабы балалар әдәбиятына, татар прозасына килеп кушылган саф сулы тау чишмәсен хәтерләтә. Төз чыршылар, биек артыш куаклары, абагалар үскән текә ташлы ярдан бәреп чыккан тау чишмәсе дә, бер тапкыр татлы суын эчеп, янынан узсаң, аерылмас дустыңа, якын сердәшеңә әйләнә бит.

**Хәнәфи БАДЫЙКОВ,**
филология фәннәре кандидаты, доцент.

## БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

# Гали Халит

(1915—1992)

Әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче Гали Халит (Гали Мөхәммәтгали улы Халитов) 1915 елның 26 июнендә Татарстанның хәзерге Тәтеш районы, Үтәмеш авылында туа. Авылда башлангыч белем алганнан соң 1930 елда Казанга килеп башта педагогия техникумында, аннары Казан дәүләт педагогия институтының тел-әдәбият факультетында укый. Институтны тәмамлагач, Арча педагогия училищесында укыта, ә 1942 елның ахырыннан башлап ул Казан Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшли. 1948 елда кандидатлык, ә 1968 елда докторлык диссертациясе яклый.

Г. Халит педагогия техникумында укыган елларда әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә башлый. Соңрак ул иҗади кызыксынуын әдәби тәнкыйть өлкәсенә юнәлтеп, күпсанлы хезмәтләр, китаплар бастыра. Г. Тукай, Г. Камал, М. Гафури, Ш. Камал, М. Фәйзи, Һ. Такташ кебек классик әдипләрнең иҗатын өйрәнә.

Г. Халитның татар әдәбияты тарихына багышланган мәкаләләре үзәк матбугатта, СССР Фәннәр академиясенең М. Горький исемендәге Дөнья әдәбияты институты хезмәтләрендә дә еш басыла.

Г. Халит озак еллардан бирле урта мәктәпләрдә татар әдәбиятын укыту программаларын төзү һәм дәреслекләр язу эшендә дә актив катнаша.

Әдәби тәнкыйть һәм әдәбият фәне өлкәсендәге нәтиҗәле эшчәнлеге өчен Г. Халитка Татарстанның һәм РСФСРның атказанган фән эшлеклесе дигән мактаулы исемнәр бирелде.

Ул 1939 елдан бирле СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

# УКУЧЫ СҮЗЕ

* * *

Без татар халкының төп журналы саналган «Казан утлары»н даими укып барабыз. Рәхмәт — кызыклы, уйландырырлык язмалар урнаштырасыз! Аяз Гыйләҗевнең «Балта кем кулында?», «Йөгез, бер дога!», Ринат Мөхәммәдиевнең «Кенәри — читлек кошы», «Сират күпере», Мәскәүдә яшәүче татар язучысы Миргазыян Юнысның «Европа ат сагына» кебек әсәрләре безне аеруча тәэсирләндерде. Ә инде Казагыстанның Көкчәтау өлкәсендәге Кызыл Яр авылында гомер кичерүче аксакал әдибебез Ибраһим Салаховның «Тайгак кичү» («Колыма хикәяләре») роман-хроникасын без татар әдәбиятының зур казанышы буларак кабул иттек (юкка гына аңа Татарстан җөмһүриятенең Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге бирелмәгәндер. Ихлас күңелдән язылган, шул чорның утлы-бозлы сулышын, чын хакыйкатьне сурәтләгән тарихи әсәр үзенең кыйммәте ягыннан рус язучысы А. Солженицынның атаклы «ГУЛАГ архипелагы» белән янәшә тора.

Әмма бездә язучының кадерен белеп-бәяләп житкермиләр, ахрысы. Бүген кемнәрдер миллионнарын уңга-сулга сипкәндә, типтергәндә, житез машиналарда җилдергәндә, сиксән дүрт яшьлек Ибраһим ага Салахов, үзенең агач аягында (чынын Колымада калдырып-күмеп кайткан!) Казанның Бауман урамы буйлап шак-шок атлап, Татарстан китап нәшриятына көчкә килеп житә (чагыштыру өчен: Солженицын Владивостоктан Мәскәүгә триумф белән килде!) Ибраһим агага да — исән чагында! — кадер-хөрмәт күрсәтеп калырга иде. Теләк-омтылыш булганда, Казан каласында аның өчен ике бүлмәле фатир табып булыр иде — кунакханәләрдә, күп акчалар түләп, заман газапларын татымаса да ярыйдыр аңарга. Әсәрләрен тизрәк бастырып калырга дип, ел саен ашкынып килә әдип Казанга...

Инде тагын «Казан утлары» журналында басылган кайбер әсәрләргә әйләнеп кайтыйк. Соңгы елларда редакция хезмәткәрләре үзләренең эзләнүләрен киңрәк җәелдереп җибәрделәр, тарихка, аерым шәхесләргә игътибарны юнәлттеләр. Безгә, мәсәлән, «Явыз Иванның хатыннары» (1991 ел, 7 нче сан), «Әби патшаның сөяркәләре» (1992 ел, 11 нче сан) дип исемләнгән язмалар кызыклыгыйбрәтле тоелды. Журналда, редакция исеменнән: «Бөек Петр белән дә якыннанрак таныштырырбыз әле», — дигән сүзләр дә (1992 ел, 11 сан, 128 бит) әйтелгән иде. Әмма ләкин бу таныштыру әле дә булса күренми. Якын киләчәктә бу ниятне дә тормышка ашырсагыз иде...

Талип ДАУТОВ,
Башкортстан, Уфа районы, Лекаревка авылы.

* * *

...Инде егерме елдан артык «Казан утлары» журналын алдырам. Ул килми торса — күңел көйсезләнә, тормышның яме-тәме бетә. Зинһар өчен, вакытында чыгып, вакытында безнең өйләргә җирдәге Кояш булып кил, «Казан утлары»! Без сине зур түземсезлек белән көтәбез...

Вакыйф САФИУЛЛИН,
Монино (Мәскәү өлкәсе).

* * *

...Күптән түгел генә мин академик Д. С. Лихачевның «Земля родная» (Мәскәү, «Просвещение» нәшрияты, 1983) дигән китабын укып чыктым. Китабы бик ошады — акыллы китап! Әлеге китапның 240 нчы битендә мондый җөмлә бар: «Многие русские знатные роды во все последующие века вплоть до XX века гордились своим татарским происхождением».

Әгәр мөмкин булса, шулар турында «Казан утлары»нда берәр мәкалә язсагызчы?! Чөнки барлык журналлар арасында иң яраткан журналым — «Казан утлары»! Бу эчкерсез, ихлас мәхәббәтемнең сәбәбе — туган татар халкымның тарихы белән иң элек сезнең данлыклы журналдагы сәхифәләре аша таныштым. Ә инде татарлардан килеп чыккан «Русские знатные роды» турында язу, мине генә түгел, халкыбызның тарихын белергә омтылучыларның күбесен тирәнтен кызыксындырыр дип уйлыйм.

Мөнир РАМАЗАНОВ,
Ульяновск өлкәсе, Инза районы,
Коржевка авылы.

* * *

Хөрмәтле «Казан утлары» журналы редакциясе! Сезгә Оренбург шәһәрендә чыгып килүче «Яңа Вакыт» газетасы редакциясе хезмәткәрләреннән кайнар сәлам юллыйбыз!

Иң элек сезгә шуны белдерәбез: «Казан утлары» безнең редакциядә күренекле урында — китап киштәсендә иң түрдә тора. Без аның һәр санын көтеп алабыз да, чиратлашып укыйбыз.

Бер уңайдан, журналга карата күңелебездә туган кайбер уй-фикерләр белән дә уртаклашасыбыз килә. Соңгы вакытта, әйтик, журналда заман темасына язылган хикәяләр күзгә ташланмый. Язучы юкмы яисә зур күләмле романнарга урынны күбрәк биргәч, бастырырга мөмкинлек калмыймы? Шигъри сәхифәләргә кытлык юк, анысы — куанычлы хәл. Әмма чит төбәкләрдәге, әйтик, безнең Оренбург өлкәсендә яшәүче шагыйрьләрне дә, әдипләрне дә онытмасагыз иде. «Казан утлары» Казанлыларныкы гына булып калмасын иде, дим. Бөтен җир шары күләмендә дан тоткан «Казан утлары» чит-ят илләргә, милләттәшләребезгә, элеккечә, үзенең нурларын мул итеп сипсен, күңелләрен җылытсын, аларны халкыбызга файдалы яңа, зур эшләргә, иҗатка рухландырсын иде. Без сезгә өмет һәм ышаныч тулы күзләребезне төбәп калабыз!

Әминә МОРАТОВА,
Оренбург шәһәре.

* * *

Мөхтәрәм Равил әфәнде Фәйзуллин!

Ниһаять, минем «Иртеш таңнары» дип исемләнгән романымның икенче китабы да сез җитәкләгән «Казан утлары» журналында (1994 ел, 10—12 саннар) дөнья күрде. Әсәрне бастыруыгыз өчен сезгә, журналның һәр хезмәткәренә ихлас күңелдән зур рәхмәт!

Тик шунысы кызганыч: почтаның гаебе аркасында, «Казан утлары» безнең якларга бик соңлап килеп җитә. Аннары Россия җирендә татарча укый белүчеләр саны да елдан-ел кими бара. Өлкән буын кешеләре фани дөньядан китәләр. Ә яшьләр (чама белән 45 яшькәчә булганнар) татарчаны рәтләп белмиләр. Бездә бит күпчелек татар мәктәпләрендә әлегә кадәр туган телебез, әдәбиятыбыз тиешенчә укытылмый. Бу инде — халкыбызның зур фаҗигасе...

Шундый авыр, болгавыр заманнарда журналыбызның йөзен, сыйфатын җуймыйча саклап калуыгыз өчен Сезгә ихтирамым артканнан арта бара. Сезнең эшчән коллективыгызга, барлык каләмдәшләремә нык сәламәтлек, иҗат уңышлары телим!

Тирән ихтирам хисләре белән:

Якуб ЗӘНКИЕВ,
Тобол шәһәре.

## ҖИҢҮ БӘЙРӘМЕ КӨННӘРЕНДӘ

Бөек Ватан сугышында фашизмны җиңүнең 50 еллыгы Татарстан Республикасында да зурлап билгеләп үтелде. 6 майда Казанга Татарстанда яшәүче Советлар Союзы Геройлары, Дан орденнарының өч дәрәҗәсенә дә лаек булган каһарманнар җыелды. Батырларны Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев үзенең резиденциясендә кабул итеп, Җиңү бәйрәме белән кайнар котлады һәм аларга юбилей хөрмәтенә чыгарылган медальләр, кыйммәтле бүләкләр тапшырды. Ветераннар М. Җәлил исемендәге опера һәм балет академия театры бинасында үткәрелгән, Җиңүнең 50 еллыгына багышланган тантаналы җыелышта да катнаштылар.

Бәйрәм көннәрендә башкалабызда Ямашев проспекты чатында Җиңү паркын, Р. Зорге урамы белән Җиңү проспекты тоташкан урында Дан бакчасын ачу тантаналары булды. М. Горький исемендәге мәдәният һәм ял паркы, Г. Камал театры, цирк янында, стадионда, 1 май һәм Ирек мәйданнарында да кызыклы-мөһим чаралар үткәрелде. Кичен Казан Кремле янында фейерверк балкыды.

Әлмәт, Чаллы, Түбән Кама, Азнакай, Мамадыш, Саба һ. б. күп кенә шәһәрләрдә, районнарда Җиңү хөрмәтенә Дан монументлары, һәйкәлләр куелды. Кукмарада исә сугыш һәм тыл батырларының фидакарьлекләрен гәүдәләндергән туган як тарихы музее ачылды.

## ТӨРКИЯ — ТАТАРСТАН КИЛЕШҮЕНӘ КУЛ КУЕЛДЫ

22 майда Анкарага беренче тапкыр Татарстан Республикасының рәсми делегациясе килде. Аның составында ТР Премьер-министры Ф. Мөхәммәтшин, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р. Харисов, җөмһүриятебезнең Фәннәр Академиясе президенты М. Хәсәнов, тышкы икътисадый элемтәләр министры урынбасары Р. Кашапов һ. б. бар иде.

Татарстан делегациясен аэропортта Төркия вице-премьеры Хикмәт Четин әфәнде, Россия илчесе Вадим Кузнецов һ. б. рәсми кешеләр каршылады. Делегация әгъзалары Төркиянең беренче Президенты Мостафа Кемаль Ататөрек мавзолеена чәчәк бәйләмнәре куйдылар. Аннары илнең Баш министрлыгында рәсми сөйләшүләр башланды. Татарстан белән Төркия арасында икътисадый, сәүдә, технология һәм мәдәният мәсьәләләре буенча үзара килешүгә тантаналы шартларда кул куелды.

Шул ук көнне Татарстан Республикасы делегациясе Төркия Премьер-министры Тансу Чилләр ханым белән очрашты. Ул якын киләчәктә үзенең Татарстанга визит белән киләчәген хәбәр итте.

## ФРАНЦИЯ ИЛЧЕСЕНӘ — «КАЗАН УТЛАРЫ»

24 апрельдә Казанга Франция дипломатлары делегациясе — бу илнең Россиядәге гадәттән тыш һәм вәкаләтле илчесе Пьер Морель, мәдәният һәм фән буенча илчелек киңәшчесе Ролян Батман, сәясәт буенча илчелек киңәшчесе Николя Шибаев әфәнделәр килде.

Шул ук көнне Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев Франция илчесе белән сөйләшүләр алып барды.

П. Морель әфәнде М. Горький исемендәге мәдәният һәм ял паркында булып, азатлык өчен көрәштә һәлак булганнарның һәйкәленә венок куйды, җәлилчеләрнең Франциядәге яшерен оешмасы җитәкчесе Әмир ага Утяшев белән очрашты. Очрашу барышында илчегә җәлилче-макизарларның Франциядәге эшчәнлеген яктырткан «Казан утлары» журналының 1994 елда чыккан 8—9 саннары тапшырылды. Ул әлеге бүләкне, рәхмәт белдереп, кабул итте.

Аннары П. Морель әфәнде һәм аның белән бергә килүчеләр Казанның Актерлар йортында тантаналы төстә Франция мәдәнияте атналыгын ачуда катнаштылар. Олы кунакларны Татарстан Дәүләт Советы Рәисе В. Лихачев һәм Казан шәһәре мэры К. Исхаков кайнар тәбрикләде.

## ЭШ УРЫНЫ — ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ

11 майда Татарстан Республикасының профессиональ парламенты үзенең беренче эш көнен башлап җибәрде.

ТР Дәүләт Советының 37 депутаты (алар арасында 5 язучы да бар) парламентта даими эшләячәк. Депутатлардан 7 даими комиссия дә төзелде.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ — ГЕРМАНИЯДӘ

Апрель аенда республика газета-журналларының баш мөхәррирләре Германиянең Эрфурт шәһәрендә атналык курсларда булдылар. Максат: базар мөнәсәбәтләрендә матбугат эшен оештыру буенча тәҗрибә уртаклашу, полиграфик казанышларны өйрәнү, ил һәм кешеләр белән танышу, Тюренгия җиренең тарихи истәлекле урыннарын күрү... Журналистлар делегациясе арасында «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллин да бар иде. Ул Германиянең Веймар, Франкфурт, Гиссен шәһә-

рләрендә булды һәм анда уздырылган чараларда катнашты. Журналистлар төркемендә, шулай ук, язучылардан — «Татарстан хәбәрләре», «Сабантуй», «Идел» басмаларының баш мөхәррирләре Ренат Харис, Роберт Миңнуллин, Фәиз Зөлкарнәйләр дә бар иде.

## «КАРДӘШ ӘДӘБИЯТЛАР»

исемендәге әдәби журнал Төркиянең Измир шәһәрендә чыгарыла, анда даими рәвештә татар язучылары иҗатына да урын бирелә. Мисалга, аның 27 санында Фәрит Хәкимҗанның кереш сүзе белән Роберт Миңнуллин шигырьләре басылды. Шушы ук санда төрек укучыларына «Казан» журналы танытылды.

«Кардәш әдәбиятлар»ның 29 санында Казанда уздырылган Садрый Максуди гыйльми конференциясе, Татарстан Язучылар берлегенең XII корылтае эше белән танышырга мөмкин. Төрек дөньясы язучыларының Анкарада уздырылган корылтаенда катнашкан Ринат Мөхәммәдиев, Тәлгат Галиуллин чыгышлары язмасы да 29 санда нәшер ителгән.

«Кардәш әдәбиятлар»ның 30 санында Тәүфикъ Әйдинең «Кардәшләр кочагында» әсәреннән бер өзек урнаштырылган (Әүвәл «Казан утлары»нда дөнья күргән бу сәяхәтнамә Анкара һәм Истанбул журналларының да игътибарын тарткан иде). Шушы ук санда Җәмил Зәйнуллин төзегән «Хан кызы» җыентыгына игътибар юнәлтелгән. Халкыбызның мәшһүр галиме һәм дәүләт эшлеклесе С. Максудига Мөхәммәт Әмин Рәсүлзадә язган хатлар игълан ителгән.

«Кардәш әдәбиятлар» журналы редколлегиясе мөдире Явыз Аккынар май аенда редакциябездә кунакта булып, үзара хезмәттәшлекне һәм дуслыкны тагын да үстерү, ныгыту хакында киңәшеп китте.

## ЯҢА ЖУРНАЛ

Татарстанның матбугат диңгезендә тагын бер яңа журнал пәйда булды. «Гасырлар авазы» дип исемләнгән әлеге күләмле, тарихи-документаль басманы (баш мөхәррире — Дамир Шәрәфетдинов) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Архив идарәсе, Татарстан Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы, «Казан» милли-мәдәни үзәге дөньяга чыгарды.

Журналның беренче санында Татарстан һәм Рәсәй, Төркия һәм башка чит илләр архивларында саклanучы гаҗәеп кызыклы-гыйбрәтле документлар һәм материаллар урын алган, фотокүчермәләр муллап бирелгән.

## ХАЛЫКАРА БАЛЕТ ФЕСТИВАЛЕ

12—20 май көннәрендә Казанда, М. Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет академия театры бинасында, дөньякүләм танылган атаклы милләттәшебез — бию остасы Рудольф Нуриев исемендәге халыкара классик балет фестивале зур уңыш белән үтте. Анда Татарстан белән Россиянең, күп кенә чит илләрнең танылган балет осталары, олы кунаклар катнашты.

Фестиваль көннәрендә театрда Россиянең һәм Татарстанның халык артисткасы, җөмһүриятебезнең Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, мәшһүр балерина Ирина Хәкимованың бенефисы да мәртәбәле төстә узды.

## КОЛ ГАЛИ БҮЛӘГЕ ЛАУРЕАТЛАРЫ

19 майда Татар халкының Кол Гали исемендәге халыкара премияләр бирү комитетының чираттагы утырышы булды. Анда яшерен тавыш бирү юлы белән иң күп балл җыйган яңа лауреатларның исемнәре аталды. Татар китабын өйрәнү өлкәсендәге хезмәтләре һәм бөтен дөньяга таралган тарихи-мәдәни мирасыбызның җыелма каталогын төзегән өчен язучы-академик Әбрар Кәримуллин, татар язма шигъриятенә нигез салучы Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасын тикшерүгә багышланган хезмәтләре өчен язучы-галим Нурмөхәммәт Хисамов һәм, халкыбызның милли гореф-гадәтләрен тергезү һәм кайтару өлкәсендәге хезмәтләре өчен, Татарстан Җөмһүриятенең Аксакаллар Шурасы Рәисе Рәфигулла Хәмидулла шул премиягә лаек булдылар.

## ИҖАДИ БӘЙГЕДӘ ҖИҢҮЧЕЛӘР

Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы, халыкара иҗтимагый-сәяси, мәдәни «Заман-Татарстан» газетасы быелның 1 гыйнвареннан 10 апреленә кадәр «Алтын Урдада — әдәбият һәм мәдәният» дигән темага ябык конкурс үткәргән иде. Анда тарихчылар, галимнәр, язучылар, журналистлар һәм газета укучылар катнашты.

Фән докторларыннан торган мәртәбәле жюри, конкурска килгән язмаларны җентекләп карап чыкканнан соң, иҗади бәйгедә җиңүчеләрне билгеләде. Беренче урын филология фәннәре докторы Хатыйп Миңнегуловка, икенче урын — филология фәннәре докторы, язучы Фатих Урманчега, өченче урын язучы Солтан Шәмсигә бирелде. Аларга акчалата бүләк һәм Төркиягә бушлай путевкалар тапшырылачак.

## МАРИ ИЛЕНДӘ — ТАТАР МӘДӘНИ ҮЗӘГЕ

Мари-Эль Республикасының Бәрәңге поселогында Татар мәдәни үзәге ачылды. Әлеге үзәк урнашкан бинада (Тукай урамы, 46 нчы йорт) һәртөрле мәдәни чараларны һәм дини йолаларны үткәрү өчен бөтен мөмкинлекләр тудырылган.

Татар мәдәни үзәген ачу тантанасында Мари-Эль Республикасы Президенты В. Зотин да катнашты. Ул мондый үзәкне ачуның Бәрәңгедә яшәүче милләттәшләребез өчен генә түгел, республикадагы 47 мең татар кешесе өчен дә зур вакыйга булуын билгеләп үтте.

■ ■ ■

# ТӨСЛӘРДӘН — «ИРТӘ ЯЗ»

1980—1990 елларның нәкышче-рәссамнары арасыннан Рифкат Шәйхулла улы Кәримуллин үзенчәлекле урын алып тора. Ул сурәтләү рәвешендә әллә нинди алымнарга барырга мөмкин, әмма дөньяның гармоник матурлыгы, «әшьялар торышы», матди-гамәли яшәешнең тоюлы, күрүле, ишетүле ягы да аңа һич ят түгел.

Татар сәнгатенә ул билгеле бер кысаларга сыя алмый торган, каршылыклы шәхес булып килеп керде, пумаласын идея сулышыннан яралган төсләргә манмыйча, кеше күңеленең кыллары соң дәрәҗәдә тартылырлык кимәлгә җиткерерлек хисле табигать манзараларын тудырды. Аның әсәрләренә карап баккач, цивилизация, болгавыр җәмгыятьнең сату-алулы, базарлы көнкүреше артка чигенә, рәссам рухы гүя беренчел сафлыкта, керләнгән чынбарлыкны инкяр итеп, самими нурларда коена. Аңа мондый билгеләмәләр ябыштырырга мөмкин: «импрессионист», «романтик»... Картиналарында — тыгыз, урыны-урыны белән бер-берсе өстенә калынайтып салынган буяулар... Шулар аша эчтән, бик тирәннән серле төс сирпелә, рәссамның тынгысыз рухы шулай көйри диярсең...

Р. Кәримуллин пейзажларында — тормышның үз сулышы. Әнә ул, борынгылык төсмерс биргән көрәнсу-яшел төс, бакый заманнарның гореф-гадәтләрен уятучы көлсу җир төсендәге фон — «Үткәннәр белән көрәшү», «Шомлы дәвер», «Курай» — болар бабаларыбызның узганы, борынгылар эпосы.

Пейзаж эчендә рәссам гаҗәп оста итеп, хәтта күз карашын талдырырлык дәрәҗәдә төгәл сызыклар белән гамәли күренешне бирә белә, һәм кинәт кенә пумаласын көчле-тәвәккәллек белән борып җибәреп көтелмәгән штрихлар ясап куя, бөтенләй яңа аккордлар таба. Үз җирлегебездә ныклы юнәлеш алган нәкыш мәктәбенә тугрылык саклаган хәлдә, рәссам аны импрессионизм ачкан яңалыклар белән дә баста һәм ике полюсны бергә кушып, үзгә бер яссылыкка килеп чыга. Рифкат Кәримуллин һава авырлыгын, эңгер сулышын буяулар телендә тасвирлый, гамәлдәге әйберләрне ачыграк төсләр белән каймалап, җаны иңдерелгән яссылык тудыра һәм аларны «төтенсу илаһ»ка манып, япон-кытай сәнгатендәге чалымнарга якыная.

Композицион яктан кайбер әсәрләре саран гына сайлап алынган мотивларның кристаллик төенләнеше сыйфатында абстракциягә, миражга төреп бирелә. Мона мисал итеп «Багышлау» картинасын китерергә мөмкин.

«Йорт», «Кеше», «Агач» дигән әсәрләрендә ул эчтәлек киеренкелегеннән форма таралып төшмәсен өчен, реаль җирлекне сиздергән хәлдә, импрессионистик алымга бара, романтик дәрт белән буяуларны кыю сала.

Туксанынчы еллар азагында инде рәссамның сәләт-кодрәте тагын да ачыграк сизелә башлый, ул сәнгатьнең портрет, нәкыш, натюрморт кебек төрле төрләрен колачлап ала.

Рифкат Шәйхулла улы 1935 елның 23 мартында җөмһүриятебезнең Теләче районында туып үскән. Казан сәнгать мәктәбен бетергәннән соң төрле урыннарда эшли. 1972—1995 елларда төрле зональ һәм бөтенроссия күргәзмәләрендә катнаша. Аның әсәрләре Татарстан, Россия, Төркия, Германия, Франциянең музейларында һәм аерым шәхесләрдә саклана.

Рифкаткә генә хас булганча, зәңгәрсу-ак гаммада башкарылган, агач сыннарын, адәм сурәтләрен күк-җир белән бер сулыш итеп, бер халәт итеп тасвирлаган «Иртә яз» әсәре — Р. Кәримуллинның могҗизалы нәкышенең гүзәл чагылышы. Монда бихисап төсләр тантанасы; алсу-көмеш пәрәвез билгеләре аша туган кодрәтле яшь дөнья — яз, язгы хозурлык.

**Розалина ШАҺИЕВА,**
сәнгать белгече.

**Тышлыкның беренче битендә:** рәссам Рифкат Кәримуллинның «Иртә яз» картинасыннан фоторепродукция.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** танылган шагыйрә Лена Шагыйрьҗан.

# ЯҢА КИТАПЛАР




ӘМИРХАН ЕНИКИ. **Җиз кыңгырау.** *Сайланма хикәяләр җыентыгы.* Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1995 ел, 224 бит.

Бу китапка халык язучысы исемен йөрткән әдипнең иң яхшы хикәяләре тупланган. Әсәрләр язылу вакытлары буенча хронологик тәртиптә урнаштырылган. Бер иш әсәрләр, әйтик, «Бер генә сәгатькә» хикәясе Ватан сугышы елларында иҗат ителгән булса, китапта урнаштырылу буенча соңгылары — «Мандарин сатучы», «Тынычлану» исемле хикәяләр 70 еллар ахырында язылганнар. Китапта, шулай ук, «Шаяру», «Матурлык», «Төнге тамчылар», «Җиз кыңгырау» кебек әдәбият сөючеләргә яхшы мәгълүм булган хикәяләр дә кертелгән.

ӘНӘС ГАЛИЕВ. **Авылдашлар.** *Роман һәм повесть.* Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1995 ел, 296 бит.




Китапта танылган язучының «Авылдашлар» романы һәм «Һәр солдатның үз язмышы» исемле повесте урын алган. «Авылдашлар» романының күп геройлары бер авылда туып-үскән кешеләр, ләкин тормыш аларны туган нигезләреннән читтә очраштыра һәм аларның һәрберсе ачы хакыйкатьтә зур сынау үтә: дөньялыкта кемнең кем икәнлеге шунда ачыклана.

«Һәр солдатның үз язмышы» автобиографик повестьта исә Ватан сугышының башлангыч чорында солдат җилкәсенә төшкән төрле авырлыклар сурәтләнә.

Моннан берничә ел элек һәр ике әсәр дә беренче мәртәбә «Казан утлары» журналында басылып укучыларыбыз тарафыннан югары бәяләнгәннәр иде.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)

Журнал включен в центральный каталог